ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

10.2002



# КАЗАН ШӘҺӘРЕНӘ—1000 ЕЛ



*Федоров яры*



*«Казан» милли-мәдәни үзәге*

Үткәнебез һәм бүгенгебез. Бер үк ноктадан бер гасыр аерма белән төшерелгән фоторәсемнәр. *Хаҗи Абдулла Дубин коллекциясеннән.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2002

**10**

(960)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**ШИГЪРИ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Зиннур МАНСУРОВ. Ике еглау. *Поэма* ........ 5
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Һәрнәрсәгә—акчалата. *Роман* ........ 27
Марат ЗАКИР. Вакыт аты. *Шигырьләр* ........ 92
Әсгать САЛАХ. Соңгы вальс. *Повесть* ........ 97

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Әгъдәс БОРҺАНОВ. Татар! Дөреслекне бел! ........ 143
Мәгъсүм ГӘРӘЕВ. Солтанатлы генерал ........ 151

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Олы юлның юлчысы *(Азат Әхмәдуллинга 70 яшь)* ........ 156

**КАЗАННЫҢ 1000 ЕЛЛЫГЫНА**

Әзһәр МӨХӘММӘДИ. Казан шәһәренең барлыкка килүе һәм аның борынгы исемнәре ........ 167

**КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ**

31—Локман (Локман) сүрәсе ........ 180
32—Сәҗдә (Сәҗдә) сүрәсе ........ 182

**«КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ**

Фоторепортаж ........ 186

**ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР**

Розалина ШАҺИЕВА. Татар рыцарьлар поэзиясе ........ 191

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 186

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Р. МИР-ХАЙДАРОВ. Роман. «За все—наличными» *(окончание)*; повесть А. САЛАХА «Последний вальс»; поэма З. МАНСУРОВА, стихи М. ЗАКИРА.
«Публицистика»: А. БУРГАНОВ. «Татарин! Узнай истину!»; статья М. ГАРАЕВА «Знаменитый генерал».
«Литературная критика»: статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА «Путник большой дороги» *(к 70 - летию А. Ахмадуллина)*.
«К 1000-летию Казани»: А. МУХАМАДИ. «Возникновение города Казани и его древние названия».
Коран на татарском языке.
«К 80-летию «Казан утлары»: фоторепортаж.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Средневековый татарский рыцарь»; писатель-публицист Махмут Ахметзянов.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": R. MIRKHAIDAROV'S novel «Cash for anything» *(ending)*; A. SALAKH'S narrative «The last waltz»; Z. MANSUROV'S poem; M. ZAKIR'S verses.
"Journalism": A. BOURGANOV «Tatars! Know the truth!»; M. GAREEV'S article «The famous general...»
"Literary criticism": R. GALIMULLIN'S article «The traveler of the main road» *(devoted to the 70 th anniversary of A. Akhmadullina)*.
"Commemorating the 1000 anniversary of Kazan ": A. MUKHAMADI «Beginnings of Kazan city and its old names».
Koran in Tatar language.
"Commemorating the 80th anniversary of «Kazan utlary»": photoreport.
The diary of social and cultural life.
On our covers: «Medieval Tatars knight », writer Makhmut Akhmetzianov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 30.09.2002 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 9134. Заказ Б—567
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2002 ел.



## Зиннур Мансуров

### ИКЕ ЕГЛАУ

ПОЭМА

**Башлам**

**Җиде иклим чиген иңләп иңрәү йөри,**
**иңрәү кайта, кайта ничә ел аша.**
**Мәшрикъ якны тоташтырып мәгъриб якка,**
**кара-каршы ике бикәч еглаша.**

**Хәсрәтләргә чумган дөнья хәтерләми—**
**мондый аглау юктыр кебек бер җирдә;**
**кыйтталарны айкап йөргән кайтавазы**
**үкси-үкси бәрелешә бәгырьдә.**

**Ике якта гомер сөргән чит-ят затлар:**
**берсе—Идел, берсе Дунай буенда.**
**Илләрендә көйләп-көйләп илерәләр,**
**үзәк өзгеч аһ-зар бардыр бу моңда.**

**Кенәзбикә, килешмәүчән килендәштәй,**
**ханбикәдә танып ала көндәшен...**
**Итәк тотып энҗе-мәрҗән җыйган төсле,**
**фәрештәләр санап бара күз яшен.**

**Йөрәгеңнән гамьнәр савып йөдәгәндә**
**килми калмый, килми калмый кан исе.**

Зиннур МАНСУРОВ *(1949)—шагыйрь, публицист; «Йөз суы», «Ваем», «Яшәү үзәне», «Күңел сәфәре» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

**Бәгырьләрдә Вакыт... Хәтер бәрелешә,**
**хаклы итеп тоя үзен кайсысы?..**

**Ил-йорттагы барлык, барлык елгауларны**
**күмеп китә икәвенең елгавы.**
**Йодрык аша саркып чыккан ачы яшькә**
**кушылгандыр йөзәр-меңәр ел давы.**

1

Сөембикә

**Егла, халкым, әйдә, егла, халкым,**
**минем белән бергә еглачы.**
**Ходайдандыр бүген хадимәңә**
**тәкъдирләнде яңа юл башы.**

**Өметләнеп дәшәм: өммәтемә**
**әҗер килсә, куып йөрт кенә!**
**Һиҗрәт итү язган икән миңа,**
**әсир төшеп урыс йортына.**

**Килененңне, илем, килешенеп,**
**канлы туйга калым иттеләр,—**
**еглаганда... Казан нигезенә**
**салып калдырылган эт көләр...**

**Бүген инде, углым, миңа кушыл,**
**күзләреңнән яшьләр түгелсен.**
**Сыктавымның асыл сәбәпләрен**
**әле аңлар яшьтә түгел син.**

**Ирексезләп ачам йөрәгемне—**
**тыңла җәрәхәтле кыл зарын.**
**Үзенеке итеп үзгәртмәкче**
**залим патша Аллаһ колларын.**

**Урда рухы бүген сызлый булыр—**
**җуйдык бугай инде барсын да.**
**Хөрлек тағы ничек тора алсын**
**табан ялаучылар башында.**

**Канлы чыкка батып бара җирем,**
**Идел-йортның хәзер язы... көз.**
**Фәрештәләр, гамәл дәфтәремә**
**күз яшенә манчып языгыз!..**

* * *

**Чәчен йолкып, битен тырнап, кулын чәйнәп,**
**бузлый-бузлый еглый барча кыз-кыркын.**
**«Мәҗүсидәй хәттин ашып мавыкмагыз!**
**Җитәр!»—диеп ник бер сәед кычкырсын.**

**Төшләреңдә энҗе күреп тәшвишләнү**
**түгел икән, түгел икән яхшыга.**
**Егламаган ташлар юктыр ханкирмәндә,**
**бичураның күзеннән дә яшь чыга.**

Йодрык белән сөртә сабый яшьле битен,
күкрәгендә кемдер елан җылыта.
Кыйтгалардан көйле иңрәү кайтарыла,
аһ-зарларны арлы-бирле җил йөртә.

2

Ярославна

Гыйш-гашрәтле яшьлек бәйрәмнәре,
җитәр инде, озак көлдертте.
Еглашыгыз, кызлар, еглашыгыз,
яшебезне кояр көн җитте.

Яшьнәп торган төнге күкнең сүзе
канлы сөңге белән язылган.
Каргышыбыз төшсен каракошка—
безнең газизләрне ят кылган.

Канатлансын кыпчак кәнизәге—
дала хөкемедер бу яшен!..
Сиңа дәшәм, Игорь, таулар аша:
сизмәдеңме шулай буласын?..

Мәрхүм әнкәм төшкә кергән иде,
җиргә җәеп кара яулыгын.
Иртәгесен кояш тотылганда
күләгәләр кисте яу юлын...

Иләмәннәр белән киңәшмичә,
качып киткән кебек ашыктың.
Көнчел күршең Көнчак ханга барып,
өрми генә утлы аш йоттың.

«Онытырмын,—дидем,—ятимлекне,
әгәр сине хәләл ир итсәм...»
Өзелерме, бәгърем, зынҗырларың,
күз яшьләрем белән эретсәм?

Юылырмы безнең еглаулардан
бәгырьдәге хәсрәт дуены?..
Үксезләрем ничек үксемәсен—
иртәләде соңгы туй көне.

Ахириләр, йәгез, ахыргача
ахылдашыйк—күкләр ишетсен!
Адәм затын аяп еглый алган
фәрештәләр безне иш итсен.

* * *

Дерелдәшә кирмән-кала диварлары—
хәтта ташлар түзә алмый кан-яшькә.
Егылышып бөтен дөнья еглаганда
көндәшләрең әверелә гамьдәшкә.

Җарияләр иңри башлый ирексездән,
коллыктагы җәберләрен онытып.
Мәдхияләр укып йөри мәшһүр Баян—
матур төшен күрсәтмәкче өн итеп.

Тавышында кайгы-шатлык тынышкандай,
әллә еглый, әллә җырлый бер кортка.
Сусыз дала кылганнары сәҗдә кыла
болытларның яшен койган бөркеткә.

Шомландырып яшьләр тама шәмдәлләргә,
еглый торгач дәргаһ-йорттан кот качкан.
Коргаксыган иске арба шыгырдавы
иңрәү булып кайта Дәшти Кыпчактан.

Җиңелүнең ачы яше җемелдидер
сәргаскәрен җуйган атның эзендә.
Угланнары язмышыннан угаланып,
ачулана бөек кенәз үзен дә.

Җәберсенгән кальбе белән еглаганда
үзен һәркем әүлиядәй пакь саный.
Кирәк чакта яудаш булган гаярь кавем
хәзер инде әшнә түгел—«Поганый!..»

**... Урамдагы мөлдерәмә канаулардан**
**әллә нинди кан-яшь катыш су ага.**
**Таралыша ыңгырашу тавышлары,**
**Куяба[1]дан кайтарыла Сула[2]га.**

**Дала илен иңләп үтә бәгырь өне,**
**Җигүлетау яшененнән ут ала.**
**Казансуга килеп җиткән күкрәүләре**
**ачы нәгърә ормак булып уктала...**

**3**

Сөембикә

**Аһ-зарларны бергә очраштырды—**
**әллә дөрестән дә Җир тармы?!**
**Миңа тыңдаш булып еглар өчен,**
**Ярыслауна, яшең җитәрме?**

**Сагышларны сыгып сыктаганда**
**сабырлыклар булмый күпләрдә...**
**Ике күздән ташып чыккан яшьне**
**еглап бетермәстер күкләр дә.**

Ярославна

**Безгә инде, бикәм, шулай язган—**
**азрак көлеп, күбрәк егларга.**
**Әмма синең кебек горур затлар**
**җебеп җавап бирмәс юк-барга.**

**Тыеп тоткан күпме хәләл яшең**
**сабыр бәгырeңдә тулгаклый...**
**Ачылуым өчен ачуланма—**
**толны кыен чакта тол яклый.**

**Башкарактыр иман багышлавым,**
**бүтәнчәдер күзем, кашым да,—**
**кайгы безне тигез күрә булыр**
**ихлас яшь бөртеге каршында.**

Сөембикә

**Бөтен галәм дәррәү көлгән чакта**
**күренербез игез булып та.**
**Синең яшь тә, бәлки, бардыр әле**
**Казан өсләп йөзгән болытта.**

**Сорасалар еглау сәбәпләрен,**
**безне кемнәр генә иш санар?**
**Дөресләсен хәсрәт дәрьясының**
**төбен күрә алган инсаннар.**

**Фәрештәләр безнең күз яшьләрен**
**үлчәп тормас мәхшәр көнендә...**

[1]Куяба—Киев шәһәренең кыпчакча әйтелеше.
[2]Сула—Днепр елгасының сул кушылдыгы.

Ярославна

Кайгыларга саксыз кагылмыйкчы—
хакы бардыр анда кемнең дә.

Йөзеп китә бара фани дөнья,
еглап башланмаган көн әздер.
Исәнгерәп ята әсирлектә—
ул бит ... кенәз кадәр кенәздер!..

Сөембикә

Җирдә сынау үткән һәрбер бәндә—
кылган гамәленең тоткыны.
Аңлатачак әле Аллаһының
җавап ала торган төп көне.

Борын чөеп, бакчы, сөңге кадый
кыпчак даласының читенә.
Очлым белән Донны эчеп кую
аның өчен, имеш, чүп кенә.

Ханның атын асылташлар бизи,
аткан угы, әйе, көмештән.
Балбалларның алтын билбавында
кылыч беләүләргә кем кушкан?

Бүрегендә кайсы бөрадәрең
каракошка оя ясаткан?

Чынлык өчен, әйдә, санап карыйк—
кемнәр башлап күбрәк яу чапкан?..

Әле кайчан гына Күбәк ханның
әсирлектә башы җуелды.
Яшьләнгәндә дала җәмшәннәре
сездә бәйрәм, уен, җыр булды.

Галибанә «җанлы ганимәт»не
яугирләргә бүлеп биргәндә,
кенәзлекнең колын кызганудан
еглап җибәрдеме бер бәндә?

Ничә ишкәк белән Идел суын
чайпалдырып кайтты кайнишең?
Хаталанса халык хәтерләре,
балык хәтерлидер кан исен...

Ярославна

Күңелдәге тутын күрсәтмичә,
йөри, энә, Башту җыр әйтеп.
Һәрбер шәйне кабул итмик әле
күз яшьләре аша зурайтып.

Орышларны уйлап чыгармадык,
шаны—иргә, яше ... безгәдер.
Ике илче кебек, хаклык эзләп
еглашабыз менә бергә-бер.

Сөембикә

Еглаганда сиңа әлгәрләрең
инде күптән мәгълүм сер әйтер:
кайнар канның җирдә ачы яшькә
кушылмаган көне сирәктер.

Ярославна

Олы халык сугыш белән яши,
ыру... узмый, диләр, бузадан.
Узаманлы дөнья үзгәрмәстер,
үзгәрмәстер безнең бу зардан.

Ничә тапкыр төштә кошлар күрәм—
әле агын, әле карасын.
Савап арты савап эшләп кенә
милләтеңне саклап кара син!..

Сөембикә

**Бәләкәйдән адәм балалары**
**иялэнеп үсә кан-яшькә...**

Ярославна

**Берәр газиз башны... кисеп кенә**
**илтә көндәш үчле көндәшкә.**

**Кылыч сорап торган чарыс затка**
**фатиханы бирми ил генә,—**
**Мөхәммәднең яугир тудыкасы**
**кулын салган, имеш, иңенә.**

Сөембикә

**Төрле хәлләр була: колмак бата,**
**ә таш йөзә башлый еш кына.**
**Беркетелгән антлар бозылганда**
**җәясеннән ук та ычкына.**

**Иделләрне эчеп бетерүләр**
**иман-денгә ничек ялгансын?!**
**Очлым белән тәгам җияр ирнең**
**комсызлыгы арта яудан соң...**

**Җитеп торыр, моңдаш, авыр чакта**
**сиңа хөтбә укый башладым.**
**Бетеренмик әле битәрләрдән—**
**еглар, көләр өчен баш лазим.**

**Күлмәк җиңең бигрәк озын икән—**
**кипмәс әле, кипмәс тиз генә.**

Ярославна

**Кара кашлы зур күз яшьле була,**
**дөреслеген җаным сизенә.**

**4**

**Чарт-чорт итеп багбөстанда борчак ата,**
**кипкән сәрви кузаклары ярыла.**
**Тып-тын очкан күбәләкнең өнен алып,**
**ханзираттан ыңгырашлы зар кылә.**

**Болынлыкта бертуктаусыз бөтерелгән**
**шәүлегәннәр бүген яңгыр теләми.**
**Төрбә ташын соңгы тапкыр сыйпап сыктый**
**ирдән калган, илдән калган тол җаный.**

**Иләмсерәп тулгый-тулгый еглауларның**
**кайтавазы ишетелә дүрт яктан.**
**Дивансарай диварлары дерелдәшә**
**үзәк өзгеч сәмум-җилле фөрьяттан.**

**Кан-яшь белән Аллаһыдан яклау сорап,**
**рәкәгатькә егылганда ил-ыру,**
**сыеныргa тыныч почмак сайлагандай,**
**манарада гүләп тора илерү.**

Бүре кебек берәм-берәм улый башлый
куркынычны сизенүче сак этләр.
Гаҗиз хәлдән бөтен гавам үксеп еглый,
бәкләр еглый, мирза, тархан, сәедләр...

Моңлы азан тавышына ачы сыктау
авазлары кушылганда мең авыр!
Камчы белән үзен-үзе кыйнап еглый
каберлекне саклап торган мөҗавир.

Баскын кенәз ничек шулай йомшый ала
чиксез кодрәт иясенә тиң чакта?!
... Дөге-дөге яшен түгеп еглый икән
корбанына якынлашкан тимсах[1] та...

Бөтен халык сыктаганда берәү генә
авызыннан аждаһадай ут ата:
көндәшенең янып-көеп кансыравы
анда бары ләззәт кенә уята...

Ханбикәне көймә көтә Казансуда
«шөһрәт-сыйлы әсирлек»кә илтергә.
Икълимнәргә ишетелгән еглауларның
газиз яше сеңеп кала ил-җиргә.

* * *

## Сөембикә

Ярдәм итче, Сафам, мөмкин булса,
Аллаһыдан җибәрт иштирак[2]!
Җырлау өчен ят та ярап тора,
еглаганда якын иш кирәк.

Игътибарлап тыңла еглавымны,
җавап бирсәң—җаным сизенсен.
Хан-солтаным, бөтен хатыныңнан
артык күреп мине сөйдең син.

Күрәсеңме урыс яугирләрен—
зиратыңда гына алты пар.
Биектәге сылу бикәчеңне
аккош төслүк атып алдылар.

Кяфер колы иткән канлы туйда
матурлыгым нигә кирәк соң?!
Манарадан атыйм йөрәгемне—
ахыргача янып көйрәсен!..

Бигрәк елгыр атта чабып үттең
тәхет белән ләхет арасын.
Ялгызыма бик күп калдыргансың
мәкер, гайбәт, шелтә, әр ашын.

Тәкъдиремне еглап тәфсирләргә
юктыр, бәлки, юктыр хакым да.
Кемгә сөйлим өскә авып торган
янар таудай кайгым хакында?

---

[1]Тимсах—крокодил.
[2]Иштирак—булышлык.

**Козгыннарның көтмим кызгануын,**
**ярдәм өмет итмим чит ымнан.**
**Кемгә сөйлим, җанкач, үксез углың**
**аерылмый әле сөтемнән.**

**Нугай ерак, әйтмә, Кырым ерак,**
**һәм дә арабызны корт чаккан.**
**Миңа киңәш биргән күпме затның**
**әйтер сүзе чыга корсактан.**

**Монафикътай йөри мөэминнәрең,**
**шикле ладан исе аңкытып.**
**Менә шулар инде сөрә мине,**
**ирекләре белән ант итеп.**

**Варисыңны нинди вәсвәсәләр**
**көтеп ята икән тегендә?**
**Имәндереп тора иманнары,**
**кабул итә алмыйм телен дә...**

**Ялыгудан гаҗиз ялгызлыгым**
**синең ялгызлыкка кушылсын,—**
**ятимәңне алдыр ятагыңа,**
**җаннарыбыз игез кош булсын.**

**Ничә алтын анда ишек бавы—**
**үткәр мине гүрең түренә!..**
**Еглап ташкан зарлы Идел аша**
**алып китәр безне зур көймә.**

**Шатлык яше белән кайгы яшен**
**бүлеп торган юллар, аһ, ерак.**
**Һиҗрәтемнең зур-зур әҗерләре**
**сиңа булсын, илем—әлфирак!..**

**5**

## Ярославна

**Ятим җаның тоташ яра икән,**
**сиңа карап, мин дә җебенәм.**
**Сөзелешеп чыккан сүзләреңне**
**бүлим әле ефәк җеп белән.**

**Казаланып торган Казаныңда**
**әйтмәдеме татар кардәшең:**
**«Бездә бикә булып яшәр өчен**
**җитәр микән,—диеп,—кан-яшең?!»**

**Еглашабыз менә икәүләшеп,**
**еглашабыз инде кай заман.**
**Ышанамы синең яшьләреңә**
**тәкъдир атлы кырыс кайнанаң?**

**Мөлдер күзне сөртеп торыр өчен**
**яулык очы күбәү, җиң озын...**
**Хафалану тулы халәтемне**
**аңлый аласыңмы син үзең?**

**Ялгыз баштан ниләр кылып була—**
**син бит байтак тарттың ир йөген.**

Әсир хәлен әсир белми калмас—
һәркем җандай күрә ireгeн.

Сөембикә

Еглауларны тыңлап еглауларга,
тыңдаш эзләр өчен юк хакым.
Тәкъдир кушып, әйе, ханча булгач,
хөрлегемне мин дә югалттым.

Каударланып сөңге кадамадым
башка мәмләкәтләр читенә.
Газиз илдән улҗа малы итеп
алып китә мине чит көймә.

Кенәзеңнең канлы барымтасын
аклап күпме генә аһ орма,
әсир төшү белән әсир алу
арасында бардыр аерма.

Барлап тормыйм барча корбан санын—
каракошлар тагын ит теләр.
Хәрамиләр ил-күз хозурында
ничә ханны тоткын иттеләр.

Мордарлыкның гарьле моң-зарларын
әрнеп кичермәгән җан бармы?
Череттеләр ерак әсирлектә
Габдел Латыйф, Илһам ханнарны.

Тагын күпме асыл затлар шулай
җиргә күчте коллык базында.
Үтәмешем киеп өлгермәде
әтисеннән калган таҗын да...

Ярославна

Әсирлектә кенәз Василийны
күздән яздыручы кем иде?

Сөембикә

Нахак яла безнең бавыр итен,
җитәр инде, байтак кимерде.

Миннән йөз кат өлкән була торып,
кайчак әле һаман бала син.
Кемдер файда күрер—сылтыйк гелән
кара этка ак эт бәласен...

... Яуга шулай качып китәр кенәз,
безнеңчәләп әйтсәк, кылтык ул.
Анда сөрән салып яткан ирең,
әсир ителсә дә, кол түгел!

Ерактагы кыпчак җәйләвендә
җайсызлыктан бер дә ертылмый:
тели икән, ауга чыгып керә,
кичен, кымыз эчеп, җыр тыңлый.

Кенәзлектән поп та китертелгән,
учакларда көйри куз гына.
Улыгызны димләп йөрүләре
Көнчак ханның кече кызына.

Тоткын җайдак тиздән кайтып килер,
кылганнарның коеп чык-яшен...

Ярославна

Кодалашу артык көендерми—
сиздем шулай килеп чыгасын.

Ярәшүләр кайчак ярашуга
китергәли Кара Болгар[1]да.

---

[1] Киев Русенен шулай аталган чоры да булган.

**Нәсарины әһле мөселманнан**
**ерагайтмас әле болар да.**

Сөембикә

**Сөенимме ханнар суешканда**
**тамырдагы каннар сугышса,**
**Туранымның соңгы туруннары**
**баскын очлымыннан су эчсә?!.**

* * *

Ярославна

**Ничә меңле гаскәр саклап тора**
**гайрәт чәчәр Казан кальгасын.**
**Олугларың патша калгаеннан**
**нигә шулай куркып калган соң?**

**Мәгърур таудай басып торган калаң**
**батып бара, әнә, аһ-зарга.**
**Ханбикәсен биреп җибәрүче**
**кавемеңне ничек аңларга?**

Сөембикә

**Ачынышып еглый алучылар**
**ишарәгә күчми шикелле.**
**Күзгә бәреп әйтик туры сүзне—**
**нигә сиңа андый шик килде?**

**Күңелемдә урын калдырмадым**
**нахак яла, кинә, кер өчен.**
**Гаепләсәм сөйгән милләтемне,**
**хаксыз әйтсәм—телем корысын.**

**Аллаһыга ярсып әләклимме,**
**кемгә шикаятьләр языйм соң,—**
**килен булып төшкән ятим илдән**
**«Талак!» әйтеп куса язмышың?!**

**Сатылырга безне өйрәтмәгән**
**Ага-базар, ефәк юллары...**
**Гаҗизлекнең ниләр күрсәтәсен**
**белә булыр, белә Ул бары.**

Ярославна

**Сәерсенмә, зинһар, соравыма,**
**җанга тынгы гына эзлимен:**
**ханбикәсе, биреп һамаюн[1]ын,**
**саклап калган, димәк, үз илен.**

**Янып сөйгән газиз иле генә**
**ханбикәсен саклый алмаган...**

Сөембикә

**Алай зурдан кубып хөкем йөртмик,**
**гөман кылмыйк, узып Алладан.**

---

[1]Һамаюн—бәхет кошы.

**Бәйләнмәгән безнең ихтыярга**
**иртәгесе көннәр гамәле.**
**Кемнәр генә аны саклап калыр—**
**җанда өмет түгел, гамь әле.**

**Бәхет кошы озак тора алмас,**
**тәхетеңә менсә үч-кинә...**
**Күзем йомган чакта юк-бар төшләр**
**сискәндерә шуның өчен дә.**

Ярославна

**Кайнатамның зәңгәр шәрабенә**
**кемдер гүя энҗе төшергән...**
**Кенәзнеке бер дә куандырмый,**
**ә ханбикә нинди төш күргән?**

Сөембикә

**Ышанмаслык шайтан ишарәсе—**
**башкаеңа сәер уй иңәр:**
**әүлиядәй диван әһелләре**
**Хансарайда ... «бишташ» уйныйлар.**

**Бисмилладан башлый басымчагы—**
**Аллаһыга, имеш, тапшыра.**
**Ханлыгымның асыл чүлмәгенә**
**берсе уйнап кына таш ора.**

**Әллә кайдан шомлы тавыш килә:**
**«Аңа...**
**Олуг Мөхәммәтләр бакты ла!»**
**Ташны юри генә ата кебек,**
**чүлмәк исә чынлап ватыла...**

Ярославна

**Үзәгеңә тия үзеңнеке,**
**гарьләндерә—ни хәл итәсең.**
**Бөялгәндер, беләм, бәгыреңдә—**
**каргап булмый туган ил ташын.**

**Төшләреңә кереп тәшвишләтә,**
**өнгә саркып чыга бу ачы.**
**Кан-яшеңдә юган ташларыңны**
**нигезеңә салып булсачы...**

* * *

Сөембикә

**Байтирәкләр бездә башкачарак,**
**очып куна торган кош башка.**
**Язмышымның яшьле яулыкларын**
**элеп куймыйк әле кояшка.**

**Гарше әгъля, сизәм, күрми калмас**
**миндәй кайгыручы мөмтаз[1]ны...**

[1] Мөмтаз—башкалардан аерылып торучы зат.

**Үз-үземне артык кызгандырдым—**
**синең күзләреңдә моң азмы?**

Ярославна

**Байтирәгем еглый вакытлыча,**
**шунысына ничек түзәсе?!**
**Ханбикәнең хәле хәвефлерәк,**
**күпкә ачырактыр күз яше.**

**Ярга сыймас дәрья кебек аккан**
**хәсрәтеңдә булмый батып та.**
**Дөнья тоткан илең ничек шулай**
**башсыз калган кыен вакытта?**

Сөембикә

**Минем углым ханлык таҗын киде—**
**нигә чыгарасың исәптән?**

Ярославна

**Карышкыдан кечек нарасыйны**
**аердыңмы әле имчәктән?**

**Ачыклавым өчен ачуланма,**
**ачындыра болар мине дә.**
**Кыйтгаларга китсен кайтавазым,**
**еглый-еглый кылам мең нида.**

**Олег каны, имеш, Чыңгыз каны—**
**һәлакәтле шан бар бу канда.**
**Хакимлеккә хөкем ителгәнсең,**
**җаһил,**
**чирле,**
**сабый булсаң да.**

**Хаким булып торса шундый кенәз,**
**шундый солтан, патша, корольләр,—**
**дан-шөһрәтле илең дошманында,**
**димәк, иң дәһшәтле корал бар.**

**Илаһлыктан ерак иләмәннәр**
**тәхет менсә—халык интеккән;**
**томаланып ыру тамырлары,**
**вәйранлыкка күпме ил киткән...**

**Фәрештәләр чын-хак патшаларның**
**күрә, диләр, нурлы каймасын.**
**Татарыңның Тәңре тамгалаган**
**изгеләре бүген кайда соң?**

**Йортын нигә саклап кала алмый**
**Күкләр билгеләгән хакимлек?..**
**Кичер мине, бикәч, барсын бергә**
**тоташ гаепләргә хакым юк.**

Сөембикә

**Зәнки затлар инде ничә тапкыр**
**сабыема тешен ыржайтты;**
**кимсетмәче: ул бит нәбиләрнең**
**җенестәше булган ир заты.**

**Җанкылымлы Игорь җәнапләре**
**аерылды мәллә имидән?..**
**Бирелгәндәй шайтан коткысына,**
**шулай әйтәм әле мин нидән?!**

Ярославна

**Бәрәкалла, шуңа бәйләнгәнме**
**ымсындырып торган тәхет тә?**

Сөембикә

**Сөттән бизгән ватан үксез кала—**
**бөтен хикмәт шушы тәүхид[1]тә.**

**Хатын терәк булыр газиз иргә,**
**ил терәге, шиксез, ир булыр.**

Ярославна

**Әйтеп бетер инде—тажга әле**
**безнең таифә дә ыргылыр.**

**Мәрьям ана чынын раслап бирсен:**
**тәхет басу безгә хәләлме?**
**Дөнья тотар өчен нык кул кирәк—**
**бүгенгеңдә шундый хәл әле.**

**Кинаяле сүзләр күңелеңнең,**
**әйдә, әрнүләрен кузгатсын:**
**патша булып торыр, җае чыкса,**
**тик идарә итмәс кыз-хатын.**

Сөембикә

**Көчле куллар нигә саклый алмый**
**милләтеңә язган бер йортны?**

Ярославна

**Әллә киеп карау уең бармы**
**Мономахтан калган бүрекне?**

Сөембикә

**Әгәр ният итеп киям икән,**
**йәле, шуннан нәрсә була соң?**
**Ошбу бүрек Мәскәү-йортка барган**
**Көнчәк[2] бикәнеке—беләмсең!**

Ярославна

**Халыкларда кием алмашулар**
**була инде—читкә борма син.**

Сөембикә

**Бүләк иткән бүрек белән бергә**
**башың гына китеп бармасын...**

---

1 Тәүхид—бергәлек мәгънәсендә.
2 Көнчәк—Үзбәк ханның сеңлесе.

Булган инде бездә төрле хәлләр:
күпләр яулап-талап таҗ алган;
сарык урлап угры атын йөртсә,
тәхет урлап патша саналган.

Аруланмый дөнья—ырусызлар
әрсезләнеп таҗга үрелсә.
Үртәләнмәс идем, Үтәмешем
ил куйнына сыйган ир булса.

Йөрәгемне телә парә-парә
үксез кавемемнең һәр гаме.
Төрле хәлләр булды, гыйбрәт алсаң—
хәләленнән күбрәк хәрәме.

Күрмисеңме: күпме кардәшеңнең
тәхетеннән саркып тама кан.
Кенәзләрдән узып, Куябаны
кыпчаклармы әллә талаган?

Ярославна

Хак-нахактан азган хакимлеккә
мөһим түгел кан, сөт, тел ягы.
Оныттыра хәтта өммәтеңне
таҗга хуҗа булу теләге.

Сиңа инде барсы яхшы таныш,
гамем әле башка борчуда:
Казан башы булган ундүрт ханның
ник Болгардан түгел берсе дә?

Сөембикә

Килешмимен: әллә килмешәкме
монда туып-үскән ханзадә?
Атилладан килгән алмашчылар
чит-ят токым түгел кайда да...

Инде сүзләр генә ярдәм итмәс,
фәган[1] халәтенә кайтамын.

Ярославна

Яшең белән әллә юмак булдың
бәхет кошындагы кан табын?!

**6**

Җиде икълим чиген иңләп инрәү йөри,
иңрәү кайта, кайта ничә ел аша.
Мәшрикъ якны тоташтырып мәгъриб якка,
кара-каршы ике бикәч еглаша.

Гамьдәшләрнең көяләнү гамәлендә
юктыр кинә, юктыр рия, ялган да...
Өзгәләнеп Аллаһыга ялваргандай,
Ана бүре улап куя яланда.

[1] Фәган —еглау-сыктау.

Әллә инде гасырларны пәрдә кебек
бүлеп тора бары ярты төн генә?!.
Дәрья буйлый агып төшкән бөрчек яшьләр
мәрҗән булып ята диңгез төбенә.

Мәәюсләнеп маликәләр моңланганда
халык хәлен аңлый алыр балык та.
Сыктаулардан хәтта җир-күк сагаядыр—
актарыла күңелдәге бар нөктә.

* * *

Хәзрәти Мәрьям

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!

Яшең белән чыгып бетәр димсең
бәгыреңә тулган бар ачы?
Мәлҗерәмә әле мәҗүсидәй,
хәттин ашма, нугай баласы!..

Канны юып булмый кан-яшь белән,
кан-яшь тамган җирдә гөл үсми.
Кенәзбикә, болай кызгандыру
синең кебекләргә килешми.

Еглашулар бит ул сөйләшүне
дәвам итү башка әмәлдә.
Нәүхәчеләр кебек кыланмагыз—
бар бит әле фарыз гамәл дә.

Алыштырмый зекер әйләүләрне,
гыйбадәтне андый аһ-ваһлар.
Егламагыз шулай егылышып—
су эчендә ята әрвахлар.

Чыдамлыгын яшькә чылатмаган
сабырларны сөя Аллабыз.
Балакайлар, әйдә, бергәләшеп
«Вәл-гаср»ны укып алабыз...
. . . . . . . . . . . . . .

Сөембикә

Күздән яшең ничек чәчрәп чыкмас
сабырлыклар тулып ашканда?!

Ярославна

Тирәнәя хәсрәт дәрьялары,
буаларын тырнап ачсаң да.

Сөембикә

Фөрьятыма каршы фәрештәләр
кара «амин» сүзен ник әйтте?

Хәзрәти Мәрьям

Пот-санәмнән килми авырлыклар—
барысы да Аллаһ нигъмәте.

**Мәләкләргә үпкә белдергәндәй,**
**карап алма рәхмәт юлына.**
**Иләмсерәр мәлдә елмайткан да,**
**еглаткан да бары Ул гына.**

Ярославна

**Әллә инде безнең яшьле күздә**
**көннәр белән төннәр буталды?!**

Хәзрәти Мәрьям

**Саргаешкан чакта сорашыгыз:**
**«Кайдан килде,—диеп,—бу кайгы?»**

**Үзегездән үзәк өзелүләр,**
**үзегездән килә барсы да...**
**Ихлас белән шуны икърар итсәң,**
**авыртулар бераз басыла.**

Сөембикә

**Йөрәгемнең тоймыйм җәрәхәтен,**
**яшемдә дә инде кан күрмим.**
**Сизәсеңдер: мин бит, сабырсыздай,**
**үзем өчен генә кайгырмыйм.**

Хәзрәти Мәрьям

**Туган халкы өчен бәхет даулап,**
**сез генәме шулай җан аткан?..**
**Гарше-көрси мотлак һәрнәрсәне**
**үз тәкъдире белән яраткан.**

**Галәлгомья[1] кылган гамәлләрне**
**хәтереңә син дә яза бар.**
**Көч-кодрәтле Аллаһ кавемнәрне**
**язгына күрә җәзалар.**

**Хак Тәгалә бәгъзе халыкларга**
**нигъмәтләрен өстәп биргәндә,**
**тәкәбберлек йота тәкатьсезен,**
**башларында калмый бер гамь дә.**

**Ил-суларын җәннәт мисалында**
**күреп масайганнар кем иде?**
**Кәпәренгән шундый кавемнәрнең**
**тора-бара... җире кимеде.**

Сөембикә

**Безнең илне оҗмах багы санап,**
**дошман нигә җирен арттыра?**
**Арабызда, юкса, ыруглыктан**
**килә торган изге ант тора.**
**Өммәтемнең шушы әманәтен**
**мирас итәр идем углыма...**

[1] Галәлгомья —сукырларча.

Ярославна

**Вәгъдә сүзен кемнәр башлап боза—**
**белә булыр аны Ул гына.**

Сөембикә

**Хәләл халкым хакын хаклар өчен**
**миннән тагын күпме хак кирәк?**

Хәзрәти Мәрьям

**Дулашмагыз: сезнең дошманнарны**
**белә Ходай сездән яхшырак.**

Ярославна

**Ачылыгы анда ачыкланыр,**
**кемнең—эре, кемнең вак яше...**

Хәзрәти Мәрьям

**Сезне гирьян[1] иткән дошман явы—**
**Аллаһ биргән сынау вәгъдәсе.**

Сөембикә

**Татар иле авып барган чакта**
**Хак йортына ничек килмә ди?!**
**Илчесенең биш мең фәрештәсе,**
**юк, барыбер ярдәм кылмады.**

Ярославна

**Кенәземә сәлам күндергәндә**
**әйттем җилгә изге сүз генә.**
**Нигә алар яуда ике булып**
**күренмәгән кыпчак күзенә?..**

**Язык саен төшкән җәза кебек,**
**гел-гел безне эзли бу каза.**

Хәзрәти Мәрьям

**Үтәмисез фарыз кануннарны—**
**унның берсен генә булса да.**

Сөембикә

**Вөҗданымны сыгып вөҗүдемнән,**
**нинди бушлык изә бу җанны?**
**Әллә инде, халкым, сине саклар**
**фәрештәләр гаип булганмы?!**

Хәзрәти Мәрьям

**Ябырылса дошман яугирләре,**
**шик кылмасен Раббың хакында,—**
**чиратлашып торыр чарасызлык,**
**җиңү яулар синең халкың да.**

---

[1] Гирьян—еглаучы.

Әлмисактан килгән әүлиялар
хикмәтенә дикъкать әйлә бер:
ирексезләп артта калдырылган
соңра ... беренчегә әйләнер.

Әгәр Ходай ярдәм итәр булса,
хәтта зәгыйфьләргә көч керер...
Ялгыш юлга илен дәшкән рәһбәр
ике тапкыр газап кичерер.

Бер гөнаһтыр—хаким үз халкының
язмышында уйнап көн күрсә,
мең гөнаһтыр—башка кавемнәрнең
туфрагына бәла китерсә.

### Сөембикә

Казанымның кузлы казнасында
әллә чынлап азман эт бармы?
Өч-дүрт ахмак кылган гөнаһ өчен
Аллаһ безне һәлак итәрме?

### Хәзрәти Мәрьям

Уфтанулар тулы үткәннәрне
уйлар дәрәҗәдә аңлы сез.
Инде ничә халык юкка чыкты—
нигә бер дә сабак алмыйсыз?

Хафаламый сезне һәлакәтләр,
туклар белмәгәндәй ач хәлен.
Һичбер милләт узып китә алмас,
кичектерә алмас әҗәлен.

Ашкынышып хәттин ашканнарга
гарше-күктән нәфрәт аркылыр.
Хак Тәгалә алар урынына
башка бер халыкны бар кылыр.

### Сөембикә

«Аллаһ әмре» белән килә Мәсих[1]—
татар үксез, татар ят һаман.
Иңдерелгән күпме пәйгамбәрнең
нигә берсе безгә язмаган?

Пәйгамбәргә лаек халыкларга
өстенлекләр өстәп бирелгән.
Үтсәң иде иң-иң кыен чакта
Хозыр Ильяс белән бер юлдан!..

### Хәзрәти Мәрьям

Кыйбласызлар сымак кыйланганга
кабатларга әзер мең кабат:
мәхшәргәчә барлык кавемнәрнең
пәйгамбәре булыр Мөхәммәд!..

Балакайлар, күрә беләсезме
эчтән янып торган тау ямен?

---

[1]Илбасар урыс патшаларының «Аллаһ исеме» белән басып алу сугышлары башлавына ишарә.

Кайтарылыш көнгә калдырыгыз
кайгырышып еглау тәмамын.

Кемнәр хаклы, дисез, кемнәр хаксыз—
ачыкланыр шунда яхшырак.
Куанышып җәннәт капкаларын
үткәндә дә әле яшь кирәк.

Сыктамагыз!..

7

Сөембикә төштәй тонык хәтеренең
төпкелендә татлы-ачы уй саклый.
... Айдаланың өер-өер айгырлары
Нугай җирен дерелдәтеп уйнаклый!

Кылганлыклар чайкалыша калкулыкта,
кызалакка ятып аунар ат сыман.
Әллә чыкмы, әллә яшьме, әллә канмы
чәчрәп китә утлы тояк астыннан.

Җилдертәләр Йосыф мирза җегетләре—
бүген алар изге йола үтәүдә:
«Иярдәге шушы тәүге ыргымыңны,
Сөем сабый, егламыйча үт, әйдә!»

Урдасының алтын йортлы уртасында
бүген бит ул җайдакларның япь-яше.
Аргамакта егламаган нарасыйлар
дәрәҗәдә гомер кичәр, янәсе.

... Айдаласы хәтер төбен айкалдырды
тәкъдир җиле йолыкканда иярдән.
Әллә инде теге чакны чытлык кызга
еглап туймас кара болыт ияргән?!.

* * *

Сөембикә

Мәхшәр көнгә тикле җитәр микән,
Ярыслауна, безнең түземнәр?..
Зинһар өчен тыңлап торма мине—
кардәшләргә әйтер сүзем бар.

Галәмемнең оят гамәлләрен
белеп бетермәсен көндәшем.
Егламыйча әйтим уйлаганны,
син дә туктап торчы, күз яшем!..

Гомер сөрә җирдә ничә кавем,
бардыр алар йөзләп, меңләп тә.
Зекер әйтмәс идем: зирәк акыл
күбрәк, диеп, безнең милләттә.

Вакланыша торды алыплары
киртә булып калкыр тау саен.
Татарымның, ахры, тәкъдиренә
тәдбир[1] салынмаган тәгаен.

---

[1] Тәдбир—алдан күреп эш йөртү.

**Бөек Туран рухын туры тотып,**
**селкетмичә сыңар кашын да,**
**көчен туплый алмый төрки кавем**
**зурдан купкан дошман каршында.**

**Милләтеңә керсә мин-минләнү,**
**аннан шуның кадәр мән чыга.**
**Әверелеп бетте арысланнар**
**йоклап яткан мәхлук мәчегә.**

**Күккә сыймас мәгъруp бөркет җаны**
**яши кебек хәзер... тавыкта.**
**... Безнең халык бер көн тора алмас**
**туганара ызгыш, дау юкта...**

**Кояш чыккан чакта базмас идем,**
**җөрьәт итеп әйтәм—кич инде:**
**кардәшләрең белән көрәшүгә**
**бирдең, төрк, иң күп көчеңне.**

**Шан-шәрәфле нәсел шәҗәрәбез**
**башлангандыр изге ант илә.**
**Үчләнүне синең угланнарың**
**уйлап тапкан, Олуг Атилла!..**

**Илен һәлак итәр чиккә җитә**
**туганлыктан туйган вак даучы.**
**Карымталар кырды кардәшлекне,**
**онытылды ыру вәгъдәсе...**

## Ярославна

**Кардәшләрен ашар каракошка**
**каргыш төшми бугай, ханбикәм.**
**Ярославның соңгы васыятен**
**искә алсам, күпме кан йотам.**

**Әйткән кенәз: туган белән туган**
**сугышмаска тиеш моннан соң!..**

## Сөембикә

**Үзең генә йотма гарьлек утын,**
**вәгъдә бозган ир дә моңлансын.**

**Ыру анты, беләм, түгел әле**
**эчеп исәрләнер эчемлек...**
**Ярыслауна, бүлмә ярсуымны—**
**бүген минем синдә эшем юк.**

**Кан-яшьләрем сауган кардәшлекне**
**аңлый алмый канча ел барам.**
**Айдалалы нугай агайларым,**
**еглый-еглый сезгә ялварам!**

**Нәгърә ормый гына сорыйм әле,**
**ишетмәсен аны кай кеше:**
**берәр вакыт булды микән сездә**
**нәселдәшлек, ден-дин кайгысы?**

**Сезнең өчен, ахры, ашы кыйммәт,**
**баштан ашканда да ил эше.**
**Туемсызлык йоткач туганлыкны,**
**ауган, әнә, Җучи олысы.**

**Гарьсезләрең дала горурлыгын**
**сатты юк-бар бүләк хакына;**
**мескенләнеп сорау мисалында**
**мәскәүләргә китте хат кына.**

**Ияр юлла, имеш, быргы җибәр—**
**теләндегез даулап һәммәсен:**
**кәгазь, буяу, кургаш, көбә, акча,**
**зәгъфран, бүрек, кадак һәм лачын...**

**Алтын чире йоккан кылтык ханың**
**ашамаган ... бакыр казаннан.**

Шундый җимнәр белән дәҗҗал үзе
сезнең ышанычны казанган.

Яманатлы Мәсих ямаулыгын
ташып торган җасус ямчылар.
Шуның өчен бит ул һәрбер заттан,
Газраилне узып, җан сорар!..

Сарык бүлә алмас ике туган,
сезме милләт өчен янучы?
Кардәшлекнең канын корытадыр
карымтага сыймас кан үче.

Илаһыннан куркыр иләмәнне
таба алмый йөри ил гаме.
Ә мин җавап эзлим: бездә илхан
үз үлеме белән үләме?

Агуласа берсен агалары,
икенчесен... углы үтерә.
Бердәмләшер иде бөрадәрләр—
киртә булып зәһәр үт тора.

Канлы дауга сылтау булсын әле
дала буйлап чапкан бер дүдәк!..
Унөч туган суеп кигән таҗның
бәрәкәте кайда, Бирдебәк?

Бакчасарай ханы[1], ваксынмыйча,
кыйган, әнә, газиз ун җанны.
Ыру каны сеңгән тетрек җиргә
нигез корып алар уңганмы?

Тәсбихеңнең асыл мәрҗәннәре
нигә, каумем, һәрчак ким торган?
Идегәйнең башын игелексез
Барын кисеп, Ширин китергән...

Кисәтүчән була кисекбашлар,
зирәкләнеп сабак бирүчән...
Безнекеләр һаман бугазлаша
кечтек кенә иске бер үчтән.

Мордарлыкка баткан мирзаларым,
нәрсә җене сезгә кагылган?
Аллаһыны сөю тәһарәте
кылынмыйдыр алай кан белән.

Кыландыгыз сыйлы келәмнәрдә,
дошман сигез, диеп, без тугыз.
Ә кылмышта баскын кулындагы
айбалтаның сабы булдыгыз.

Бүрек сорап, шулай бүре чакыр,
һәрбер монафыйкъның үз җиме.
Ерак чорга барып җитәр әле
кысыр Шаһгалинең ... үрчеме.

Әгәр түккән яшем дәлил икән,
хасил булыр күктә бер диңгез...
Дилбегәсен чиксез далаларның
җиде ятка ничек бирдегез?

Безнең өммәт бөтен яктан камил:
һәм гакыллы, имеш, һәм ипле;
һәлакәтле язмыш хәлләренә
унбиш яшьлек[2] Иван гаепле...

Дәүләтеңнең черү сәбәбе дә
төенләнгән шушы баскында.
Каныгуы татар канынནандыр—
аударыгыз аңа барсын да.

Искәртмиме безнең өстебезгә
ябырылып торган яу үзе?
Үткапчыкта гына утырадыр
дошманыңның үтә явызы.

Аңлый күрче, каумем: шуннан гына
килә, димим, безгә бар афәт;
уйла әле тәсбих өзгән мәлдә—
башсыз илдә булмый бәрәкәт...

Шушы хәтәр чакта берәр ир-ат
күрсәтсәме тәҗел эш кылып?!—
Зәүҗә башым белән йөрмәс идем
тәхет тирәсендә ышкылып.

Һиҗрәт кылу гына пакьли алмас,
намусымда барыбер тап булыр.
Шелтәләгән чакта Шаһгалине,
миннән шигәюче табылыр.

Дәгъваларын гамәл дәфтәремә
язып куяр кара кавырсын.
Илдә сату итеш барган чакта
кем фәрештә булып калыр соң?!.

Аңа кадак, имеш, моңа Казан—
мәхшәргәчә тынмас ул сәүдә.
Тамчы яшем шундый авыр булып
ятса икән гарше үлчәүдә...

## Бетем

Даулы җиргә тамып торган ачы яшьләр
саркып чыга эремдәге чык булып.
Кыйтталардан тонык тавыш кайтарыла—
тагын кемнәр еглый анда сыгылып?

[1] Мөхәммәт Гәрәй күздә тотыла.

[2] Явыз Иван үзенең гаскәре белән Казанга шушы яшьтә һөҗүм итә башлаган.

**Кавемнәрнең көяләнгән күңеленә**
**моң-зар өстәп, исмә әле, исмә, җил!..**
**Җырлауларны ялгагандай еглауларга,**
**аять укый Муса, Идрис, Исмәгыйль.**

**Кавышырга өмет итеп кыяматтә,**
**карурманда Сак белән Сок яшь сыга.**
**Иконалар «еглый» башлый чиркәүләрдә,**
**и Ходаем, була күрсен яхшыга!..**

**Кардәшләрнең яше сыймый каберенә—**
**гаҗизлектән үкси Аксак Тимер дә.**
**Әтрәк ханны, җәмшән иснәп, сыктый һаман**
**гариб башын сыендырган чит җирдә?**

**Тагын кемнәр бузлый анда? Зөһрә кызмы**
**чиләк белән Айга ташый... күз яшен?**
**Нәүхәчеләр юа хәсрәт дәрьясында**
**яугирләрнең канга баткан көбәсен.**

**Фәрештәләр мышык-мышык сулкылдаша**
**Рамазанның соңгы көне батканда.**
**Хәтерләтеп Бакчасарай ханбикәсен,**
**яшен түгә моңлы күздәй фонтан да.**

**Күздән язар хәлгә җитеп ярсый Ягъкуб—**
**тама Йосыф күлмәгенә канлы яшь.**
**Якыннарын югалтудан ахылдаша**
**Миңлесылу, Даныбикә, Карлыгаш.**

**Ибраһимның ялгыз калган хатыннары**
**еглашадыр: «Хур буламыз,—дип,—Ходай!»**
**Ә кулларын угалаучы угланнары**
**сөенешә: «Хан буламыз,—дип,—Ходай!..»**

**Янмас кызның үксез җаны очып йөри—**
**аглый Казан, Җылантауда ут күреп.**
**Сабый төсле сыктый һаман Явыз Иван,**
**ауган ханлык тәхетенә утырып...**

**Җиде икълим чиген иңләп иңрәү йөри,**
**иңрәү кайта, кайта ничә ел аша.**
**Дөньядагы барлык, барлык фөрьятларны**
**күмә төшеп, мәликәләр еглаша.**

**Йөрәгеңнән гамьнәр савып йөдәгәндә**
**килми калмый, килми калмый кан исе.**
**Бәгырьләрдә Вакыт... Хәтер бәрелешә,**
**хаклы итеп тоя үзен кайсысы?**

**Исәннәргә нинди аһлар ишетәсе,**
**алгы көндә тагын ниләр күрәсе?!**
**Ике бикәч көн-төн еглый ике ярда,**
**яраларга тамып тора күз яше...**

*2001-2002.*

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр

**Рауль Мирхәйдәров**

## ҺӘРНӘРСӘГӘ—АКЧАЛАТА

РОМАН

### Барвихадагы катран

1

Күренеп торган сәбәпләре булмаса да, Аргентинлы, ни өчендер, сентябрь буе авыр күңел төшенкелегә кичереп йөрде. Кәрт уенында юкса хәлләре әйбәт кенә, еш кына саллы-саллы зур отышлары да була, Аллага шөкер, бер өч еллап инде «янганы» да юк. Өйдә дә һәммәсе дә тыныч-имин шикелле, бары тик кече кызы Эйнштейнга гашыйк булды бугай, әллә шул борчыймы соң? Әйе, аның күңеленә шул борчу салды, ул Верочкасының, хәтта Эйнштейн сәләтле булса да, кәрт уйнаучыга кияүгә чыгуын теләми—үзенең яраткан кызын андый язмышка дучар итәсе килми иде. Хәер, Георгий тарафыннан кызына карата сизелерлек кызыксыну әлегә күренми-күренүен, егеткә табынырга әзер торучы кызлар буа буарлык: ягымлы, һәрвакыт көяз киенеп йөри, еш кына акчалы, машинасы бар, шуның өстәвенә, белемле, күп укыган—кыскасы, күзгә төтен җибәрергә булдыра ала, андыйларны кызлар да ярата, артыннан тагылып йөриләр. Дөрес, соңгы араларда Георгий кәрт уйнарга йөрүләрен сирәкләтте, һәрвакыт Тоглар янында була, әйтерсен, аның референты-киңәшчесе: тегесе кайда барса да, аны озата йөри, хәтта хуҗасы өйдә тормаганда, Кутузов проспектындагы йортында да яши. Тоглар белән аралашу Георгийга файдага гына булыр, әлбәттә, хәзер үк инде аларның шулай якынаеп китүләре Эйнштейнның абруен күтәрде.

Ә сентябрь ае шундый матур башланып киткән иде бит! Тогларның туеннан соң, Аргентинлыны гаиләсе белән Константин Николаевичның Кутузов проспектындагы әле генә янабаштан эшләп бетерелгән квартирасына кунакка чакырдылар. Сүз уңаенда әйтеп китик, Аргентинлының квартираны тулысынча җиһазлап-бизәп бетерелгән хәлдә беренче күрүе иде әле, югыйсә ремонт ясаганда бер генә кермәгән иде, Эдуард

---

Ахыры. Башы 7-9 саннарда

Шаһиевның картинасын да Константин Николаевич аның тәкъдиме белән алып, остаханәсенә бик урынлы урнаштырып куйды, моны хәтта рәсем сәнгатеннән ерак кеше дә төшенерлек иде—Аргентинлы өчен үзе бер горурлык, куаныч булды ул. Зиннәтле остаханә-салоны белән тулы бер катны биләп торган апартаментлар аның хатынын да, кызларын да таң калдырды, әле кайчан гына үзләренең квартиралары да Тогларның кәләше Натальяны шулай таң калдырган иде бит.

Константин Николаевичта кунакта Георгий да бар иде, нәкъ менә шул кичтә Аргентинлы Верочканың кәрт уены даһие Эйнштейнга яратып карап утырганын абайлап алды. Городецкий тагын әле шунда Константин Николаевичның бабасы бик атаклы рәссам, академик булганлыгын һәм мөһаҗирлектә, туган иленнән еракта үлеп калганлыгы турында да беренче тапкыр ишетте. Николай Фешинның рәсемнәре дә аны битараф калдырмады, аңа хәзер Тогларның ни өчен рәсем сәнгатенә тартылуы аңлашыла иде—кан кан инде, нәсел геннары кайчан да булса бер үзләрен сиздерергә тиеш. Шул җылы сентябрь кичендә легендар Тоглар Городецкийга бөтенләй икенче ягы белән ачылды, ә юкса Городецкий бу кеше турында бөтенесен дә беләм дип йөри иде—ни әйтсәң дә, утыз елга якын танышлар бит, үзе бер кеше гомере.

Тоглар Аргентинлыны гаиләсе белән үзенең Переделкинодагы дача йортына да чакырды—кыскасы, якын дусты Костя Фешин хыялланган тыныч-имин тормыш җайга салынып килә иде.

Быел Аргентинлы кәрт уенына ешрак Барвихага йөрде, кайчакларда Шаманның өендә дә уйнаштыргалый иделәр, әмма соңыннан президент тирәсендәге зур түрәләрнең берсендә чын-чынлап катран оешты. Барвихадагы ул катранны зурдан кубып уйнаучылар югары бәяләп йөрделәр: хәвефсезлек һәм уңайлылыгы тәэмин ителгән, биредә бурычка уйнау да юк, һәркем акчасын «дипломат»лар, саквояжлар, бауллар, чемоданнарга тутырып алып килә—үтә дә бай әфәнделәр җыела анда.

Аргентинлының тирән күңел төшенкелеге өлешчә Барвихадагы катранда ишеткән сүзләрдән, шунда көтелмәгән серләр ачылуны белгәннән дә килә иде. Кыйммәтле коньяк һәм виски белән җылынган түрә кешеләр, берсен-берсе уздырырга тырышып, үзләренең хезмәт һәм дәүләт серләреннән тизрәк котылырга ашыга, әйтерсең лә, ул серләрне белеп, эчләрендә саклап йөртү аларны буа, тормышта рәхәтләнеп-шатланып яшәргә бирми. Шуна күрә дә бу тук һәм үз-үзләреннән канәгать әфәнделәр бер кызганусыз, бик җинел генә, әле хәтта әтәчләнеп, бер төндә әллә никадәр байлыкларын югалта иделәр. Урлап, ришвәт алып гаделсез тупланган акчалар гүя аларның кулларын пешерә, тормыш чынбарлыгын тоярга бирми, шунлыктан отканнар да шатлана алмый, оттырганнар да офтанмый: резинка яки бау белән игътибарсыз гына бәйләштереп куелган егермешәрутызар меңлек төргәкләренең кайберләре бер төн эчендә берничә мәртәбә кулдан-кулга, баулдан чемоданга, чемоданнан «дипломат»ка күчеп йөри. Беркем дә аларны санап тормый, типтереп, туздырып бетерү, яки бүләк итү турында сүз дә булырга мөмкин түгел, үзләре әйтмешли, болар—уен акчалары, кайберәүләр хәтта ул саквояж-сумкаларын алып кайтып та тормый, атна арасында янадан уйныйсы булгач, нигә аларны өстерәп йөрергә, ди? Шулкадәр күп акчаларга шулай битараф карау,—һәй, иртәгә тагын ришвәт китерәчәкләр ич!—яки аларны җинел генә, хәвеф-хәтәрсез генә кулга төшерүләре Городецкийның элеккечә онытылып уйнау теләген генә түгел, гомумән, тормышның тәмен-ямен җуйды. Уенга бөтенесен дә, хәтта гомеренне дә салып, комарланып-дәртләнеп уйнамагач, уенуенмы инде?! Әйтерең бармы, тәвәккәл кәртче кешеләрнең бөек белгече Федор Михайлович Достоевский, Барвихадагы катранга килеп эләксә, исе-акылы китәр иде: Россиянең болгавыр яна заманы нинди уенчылар тудырган бит!

Ләкин һәрвакыт шаян-шук, үткен телле, һич төшенкелеккә бирелә белмәс Аргентинлының тәвәккәл дәрт-теләкләр юклыктан гына пошмый

эче—ул үзе еллар буе туплаган акчаларын куеп уйный, ана үзләре теләп тә, мәжбүри дә ришвәт бирүчеләр юк, ә акчаның үтә дә кирәк чагы хәзер. Кызларының икесе дә пешеп өлгергән—кияүгә бирер вакыт, йорт, гаилә чыгымнары да арта тора, тормыш көнләп түгел, сәгатьләп кыйммәтләнә бара.

Әмма аны башка нәрсә борчый-боектыра—үз иленең, үз халкының киләчәге турында ул имеш-мимешләрдән чыгып кына уйланмый, ул бит Россиянең язмышын хәл итүче түрәләр, закон чыгаручы депутатлар, министрлар белән кәрт уйный.

Кайвакытларда Аргентинлының уенга бармый каласы килгән чаклары да була—анда бигрәк ачыктан-ачык сөйләнә башладылар инде, ә ул үз тәҗрибәсеннән чыгып әйтә ала: чит серләрне күп белсән—гомерең кыска булыр, диләр. Җинаятьчел дөньяның төп васыятьләреннән берсе бу, шуңа күрә дә анда синең күңелеңдә казынмыйлар, кирәкмәгәнгә башкалар эшенә тыгылмыйлар да. Ләкин Аргентинлы Барвихага барудан туктый да алмый, ул бит Мәскәүдәге бик күп акчалар әйләнә торган бердәнбер урын. Аргентинлының исә бик тирәндә яткан яшерен хыялы бар: бер ун-егерме миллион доллар отса, уйнаудан туктап, төпкә ятар иде. Аңа туктар вакыт бик житкән, нервылары гел киеренке халәттә, сәламәтлеге дә элекке түгел инде, яраткан хатыны да, рәсем сәнгате белән генә мәш килгән Тоглар мисалы да шуңа дәртсендерә иде. Бәлки, ул да үзенә берәр төрле хобби—шөгыль табар һәм көннәрен, Константин Николаевич мольбертка багышлаган кебек, гел шул мавыгуына багышлар иде. Дустының яңа шөгыленә Городецкий барыннан да бигрәк көнләшеп карый—менә бит, үткәнен бөтенләйгә «төйнәп куйды да», гомер кояшы баюга барганда булса да, күңеленә хуш килердәй һөнәр тапты. Әмма Аргентинлы тагын шунысын да аңлый—Тогларга җиңелрәк, аның нәселдән килгән геннары уянган, анарда рәссам каны уйный.

Бервакыт, сентябрь урталарында, Барвихада яңа уенчы пәйда булды, уенга даими йөрүчеләр аны президент командасына ниндидер эшкә яңа билгеләнгән кеше дип таныштырдылар. Альберт Янович нәселдән килгән чекистлар гаиләсеннән булып, шәҗәрәсе әллә Берзиньнән, әллә Дзержинскийның үзеннән үк башлана икән. Дөрес, ул үзе, хәзерге демократик заманда, бай совет чоры шәҗәрәсен искә төшерергә яратмый һәм хәзер бик модада булган һөнәр иясе—политолог, ягъни сәясәт белгече, имеш. Бу һөнәрдән үзенне күрсәтергә теләү яки шарлатанлык ачыктан-ачык аңкып тора иде. Әмма, күрәсең, ул кирәкле тикшеренүләр һәм фараз кылулар ясыйдыр, юкса президент командасына эләкмәс иде. Яңа кеше булуына карамастан, ул инде каптырасын каптырып, эләктерәсен эләктереп алырга өлгергән һәм уйнарга шыплап тутырылган яңа күн саквояж белән килә, ләкин аны бервакытта да, икенче уенга кадәр калып торсын дип, катранда калдырып китми иде. Аның тел тегермәнен һич тыяр хәл юк, ул хәбәр арты хәбәрләрне туктаусыз сибеп тора, аның ул мәгълүматлары бер Аргентинлыны гына түгел, башка уенчыларны да туйдырып бетерде. Кайбер түрәләр, үзенә сиздермәскә тырышсалар да, бу сәясәт белгече ниндидер аңлашылмаган провокация белән шөгыльләнә, дип шикләнә, моны Городецкий да тоя иде. Альберт Яновичның коткыларыннан борчылмыйча да хәлең юк...

Мәсәлән, бу чекистлар токымы, Россиянең яңа Генераль прокуроры турында, президент аны Себердән табып алып күтәргән булуга карамастан, тиздән төрмәгә үзе кереп утырырга мөмкин, дип сөйли. Прокурор үзенең якын туганнарын бик тырышып нефть бизнесына этеп-төртеп урнаштырырга тырышкан, юкса күптән бүленәсе бүленгән һәм көндәшләрне сыйдырмыйлар икән. Әле, житмәсә, югары хакимлегеннән файдаланып, Мәскәү кланнарына да бәйләнә башлаган, ди. Алар артында да гади гражданнар гына тормый бит, үз өлешләрен алай тиз генә ычкындырмаслар. Альберт Янович Генераль прокурорның гап-гади ришвәтчелектә, коррупциядә гаепләнүе Россия тарихында әле беренче тапкыр булачак

һәм ул көннәрен төрмә ятагында үткәрәчәк, дип ышандырырга тырыша. Аның мондый фараз кылуларыннан күпләрнең кәефе кырыла һәм алар кәртләрен урынлы-урынсыз, уйлап-нитеп тормыйча, ыргыта башлый, шуннан Аргентинлы бик оста гына файдаланып та кала иде. Ләкин уенчылар тиздән исләренә килә: изге урын буш тормый, ул прокурор урынына, бәлки, үзебезнең кешеләрдән берәрсе утырыр, шулай булгач, бер яманның бер яхшысы булыр—Мәскәү читтән килгәннәрне беркайчан да, бигрәк тә зур урын биләгәннәрен, яратмады һәм яратмаячак та диләр.

Шул ук Альберт Янович кайчандыр телевизион тапшырулар алып барган, ә хәзер абруйлы бизнесмен булып киткән билгеле бер кешене тиздән атып үтерәчәкләрен әйтеп ычкындырды. Әле өстәвенә, телевидениедә рекламалардан һәм рәсми рәвештә, һәм кулдан-кулга кара «нал» булып нинди акчалар кергәнен санап узды—моны ишеткәч, күпне күргән, алты-җиде урынлы саннарның нәрсә икәнен белгән уенчыларның да авызлары ачылды да калды.

Берничә ай үткәч, бу сүзчән политологның күрәзәлек итүе дөрескә чыкканлыгына Аргентинлы да ышанды. Ул көннәрдә әлеге сәясәт белгече, йөзенә кайгылы төс чыгарып, телевидение экраннарыннан кадерле дустының җир йөзендә иң эчкерсез кеше булганлыгын, бары тик аның иҗади уй-ниятләре белән килешмәгән кешеләр генә аны үтергәнлекләрен ачынып сөйләде һәм дустының үлемен Пушкин үлеменә тиңләп сүзен бетерде. Валлаһи, икейөзлелекнең чиге юк. Ләкин Альберт Янович һәрвакытта да икейөзлеләнми—уен өстәле янындагы үз ишләре арасында ул ихластан сөйли, дөреслекне, күзенә карап, туп-туры ярып салмаса да, бай җиһазлы бүлмә эченә ыргыта—монысы хак.

Чечняда менә-менә башланырга торган сугыш турында Барвихада да ешрак сөйләнергә тотындылар, чеченнәргә тау-тау корал, бронетехника һәм хәтта авиация калдырып чыгып, миллиард долларларны кесәләренә салган кемсәләрнең исем-фамилияләрен дә яшермичә, ачыктан-ачык әйтә иделәр. Булачак сугыш түрә халкын куркытмый, киресенчә, дәртсендерә, исертә генә иде, армиягә төрле кирәк-яраклар биргәндә чын-чынлап баеп калырга мөмкин, ә инде урлашу турында сөйләп торасы да юк. Ә иң мөһиме—халык алдында биргән бер вәгъдәне дә үтәмәскә була, һәрнәрсәгә җавап бер генә—сугыш...

Барысын да белеп торган Альберт Янович бу юлы да үзенең акыллы сүзен әйтте: сугыш ул—беренче кар кебек, реформа елларында кылынган барлык җинаятьләрнең дә эзен күмеп китәчәк, әгәр монысы барып чыкмаса, икенче сугышны оештырырлар, диде. Бары тик зур кайгы-хәсрәт кенә, меңәрләгән яшьләрнең үлеме һәм тагын меңәрләгән яңа яшь инвалид-гарипләр генә халыкның игътибарын җәлеп итеп, хакимият башында утыручыларның элекке җинаятьләрен оныттырыр, ә ул оятсызлар, шул ыгы-зыгыдан файдаланып, әле сатылып-урланып бетмәгән халык байлыгының калганын да сатып-урлап бетерергә ашыгыр. Мәчегә—көлке, тычканга—үлем, дип халык юкка гына әйтмәгәндер.

Чечняда булачак сугыш турында сүзләр киткәч, Аргентинлы шундук Тогларны исенә төшерде, ул бит анда өч ел әсирлектә булган һәм андагы хәл-әхвәлне яхшы белә. Әле бер ел элек үк ул, «чехлар» белән бәрелешүдән котылып булмаячак, әлеге таулы төбәктә кемнәрнеңдер бик зур акча мәнфәгатьләре кисешә, болай да сугышчан халык кулына бик күп корал бирелде, житмәсә, Чечня үзенең регуляр армиясен дә булдырды, дип раслап килде. Корал исә һәркемне—олысын да, кечесен дә исертә.

Аргентинлы үз кешеләре аша тагын шунысын да белеште: алда торган Чечня сугышы аркасында Мәскәүдәге банкирлар, сәнәгатьчеләр, нефть өлкәсендәге бизнесменнардан ясак алу да кискен арткан икән—сугышның күп акчалар сораячагы аңлашыла, димәк, Терек елгасы аръягында аңа житди әзерләнәләр, дигән сүз.

Әле башланмаган сугыш-кырылыш Аргентинлыны әнә шундый пошынулы уйларга сала һәм, әлбәттә, кәефен һич кенә дә күтәрми иде.

## 2

Чечня турында беренче мәртәбә сүзләр кузгалган көннәрдә катранда тагын бер уенчы пәйда булды, монысын Александр Михайлович дип таныштырдылар, ул Альберт Янович белән бергә килеп кергән иде. Теләсә кайсы катранда, хәтта Барвихада да, уенчыларның тотрыклы төркеме юк, хәер, нинди дер үзәге, даими йөрүчеләре була-булуын. Кәрт уйнаучылар һаман да үзгәреп-янарып торучылар хисабына яшәп килә дә: берәүләр, ыштансыз калганчы, бар булганын оттырып бетереп юкка чыга, икенчеләренең мәхәббәт, эчкечелеккә сабышу, наркотиклар, эшендә йә гаиләсендәге күңелсезлекләр, урын алыштыру, каядыр китеп бару кебек сәбәпләре була. Кайберәүләр еш отып торсалар да, уеннан туя, кемнәрнедер чит илләргә эшкә билгелиләр. Шуна күрә дә өстәл янында яна кеше күренү көтелмәгән хәл түгел, ул бит урамнан броняды ишекне шакып килеп кермәгән. Клуб кагыйдәләре буенча, яна кеше еш йөрүчеләрнең кайсысына булса да ияреп килә, бу хәл сораулар да, кызыксыну да тудырмый, бирeдә һәркем үзен мөстәкыйль-бәйсез хис итә, шунлыктан кемнең кем икәнен төпченүнең дә кирәге калмый. Ә инде яна уенчы Александр Михайловичның Альберт Янович белән бергә килүе уен өстәле тирәсендәгеләрне үзеннән-үзе ана дустанә мөнәсәбәттә булырга мәҗбүр итә иде. Кайбер көннәрдә катранда берьюлы ике, өч, хәтта тагын да күбрәк яна кешеләр була, андый чакларда бер үк вакытта ике өстәлдә уйныйлар. Яналар арасында танылган кешеләр дә булгалый: артистлар, исемнәре билгеле журналистлар, банкирлар, сәяхәтчеләр... Ләкин Александр Михайлович дигәннәре беркемгә дә таныш түгел, матбугатта һәм телевидениедә күзгә чалынганы юк, югары урында утыручыларга мөнәсәбәте барлыгы белән мактанмый, үзен гади-табигый тота, әмма үз дәрәҗәсен үзе белә.

Җитди уенда,—ә Барвихада җитди булмаган уен да юк,—каршы як уенчыларын бик караштырып утырыр вакыт булмый, бөтен игътибарын үз кулындагы кәртләрдә, нинди кәртләр уеннан чыга бара, ни өчен нәкъ шул кәртне тизрәк ташларга ашыктырдылар, дип, кемнең кулында нинди кәртләр калганын иснәнеп-чамалап чыгарырга тырышып утырасын. Кайчагында, кулдагы утыз биш кәртнең барысын да белеп торсаң да, синең төп көндәшең кулында калган бердәнбер—утыз алтынчы кәртне белмәвең аркасында, оттырасын да куясын. Зур отышлар өчен уенны кыска арага йөгерешү ярышлары белән тинләргә мөмкин, анда да бит җиңүчене бары тик фотофиниш ярдәмендә генә ачыклыйлар. Ә җиңүче белән аннан артта калган икенче яки өченче кешене секундның йөздәнмеңнән бер өлеше генә аерып торса да, җиңүче тарихка кереп кала, бүләкләр ала, җиңү данында коена, ә теге артта калганнарны беркем дә искә алып тормый. Кәрт уенында да шул ук хәл: биредә икенчеләр булмый. Катраннар диварына шундый язу эләргә дә була: «Бирермен дигән колына, чыгарып куяр юлына».

Соңрак, инде буласы булгач, кем әйтмешли, туны тузгач, Аргентинлы үзен яна уенчы Александр Михайлович белән күпмедер вакытка бәйләп торган вакыйгаларга әйләнеп кайтыр да, үзе югында тиздән Оракул кушаматы алган политолог белән бергә катранга килеп кергән бу яшь кешенең төс-кыяфәтен исенә төшереп азапланыр. Әлбәттә, Городецкий бу яңа кешегә игътибар итми калмаган иде юкса. Картая барган саен ул үзеннән остарак хәрәмләп уйнаучыга тап булудан курка иде, ә андыйлар хәзер буа буарлык, гел генә сәләтле алдакчы хәйләкәрләр, аның үзенең укучысы булган Эйнштейнны гына алыйк—даһи да даһи, ул да даһи! Андыйларны хәзер төрмә даими тудырып кына тора. Хәтта, төрмәдә биш-алты мәртәбә утырып та, кулына кәрттән башка нәрсә тотмаган, шунда көненә ун-уникешәр сәгать кәрт сугып өйрәнеп утырган бәндәләр бар, аларга исә шундый шартларны үзләреннән көчлерәк «авторитетлар» тудырып тора. Ирекккә чыккач, мондый уенчыдан үзләренә дә зур файда

киләчәген алар беләләр. Иректә бу «оста» тирәсендә бер кәтү әрәмтамак жыела—алар башта аны ашата-эчертә, әйбәтләп киендерә, берәр уенчылар төркеменә кертеп жибәрә һәм кем белән уйнау файдалы икәнен дә әйтә. Чөнки соныннан, отыш әйбәт булганда, үзләренә дә өлеш чыга тора бит.

Ләкин элек билгеле булмаган башка төрле уенчылар да барлыкка килде—алар гипнозга сәләтле, күз буа, сине үз ихтыярына буйсындыра, хәзергечә әйтсәк, экстрасенс көченә ия була—мондыйлар үзе бер бәла, кәрт уенында даһи булмасалар да, күзенә карап сине алдый. Аргентинлы Мәскәүдә шундый уенчыларга өч мәртәбә тарыды инде, әле ярый, нниндидер сәбәпләр табып, уеннан төшеп кала килде. Менә шундыйрак хәл килеп чыкмагае дип, Городецкий Александр Михайловичны да күзәтми калмады. Хәрәмләшкән уенчыны һәрвакыт куллары сата,—андыйларның кулы горурлыклары да, кадерләп кенә тота торган уен коралы да,—андый кеше үзенең сәләтен һәм мөмкинлекләрен һәрвакыт яшереп тотарга тырыша. Аргентинлы үзе дә шундыйлар исәбендә булып, инде утыз биш еллар чамасы шул ук алымнар белән уйнаганлыктан, тәҗрибәле «бүре» санала һәм әле үз көндәшләрен исәпләп чыгарганда бер мәртәбә дә ялгышмавы белән горурлана иде. Хәрәмләшүчеләрдән артык курыкмый, күз буучы гипнозчылардан курка иде ул—андыйлар бер мизгелгә генә синең игътибарыңны ала да, йә кәртеңне ташлата, йә аны алыштырттыра, яки үзенең кәрте синекеннән кечкенәрәклеккә сине инандыра һәм синдә уенга куйган акчаларны һаман-һаман икеләтә арттырып барырга, ахыр чиктә бар булганыңны салырга мәҗбүр итә! Андый уенның нәтиҗәсе билгеле инде—тулысынча тар-мар ителәсең. Көндәшеннең кулында күз иярмәс тизлек белән йөргән кәртне буби валеты яки пики дамасыдыр дип утырасың, ә ул, ни өчендер, көтмәгәндә уен тузы булып чыга—беркемне дә гаепли алмыйсың.

Ләкин Александр Михайлович Аргентинлы белгән алдакчы-хәрәмләшүче уенчыларга бер сыйфаты белән дә туры килми иде шикелле. Хәер, ул үзенә ышанып, иркенләп уйный, бик зур тәвәккәллеккә дә бара—Городецкий моны аның чыгарып ташлаган кәртләреннән дә күрә иде. Гомумән, ул кешенең көчле ихтыярлы, дәртле икәнлеге күренеп тора. Аргентинлы аның сөйләшүләренә дә ирексездән игътибар итә, гадәттә, сәнәктән көрәк булу эзсез калмый, кемнәр белән аралашып яшәсән, шунын җуелмас эзе кала—сүзләрендәме, гадәтләрендәме, һәвәслегендәме, хәрәкәт-кыланышларындамы—бер калкып килеп чыга ул. Александр Михайлович исә четерекле сөйләшүләрдән дә качмый, ә Барвихада андый сөйләшүләргә үзе югары даирәләрдә бөтерелгән кеше генә кайнаша ала иде. Аның менә шул сыйфаты—түрәләргә катнашы булганлыгы Аргентинлыны сагаштырды да инде һәм ул бу яңа уенчыга игътибарын киметте. Кызганыч, бәлки, сонрак аның комарлыгын тыя алырдай яки бу уенчы белән саграк булырга кирәклеген искәртердәй берәр нәрсә дә сизелгән булыр иде.

Дөрес, Городецкий гына түгел, башкалар да искәрткән бер нәрсә бар иде барын, әмма ул—сизгерлеккә өндәми, киресенчә, игътибарны читкә генә алып китә иде. Александр Михайлович кирәгеннән артык фырт-көяз киенеп йөри, шунын белән мондагы башка көязләрдән дә аерылып тора, Аргентинлы үзе кием-салым мәсьәләсендә оста түгел, әмма Александр Михайловичның шулай киенеп йөрүе ана да ошый иде.

Ә Городецкийның игътибарын Александр Михайловичның уенчылар үзара мактанышып сөйләшкән сүзләрен тынлый белүе һәм, кирәк чакта, тиешле юнәлештә борып җибәрә алуы җәлеп итте. Әле тагын шунысы да бар: аның башкаларга сизелмәгән кырыс, боз кебек салкын күз карашы. Мондый күз карашы бары тик тиешле хокук оешмаларында, анда да иң югары урыннарда утыручыларга гына хас була иде. Барвихадагы катран андый кешегә, һичшиксез, кыйммәтле мәгълүмат бирә, кызыксыну тудыра ала—атап әйтелгән исем-фамилияләр һәм анык суммалар турында

сөйләшүләр, тәмәке төтене белән бергә, уен өстәле өстендә эленеп тора: тыңла, хәтереңә сендер дә язып кына ал!

Туй үткәч—дөмбергә, дигәндәй, Городецкий үзе белән булган хәлне кырыс очраклылыкка сылтап аңлатырга тырышыр, ана каршы анык кына беркем дә әшәкелек оештырмады, ана берәү дә аяк чалмады бит. Кыскасы, бу—аның язмышы иде, Хавтан әйтмешли, ул паровоз астына эләкте. Үз гаебе дә бар, әлбәттә, сүз дә юк, үзе теге бәхетлегә карата әшәкелек эшләргә тырышты... Әгәр белгән булса... алдан күргән булса... Кайда егыласыңны белсәң, түшәк җәяр идең, диләрме әле? Кәртләрен ачылып беткәч, боржоми суы эчүнең файдасы юк шул инде...

Хәер, иртәме-соңмы, мондый күңелсезлек бер килеп чыгарга тиеш иде. Бәхетең басып, фарт килү—иркә бала кебек, тиз алмашынучан була ул. Аргентинлының бер дә үпкәләр урыны юк, бөтен гомерен кулына кәрт тотып үткәрде, рәхәт-имин яшәде, балаларын үстерде, менә дигән квартиралы булды. Бәла киләсен алдан сизенмәсә дә, картайганын тоя, тиз фикерләү сәләтен югалта бара, эчке сиземләве бетте, туктарга бик вакыт иде югыйсә. Юк шул, һаман да бер бик зур отыш эләктерергә чамалап йөрде...

Александр Михайлович катранга өзек-төтек кенә килгәләп йөри, ләкин һәрвакыт теге тел бистәсе—сәясәтче белән бергә була. Ул килгән саен уен җанланып китә, банкка салынган акчалар күкләргә ашардай күперә-күтәрелә, яшел тукыма ябылган өстәл өстендә дәрт-комарлык, куе тәмәке төтененә кушылып, артканнан-арта бара, уенчылар хәтта бай сый-нигъмәтне дә онытталар. Барвихага барырга җыенган саен Аргентинлы үзен бер уйда тота: бүген Александр Михайлович белән Альберт Янович килсә, әйбәт булыр, алар уенга ниндидер бер ямь өстәп торалар, дип уйлый иде. Берсе сүз арасында гына аяктан егарлык берәр яналык әйтеп ташлый, икенчесе, кулында уртача гына кәртләр булуга да карамастан, акчаларын икеләтә тота, бу исә уенчыларны тирләп чыгарга мәҗбүр итә, алар инде үзләренең кәртләрен бик отышлы дип санамый башлый, ә бу хәл еш кына Аргентинлы файдасына була—ул, иң беренчеләрдән булып, Александр Михайловичның уенда үзен шулай гадәттән тыш тотарга, башкаларны шаккатырырга яратуын сизеп алган иде.

Мөгаен, бирегә берәү дә оттырырга дип килми: махсус та, очраклы да мондый хәл кешенең табигатенә яраша алмый, әмма, шул ук вакытта атаклы катранга йөрүчеләрнең байтагы кул-аяклар калтырарлык тойгылар кичерергә тели, банкка салынган зур суммалар һәркемнең йөрәген сикертә башлый—боларын да Аргентинлы күреп тора иде. Ләкин «лендровер» машинасы хуҗасы Александр Михайловичны ул һич тә андый күңелне кытыклый торган үз-үзен яратучы шәхес итеп тоймый, тегенең бөтенләй башка максатлары бар иде шикелле.

Аргентинлының игътибарын «йоклаткан» тагын бер нәрсә шул булды: Александр Михайлович комсыз түгел, монысы аның отканда да, оттырганда да акчага мөнәсәбәтеннән үк күренеп тора иде.

Александр Михайлович катранга политолог белән бергә килеп кергәннән соң, айдан артык вакыт эчендә алар һаман оттыра килделәр, алай артык зурдан булмаса да, уеннары гел сизелерлек минус белән бара иде. «Сизелерлек минус»—уенчыларның гадәттә әйтә торган сүзләре. Ничектер, Аргентинлыда шундый уй да баш калкыткан иде: аларга икәүләп-парлашып та уйнарга була ич, дөрес, һәр икесе дә тигез дәрәҗәдәге уенчылар булырга тиеш, ә бу чекистлар токымы, турысын әйткәндә, йомшаграк уйный шикелле, әллә шунамы, Городецкийның бу уе ничек кабынган булса, шулай сүнеп тә куйган иде. Барысын да җыеп-төйнәп әйткәндә, менә шушы хәлләр Аргентинлының игътибарын Александр Михайлович һәм аның дусты Альберт Яновичтан читкә алып китте дә, ул аларны житди уенчыга санамый башлады, шуның өстенә, катранга очраклы килеп кергән кунаклар да була тора, алары бер кичтә илле-алтмыш меңне оттырып китә, андыйларга бигрәк тә күз-колак

булырга туры килә. Кем сиңа шул оттыручыларның берәрсе үзенең дуслары белән кайтышлый юлында яки ишек төбендә үк үзеңне сагалап тормас дип ышандырып әйтә ала. Заманалар хәзер кабәхәт, күпләр өчен бер генә Алла—акча.

3

Ул шимбә кичендә урамда эчпошыргыч көзге вак яңгыр сибәли, һавадан инде кыш исе килә башлаган, ә Барвихадагы утларын балкытып утырган ялгыз йортта җылы һәм рәхәт иде. Очрашу, алдан сөйләшенеп-килешенеп, көндез телефоннан чылтыратулар белән ныгытылса да, хезмәт хезмәт инде, Барвихага даими йөрүче зур түрәләрнең дә үзләреннән зуррак башлыклары бар, шуңа күрә уенчылар бик көттереп кенә, акрын җыела тордылар. Көндез йорт хуҗабикәсе, мөгаен, эче пошканнандыр, хатын-кызларны җыеп кына бер мәҗлес ясап алган, ул мәҗлес кичкә кадәр сузылган, инде җыелып өлгергән уенчылар һәм эшеннән кайтып кергән катран хуҗасы хатын-кызларны, соңыннан өйләренә машина белән генә кайтарып куярга вәгъдә итеп,—хәер, дамаларның күпчелеге үз машинасында, ә кайберләре хәтта тән сакчылары белән үк килгән иде,—аларны һич кенә дә җибәрергә теләмәде. Кыскасы, йортта җанлылык хөкем сөрә, көлешүләр, музыка тавышлары ишетелеп тора. Камин мичле залда, оранжереядә, кунак бүлмәсендә, рәсемнәр эленгән өй галереясендә—кыскасы, һәркайда табын әзерләнгән, фуршет өчен эчемлекләр куелган, ә кунакларга шәһәрдән чакыртып китерелгән официантлар сүзсез генә хезмәт күрсәтәләр. Йорт хуҗабикәсе үзе Тверской урамындагы иң танылган рәсем сәнгате салоннарының берсен тота иде.

Аргентинлы, бүген, мөгаен, уйнап торулар булмастыр инде, дип исәпләп, хуҗабикә һәм аның ахирәтләре белән бергәләп ике фужер француз шәрабе «Де Кастеллани»ны да эчеп куйды. Кайчандыр Ростов-Донда Тоглар да аны шундый шәраб белән сыйлаган иде. Әмма тиздән хатын-кызлар, ни өчендер, дәррәү кузгалып, кайтып китәргә җыена башлады, ир-атлар исә, җиңел сулап, өске каттагы бильярд бүлмәсенә—гадәтләнгән кәрт өстәле янына күтәрелде. «Хатын-кыз белән кәрт уены бергә сыеша алмый»,—дип куйды телгә үткен Альберт Янович. Күрәсең, хатын-кызларның китүеннән иң канәгать кеше ул иде. Үзенең кырык яшьтә генә булуына да карамастан, бу политолог инде рәсми төстә дүрт мәртәбә өйләнеп караган һәм гүзәл затларга карата бер дә төче-матур сүзләр сөйләнеп тормый иде.

Ул көнне покер уены уйнарга булдылар, әмма һәр билгеле булган уенга, үзара килешеп, вак-төяк үзгәрешләр кертәләр һәм алар уенны кызыклырак итә иделәр. Һәрвакыттагыча җирәбә салып, әле ачылмаган кәрт колодасын ачтылар—һәр уенга яна колода гына ачыла иде. Гүзәл ханымнар калдырып киткән ашкыну-ымсыну хисләре уен өстәле янына да күчте—беренче өләшкәндә, әле шау-шу һәм дәртлелек тынып өлгермәгән иде. Төн урталарында, аларны ашап алырга икенче катка чакырган чагында, Аргентинлы шактый отып өлгергән—отышы йөз меңнән дә ким түгел иде. Хәтта ана, хас булмаган сакчыл бер фикер дә башына килгән иде: тәмләп ашап-эчкәннән соң, әкрен генә кайтып китү ягын карасаң да ярар иде, дип уйлап алган иде ул—әмма бу акыллы уй кабынды да сүнде, юкса, бүген уенчылар гадәттәгедән күбрәк һәм аның китеп баруын сизми дә калыр иделәр. Ашап утырганда, башкалар шактый эчте дә, хатын-кызлар белән нык шампан шәрабе эчкәненә үкенеп утырган Аргентинлы, бик оста әйтелгән яндыргыч-көйдергеч тостлар вакытында, бокалын күтәрсә дә, эчемлеккә телен дә тигезеп карамады. Ул, үз һөнәренең остасы буларак, кәрт уены белән эчемлекләрнең сыеша алмаганын бик яхшы белә иде. Шуның өстенә, Городецкий башларына киткән уенчыларның уенны кыздырганнан-кыздыра башлаячакларын да тоя—аларның әтәчләнә-батырая барулары әле ашап-эчеп утырганда ук сизелә башлаган иде.

Ашап-эчкәннән соң, барысы да авыраеп калды һәм ике сәгатьтән дә артык уйнамаска килештеләр, чөнки төн дә танга таба авышкан иде инде, ә иртәгесен күп кенә уенчылар Кремль Сараена бер билгеле сәяси эшлекленең юбилей кичәсенә чакырылган, ул сәяси эшлекле реформаларны тагын да яна юнәлешкә кертеп җибәрергә җыена икән, дип сөйлиләр иде. Ул тантанада башкаланың барлык «асыл затлары» җыелачак, андый чараларда кайнашып, үзеннең дә шулар арасында булуынны расламый калырга, әлбәттә, беркем дә теләми иде.

Беренче өләшүдә үк уенга салынган акчалар тиз һәм кинәт арта башлады, аларны, табигый ки, оттыручылар күтәрә, шуларның икесе Төмәннән килгән яна кешеләр—аларны Аргентинлы бер ярты еллап элек шушында Барвихада, Шаман йортында күргән иде. Нефть бизнесына катнашлары бар шикелле. Акчаларның шулай бик тиз арта баруына Аргентинлы үзе әле һич өлеш кертмәгән иде, аның йөрәге шатланып тибә башлады: кулындагы кәртләре бик отышлы, андыйларны еш кына төшләрендә күрәсен—каре дип атала ул. Каре исә элек-электән үк, яу вакытында гаскәрнең дүрт почмакланып, дошман кай яктан һөҗүм итсә дә, аның һөҗүмен кире кайтарырга сәләтле булып тезелүе. Үз вакытында бу алымны Александр Суворов һөҗүм иткәндә дә бик уңышлы кулланган. Димәк, Аргентинлы, кай яктан һөҗүм итсәләр дә, отышсыз калмаска тиеш иде.

Хәзер аңа үзенең эчке дулкынлануын тышка чыгармаска гына кирәк—соңгы ике елда ул ашкынып көткән отыш үзеннән-үзе кулына килеп керергә тора лабаса! Ә банкка куелган акчалар аның катнашыннан башка, үсә дә үсә... Хәерле булсын,—әллә күз буу булды, әллә башкасы,—түзмәде, үзе дә өсти башлады бит. Уен банкына—өстәмә салган суммалар күпләр өчен күтәрә алмаслык куркыныч саннарга барып басты, күп кенә тәвәккәлләп тотынган уенчылар, өркеп, төшеп калды. Уенны дүртәү дәвам итте: теге ике нефть бароны белән Александр Михайлович һәм Городецкий гына. Менә шул чагында өстәл тирәсендәге көлешү-шаярышу тынып калды: уен бик җитдигә әйләнде, мондый зур акчалар бу катранда әле беренче генә уйнала иде. Киеренкелек шул кадәргә килеп җитте ки, төмәнлеләрнең берсе түзмәде, су эчә торган зур бокалга виски салып бирүләрен үтенде—эчемлек һәм кабымлыклар тезелгән кечкенә өстәл һәрвакыт уенчылар янында тора иде. Әмма ләкин бер стакан каты виски да төмәнлегә ярдәм итмәде, алар, бер-берсенә карашып алдылар да, кәртләрен ачып, уеннан төшеп калды, шунда Аргентинлы аларның икесе бер кесәгә уйнап маташканнарын аңлап алды. Ләкин боларның хәзер бер мәгънәсе дә юк, Александр Михайлович белән Городецкий күзгә-күз генә калган иде. Шул чакта Аргентинлы эченнән генә калтыранып алды: ул бары бер очракта гына, анда да теоретик кына, әгәр дә кәртләрне көндәше яки аның кулдашы өләшкәндә генә оттырырга мөмкин иде. Ләкин, бәхетенә, тәнәфестән соң кәртләрне Александр Михайлович үзе өләшмәде, кичкелекне ашап-эчеп бераз кәефләнгән политолог—Альберт Янович, хуҗабикә белән аның рәсем-картиналары турында шактый әңгәмәләшеп килеп кергәч кенә, өләшкән иде. Ә хәзер, әнә, катып калган кыяфәт белән уенны күзәтеп, Александр Михайлович артында басып тора. Димәк, Аргентинлы үз кулындагы оттырышсыз кәртләре белән теләсә ничек тәвәккәлли ала, хәтта гомерен дә уенга сала ала иде. Мондый уенда мондый бәхет бер генә килергә мөмкин. Александр Михайлович үзенең күн саквояжыннан берничә төргәк долларын чыгарып, өстәлгә ташлар алдыннан тыныч кына әйтеп куйды, чөнки банкка акча салырга аның чираты җиткән иде:

—Банктагы акчаларны соңгы мәртәбә күтәрергә тәкъдим итәм, бер-беребезне талап бетермик инде. Сез ризамы?—диде.

Аргентинлының артык дулкынланудан иреннәре кибеп ябышкан иде, ул «риза» дип әйтергә теләде, әмма башын гына кагып куйды—чөнки аның кесәсендә салырлык артык акчалары юк иде инде.

Александр Михайлович төргәк-төргәк акчаларын илтифатсыз гына банкка ыргытты да:

—Сезнең чират...—диде.

Аргентинлы алдында яткан акчаларны әкрен генә этеп, өстәп әйтте:

—Калганына үземнең Кутузовкадагы квартирамны салам, ул бар йорт җиһазлары белән бер миллион бакстан да ким тормый, ярыйммы шулай?—диде.

Уен кагыйдәсе буенча, көндәшенең киреләнергә хакы юк—квартира да бәя тора, ә Аргентинлыга исә нибары акчалата дүрт йөз мең доллар гына өстәргә кирәк иде.

Өстәл тирәсендә үле тынлык хөкем сөрә, бераз уйланып утырганнан соң, Александр Михайлович Аргентинлының тәкъдименә риза булды. Һәм алар, берсе артыннан берсе кәртләрен ача башлады. Бер үк вакытта шатлык һәм үкенү тавышлары төнге йортны күтәрердәй булып яңгырады. Халык арасында һәр икесе өчен дә җан атучылар бар, әмма күпчелек Аргентинлы ягында иде шикелле. Соңгы кәртен ачып салганчы ук Городецкий үзенең оттырганын аңлады: Александр Михайловичка бары тик теоретик булырга мөмкинлек биргән кәртләр кергән иде—аныкы да каре, әмма ләкин зуррак каре... Әйтик, синдә дүрт дама, ә анарда дүрт туз кебегрәк...

Аргентинлы, аңын җуйган боксчы шикелле, аңгы-миңге генә урыныннан күтәрелде, бер сүз дә әйтмичә, беркемне дә күрмичә һәм саубуллашмыйча, бильярд бүлмәсеннән чыгып китте—аның әле үз гомерендә болай оттырганы юк һәм ул моңа ни рухи, ни физик яктан әзер түгел иде. Борма-борма ясалган мәрмәр баскычтан төшеп, ишегалдына чыккач, Городецкий гомерендә беренче мәртәбә үзенең картайганлыгын ныклап сизде. Ул бөкрәеп калды, күз алдында уен өстәле тормый, гадәттәгечә, ул булып үткән уен турында да уйламый, аны тикшерми—аның бар уе Кутузов проспектындагы үз йорты турында гына иде. Ул бит аны бик ярата, аның белән бик горурлана иде. Ишегалдында да ул, каравылчылар белән саубуллашып та тормыйча, үзенең «Жигули»енә утырып катраннан чыгып китте. Ә бит ул бу катранны үзе өчен иң бәхетлесе дип, кайчан да булса бер шунда оҗмах кошын тотармын дип йөргән иде. Тотты менә сиңа!

Барвихада президент та яшәгәнлектән, Рублев шоссесы хөкүмәт карамагындагы юл булып санала һәм бу сәгатьләрдә буш, әмма, начар яктыртылган булып чыкты—әллә юл төзәтеп маташалар, әллә, башка юллардагы шикелле, экономия режимына күчкәннәр инде.

Аргентинлының тизрәк өенә кайтып житәсе, душта юынып, тирән йокыга таласы килә, ә инде иртәгә, үзенең мөшкел хәлен уйлап, алга таба ни-нәрсәләр эшләргә икәнен карар кыласы калган иде. Әлегә ул үз-үзен аңышмый, башы да юньләп эшләми, рестораннан шәпләп салып чыккан тәвәккәлләр кебек, машинасын «автопилотка» куйды да, газга басуын гына белде. Шактый озынга сузылып күтәрелеп килгән юлның бер урынында көтелмәгән борылыш бар—чөнки ул борылыш юл читенә үк килеп терәлгән урман артында ук иде—ләкин бүген, юл буш булганлыктан, Городецкий аңа игътибар итеп тә тормады. Бу юлны ул яхшы белә, һәрхәлдә атнасына ике тапкыр, ничәмә-ничә айлар буе, шушы юлдан Барвихага килеп йөри, элек тә Шаманга килеп чыккалый торган иде, әмма бүген бөтенләй башка хәл, бу хәлдә аңа, машинасына утырып, руль тотарга да кирәкмәс иде юкса. Аргентинлы теге борылышны үтеп киткәнгә санап, онытылып, зур тизлек белән шуңа барып керде дә, юл буендагы саклагыч киртәләрне җимереп, караңгы урман авызына барып төртелде. Болар барысы да шулкадәр тиз, әйтерсең, яшен тизлегендә булды ки, ул хәтта бернәрсә дә аңларга да, куркырга да өлгерә алмый калды.

Әллә баш мие селкенгән иде инде, бер ярты сәгатьләп ул һушына килә алмый утырды. Аңына килгәч, үзенең могҗиза белән генә исән калганлыгын төшенде—бер генә сыдырылган-канаган җире дә күренми,

бер сынган сөяге дә юк иде. Ул иң әүвәл Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләрен әйтте, җимерелгән машинасыннан саклык белән генә чыга алды. Барвихага йөрергә дип, махсус сатып алган яна «Жигули»ен илтифатсыз гына карап чыккан булды, машинаның ремонтлап-төзәтеп торырлык рәте калмаган—бигрәк тә хәзер, бар булганын оттырып, бетергәч, моның бернинди дә мәгънәсе юк иде. «Димәк, әҗәлемә вакыт җитмәгән икән әле»,—дип, хорафатланыбрак уйлап алды Городецкий, ләкин шунда ук, үзенең бар мөлкәтен оттырганлыгы электр тогы кебек китереп сукты да, әлеге бер мизгеллек куанычын юып ташлады. «Әгәр үлгән булсам, квартира мәсьәләсе үзеннән-үзе хәл ителгән булыр иде. Братва беркайчан да Александр Михайловичка аның тол калган хатынынннан ул квартираны тартып алырга бирмәс, аңа: «Шул кичтә отканың да бик җиткән сиңа»,—диярләр иде. Ә бәлки, күмү-җирләү чыгымнарын да аның өстендә калдырган булыр иделәр.

Машинасының шулай барып бәрелүе аны айнытып җибәрде, ул үзен кулга алып, эченнән генә уйлап куйды: «Инде исән калгансың икән, яшәргә, нәрсәдер булса эшләргә, үз йортыңны саклап калырга кирәк... Аңа бигрәк тә «үз йортыңны саклап калырга» дигән фикере ошады. Әйе, саклап-яклап калырлыгы бар иде шул бу йортның.

## 4

Городецкий үз бүлмәсеннән, бары төннәрендә генә чыгып йөреп, өч көн ятты, ләкин бер фикергә дә килә алмады. Хатыны телефоннан сөйләшү-шылтыратуларны аңа җиткереп тора иде, шуларга карап та әйтергә була: аның бу зур оттырышын бик күпләр белә иде инде. Дүртенче көнендә, «Гербалайфтан» башка да бик ныклап ябыгып булганын белеп, үзе бер унбиш килограммын ташлаганнан соң, Городецкий, өеннән чыгып, туп-туры Олег Лазовскийга—Дантеска юл тотты. Анардан, йортын саклап калыр өчен, әҗәткә ике йөз мең доллар бирең торуын үтенде, Дантес анарда бер генә булмаган һәм квартирасының менә дигән икәнен дә белә иде. Дантес, үзенең дә эшләре бик шәптән бармаганын әйтеп, иң күп дигәндә, бер илле мең доллар биреп тора алачагын әйтте. Соңыннан, кемгә оттырганын да сорарга онытмады, аннары көлемсерәп әйтеп куйды:

—Шуның кадәр байлыгыңны салганчы, ул мокытны юк итүең арзангарак төшмәсме соң? Ун мең бакска хәзер теләсә кайсы киллер (ялланып үтерүче) йөгереп килеп җитәчәк, әле ниндиләре, диген—менә дигәннәре!

Аргентинлы ярдәм кулы сузган өчен Дантеска рәхмәтләрен әйтте, әмма үзен откан кешене үтерүгә кадәр барып җитүне килештермәде:

—Алайга калса, мине откан саен үтерә башласалар, бер мең мәртәбә үтергән булыр иделәр, ә мин, күреп торасың, һаман да исән әле...—диде.

Ул көнне Аргентинлы ярдәмнәренә исәп тотарлык тагын бишалты кешене йөреп чыкты, ләкин йөз егерме мең бакстан да артыкны җыя алмады, әле аларын да берәр ун көн көтеп аласы бар иде. Кәефе китеп, усалланып һәм ачыгып өенә кайтып килгәндә, ул, ниһаять, Тогларны исенә төшерде: менә ул, ичмасам, бу бәладән коткарачак та коткарачак иде! Хәер, Аргентинлы анардан да әлләни зур суммалар көтми, Фешинның соңгы бер ел эчендә күпме акча түккәнен үзе күреп торды бит—әмма шулай да, шулай да... Иң ахыр чиктә, Тоглар аңа берәр файдалы киңәш бирә алыр—кыскасы, Аргентинлы үзенең Мәскәүдә генә йөри торган «сааб» машинасын Фешин өенә таба борды.

Тоглар өйдә булып чыкты, әмма аны мондый бөкерәеп калган, кырынмаган, дөресен әйткәндә, гел бабайга әйләнеп калган хәлендә Городецкийның әле беркайчан да күргәне юк иде. Шуңа күрә ул, үз кайгы-хәсрәтләрен онытып, бусагадан атлап керә-керешкә үк хәвефләнеп сорады:

—Әллә бер-бер хәл булдымы? Бөтенләй төсең киткән бит! Икенче

атна инде, шылтыратканың да юк, менә, кереп, хәленне белеп чыгыйм дигән идем...

Тоглар, аңа җавап та биреп тормыйча, түргә—аш бүлмәсенә таба атлады, бары тик шунда гына аңа таба урындыкны этәреп, хәлсез генә итеп утырырга тәкъдим итте. Аргентинлы, аңа бер карап алудан ук бик зур бәла булганын абайлап алды, өстәл өстендә эчемлекләрдән бушаган шешәләрдән Константин Николаевичның инде шактый көннәр эчеп ятканын төшенде. Фешин бервакытта да эчеп-исереп йөрүчеләрдән түгел, тоташ бертуктаусыз эчүгә сабышулары аның булмый да иде. Дөресен генә әйткәндә, тыныч-акыллы Тогларны нәрсә дә булса чыгырыннан чыгаруын уйга да китереп булмый иде. Ул соңгы айларында бик бәхетле иде бит—ниһаять, үз теләгәненә ирешеп, йортлы-гаиләле булды, үзен рәсем сәнгатенә багышлап кына яши башлаган иде. Квартирасының ташландык бер хәлгә килүенә караганда, бөтен бәлаләрнең башы Натальяда булса иде кирәк. Аргентинлы аңлаганча һәм французлар әйтмешли, шерше ля фам—хатын-кызны эзләгез. Һәм Городецкий, Тоглар үзенә сузган мөлдерәмә аракылы стаканны кулына алды—югыйсә машинасы көтеп тора һәм һич кенә дә эчәргә исәбе юк иде,—йомшаграк итеп сорарга тырышты:

—Әллә Наталья белән берәр хәл килеп чыктымы?—диде.

—Әйдә, туган, башта эчеп куйыйк әле, шуннан соң мин сиңа барысын да сөйләп бирермен... Ничә көн инде эчем яна... Беркемгә дә... Беркемгә дә сөйләп булмый...—диде Тоглар.

Алар стаканнарның төбенә кадәр эчеп бетереп куйдылар да сүзсез-нисез генә нәрсәдер чәйнәргә тотындылар. Тоглар, караңгыланып килгән тәрәзә ягына карап, бик озакка тынып калды, ләкин Аргентинлы аңарга сүз кушарга базмады: бүген ул иске дустының халәтен һичбер вакыттагычадан да яхшырак аңлый иде. Күз карашын, ниһаять, тәрәзәдән алып, Константин Николаевич кинәт кенә Аргентинлыга таба борылды һәм, әйтерсең лә аны сүзеннән бүлдерерләр шикелле итеп, ашыга-ашыга үкенечле-ачынулы тавыш белән сөйли башлады:

—Ә мин бит аны ярата идем, Аркаша. Гомерем буе күңелемә беркемне дә кертмәдем, хатын-кызларга ышанып яшәмәдем... Менә, күңелемне ачып, аңа ышанган идем... бернәрсәмне дә кызганмыйча, төбенә кадәр ачып салдым. Нигә соң шулай итте ул? Мин бит братваның төп законын белә идем,—дип, ул йодрыгы белән өстәлгә шундый итеп китереп сукты ки, стаканнар сикерешеп куйды.—Безнең эше кешеләр гаилә кормаска тиешлеген дә белә идем... Соң бит, төрмә ятагына иң беренче эләккән һәр егеткә шуны тукыйлар: хатын-кыз—җәһәннәм кисәве! Җир йөзендәге барлык явызлык-әшәкелекләр, ирләргә иң күңелсезлекләр алардан килә, дип тукып торалар лабаса! Бәлки, бу миңа Аллаһы Тәгаләнең бер каргышыдыр? Картаеп барган көннәремдә, шул кагыйдәләрне онытып, калган гомеремне гади кешеләрчә яшәргә теләвемә бер афәт булып килүедер, ә?

—Костя, нәрсә булды соң? Озынга сузма,—дип, Аргентинлы үз стаканын шешәгә таба этеп куйды. Ул бүген ныклап эчкәндә генә Тогларның акылдан язмый калу мөмкинлеген чамалап алган иде, үз хәле дә шул тирәдәрәк иде бит.

Алар, тутырып салып, тагын сүзсез генә эчеп куйдылар.

—Син беләсеңме,—диде Тоглар, ниһаять,—ул миннән качып китте бит... Качып китте... Иң әшәке ана эттәй качты... Ул... миннән...—Тоглар, авызын ямшәйтеп, ямьсез итеп көлемсерәргә тырышты.—Син аңлата аласыңмы-юкмы, аңа биредә нәрсә җитешмәгән иде?—Ул тагын күзләре белән квартирасын күздән кичереп чыккандай итте.

—Син шуның өчен генә кайгырасыңмы?.. Үзеңне бетереп, эчүгә сабыштыңмы? Миндә синең кайгыларың булса икән...—дип авыр сулап куйды Аргентинлы һәм үзенең бар байлыгын—квартирасын-ниен дә оттырып бетергәнлеген чак кына әйтеп ташламады, соңгы мизгелдә аны нәрсәдер тыеп калды шикелле.

—Юк, Аркадий, син хаклы түгел,—дип, Тоглар анын борын төбендә бармагын уйнатып алды.—Эш анарда гына да түгел... Мин бөтен тормышымны җимердем—мин бит гаилә корып, балаларым булып, тыныч-имин яшәрмен дип өметләнгән идем. Бу йортны да анын өчен генә сатып алдым, шушы хәлгә китергән идем. Син бит ир-ат өчен йорт-гаиләнең ничек кирәклеген яхшы беләсең.

—Шулай булса да,—дип ризасызлык белдереп маташты Аргентинлы,—син исән-сау, йортың үз урынында, бер рәтләнерсен әле. Ә мондый квартирага хуҗабикә табылмас, дип уйлыйсыңмы? Натальядан яхшыраклары да булыр, ышан мина...—ул күнелле-күтәренке итеп сөйләргә тырышты, әмма ләкин әйтергә теләгәне барыбер үз дигәнчә барып чыкмады шикелле.

—Әмма мин сиңа барысын да әйтеп бетермәдем әле...—диде Тоглар, урындыгында сыгылып төшеп, ул бу көннәрдә бер егерме яшькә картайган кеше кыяфәтендә иде.—Ул бит мине талап чыгып киткән... Акчамның тиенен дә калдырмаган... Хәтта туйда мина братва бүләк иткән агалтын һәм алтын сәгатьләрнең бишесенең берсен дә калдырмаган. Ничек итеп, шушы хәлләрдән соң яшәргә мөмкин мина?.. Эш акчада да түгел, кабәхәтлегендә бит... Син бит белеп-күреп торасың, бу квартира анын өчен генә алынган һәм эшләнгән иде...

—Этнең дә эте икән, кәнтәй!—дип чыгырыннан чыкты Аргентинлы. Мондый хәлләрнең булуын кем дә башына кертеп карамас иде, валлаһи! Хәзер Тогларның әчеп, өметсезлеккә төшеп ятуын Аргентинлы бик яхшы аңлый, үзенең дә бит хәле шундый, рәнҗү һәм гаҗизлектән бүре булып улар чагы иде, шулай да ул, үзе дә белештермәстән:

—Күпме урлап киткән инде ул кәнтәй?—дип сорамый булдыра алмады.

—Сорап та торма, Аркадий... Бик күп, соңгы тиенемә кадәр. Мин инде аңа бүләккә алып биргән бриллиантларымның-фәләннәремнең ничә миллион бакска төшкәнлеген әйтеп тә тормыйм. Юк бит, чукынмыш, соңгы тиенемә кадәр җыеп алган. Ул акчалар бит тыныч картлык көнемә дип калдырылган иде.—Тоглар, күлмәген аерып төшерде, әйтерсең лә, күлмәк аны буып тора иде. Күзенә кайгы-хәсрәт һәм үкенү яшьләре бәреп чыкты.

—Син соң, бер ахмак мокыт-ангыра шикелле, ул акчаларыңны ул күрерлек урында тоткан идеңмени?—дип гаҗәпләнде Городецкий.—Күзгә күренгән акча теләсә кемне акылдан яздырырга мөмкин иң.

—Юк ла! Бөтен хикмәт тә шунда, акчаларым үз остаханәмдә махсус ясаткан яшерен урында иде. Табарсыңмы-юкмы, тапсаң да, акча икәнен тиз генә төшенеп алмаслык иде... Ә ул маржа тапкан, аңлап алган...

—И-и-и, әшәкенең әшәкесе булган икән! Кулыма эләксә, аяк-кулларын үзем тартып өзәр идем!—дип, кайнарланып маташты Аргентинлы.

Ул Тогларны шундый бер бик түбән марҗаның алдап чыгып качуына да һәм үзе өчен дә бик рәнҗегән-нәфрәтләнгән иде: хәзер Тоглардан ярдәм көтәргә дә мөмкинлек калмаган иде бит.

Ул кичтә Аргентинлы иске дустын шул кайгы-хәсрәтендә ялгыз калдырып китә алмады, аңарда йоклап калды, чөнки анын үзенә дә бик көчле бер йомшап-ычкынып алу кирәк иде, ә Россиядә монын өчен аракыдан да яхшы дәва таба алган кешеләр юк иде әле.

Күп эчтеләр, каһәр суккан хатын-кызларны эттән алып эткә салып тиргәделәр, тормыш, мәхәббәт турында сөйләнделәр, ләкин шунысы бар—Городецкий, ничек кенә исерек булмасын, үз кайгы-хәсрәте турында авыз ачып бер сүз дә әйтмәде—иң әүвәл Тогларны бу рухи төшенкелеге-өметсезлегеннән тартып чыгарырга кирәк иде.

## 5

Тогларда дулап-әчеп үткәргән өч көненнән сон, иртән иртүк Городецкий квартирасында телефон чылтырады. Александр Михайлович икән. Ул Аргентинлыга «Украина» кунакханәсенә килеп, бурыч мәсьәләсен шунда хәл итәргә тәкъдим ясады. Городецкий «Украина»дан әллә ни ерак тормый, троллейбуста нибары ике-өч тукталыш кына барасы—бер сәгатьтән очрашырга килештеләр.

Городецкийны Александр Михайловичның кунакханәдә яшәве сагайтты, ул бит аны Мәскәү кешеседер дип ышанып йөри иде. Болай булуы, бер яктан караганда, аның хәлен жинеләйтер дә әле: бәлки, Александр Михайловичка ничектер йогынты ясап булыр, ни әйтсән дә, Аргентинлы билгеле, абруйлы кеше бит, икенче яктан караганда—токымсыз ат, аңардан нәрсә көтәргә дә белмәссең, кемнәр белән дустыр бит әле ул—анысы да бар. Шуңа күрә Городецкий очрашуга җәяү генә барырга булды, үзенең «сааб» машинасы барлыгын белгертәсе килмәде: машинасыз син аяксыз калдың дип шаяртырга ярата аның ассистенты Эйнштейн. Элек комарлы кәрт уеннары тыелган заманнарда, Аргентинлы «Украина» кунакханәсендә еш кына уйнаштыргалый, кунакханәне яхшы белә, хәтта Александр Михайлович әйткән алтынчы каттагы люкста да еш булгалады—анда, үзе Германиягә китеп барганчы, Алик Тайванлы яшәргә ярата иде.

Александр Михайлович бүлмәсендә ялгызы гына булып чыкты, Аргентинлы, әлбәттә, монысын көтмәгән иде. Сүзне шуннанрак башлап җибәрергә ниятләп килсә дә, бу номерда булгалаганын искәртеп тормады... Люкс хуҗасы аны ачык йөз белән каршы алды, әйтерсең лә, аларның һәр икесен дә бик авыр сөйләшү көтеп тормый иде, хуҗа аны кәнәфигә утырырга чакырды, кәнәфи янында табын корылган, кабымлыклар һәм эчемлекләр утыра иде инде.

—Нәрсә эчәбез—вискимы, коньякмы?—дип сорады Александр Михайлович, Аргентинлы янәшәсенә утырып. Бүген эчәргә нияте булмаса да, баш тарту да килешми иде, Аргентинлы:

—Мөгаен, аракыдыр,—диде.

Икесе дә бик киеренке хәл кичерә иде, вакыйганы тагын да тирәнәйтергә теләмичә, Александр Михайлович үзе сүз башлады:

—Мин сезне яхшы белгән кешеләрдән сораштым... Һәрберсе сезнең квартирагызның миллион гына торырлыгы барын бик мактап сөйләде. Билгеле, кулымда сезнекеләрдән зур каре булгач, мин бәяне тагын да күтәрә ала идем. Үткән эшкә салават, диләрме әле? Әгәр дә сез квартирагыздан аерылырга теләсәгез, мин акча урынына алырга әзер. Районы абруйлы, йортлары да бер дигән...

—Квартира турында сүз йөртергә иртәрәк булыр әле,—дип аны кырыс кына бүлдерде Аргентинлы.—Дүрт йөз мең бакс житди акча, билгеле, әмма минем мөмкинлекләрем һәм дусларым булганда, күтәрмәслек тә түгел. Уен кагыйдәләре буенча, мин сезнең түләүне чигереп торуыгызны телим. Шул арада мин янадан отармын, яки әҗәткә алып түләрмен. Әгәр дә инде түли алмасам, янадан бу сөйләшүгә кайтырбыз. Шулай гадел булыр дип уйлыйм... Яки мин хаклы түгелме?

—Ярар, сезненчә булсын,—диде хуҗа кеше, бәхәсләшеп тору мәгънәсез булыр иде.—Сез, Аргентинлы, танылган, абруйлы кеше, шулай булгач, сез бер айга бурычыгызны чигереп тора аласыз. Мин уеннан да баш тартмыйм, әмма сез үзегез Барвихага килеп йөрми башладыгыз.—Сөйләшүне беткәнгә санап, Александр Михайлович урыныннан күтәрелде.

Шул мизгелдә Городецкий аның бераз көлемсерәп кенә торган акыллы күзләрен күреп алды—мондый караш бик мөстәкыйль-бәйсез, тәэсирле, үз көченә бик нык ышанган кешедә генә була ала. Боларның берсе дә, Аргентинлы белгән үз-үзләреннән канәгать, әмма куркак түрәләргә туры килми иде. Менә шунда, Тайванлының элекке номерында Аргентинлы Александр Михайловичның теге дәүләт хезмәткәрләре өеренә,

хәтта бик югары посттагыларына да катнашы юклыгын аңлап алды, юк, бу адәм хәтта зур бизнесменга да охшамаган—бу бик югарыдан оча торган кош, юкка гына чекистлар белән аралашып йөрмәс иде. Нинди кош һәм бик биек очамы, әгәр жай туры килсә, моны, әлбәттә, ачыкларга кирәк, әмма аны томана-мокыт, лохка санап йөрергә дә һич ярамас, юкса үзеңне тагын бер кат бик каты очыртырга мөмкиннәр.

«Украина» кунакханәсеннән чыккач, Аргентинлы үзенең календарлы кул сәгатенә күз төшереп алды, бу сәгатьне дә ул Мәскәүгә килеп чыккан бер пижоннан откан иде—Аргентинлы карамагында нәкъ өч атна вакыты калган икән. Александр Михайлович, әлбәттә, кәрт уены кагыйдәләрен бик әйбәт белә: исәп оттырган көннән үк башланып, беренче чигереп тору нәкъ бер ай була. Аргентинлының бер атнасы жан газаплары, икеләнү-шикләнүләр белән үтеп тә киткән инде, әнә. Хәзер нәрсәдер эшләргә кирәк иде бит, квартирасын бирү турында сүз дә булырга мөмкин түгел.

Аргентинлы, Барвихага барып, янадан отып булмасмы дип, бик тырыша-тырыша акча эзли башлады—катранга зур акчасыз барып керү һич мөмкин түгел, бигрәк тә аның кебек зур сумма оттырган кешегә. Ул үзенә тук йөзле уенчыларның мыскыллап караячакларын да аңлый, түзәргә туры киләчәк: андый акчалар салып уйный торган катран барын да белми иде ул. Ләкин алдагы бер атна эчендә ана Дантес кына бер илле мең биреп торды: үзенең дә саеккан чагы икән, башкалар, бер атнадан, ун көннән, дип вәгъдә итүдән ары узмадылар, тагын ярты айдан Александр Михайлович билгеләгән вакыт бетә. Ә илле мең белән Барвихага барып керү көлке генә булыр иде. Шунда Аргентинлы беренче тапкыр үзенең акылсызлыгына үкенеп куйды—ана комсызланмаска, Барвихага Эйнштейнны алып барырга, ана күнегә төшкәч, бүген акча тапса, парлашып ике кулдан уйнар иделәр. Алар икәүләп бик сирәк уйный, акча бик кирәк булган гадәттән тыш хәлләрдә генә. Бу очракта отыш йөз процент ышанычлы була иде. Алар бер хәйлә-шулерлык та кылмый, үз кулларында нинди кәртләр булганлыгын белә һәм шуннан чыгып уйный да иделәр. Моңа алар ничәмә-ничә айлар бик озак күнегүләр белән ирештеләр, аннары икесендә дә махсус сиземләү һәм акыл да житәрлек булды.

Беренче ике атна үтеп тә китте, ә жыелган акча бик аз иде әле. Инде хәзер тиешле сумманы жыеп бетерерлек вакыт калмады. Аргентинлы бик нык кайгырды, ябыкты, Тоглар шикеллерәк булып кына калды. Аңа берәр бай мокыт-лох белән уйнау да файда китермәде, бер-ике йөз мең откаласа да, үз кешеләре белән бүлешергә кирәк була иде.

Бу көннәрдә акча эзләп йөргәндә, Аргентинлы юк-юк та Дантесның киңәшен искә төшереп ала—аңысы бу мәсьәләне киллер яллап кына хәл итә алырсың, дип котыртып тора, ләкин Аргентинлы бу фикерне куарга тырыша, ни дисәң дә, ул кәрт уенчысы, ә «юеш эшкә»—кеше үтерүгә бармаячак. Әле бит шунысы да бар, ул киллер белән булган хәл кайчан да булса бер тишелеп чыкса, кәрт уйнауларыңны онытырга туры киләчәк, кем инде үтерү оештырган кеше белән бер өстәл янында утырсын, ди?

Билгеләнгән вакыт килеп житәргә дүрт көн калгач, Аргентинлы бөтенләй коелып төште, яңадан үз бүлмәсенә кереп бикләнде, үз-үзенә кул салу турында уйлана башлады—бары тик шул очракта гына ул гаиләсенә квартирасын саклап кала ала иде. Ул хәтта, Александр Михайловичны юк гаепләрендә дә гаепләп үлем алды хаты да яза башлаган иде. Яңәсе, аның оттырышын теге бик жентекләп әзерләнгән һәм, шулай янап, Аргентинлыны почмакка китереп кыскан. Мондый кәгазь кисәге братва-корешлар кулына барып эләксә, гаиләсен тынычта калдырыр иделәр, Россиянең жинаятьчел дөньясында теге дөньяга китеп баручыга изге итеп карыйлар, юкка гына үлгән кеше турында яки яхшы итеп кенә сөйлә, яки бөтенләй сөйләнмә, димиләр бит. Кыскасы, Городецкий барысын да әйбәтләп уйлап бетергән, әмма аның асылынып та, атылып та, агу эчеп тә үләсе килми иде шул. Үзен-үзе үтерердәй бик күп

алымнарны уйлап-исәпләп карады, әмма берсе дә куанырлык түгел иде...

Тагын ике көн газапланганнан соң, ул үлем турындагы уй-фикерләрен бөтенләй кире какты. Рублев шоссесында күптән түгел булган бәрелешне исенә төшерде, анда да үлем котылгысыз кебек күренгән иде. Хәтта күпне күргән ГАИ хезмәткәрләре дә: «Ну туган, ефәк күлмәктән тугансын икән. Димәк, әле синең бу җирдә яшәвең илаһи көчләрнең үзенә кирәк»...—диделәр. Үзенең йөрәксезлеген, тормыштан лаеклы китәрдәй ихтыяр көче юклыгын да ул әнә шул югары мистикага китереп тераде—аны ниндидер югарыдагы илаһи көч тотып тора, аның яшәвен тели, янәсе... Бу фикер аңа яна көч өстәгәндәй булды, үзенең куркак-йөрәксез булуын ул хәтта фәлсәфи нигезләп тә куйды: «Мин яшәргә тиеш икән, димәк, кемдер үләргә дә тиеш».

Инде хәзер, шушы фикере өлгереп җиткәч, яңадан Дантесны исенә төшерде... Аның кинәше хәзер алай тупас кабәхәтлек булып түгел, киресенчә, бик акыллы шикелле тоелды. Городецкийның бу фикере тәмам тулышып килгәндә, инде караңгы төшкән иде, үзенең нибары ике генә көн вакыты калганлыгы аны ашыгырга, эшкә кичекмәстән тотынырга мәҗбүр итә иде. Аның акчасы Дантес әйткән суммага гына җитәрлек, хәер, ашыгычлык өчен бәясен дә күтәрергә бик мөмкин, мондый хәвефле-куркыныч эштә кысмыр булып тору ярамас, үзенә кыйммәткәрәк төшмәгәе.

Аргентинлы һәйбәтләп кырынды, өстенә ак смокинг костюмын киеп алды да юлга чыкты. Бер сәгать дигәндә ул «Пекин»да иде инде.

## 6

Кытай ресторанында һәрвакыт үзенә кирәкле кешене очратырга була, ләкин Аргентинлының анда Хавтанны эзләп табасы килә иде, иске гвардия абруйлыларны хөрмәт итә, Аргентинлы исә аның өчен Мәскәүдә соңгы кешеләрдән саналмый иде. «Пекин»да Городецкийның байтактан, Тоглар белән Натальяның туеннан соң бер дә булганы юк иде әле.

Ул Хавтанны «Пекин»да очрата алмады, таныш-белешләр шактый күренә иде күренүен. Сапер кушаматлы Вася Головачев, Городецкийның Хавтанны эзләп йөрүен белгәч, үзенең әле генә «Золотой петушок»тан килүен, әгәр хәзер үк Аргентинлы шунда элдерсә, хуҗасын үз ресторанында тотып алачагын әйтте.

«Золотой петушок»та да, Городецкийны кертеп җибәргән швейцар әйтмешли, «капчык шыплап тутырылган» булып чыкты. Залда ул Хавтанны офицерлардан сорашып тормыйча да бик җиңел табып алды—тегесе камуфляж форма кигән ниндидер зур гына гәүдәле кеше белән утыра иде. Швед эчемлеге «Абсолют»тан бушаган ике буш штофка караганда, шактый утыралар булса кирәк, табыннары да бик бай күренә иде. «Мөгаен, Хавтан камуфляжлы теләсә кем белән озак утырмас»,—дип уйлап, Аргентинлы хуҗа аны күреп алырлык урынга барып утырды.

Чынлап та, шулай булып чыкты, бер биш минуттан Хавтан, үзенең ресторан хуҗасы икәнлеген онытмыйча, залның аргы башындагы ниндидер шау-шуга башын күтәреп карады һәм Аргентинлыны да күреп алды. Күрде дә, гаҗәпләнеп тә куйды: Аргентинлы «Золотой петушок»ка алай артык илтифат күрсәтүчеләрдән түгел иде. Аргентинлы үзе генә килгән, буш өстәл янында утыра, кәеф-сафа корырга җыенмый, димәк, ниндидер җитди эш белән килгән ул. Городецкий вак кеше түгел, вак-төяк йомышы гына булса, үзенең «алтылыгын»—Эйнштейнны гына җибәргән булыр иде. «Димәк, көтеп торып булмаслык җитди эш белән бу»,—дип нәтиҗә ясады Хавтан.

Хавтан якында торган официантка ым какты, бу—«мине йолкып алып кит әле» дигәнне аңлата иде, тегесе, хуҗасы янына килеп, аның колагына нәрсәдер пышылдаган булды.

—Йә, Гера, без синен белән бик матур күнелле сөйләшеп утырдык, ә мине хәзер быргы чакыра, эшләр көтә,—диде Хавтан, очрашу тәмамланганны аңлатып.—Ләкин син башыңны бик катырма әле, тормышыңн бер җайга салыныр. Мин сине эшсез һәм бер сынык икмәксез калдырмам, син бит үзебезнең Люберцыныкы, ә мин яхшылыкны онытмыйм. Ләкин син артык күп эчмә, элек сиңа сокланып йөргән минем халдей егетләр, хәзер син бер штофтан соң ук исерә башлыйсың, дип сөйлиләр. Ә синең кулың нык, күзең төз булырга тиеш.—Хавтан урыныннан җинел генә күтәрелде дә, тиз-тиз атлап үз кабинетына юнәлде, хәтта Аргентинлыга күз дә салып алмады ичмасам.

Хавтан өстәле өстендәге кайбер әйберләрне дә алып куярга өлгермәде, ишекне каерып ачып, бусагада Аргентинлы күренде, ул елмаерга итенгәндәй кыланса да, елмаюы көчәнүле генә булды.

—Сәлам, Леня, сине күптән күргән юк.—Аргентинлы каршысына чыгып килгән Хавтанга кулларын сузып алга атлады.

—Әйе, байтактан күрешкән юк шул. Соңгы мәртәбә Тогларның туенда шактый «төянеп» чыккан идек бугай,—дип җавап бирде Леонид Андреевич, алар кочаклашып күрешеп алдылар.

—Әйе, балаларыбыз туенда яки мәет җирләгәндә генә күрешә башладык,—дип күнелсез генә әйтеп куйды Аргентинлы һәм хуҗа тәкъдим иткән кәнәфигә барып утырды.

—Бәлки, ашап-эчеп алырсың? Кичке ашка да кала аласың... Петрович иске корешы өчен тырышмый калмас, ул бит сине күптәннән белә.

—Рәхмәт. Дөресен әйткәндә, бүген кәефләнеп утырыр чагым түгел әле. Ә синдәге аш-су турында күптән ишетеп беләм, менә өстемнән бер йөкне алып ташласам, бөтен дусларны җыеп, синдә бер утырырбыз әле.

—Нинди авыр хәлләргә тарыдың? Безнең көчтән килерлек булса, Аркадий, һәрвакыт ярдәм итәрбез, Аргентинлыга да булышмасаң, кемгә булышасың, ди аннары...

—Менә-менә...—Городецкийның күзләре тоныкланды, ул гасабиланып җилкәләрен сикертеп куйды.—Каптым мин, Леня, бик нык килеп каптым. Сәгатем санаулы, иртәгә соңгы көнем. Ә, беләсеңме, мин йортымны оттырдым...

Хавтан көтелмәгән бу хәбәрдән сикереп торды, әмма шундук, башына суккандай, кире шып итеп утырды.

—Син Кутузов проспектындагы йортыңны оттырдыңмы? Без синең өлкән кызыңның туган көнендә утырган йортыңнымы? Кызыңа ул көнне унсигез яшь тулган иде бугай.

—Әйе, туган, шул йортымны. Башы-аягы белән...—дип үкенеп раслады Аргентинлы.

—Кемгә килеп каптың соң син, Аркаша? Мин нишләптер бу оттырыш турында ишетмәдем дә, юкса кирәген дә, кирәкмәгәнен дә белеп торам. Күрәсең, безнең арадагы кеше түгелдер ул.

—Өстенә бастың, Хавтан. Безнекеләрдән түгел. Нефть эшендә кулың җылытып калган бер түрә бугай.

—Нишләп соң син, соңгы көнең килеп җиткәнче, озакка сузып йөрдең? Бер көннән соң дөмектерергә кирәк иде үзен. Безнең кеше дә булмагач, бигрәк тә...

—Сиңа сөйләве җиңел, мин бит саф кәрт уенчысы, безнең әхлакыбыз башка, без Ходай Тәгалә васыятен тотабыз—үтермә. Мин аның каны аша атлап чыга алмый идем, аңлыйсыңмы? Бер ай акча эзләп йөрдем, беркем дә бирмәде. Бәлки, уйнап-отып кире кайтарган булыр идем... Ләкин гаиләне урамга чыгарып ташлау да үлем белән бер, кайда яшәргә, ди, кыш борын төбендә генә. Аннары, мин ул йортыма җаным-тәнем белән береккән, балаларга да бик ошый, картлыгым да әллә кайда түгел—әнә генә. Син мине дөрес аңладың, Ходай Тәгалә васыятен атлап чыгарлык булып өлгереп җиттем мин хәзер... Кыскасы, профессионал киллер кирәк. Аңа түләрлек кенә акчам бар минем.

—Анысы билгеле,—Хавтан кунагына кызганып карады.—Акчаң булмаса, бу хакта базар да ясап тормыйлар, киллерлар хәзер кредитка эшли, ә кайвакыт хәтта алдан түләп куюны да сорыйлар. Хәзер сиңа ашыгычлыксызлек өчен дә түләргә кирәк булачак, анысы тагын илле процент дигән сүз. Ләкин эш акчадан гына да тормый бит... Син бит аңлыйсың, бу эшне иң беренче итеп сиңа сылаячаклар, шул ягын уйлап бетердеңме?— дип пошынып сорады кабинет хуҗасы.

—Вакытым күп иде бит, барысын да уйладым.—Аргентинлы үзенең дәлилләрен җентекләп сөйли башлады.—Беренчедән, Барвихадагы ул катран турында, анда нинди кешеләр уйнап, нинди суммалар оттырып йөргәннәре турында да беркем сөйләнеп йөрмәячәк—ул алар өчен үлемгә тиң, хәзер матбугат җанҗалга сусаган, шуны гына көтеп тора. Икенчедән, син бик акыллы әйтәсең, миңа соңгы көнгә кадәр сузып йөрмәскә, ә иртәгесен үк аны юк итәргә кирәк иде. Өченчедән, анда уйнаганда шунысы да ачыкланды, ул нефть белән шөгыльләнүчеләрне көн аралаш диярлек кырып кына торалар икән. Шулай булгач, минем өлешемдәге көмешем Александр Михайловичның да дошманнары күп, ул кайвакыт үзе кайберләрен әйтеп ычкындыргалаган иде. Нефть бароннарын үтергәндә, тагын бер кызыклы гадәт бар—башына контроль атудан соң, аларның өстенә шешәдән нефть тә сибәләр икән, монысы кем кемне һәм ни өчен үтергәнлеген белмәсеннәр өчен эшләнәдер инде. Без дә шул алымны кулланырбыз. Ә ментларга чокчынып-казынып торуның файдасы юк. Аларга һәр эшне тизрәк ябып кую гына кирәк, ачылмаган җинаятьне кемнең күтәреп йөрисе килсен. Бер бизнесмен дөмеккәннән генә дөнья бетәме? Икенчесе шунда ук туа тора аның. Һәм соңгы сүзем: мин иртәгә аңа шылтыратам да: «Килеп кара, квартирамны бирергә булдым»,—дим.— Аргентинлы тынычлана төшкән иде инде.

—Әйе, алдын-артын ныклап уйлап эшләгәнгә охшыйсың болай,— дип, башын кашып алды Хавтан.—Ләкин, миңа калса, вариант һәм алибиларың никадәр азрак булса, шул кадәр яхшырактыр. Син бер мәсьәләдә хаклы, ментлар ул «яна урысларны» бандитлардан да артыграк яратмый. Әгәр дә инде, кемдер, квартира өчен чәнчелдергәннәр, дип мәтәштерсә, бу фаразга берәү дә ышанмас, нефть өчен башын ашаганнар, диярләр.

—Синең күз алдында торткан берәр ышанычлы кешең бармы?—дип сорады Аргентинлы, ул инде бу киеренке сөйләшүдән арып, кәнәфигә аркасы белән ауган иде.

—Соң хәзер кемнәр генә юк?—дип көлемсерәде Хавтан.—Син сәяси икътисадның төп канунын беләсең: ихтыяҗ тәкъдим тудыра.—Ул җанланып китте, ресторан шау-шуы ишетелгән ишеккә таба ымлады.—Менә әле генә мин бер офицер белән ашап-эчеп утырдым. Бәлки, ул да ярап куяр...

—Нindиерәк кеше үзе? Аңа ышанырга ярыймы?—Аргентинлы эш болай тиз генә пешеп чыгар дип һич тә көтмәгән иде.

—Мин аны әле армиягә чаклы ук, яшь егет чагыннан беләм, аннары бер җиде ел күздән югалып торды. Ул Люберцыдан, кушаматы Самурай. Дингез десантында хезмәт иткән, армия хезмәтен махсус гаскәрләрнең аерым подразделениесында төгәлләгән. Армиядән соң Владивостокта калган, шунда өйләнгән, читтән торып эчке эшләр министрлыгының Югары мәктәбен тәмамлаган, порт милициясендә эшләгән. Ниһаять, барлык Россия акчаларының да Мәскәүдә генә әйләнгәнен аңлап, өенә кайткан, эчке эшләр министрлыгының махсус подразделениесенә эләккән. Ләкин бит Люберцы егете булуыннан берничек тә качып котыла алмыйсың, дәүләтең дә сиңа хәвефле-куркыныч эшең өчен тиеннәр генә түли. Тегендә, Приморьеда кайберәүләрне әкренләп кенә йолкыштыргалап торган. Сизәм, кайткач, биредә дә шул шөгылен ташламаган. Менә шул чагында безнең сукмак-юллар кисеште дә инде, ментлар арасында үз кешең булу комачау итмәс дип уйладым. Ул безне берничә мәртәбә зур күңелсезлек-бәлаләрдән саклап калды инде. Кыскасы, органнарда минем үз кешем иде ул.

—Ә ни өчен «иде»?—дип, ирексездән бүлдерде аны Аргентинлы.

—Әйе, бәхетсезлеккә, бар иде.—Хавтан кызганган кыяфәт белән кулларын җәеп җибәрде.—Аларның эшеннән Аллам сакласын, бер ел эчендә үзенең ун егетен җирләде, нервылары уйный башлады. Хатыны белән дә рәтле тормышы барып чыкмады. Анысы аның Владивостоктан—Мәскәүгә иялэшә алмадымы шунда, кыскасы, ирен ташлап, кире китеп барды. Ә ул арада аның кешеләре арасында әйтерсең вируслы чир таралды—курку чире. Нәтиҗәдә—берсе артыннан икенчесен эштән куып чыгара башладылар: яшьләр юк-бар тиеннәр өчен башларын салырга теләми. Ә артында үзеннекеләр торганны сизмәгәндә, яна команда белән генә чираттагы броня ишекне штрумлау тез астына сугадыр шул. Ә бәлки, яше дә үзенекен аладыр... Кыскасы, эштән китәргә рапорт яза бу. Ә үзе менә дигән профессионал: диверсион әзерлек мәктәбен үткән, электротехниканы белә, кул астындагы әйберләрдән бомба-фәлән ясау—аның өчен бер төкрек кенә. Теләсәң, аның белән сөйләшеп карыйм,—дип тәкъдим итте Хавтан һәм, Самурайны чакыртырга дип, кыңгырауга үрелде.

Городецкий уйланып, янагын сыйпап торды.

—Юк, ул мина ярамас шул. Мин аны залда күрдем—анарда озакка сузылган өметсез рухи төшенкелек, үземнән беләм. Аннары, мин, иске кагыйдәләр кешесе буларак, ментларга ышанып та бетмим—элеккеләренә дә, хәтта Люберцыныкыларга да. Син мина үзебезнекеләр арасыннан берәрсен тап, зонадан кайткан, житди статья буенча утырган булсын. Акча бик кирәк, бала-чагасы ач-ялангач, гаиләсе хәерче нинди дер баклан булмасын инде. Аңа бер байны чәнчелдерү шатлык кына китерсен. Ә минем уй-ниятем яхшы уйлап эшләнгән, башкарып чыгучысы гына кирәк.

—Күпме түләргә әзер сон син?—дип, эшлекле генә сорады Хавтан.

—Хәзер кабул ителгәнчә, ун мең бакс, мин белештем инде, тиз үтәлүе өчен тагын биш мең плюс. Әгәр дә янә ике-өч кисәк кысып алырга теләсә, ризалаш, житди кеше генә булсын.

—Ярар, төйнәп куйдык,—дип, ресторан хуҗасы учы белән шап иттереп өстәлгә сугып алды.—Иртәгә көндезгә кадәр өендә утыр, ул сина үзе шылтыратыр, исемен, әйтик, Жора дияр, кайда булса да ашап-эчеп алырга һәм шунда чираттагы кәрт уены турында сөйләшергә чакырыр. Очрашу урынын үзең әйтерсең. Килештекме?

Городецкий ризалык белдереп баш какты да кәнәфидән күтәрелде. Инде ишеккә юнәлгәч кенә, ул кинәт янадан өстәл янына килде.

—Ә син, Леонид Андреевич, хаклы: синең Самураең, чынлап та, кызыклы шәхес. Бәлки, берәр кирәге килеп чыгар әле. Бир әле мина аның телефонын, мин аны, мөгаен, тән сакчым итеп алырмын. Тик кисәтеп куй, эчүен ташласын, мин үзем сирәк салгалыйм һәм исерекләрне яратмыйм, аларның психикасы башка була...

—Ярар алайса, килештек,—дип шатланды Хавтан.—Юкса, мин инде минем кешемне бәяләп бетермисең дип, пошына башлаган идем. Ә тән сакчысына—менә дигән килә инде ул... Син аның аю кебек килбәтсезлегенә карама, мин аны спортзалда күрдем: пантера, гепард, буар елан. Әгәр дә Самурай башка хуҗа кулына китсә, кызганыч булыр иде.

Алар шулай килешенеп, аерылдылар.

Ресторанның чыгып киткәндә, Аргентинлы игътибар белән залны тагын бер күздән кичереп алды—яна кешеләр өстәлмәгән иде бугай. Машинасын куйган җирдә дә шулай, бер үзгәрешсез иде—бер машина китмәгән дә, килмәгән дә: ул моны үзенең фотографик хәтеренә таянып, ышанып әйтә ала иде. Саклык беркайчан да зыян итми, бигрәк тә бу Александр Михайлович дигәннәре—Алла белсен, кемдер, хәзер инде аны төпченеп, кем икәнен ачыклап, артында кемнәр торганын чамалап маташырга Городецкийның вакыты юк, ә хәзер, Хавтан белән сөйләшкәннән соң, моның кирәге дә калмады. Шулай да бик сак эш итәргә кирәк...

## 7

Ләкин Аргентинлы әллә үз мөмкинлекләренә артык ышанып ташлады, әллә, киресенчә, үзен тар-мар иткән адәмнен сизгерлеген бәяләп бетерә алмады. Аргентинлы «Украина» кунакханәсенә килеп, үзе белән очрашып киткәч, Александр Михайлович Кутузов проспектындагы квартира хуҗасының берникди шартларда да ул квартирадан аерылырга теләмәгәнен аңлап алды, ә шундый кыска вакыт эчендә аның дүрт йөз мен баксны җыеп бетерү мөмкинлеге дә юк—Мәскәүдә андый котырган акчаларның йөри торган вакыты узды шул инде. Димәк, Россиядә яхшы үзләштерелгән бердәнбер билгеле юл гына кала. Криминал даирәләр бик тиз инандылар: кичә син әле аягына егылып, әҗәткә акча биреп торуын сораган һәм сиңа яхшылык эшләгән кешегә бурычны кайтарып бирүгә караганда, аны үтереп ташлау җинелрәк. Шуңа күрә дә, инде ничәнче ел рәттән Россиядә банкирларны һәм бай кешеләрне көннең көнендә атып үтереп кенә торалар. Моңа кадәр бу мәсьәләдә абруена тел-теш тидерерлек булмаса да, Аргентинлы да шушы сыналган юлга басарга мөмкин бит. Дөрес, ул бурычларын һәрвакыт кайтара килгән, оттырганнарга карата да үзен лаеклы тоткан, Мәскәүдә аның турында дистәләрчә шундый легендалар йөри. Бөек уенчының дәрәҗәсе дә шунда шул. Әмма Александр Михайлович бер мәкальне ярата иде: сакланганны Ходай саклар. Шуңлыктан, Аргентинлыны ныклы күзәтү астына алдылар—телефонын тыңлауны оештырдылар, өеннән чыгып йөргәндә, артыннан калмый күзәтеп тордылар. Шулай булгач, «Украина» кунакханәсендә яшәүче кеше Аргентинлының эшләре ничек барганын һәм аның ни өчен Барвихада күренмәгәнен бик яхшы белеп торды. Александр Михайлович үз фаразларында ялгышмады: теге түләргә тиешле бурычының чиректән әз генә артыгын җыя алган, димәк, шул сыналган бердәнбер юл гына кала аңа...

Александр Михайловичка Аргентинлының «Золотой петушок» ресторанына килүен ишеттергәч, ул бик сак эшләргә, шикләндермәскә кушты—кунакханәнен алтынчы катында яшәүченең Хавтан белән дә аерым исәп-хисаплары бар иде. Дөресен әйткәндә, Александр Михайлович бераз борчыла да башлады: бередә ике теләк бергә кушылмадымы икән? Һәм ул «Золотой петушок» ресторанына янына тиз генә үзенең төрле катлаулы аппаратуралар белән җиһазландырылган «лендровер» машинасын җибәрде. Ләкин директор кабинетындагы сөйләшүне язып алып булмады. Картье кушаматлы Слава Неделинның үз вакытында Хавтанга, тыңлый да, күрә дә ала торган хикмәтле нәрсә ясап куйгач, аны кыйммәтле саклану экраны белән дә ышыклаганын Александр Михайлович кайдан белсен, ди? Шуңа күрә аның кешеләре алданып кына калды да.

Хавтанның диварларын тыңлаудан саклый торган бик камил техникага барып төртелгәч, тыңларга килүчеләр бу хакта Александр Михайловичка хәбәр иттеләр, «лендровер» хуҗасы аларга Кутузов проспектына—Аргентинлы йорты янына кайтып, унайлы урынга урнашырга һәм тәүлек буе күзәтеп торырга боерды—операция үзенең ахырына якынлашып килә иде тәсле. Барвихада шундый зур отышлы булган кеше Аргентинлының Хавтан янына ни өчен килгәнлеген тәгаен белә, ләкин аның өчен икенче нәрсә мөһим—Городецкий кайсы киллерны яллады икән дә, алар нинди план корды икән, ә иң белергә кирәклесе шул: Александр Михайловичка ау кайда оештырыла—кунакханәдәме, урамдамы, юлдамы яки Барвихадамы?

Оттырган көненнән сон беренче мәртәбә Городецкий тыныч йоклады. Карар кабул ителгән, максат ачык, киллер бар, ул инде шикләнеп-икеләнеп газаплануларыннан котылган иде. Бер генә төп мәсьәлә кала, кәрт уенындагы кебек үк, уныш әфәнде генә сынатмасын, ул бик тә каприз һәм ни-нәрсәләр эшләсен алдан әйтеп булмый торган холыклы әфәнде. Бүреләр өере арасында яшәп, Аргентинлы тәүге мәртәбә гладиаторлар законын бар-барлыгы белән тойды: яки син, яки сине—һәм ул шул юлны сайларга мәҗбүр булды.

Сәгать нәкъ унбердә, үзен Жора дип таныштырып, бер адәм шылтыратты. Ул кайда булса да барып ашап-эчеп алырга һәм шунда алдагы шимбә-якшәмбе көннәрендә буласы житди кәрт уены турында да сөйләшеп-килешеп куярга тәкъдим итте—кыскасы, Хавтан карусельне әйләндереп жибәргән иде инде. Аргентинлы очрашу урынын алдан ук уйлап куйган, монын өчен ин яхшысы—бу сәгатьләрдә кеше күп булгана торган Тверская урамы иде.

Аргентинлы:

—Ярый, шимбә буш көнем. Әбәтне исә, каршы килмәсәгез, белорус вокзалы янындагы «Якорь» ресторанында ашарбыз,—диде.—Килештекме? Алайса, бер сәгатьтән шунда очрашабыз. Мин төгәл кеше, һәр көнемнен сәгате-минутлары исәпле, сонга калмагыз, яме,—дип, Аргентинлы трубкасын куйды. Һәммәсе дә майлаган кебек бара, ул канәгатьлек белән кулларын уып алды, бүген уныш әфәнде йокысыннан ун аягы белән торган бугай.

Киллерга аванс бирү турында ул ни кичтән, ни иртән бернәрсә дә уйламаган иде, хәзер исә акчаларын яшереп куйган урынга ташланды, башына тагын бер уй килде: эшне тизләтү өчен дә аванс түләргә кирәкме икән? Ахыр чиктә, акча—четерекле нәрсә, әйтүләренә караганда, киллерлар бик саран-вакчыл һәм каприз халык, заказлар күп булып, акча юмарт тамганга шулай кыланалардыр инде. Аргентинлы, ул-бу була калса, дип, йөз долларлы акчалардан ике төргәк ясады: берсе—биш менлек, икенчесе ике мен ярымлык иде. Шуннан сон ул гаражына ашыкты, анын машинадан чыгып торырга нияте юк иде, бер минутка гына ресторан алдында туктый да, киллерны машинасына алып, жилдереп китә, янәсе. Ә киллер «сааб» эчендә генә тиешле күрсәтмәләрне ала һәм әгәр килешсәләр, әлбәттә, акчасы да кулдан-кулга күчә.

Утыз-утыз биш яшьләрендәге, яна мода белән тегелгән кәшемир пәлтәсен ачык төстәге шарф белән ураган бер адәм, «Якорь» рестораны ишеге төбендә үк, аякларын бер-берсенә бәргәләп, көтеп тора иде инде. Аны ерактан ук күреп алган Аргентинлы уйлап куйды: «Минем арттан «койрык» булса, бу «джентльменнын» зонада бер генә түгел, ә мөгаен, берничә мәртәбә булып кайтканлыгын бик акыллы булмаган кеше дә анлап алыр иде». Бу хакта теге адәмнен жир төсенә кергән йөзе дә, сыекланып-пеләшләнеп беткән чәче-башы һәм үз-үзен гомуми тотышы да әйтеп тора иде. Ул үзе боларны бик күрсәтергә теләмичә, бер урында ябык аяклары белән биештереп кенә торса да,—әле житмәсә, кыш көннәренә һич яраклашмаган юка табанлы туфлиләрдән генә әле!—аратирә як-ягына карангалап ала—зонада утырганда үзләштергән бу гадәтләр анын канына сенгән, аларны беркайчан да, бер костюм белән дә яшерә алмас иден. Хавтан бик житди кешене жибәргән булып чыга болай булгач. Аргентинлы, алдан уйлап куйганча, якынрак килде дә, машина ишеген ачып, әкрен генә дәште:

—Жора!

Алай ук эшләргә, бәлки, кирәкмәгән дә булгандыр, әмма күз ачып йомган арада көяз егет дигәнебез машина эчендә иде инде, ә «сааб» Тверской урамы буйлап алга ыргылды.

Әгәр дә Городецкий, күзгегә карагандай, күргән-белгән булса икән?! Александр Михайлович кешеләренен очрашуны көтеп торып, әле Аргентинлы килеп житкәнче үк, бу киллерны абайлап алып, аны берничә мәртәбә фоторәсемгә төшереп алганлыкларын, шуны шефларына хәбәр итеп тә өлгергәнлекләрен, ә тегесенен, Городецкий белән очрашкан киллерны бүген бер адым да күздән югалтмаска боерганын белгән булса—нишләр иде икән? Шуна күрә, гөжләтеп китеп барган ак «сааб» артыннан ук күзгә бик ташланмый торган өч «Волга» машинасы да жилдереп китте. Алар, бер-берсен алмаштырып, ягъни берсе алга чыгып, икенчесе артка калып, дигәндәй, Аргентинлынын машинасын күздән югалтмыйча бардылар, шуннан сон һәммәсе дә ачыкланды, Аргентинлы яллаган

киллерын булачак җинаять урынына—Барвихага таба алып бара иде.

Хавтан тәкъдим иткән купшы-көяз егет машинада үзен Боря дип әйтте дә, рөхсәтсез-нисез генә тартып җибәрде, аның шактый туңганлыгы сизелә иде. Көн, әйтерең бармы, бигрәк тә әшәке иде шул: үзе юеш-салкын, үзе җилле, кыш һәм кар исе килеп тора иде.

Аргентинлының уйларын уйлаган шикелле итеп, сигаретын суыра-суыра, бу адәм гамьсез генә әйтеп куйды:

—Мондый көн безгә бәхет кенә. Мондый салкын лычкылдыкта урамда беркем дә булмый, шаһитлар булганын үлеп тә яратмыйм.—Җылыда эченә җан кергән Жора-Боря бераз мактанып алырга да кирәк тапты бугай.

Городецкий да, сүзне нәрсәдән башларга белмичәрәк бара иде: әллә акчадан, әллә үтерелергә тиешле кешедән, әллә бу киллерның профессиональлеген тикшерергә кирәклеген башларгамы?—белмәссең... Шуна күрә ул бары тик:

—Яратасыңмы-юкмы, кайчагында сайлап торып булмый. Кара әле, синең ике шаһитың бармы соң?—дип сорап кына куйды.

Егет, сүзнең ни-нәрсә турында барганлыгын тиз генә төшенеп житә алмыйча, тынып калды, аннары, аңына барып җиткәч, шаркылдап көлеп җибәрде. Ул башын артка ташлап, ихластан көлә иде, Аргентинлы аның тәвәккәллеген шунда ук тоеп алды.

—Әйтерсез дә соң, валлаһи, көлдерәсез. Сез исәптә түгел, сез—заказчы, аларны сатмыйбыз—бу безнең һөнәрнең төп кагыйдәләреннән берсе. Шуның өстәвенә, сез югары абруйлы кеше. Сезне сатсам—үземә үлем карары укыйм, дигән сүз. Сездәй кешеләргә ярдәм итү—минем изге эшем. Мин эләксәм—кемгә барам: Хавтанга, сезгә ярдәм эзләп барам бит. Шуңа күрә дә, мин бөтен эшләремне ташлап, беренче чылтырау белән сезгә килдем, әйттеләр—эш бик ашыгыч, диделәр...

—Әйтәсе дә юк, Боря, яна, ялкынланып яна минем эш...—дип, аңа куәт биреп куйды Аргентинлы, үзен куып узган «Волга»ны бик ышанычлы гына яңадан узып китеп.

—Борчылмагыз ла! Әгәр пуля сезнең мәсьәләләрне шундук хәл итә ала икән, без аны нәкъ маңгаена утыртырбыз. Ә инде ышанычлырак булсын өчен, «калашников»тан бер-ике тырылдатырбыз,—дип ышандырды аны Жора-Боря.

Ниһаять, Городецкий эшкә керешге:

—Сиңа аударасы кешең хакында бераз мәгълүмат бирү кирәкме?—дип сорады ул.

—Юк, кирәкмәс,—дип, тәрәзә аша сигарет көлен кагып җавап бирде киллер.—Мин беренче утырып чыгуымнан соң ук андый кызыксынуларыма чик куйдым—артык күп белү гомерне кыскарта. Ләкин дә мин аның фоторәсеменә бер күз төшереп алыр идем. Әгәр булса, әлбәттә, бутамас өчен, диюем, юкса, соныннан «Башканы тәгәрәтмәдемме икән?»—дип шикләнеп йөрерлек булмасын. Әйбәт акча сыйфатлы эш тә таләп итә,—дип, Боря үгезне мөгезеннән алып дигәндәй, түләү хакында сүз кузгатты. Бу исә Городецкийга сөйләшүне дәвам итәргә шактый жиңеләйтте.

Шулай да Аргентинлы, түләү хакында сүз кузгатканчы, кесәсеннән алдан әзерләп куйган фоторәсемне алып, киллерга сузды. Тегесе, төсле рәсемгә карап, көлеп җибәрде:

—Шаян кеше икәнсез. Бирелә бит өч лирик басып тора, мин аларның кайсысын теге дөньяга озатырга тиеш соң? Өчесен дәме әллә? Ул чагында түләү бөтенләй башка тарифтан булачак. Бер төркем, команда—бу инде йөз кисәкне сорый, хәтта үз кешеләреннән дә...

Хәзер инде Аргентинлы көлеп куйды:

—Син барысын да атып егарга ашыкма әле, игътибар беләнрәк кара, бәлки, кемне булса да кызганырга кирәктер.

—Анысы да хак сүз,—дип, авызын ерды Боря, рәсемдә Аргентинлы-

нын үзен танып алып.—Барыбер икәү кала бит әле. Кайсысын чүкергә соң боларнын?

—Ә бу сина психологик мәсьәлә, үзенә күрә имтихан—йәле, үзен исәпләп чыгар: кайсысын алырга кирәк?—дип, бераз мыскыллап та әйтеп куйды Городецкий.—Мин хәтта фаразлап та алдым: дөрес әйтсән, димәк, эшебез пешәчәк. Ләкин, дөрес әйтмәсән дә, хәзер инде чигенергә сон—операцияне кичектермәячәкмен. Ырымнарга ышанучан кеше булсам да.

Фоторәсемдәге өченче кеше Альберт Янович иде. Рәсем үзе Барвихада хатын-кызлар мәжлесе оештырган көнне төшереп алынган, сыйфаты да әллә ни түгел иде анын.

Мөгаен, Аргентинлыга үзенен ырымнарга ышанучан кеше икәнлеген әйтеп ычкындырмаска кирәк булгандыр, чөнки киллер, анын сүзләрен чынга алып, рәсемгә бик озак кадалып карап торды, хәтта анын мангаена тирләр бәреп чыкты. Ул, ахрысы, чынлап та, бу ике джентельменнын кайсысын дөмектерергә кирәклеген тапса, үзенен абруе да шуна бәйле булыр дип уйлады булса кирәк. Аргентинлы моны абайлап алды, әмма киллернын эшен жиналәйтергә ашыкмады, әйдә, башын ватсын әле!

Муенындагы шарфы бүлтәеп чыккан көяз егет, ниһаять, дулкынланып әйтте:

—Менә бу утыз-утыз биш яшьләрдәге, тәбәнәгрәген—славян кешесен,—дип, Александр Михайлович рәсеменә төртте. Юкса, чекистлар токымы «Кавказ милләте кешесенә» охшаган һәм һич тә Славянга тартмый иде.

—Булдырдын, егет икәнсен!—дип шатланып жавап бирде Городецкий, ул һич кенә дә киллернын ялгышуын теләми, чөнки, чынлап та, ырымнарга ышанучан иде.—Ярар, шул икәнен тапкансын икән, алга таба тынла,—дип, Аргентинлы житдиләнеп сөйли башлады.—Без хәзер Рублев шоссесыннан Барвихага барабыз. Күрәсенме, юлда ментлар юк, президент Германиядә рәсми визит белән йөргән чак, бу безнен бәхеткә туры килде, юкса башка вариант эзләр идек. Хужа булмагач, Барвихага һәртөрле зур түрә әфәнделәр дә килеп йөрмәячәк, алар аркасында юл махсус тикшерүдә тотылыр иде, ә хәзер, төнлә, әнә, утлары да сүрәнрәк яктырта. Минем берничә вариантым бар, әмма сина эшне артык катлауландырасым килми, ин гади һәм, ин ышанычлысына тукталыйк. Барып чыкмаса, иртәгә дә өзелергә мөмкин—иртәгә катранда зур уен булачак, чөнки жомга. Безгә башка планны уйларга туры киләчәк.

—Сезгә күренә төшә инде. Мин хәтта үзегез алдан һәммәсен дә уйлап-исәпләп куйганыгызга шат та. Ә мин, ышаныгыз, калтыранып-куркып калмам, туп-туры үзенә бәрермен...—дип сүзгә кушылды Хавтан жибәргән киллер.

—Бер вариант бар...—Аргентинлы тотлыгыбрак калды, ни әйтсән дә, ул бит кәрт уенчысы гына, бандит түгел.—Шунда, Барвихада ук. Уен барышында ул, ачык балконга чыгып, тартып керергә ярата. Без өченче каттагы бильярд залында уйныйбыз, ә ана каршы шундый ук дүрт катлы йорт төзелеп бетеп килә, хәзер анда язга кадәр эшләр тукталып тора. Менә шуннан өченчеме-дүртенчеме каттан чүкисен дә аласын. Анда ара кырык метрдан да артык түгел, тавышсыз снайпер винтовкасыннан тәрәзәсе яктырып торган балкондагы кешегә тидерми калу мөмкин түгел, ышанычлы. Ләкин соныннан поселоктан машина белән чыгып ычкыну—бик хәвефле булыр, чит машинаны шундук эләктереп алырлар. Мина калса, ана тозакны юлда корырга кирәк, бирedә бик текә-текә борылышлар житәрлек, машинанын тизлеген киметергә туры килә. Менә шунда тәгаен бәрерсен дә, тагын бер ату өчен дә вакыт кала. Ә безнен тагын бер кирәкле эш бар әле.

—Нинди эш?—дип, инде ау дәртенә кергән киллер каударланып сорады.

Шунда гына Аргентинлы анын акаеп чыккан күз караларыннан наркотик үлән-фәлән тартканын яки, тагын да яманрагы, энәдә утырганын анлап алды.

—Мәет өстенә нефть сибәргә кирәк булачак,ментлар бу байны ни өчен чүкегәннәрен аңласын дип. «Херша»дан бушаган шешәгә солярка тутырып алып килдем, багажникта булыр.

—Ә-ә-ә, беләм. Ишеткәнем бар андый йола турында,—дип тыныч кына җавап бирде Жора-Боря.

Городецкий, машинасының тизлеген киметеп, кисәтеп куйды:

—Хәзер без бер биш минуттан туктарбыз. Бер ай элек мин шунда үзем авариягә эләккән идем, Аллаһының кодрәте белән исән калдым тагын. Менә шул бик каһәрле урын безгә менә дигән инде. Барып житкәч, үзең тирә-ягын карап чыгарсын—уңайлы урын, кискен-текә борылыш, урман юлга ук терәлеп тора, телисеңме-юкмы, тизлекне киметергә туры килә. Кереп качар урынын да бар, машинаңны кая куярга да урын әзерләп куйдым.

Берничә минуттан алар юл читенә чыгып туктадылар һәм ашыкмый гына урамга таба атладылар. Аргентинлының үзе барып капланган урынны күрәсе килә иде. Төбенә кадәр кырылып-җәнчелеп беткән «Жигули» янына барып җиткәндә генә, юлдан Барвиха ягына таба ялгыз «Волга» җилдереп узып китте. «Волга» эчендә утыручылар ак «сааб»ны да, урман читендә таптанып йөргән ике кешене дә абайлап калдылар. Александр Михайловичка тозак шушында куелачагын аңлау кыен түгел иде, шундук арттан килгән машиналарга алга китмәскә, ә «сааб»ны шәһәргә кергән җирендә—бөжра юл тирәсендә көтеп торырга кушылды.

Алда торган операция белән канатланган киллер сайланган урынны бик ошатты. Шулай да, бераз уйлагач, әйтеп куйды:

—Биредә автомат та, контроль ату да кирәк булмас дип уйлыйм. Ышанычлы совет минасы гына кирәк, аннан да ышанычлысы юк, яки противопехотный, яки противотанковый,—дип, ул хәрби телгә үк күчте.

—Ә мин «калашников» белән эшне бетерербез, дип уйлаган идем,—диде Аргентинлы.—Мина, минем карашка, тулы ышаныч бирми,—дип шикләнә калды ул.

—Сөйләп тә тормагыз,—диде Жора-Боря,—кем кулында була бит алар. Мина-бомбалар, киресенчә, тулы ышанычлы, шуңа күрә дә, Мәскәүдә соңгы вакытта бер-бер артлы шартлатулар китте бит. Мин сезгә, белгеч буларак әйтәм, киләчәк—шартлатуларда булачак.

—Димәк, минер эзләргә кирәк?—дип, пошынып сорады Аргентинлы—эшнең мондый юнәлеш алуы һич кенә дә аның күңеленә ятмый иде.

—Ә нигә?—дип, үзенең хуҗасына, балага карагандай, көлемсерәп карап алды киллер.—Мин үзем Әфганны башыннан азагына кадәр үткән кеше, «Батырлык өчен» медалем дә бар, дошманнарга йөзләрчә миналар куйдым, шуларны ук үзем соныннан зарарсызландырдым, шулай булгач, нәрсәнең нәрсәгә кирәклеген генә беләмдер...

—Соң, алай булса, эш башкача,—дип, күңеле күтәрелеп китте Городецкийның.—Мина икән—мина, сез-профессионалга яхшырак билгеле.

—Ләкин минаны сатып алырга туры киләчәк, ә безгә кирәкле ышанычлысы, радио аша шартлатыла торганы, «калашников»тан да кыйммәтрәккә тарта,—дип, киллер Боря аның кикриген бик тиз шиндерде, үзенә тиешле акчага мина сатып алырга аның һич тә исәбе юк иде.

—Нинди базар ясыйбыз? Мин аванс алып килдем,—дип шундук аңа ышаныч белдерде Аргентинлы, хәзер ул бөтенесенә дә әзер иде инде.

—Алайса, минем бер генә соравым кала,—дип дәртләнеп әйтте киллер, күрәсең, ул үз кесәсенә керәсе акчаларның рәхәт авырлыгын тоя башлаган иде инде.—Аның машинасы нинди, башка машиналар белән бутамаска кирәк булыр бит. Хәзер ул иномаркалар шулкадәр күбәйде, зонада утыручыларның бетләре шикелле хәтта, барлык байлар да «мерседес»ларда гына җилдерә...

—Профессионал! Эшнең һәр нечкәлегенә төшенгән кешеләрне

яратам,—дип, аны үсендереп алды Аргентинлы.—Әмма бу мәсьәләдә буталчыклык булмас. Анын машинасы «лендровер» джипы, инглизләрнеке. Мәскәүдә бердәнбер генә булмаса да, «ролле-ройслар» кебек үк, алар санаулы гына. Ә бутавын бутамассың.—Аргентинлы авызын ерып елмайды.—Мин анын янында «Украина» кунакханәсендә булганда, чыга-чыгышлый, аның «лендровер»ына кечкенә бер нәмәстә беркеттем, ул билгеле бер радиодулкында гына эшли. Сүз уңаеннан, анысы да инглизләр әйберсе, мин аларны кайчандыр бер унлапны сатып алган идем, бурыч түләргә теләмәүчеләр артыннан чапканда, кирәге чыга тора бит,—мин аларны, үзләре һич көтмәгән жирдә шул маякларым аша барып тапкач, аларның йөзләрен күрсәң иде син,—дип кырт кына көлеп куйды Аргентинлы.—Ә менә бу соңгысы, күрәсең, житдирәк эш өчен кирәк булып чыкты. Анын джипы бер өч километр ераклыкта күренгәч, менә бу тартмачыкта тоныќ кына ут янар һәм бераз тавыш ишетелер, димәк, машина якынлашып килә, дигән сүз, анда инде бутамассың, шат.—Аргентинлы Боряга бик арзанлы пластмасс зажигалкага охшаган бер нәмәрсә тоттырды.

—Менә мина да шундый бер нәрсә булса икән,—дип, балаларча чын күңелennән сокланып куйды киллер.—Мина бит кайвакытларда минем тирәмдә кемнәр буталганын белү дә бик кирәк.

—Эшеңне башкарып чыксаң, миннән сиңа шундый ук ун данә бүләк,—дип юмартланып ташлады Аргентинлы—үз киллерыңны кул астында тоту шулай ук начар түгел, заман болгавыр, алда еллар һәм яктылык бик күренеп тормый әле.

—Мина һәммәсе дә уч төбендәге кебек. Урыны менә дигән, хәтта минаны да казып-яшереп торасы юк. Килгән машиналар кыеклап эчке якка саклану киртәләре ягына килеп керә ич, ә мин минаны нәкъ шулар артына ук куям,—диде канәгать әфганлы, юл читендә тынып калган «сааб» машинасына кайта-кайтышлый.

Машинага кереп утыргач, Аргентинлы капылт кына әйтеп куйды:

—Синең белән теләсә кайчан һәм теләсә кайдан элемтәгә керер өчен, кесә телефонын булу ярап торыр иде. Әмма монысы хәл итмәслек эш түгел. Кайтышлый ук «Билайн» кибетенә кереп чыгарбыз да, сиңа ул уенчыкны алырбыз,—диде.

—Рәнжетәсең, начальник,—дип елмайды киллер Боря.—Фирма себерке генә бәйләми бит, ул уенчыгым бар минем.—Ул куен кесәсеннән радиотелефонын чыгарып күрсәтте. Фирма табутлар ясый. Шунлыктан, ялган номерлы машинам да, аңа тиешле документларым да әзер, тик менә коралларым арасында минам гына юк, ләкин кичкә булыр ул миндә...

Хәзер инде сүз акчага килеп төртелде, артык сузарга ярамый иде, шуңа күрә Городецкий сорады:

—Мин Хавтан белән килешенгән сумманың яртысын алып килдем, житеп торырмы?

—Шуңа өстәп, плюс тагын яртысын, димәк, жиде ярым кисәк,—дип, каты гына әйтеп куйды киллер, үзенең бу очракта һич тә шаярырга теләмәгәненә басым ясап.

—Барысы да дөрес, мин нәкъ шул чаклыны алып килдем дә.—Аргентинлы аңа ике төргәк сузды.

Боря игътибар белән ике төргәкне дә ачып, санап чыкты:

—Мин Афганистанда үзбәкләр белән бергә хезмәт иттем, әйбәт, ышанычлы егетләр. Менә шуларның бер мәкале бар икән: юлда табып алсаң да, акчаны санап ал. Акыллы мәкаль бит, ул мине бик күп күңелсезлекләрдән коткарып калды.

—Алайса, иң азын гына килешәсе калды,—дип йомгак ясады Аргентинлы.—Иртәгәге көнне, төгәлрәге, төнне сәгате-минуты белән хәл итик. Кичке уннарга кадәр син буш: ял ит, йоклап ал, машинаңны, документларыңны тәртипкә китер. Мин сиңа сәгать унберләрдә шылтыратып бер сүз генә әйтермен: «Вакыт»,—диярмен. Монысы безгә бәйләнеш-

ле булмаган вакыйгалар аркасында, операция өзелмәгән очракта әйтелер. Шылтыратуымны ишетүгә, син, озын-озакка сузып тормыйча, сөйләшенгән урынга чыгып китәсең. Карале, жылырак һәм гадирәк киен. Бер сәгатьтән соң мин сиңа, барып житкәнсеңме-юкмы дип, тагын бер шылтыратырмын, яме. Ә син, минем тавышны ишеткәч: «Сезне ишетә алмыйм, янадан шылтыратыгыз әле»,—дип жавап бирерсең. Монысы, ул-бу була калган очрак өчен—анда, хөкүмәт трассасында теләсә нинди сөйләшүне радио аша тотып алырга һәм һәртөрле шикле сөйләшүләргә үзләренчә хәрәкәт итәргә мөмкиннәр. Син аннан беркемгә дә үзең шылтыратма. Бер сәгать, ике сәгать көтәргә туры килер, шуннан да артык булмастыр, ул гадәттә башкалардан иртәрәк килергә ярата.

—Сугышчан бурычымны намус белән үтәгәнемне мин ничек хәбәр итәргә тиеш?—дип сорады совет армиясенең элекке минеры.

—Мин анысын да уйлап куйдым. Синең генә түгел, минем дә нервылар уйный башлар. Синнән тиешле урынга барып житүең турында хәбәр алу белән мин, «Золотой петушок»ка китеп барырмын—ул хәзер жомга-якшәмбе көннәрендә төнге ресторан булып эшли. Мин сине шунда көтеп торырмын...

—«Золотой петушок»та соңгы исәп-хисап та булырмы?—дип сорады киллер-Боря, күренеп тора: ул да эшне озын-озакка сузарга яратмый иде.

—Әйе, шунда,—дип раслады Городецкий.—Шунда уңышыбызны да бергәләп билгеләп үтәрбез. Ярыймы шулай?

—Бик ярый. Мин барысын да төгәл исәпләдек дип уйлыйм.—Егет тыныч сөйләшә, әйтерсең лә, эшләнәсе эше күптән эшләнгән иде. Монысы карт Аргентинлының күңеленә бигрәк тә май булып ятты.

Шәһәргә кайтып кергәч, Городецкий:

—Сине кайда төшереп калдырыйм?—дип сорады.

—Метро янында көтмәгәндә генә туктап алыгыз да, мин шунда, халык белән буталып, аска төшеп тә китәрмен.

Алар шулай иттеләр дә. Александр Михайловичның алар артыннан калмый килгән кешеләре киллерның барыбер эзен югалттылар—өлгер егет булып чыкты ул.

## 8

Иртәгә булачак «ау» урынына барып кайту ике сәгать чамасы вакытны алган, әбәт вакыты житкән иде. Кәефе әйбәт чакларда Аргентинлының ашыйсы килә башлый һәм ул, ни өчендер, уйлап та тормастан, янадан Тверской урамындагы «Якорь» ресторанына юл тотты.

Городецкий «Якорь»да озаклап-тәмләп ашады, аның инде ашыгыр урыны юк иде, хәзер ул бернәрсә дә хәл итә алмый—янә дә һәммәсе дә уңыш әфәнде кулында кала.

Ул кичне Аргентинлы йокларга иртәрәк ятты һәм соңрак уянды.

Ул көне буе: «Бүген Барвихага Александр Михайлович килерме-юкмы икән, аны кемнән сорашып булыр икән?»—дигән сораулар белән баш ватып ятты. Бүген анда зур уен буласын ул төгәл белә иде. Кичке сәгать уннан соң, Аргентинлы Барвихага шылтыратты, гадәттә ул вакытта уенчылар бильярд бүлмәсендә була. Ни өчендер, трубканы икенче каттагы йорт хужабикәсе алды. Аргентинлы, исәнләшеп, үзенең кем икәнен әйткәч, хужабикәгә мактау сүзләре яудырып, бер ун минутлап тел тегермәнен әйләндереп торды. Аннары, сүз арасында гына дигәндәй «Уенга Альберт Янович бүген килдеме әле? Аның белән бер мәсьәлә турында киңәшләшеп аласы бар иде, мин үзем анда, мөгаен, берәр сәгатьтән булырмын»,—дигән булды. Хужабикә күңелле генә итеп: «Әйе, ул биредә. Гадәтенчә, фырт киенгән, һәрвакыттагыча Александр Михайлович белән бергә. Әмма мин шунысын да ишетеп калдым: алар ярты төннән соң нindидер төнге

клубка барып, анда үзләренә яна компания жыярга маташа шикелле...»

Һәммәсе дә әлегә бик әйбәт бара иде. Аргентинлы, шатлыгын афганлы киллер белән уртаклашканчы, башта «Крюг» шампан шәрабен ачты, бокалын тутырып, аны күтәреп куйгач кына, үзенә күнеленнән уныш теләп, телефонга ябышты. Минер-киллерның тавышын ишетүгә, ул шатлыгын яшермичә, әйтеп салды:

—Вакыт!—диде.

Аннары үзе әкрен генә «Золотой петушок»ка барырга жыена башлады—аның төнге рестораннарга бик күптәннән йөргәне юк иде инде. Сәгатенә караштыргалап ала-ала, ул француз шампанын шешә төбенә кадәр эчеп бетерде. Сәгать уникенче яртыда ул Боря-киллер белән янә элемтәгә чыкты, анардан килешенгән сүзләрне:

—Мин сезне ишетмим, янадан шылтыратыгыз,—дигәнне ишеткәч, трубканы куеп, Хавтан ресторанына ашыкты, әйтерсен лә, аны өмет канатлары очыртып алып бара иде.

Аргентинлының Хавтанны күреп, күнелен бушатасы, киллер өчен рәхмәт әйтәсе килгән иде. Әмма ресторан хужасын урынында туры китерә алмады. Метрдотель:

—Леонид Андреевич дуслары белән Карелиягә—кабан дуңгызлары ауларга китеп барды. Анда инде ике атна элек үк кар яткан икән,—дип аңлатты.

Аргентинлы үзенә ашарга-эчәргә китерүләрен сорады. Әллә музыка белән, әллә ашау белән мавыгып китеп, ул киллер турында да бер мәлгә онытып торды. Ә тегесе бит менә-менә килеп керергә тиеш иде инде. Әлбәттә, Александр Михайлович Барвихада тоткарланып калмаган яки төнге клубка баруын кичектермәгән булса.

Эшнең унышлы барып чыгасына Гордецкий шикләнми иде, профессионал киллер алынды бит—аңа, әлбәттә, автоматка караганда, мина белән эш итү кулайрак иде. Музыка һәм ашап-эчү белән мавыгып утырса да, ул үз янына кемнендер килеп кунаклаганын сизенде. Әллә озак көткәннән күзенә афганлы киллер күренәме дип, әйләнеп караса... Аның янында, елмаеп, Александр Михайлович үзе,—әйе, әйе, үзе!—утыра иде.

—Кемне дә булса көтәсезме, Аркадий Ильич?—дип, гадәттәгечә тыныч-ягымлы тавышы белән сорады ул. Ул! Аны отып-талап, йорт-жирсез калдырырга жыенган дошманы.

Аргентинлының башыннан иң әүвәл яшендәй бер уй чагылып узды: кабахәт афганлы аны саткан! Валлаһи, бу минутларда инде жаны жәһәннәмгә киткән минер-киллерны юкка гына битәрли иде ул. Александр Михайлович Аргентинлыны бер минутка да күздән ычкындырмаган үзенең ярдәмчеләре, Городецкийның әле генә ресторанга килеп утыруын Барвихага хәбәр иткәч, жилдереп килеп житкән иде. Ә Боря-киллер ни Аргентинлыны, ни Хавтанны сатмаган иде, ул, үзен яллаган кешеләрне сатмыйбыз дип әйткәндә һич тә мактануы түгел иде. Әле кичә үк, Аргентинлы белән ул егетнең кайда барып туктаганын, нинди уй-ният корганнарын төшенеп алгач, Александр Михайловичка вакыйгаларның ничек буласын хәбәр иттеләр. Аның кешеләре киллерның машинасын кая яшереп тору урынын, аннары шуннан шәһәргә чыгып сызу юлын да белеп алдылар. Болары, янәсе, ул шартлаткач буласы эшләр иде. Шунда Александр Михайлович кешеләре кичтән үк яшерен капкын куйды. Киллер Аргентинлыга килеп житүе һәм эшкә әзер икәнлеген хәбәр итүгә үк, ул машинасыннан радио белән эшләтелә торган минасын күтәреп чыгуга, аны ике ягыннан көчле куллы ике әзмәвер эләктереп тә алды. Алар аны бик озак кыйнап, жәзалады: «Кемне үтерергә тиеш идең, сине кемнәр яллады?»—дип тинтерәтте. Ләкин киллер, ни Хавтанга, ни Аргентинлыга турылыклы булырга ант бирмәсә дә, бер генә сүз дә әйтмәде. Вакыт кадерле иде,—янәшәдә генә хөкүмәт юлы бит,—Александр Михайлович егетләре, эше барып чыкмаган киллерны сугып һуштан яздырдылар да,

үз машинасының арткы утыргычына ыргытып, янәшәсенә үзе әзерләгән минаны куеп калдырдылар. Үзләре күпмедер китеп баргач, машинасы-ние белән шартлаттылар аннары.

Икенче көнне барлык Россия газеталары һәм телевидение каналлары, хөкүмәт юлында билгесез бер террорчы, дәүләтнең иң югары җитәкче-ләренә һөҗүм ясамакчы булган да, машинасыннан чыкканда ук үз минасында үзе шартлаган икән, дип язып чыктылар... Ни әйтсәң дә, Рублев юлында шартлау булган, әмма нинди...

Аргентинлы үзен-үзе белештермәстән:

—Ә син кем соң әле? Ни өчен мин синең алда җавап тотарга тиешмен? Кемне телим, шуны көтәм,—дип, әле үз аңына килеп җитмәгән килеш тупас кына җавап бирде. Үзе, өстәлдә элекке заманнардагыча аракылы авыр пыяла графин тормаганына үкенеп куйды. Аның яшьлегендә шулай иде бит... Күтәреп алып, теге юньсезнең башын бәреп ярыр иде дә, ыгы-зыгыдан файдаланып, кухнядан урамга чыгып шылыр иде—ул арткы ишекне яхшы белә иде. Ә «Золотой петушок»та шундый шома егетләр эшли, алар ментларга «кавказлы берәүнең» шундый сурәтен сөйләп бирер, гомер буе да эзләп таба алмаслык булыр иде.

Аргентинлы кесәсендә корал йөртмәде, аны машинасында калдыра иде, ә хәзер менә искиткеч уңайлы мизгел иде юкса. Уйланган эшенең барып чыкмаганлыгын, хәзер үзен китереп кысканлыкларын, ә бәлки, үлемгә үк хөкем ителгәнлеген аңлап алган һәм һич тә шулай икәнлегенә шикләнми иде инде ул. Шуңа күрә, ул тыныч һәм үлеме алдыннан бер ырылдап булса да калырга әзер иде. Городецкийның әле тагын бер мөмкинлеге бар: аны «Золотой петушок»та ук үтермәячәкләр—ресторанның хуҗасы кем икәнен яхшы беләләр, Хавтан теләсә кемне җир астыннан да табып алачак, аның абруе—уңышлы эшенең нигезе бит.

—Ә мин тагын уртак танышыбызны көтеп утырасыздыр, дип уйлаган идем,—дип, Александр Михайлович Аргентинлы алдына илтифатсыз гына рәвештә бер төсле фоторәсем ташлады. Рәсемдә «Якорь» ресторанындагы ишеге төбендә төшереп алынган ачык кәшимир пәлтәле егет сурәте иде.

Аргентинлы ул рәсемне алып карарга уйламады да, Городецкийның коелып төшкән кыяфәтен күргәч, чакырылмаган кунак сөйләшүен шундук үзгәртте:

—Син, падла, минем кем икәнемне беләсең киләме?—Тегенең йөзенә борынын ук терәп, дигәндәй, кайнар пышылдады, әйтерсең, Аргентин-лының башына чүкеч белән суккандай итте:—Мин—Македонский! Бәл-ки,ишеткәнең бардыр?—диде ул, үзенең сыгылмалы-күнеккән гәүдәсен үгез тиресе белән тышланган күн урындыкка җинел генә ыргытып.

Аргентинлы шундук мәлҗерәп төште, төсе үлек кыяфәтенә керде, теле сөйләү сәләтен югалтты, бары тик бер биш минуттан соң гына, аңына килеп, зәңгәрләнеп калган иреннәрен ача алды:

—Мин бит белмәгән идем!!!

—Тормыш кануннарын белмәү җаваплылыктан коткармый, сезгә беренче утырган чагыгызда прокурор шулай дип әйткән бугай,—дип усал гына нәтиҗә ясап куйды Македонский һәм шундук Аргентинлыга тулы бокал аракы салып теге аңына килерлек кенә итеп, йомшатып өстәде:—Эч тә, маңкаларыңны сөрт... Мин сине үтерергә дә җыенмыйм, яшә, минем киң күңеллегемнән файдаланып кал. Син бит мине дә күп нәрсәгә өйрәттең, кәрт уйнап, зур отыш алу алга таба миңа да рәхәтлек бирмәс иде. Әле өстәвенә, мин Мәскәүне синең шикелле оста кәрт уены белгеченнән мәхрүм итәсем дә килми, әмма борыныңа киртләп куй: син миңа йортыңны гына түгел, гомереңне дә оттырдың—белдеңме? Ә кварти-раңны мин синнән алырмын.—Бу сүзләрдән соң Аргентинлының ничек тартышып куйганын күргәч, көлемсерәп өстәде:—Алырмын, алырмын... Берсекөнгә минем янга кунакханәгә килерсең һәм шунда, документ-ларыңны карап чыккач, минем исемгә күчерергә барырбыз. Оттыргансың икән—түли дә бел!—дип әйтте Македонский.—Мин әле үзем дә бүген

генә белдем, син бит ул квартираңны да отып кына алган булгансың икән. Кеше милкенә шулай ябышып яту әйбәт түгел, туган!—Шул сүзләреннән соң, Македонский җинел генә урыныннан күтәрелде. Узышлый, әле һаман өстәлдә ятып калган киллер фотосурәтенә төртеп, өзеп әйтте:

—Аңа үпкәләмә, ул сине дә, сине аның белән таныштырган кешене дә сатмады. Хәер, мин аның кем икәнен абайлаган идем инде... Тагын бер нәрсәне исеңдә тот: син мине беркайчан да күрмәден-белмәден, бигрәк тә, хәзерге төс-кыяфәтемне хәтерләмисең. Шул сүзләреннән соң атаклы үтерүче, банкирлар һәм башка байларның котын алучы, залның караңгы ягыннан, мәче шикелле, йомшак кына басып, дивар буйлап кына китеп барды да, эреп юкка да чыкты.

Моңа кадәр аны безнең җәнҗал-гауга яратучы матбугатыбыз «Хәзерге авыру җәмгыятебезнең санитары, Россиянең Понтий Пилаты, хәтта Робин Гуды» дип атап йөрткән бу адәм заты үзе янынннан чыгып киткәч, ни сәер булмасын, Аргентинлы җинеләеп калды, үз акылына кайтты. Инде хәзер, үзе нинди дер могҗиза белән генә исән калгач, квартирасын югалту да ана әллә нинди зур фаҗига булып тоелмады. Чынлап та, башыннан мәхрүм калган кеше—юк чәче өчен елап торсынмы? Ул «Золотой петушок»та, әле моңа кадәр булмаганча, эчте дә эчте. Үзен белештермичә эчте...

Иртән ул Хавтан рестораны янында калдырган үз машинасы эчендә туңып уянды. Боря-киллерга түләргә алып килгән акчаларыннан кесәсендә нибары ике йөз генә доллар калган иде. Аргентинлы, кичәге хәлләрне исенә төшерергә теләп, машинасының көзгесенә караган булды һәм үзен-үзе танымады—коточкыч төн аны шундый хәлгә китереп җиткергән икән... Күзләре эчкә батып кергән, күз төпләре капчык-капчык бүлтәеп, зәңгәрләнеп чыккан, яңаклары мәетнеке шикеллерәк кабарынган, сакал-мыеклары үсеп тырпайган. Ул чәчен төзәтмәкче булып, кулын күтәргән иде, кулларының да калтыранганын күрде. Шунда гына ул исенә килде: кичә бит квартирасын да, гомерен дә оттырды ич! Шуннан соң үзен, гаиләсен, йорт-җирен кызганып, илереп елап җибәрде. Аның бала чагыннан бирле әле бер дә болай елаганы юк иде.

Шундый хәләттә ул машинасында әллә бер, әллә ике сәгать утыргандыр—бу килеш өйгә кайтып күренергә һич ярамый—һәм рухи, һәм физик хәләте начар иде. Бүген бит якшәмбе, бөтен гаиләсе өйдә чак. Аннары, Кутузов проспектына кайтасы да килми, ул өйдәгеләргә, бүген-иртәгә бу апартаментлардан чыгып китәргә туры киләчәк, дип әйтергә дә әзер түгел иде әле. Бүген, башы бик каты махмырдан авыртуга карамастан, ул, ниһаять, үзен нинди чыгалмас тупикка куып керткәнен аңлады, ана хәзер әле кичә генә үз-үзенә кул салып, гаиләсен-кызларын коткарып калу фикеренең дә бер мәгънәсе калмаганы ачык иде. Кулыннан эләктереп алдылар бит: оттырган кешесен үтертәм, дигәндә,—ә кабахәтлек—западло,—моны сиңа һәр шпана йөзенә бәреп әйтәчәк. Хәер, аның легендар Македонскийның үзенә—Александр Салоникка оттырганлыгын, мөгаен, үз-үзен үтерүе дә юа алмас иде, тегесе бит үзенекен беркемгә дә бирә торган шәхес түгел. Хавтан әйтмешли, Аргентинлы, чынлап та, паровоз астына барып кергән икән.

Аргентинлы «Золотой петушок» ишеге төбендә торуны үзенә ахмаклыкка санап, күзе кая караса, шул якка таба китеп барды. Ул, мөгаен, Георгий Эйнштейнга юл тотар иде, әмма теге чукынмыш тагын чираттагы хатынынннан китеп барып, адресын алыштырган иде. Кинәт кенә Городецкийның мингерәгән башында бер өмет кабынды—шушында, Кутузов проспектында ук аның күптәнге тамырдашы-корешы тора ич! Городецкийның юлы уңды. Әмма хатыны Наталья акчасын алып качканнан соң, Аргентинлы Тоглардан: «Нәрсә булды? Бөтенләй төс-кыяфәтең киткән...»—дип сорамакчы булган иде. Тоглар аны җилтерәтеп алды да үзе сорады:

—Йә, нәрсә булды?

—Бәла, Костя, зур фаҗига...—дип, Городецкий аның иңенә төртелеп елап җибәрде.

Үзе каты махмырдан булса да, Городецкий Тогларның кырынган-юынган, урын җирләре дә җыештырылган икәнлеген абайлап алды. Ул хәтта, Наталья кире кайтып кергәнме әллә, дигәндәй уйга да килгән иде. Юк, әлбәттә! Тоглар өметсез эчүдән туктаган, үзен кулга алган икән. Ул көчле ихтыярлы кеше шул...

Тоглар, дустын ашыгыч «дәваларга» кирәклеген чамалап, аны элекке килүендәге шикелле үк, кухняга алып кереп китте һәм Аргентинлы янында утырырга туры киләчәген шәйләгәч, тиз генә икесенә табын корды. Урыслар ялгызы гына баш төзәтеп утырмый, синең күңеленә теләктәш булырдай кеше кирәк, чөнки тәнне генә түгел, җанны да рухи дәвалау сорала. Беренчесен дәшми-тынмый гына эчеп куйгач, иренеп кенә казылык чәйнәштергән булдылар. Аннары шуның артыннан ук икенчесен капладылар, бары тик шуннан соң гына Городецкийның эчендә кайнаганы тышка бәреп чыкты:

—Каптым мин, Костя, бик нык килеп каптым. Йортымны оттырган идем, хәзер инде тормышымны да...

Тоглар, аны бүлдермичә, дәшми-тынмый гына тыңлап утырды, дустының фаҗигале кыйссасы уңаена ара-тирә чәркәсенә сала торды. Аргентинлы Барвихадагы оттырышы, үзен откан кешене үтертергә киллер яллавы, хәтта үзенә дә кул салырга җыенуы турында түкми-чәчми сөйләде. Боря-киллерны аңа Хавтан табып биргәнен, хәзер инде ул киллерның үзен дә теге явызлар шартлатып күккә чөйгәнен дә әйтте. Ул боларны ашыкмыйча, тәфсилләп бәян итте, Александр Михайловичны гына ни исеме, ни кушаматы белән әйтеп ычкындырмады. Тоглар белмәгән бик елгыр яшь кешегә оттырдым, дип куйды. Ай буе дүрт йөз мең доллар эзләп йөргәннәрен, әмма таба алмагач, акча сорарга дип, Тогларга килгәнен, ләкин дустының да, Наталья талап качкач, үле кеше хәлендә икәнен күреп, оттырышы турында әйтми-нитми генә кайтып киткәнен сөйләгәч, ул, көрсенеп, сүзен йомгаклап куйды:

—Беттем мин, Костя...—диде.

—Сезнең очрашуыгыз кайчанга билгеләнгән?—дип, эшлекле генә сорап куйды Тоглар, Городецкийның кайгылы кыйссасын тыңлап бетергәннән соң.

—Иртәгә иртән. Мин аңа кирәкле документларымны алып барырга тиешмен, шуннан соң без квартирамны аның исеменә яздырырга китәчәкбез.

—Син бик бетеренмә. Әле соң түгел,—дип тынычландырырга тырышты аны Тоглар.—Квартиранны ничек итеп саклап калу әмәлен беләм шикелле мин. Син нибарысы дүрт йөз мең тиешлеме? Без ул акчаларны аңа табып бирербез. Ике-өч мәртәбә артыгы белән бирербез, бары тик бернichә атна көтеп кенә торсын.

—Ул инде хәзер минем бер сүземә дә ышанмый, җитди ышанычлы кеше яки закладка нәрсәдер салуны таләп итәчәк,—дип, янадан пошына башлады Городецкий. Анарда янадан өмет чаткылары кабынган иде бит.

—Анысы, гарантияне генә бирербез,—диде Тоглар.—Әгәр минем исемем аңа бернигә дә тормый икән, мин Дантестан яки Саперддан ышанычлы кеше икәнлегемне раслауларын үтенермен. Хәер, мин аңа закладка үз квартирамны да тәкъдим итә алам, мөгаен, ул шуңа килешер.

—Әллә акылыңнан яздыңмы? Гомерең буе йортсыз яшәдең, инде хәзер шуны уенга куймакчысың. Кирәкми, ничек булса да, бер җаен табармын әле,—диде айный башлаган Аргентинлы.

—Син минем өчен борчылма, квартирам өчен дә,—Тоглар беренче мәртәбә елмайды.—Хәзер бер эш әзерләнеп ята, ул синең дә, минем дә мәсьәләләребезне хәл итәчәк. Мин бит синең өчен, гаилән өчен ул квартиранның ни-нәрсә икәнен яхшы беләм. Ә хәзер, әйдә, тагын берне эчеп куйыйк та, мин сиңа үз уй-ниятемне сөйләрмен, бәлки, миңа

синен дә ярдәмен кирәк булыр.—Тоглар дуслык өчен, дуслар өчен, братаннар өчен тост күтәрде!

Эчеп куйдылар да симез селедка һәм базардан алынган тозлы кыяркәбестә ишеләрен әйбәт кенә ашадылар. Аргентинлыга жан керде, ул Тогларның беркайчан да буш сүз сөйләмәгәнен белә иде, шуна күрә янадан өмете уянды.

Тоглар, озын-озакка сузып тормыйча, турыдан-туры эшкә күчте:

—Күнелең күтәрелер, үзенне кулга ал, мәсьәләң хәл ителеренә ышандырыр өчен мин сина бер бик житди һәм куркыныч серемне ачарга мәжбүрмен.—Тоглар Городецкийга сынаулы караш ташлады, тегесе, игътибар белән тынлыйм, дигәндәй, баш кагып куйды.—Алайса, менә шул: «чехлар»,—чеченнәр дигәнем,—мине бер дә бай банкларның ышаныч кәгазьләрен яки дәүләтнен һәм эре компанияләрнен башлыклары кул куйган кирәкле башка документларын ясап утыру өчен генә урлап алып китмәде, хәер, кирәк чакта андыйларын да ясаштыргаладым. Мина бөтенләй башка бурыч куелды... Белеп тор, Аркаша, моны мин бары тик сина гына ачам... Мин чын доллардан беркем дә аерып ала алмаслык ялган доллар ясарга тиеш идем. Моның өчен кирәкле бөтен шартлар да булдырылган иде: ни сорасам, шуны табып бирә тордылар, хәтта кайбер белгеч галимнәрнен кинәш-консультацияләрен дә алдым, тәжрибәләремне үткәрергә ин яхшы лабораторияләр дә катнашты. Дөресен әйтим, бу тәкъдим мина ошый, хәтта күнелемне күтәрә иде: кирәк бит—мин куәтле финанс империясе булган АКШка каршы! Минем американнарга күптән нинди дә булса зуррак бер этлек эшлисем килеп йөри иде—бөтен дөньяны үзләренчә үзгәртеп корырга һәм һәрнәрсәне үз аршиннары, төгәлрәге, долларлары белән үлчәргә омтылганнары өчен. Яшермим, шәхси мәнфәгатем дә шул иде. Һәм беләсенме, барып чыкты бит! Булдырдым бит! Мин сина Ростовта, «чехлардан» казналарын урлап тайдым, дигәндә, ялганламадым, ләкин мин үзем ясаган акчаларымны алдым, анда да алып китә алган кадәрен генә!

—Сон, алар ялган акча бит!—дип, бөтенләй айнып, төшенке генә әйтеп куйды Городецкий.

—Шулаен шулай да, алай ук та түгел. Менә елдан артык инде мин ул акчаларны дөнья буйлап чәчеп йөрим. «Чехлар» үзләре дә һәркайда шул долларлар белән түли, аларны капчыклап банкларга илтеп салалар. Һәм бер генә шикләнгән кеше дә юк. Бер генә махсус детекторлар да аларны тота алмый. Миннән ниндине таләп итсәләр—шундыйларны ясадым. Алар—чын, алар супербанкнотлар дип атала.

—Биргәнсен кирәкләрен! Чынлап та, рәссам син! Менә бу класс! Тәкәббер янкиларның борынына чирткәнсен. Мин шат, котлыйм үзенне!—Аргентинлы чын күнелдән Тогларның кулын кысты.

—Мина артык күп кирәкми иде,—дип дәвам итте Тоглар.—Чечнядан алып кайтканым гомеремә житәрлек иде, ләкин өйләнүем бар уйниятләремне бозды да ташлады. Ничек кайгырганымны үзен күрден. Язмышка озак үпкәләп утыру ирләр эше түгел, алга таба яшәргә кирәк, хәзер бит минем башка шөгыль-мавыгуым бар, күнелем һәм йөрәгем теләгән эшем—рәсем сәнгате. Әмма, кайсына гына барып тотынма, һәммәсе акча сорый. Шуна күрә мин картаеп барган көнемдә тагын бер тапкыр жилкенеп алырга булдым.

—Син янадан акча баса башларга телисенме?—дип куркынып сорады Аргентинлы, анын бер дә уттан чыгып, суга төшәсе килми иде.

—Юк-юк!—дип көлеп жибәрде Тоглар.—Супербанкнотларны ясар өчен өч ел вакыт һәм миллионнарча долларлар исраф ителде. Өстәвенә әле чечен дәүләтенен ышанычлы канаты астында булдым. Яна баштан андый зур эшне майтарып чыга алмаячакмын. Аннан сон, дәртем дә сүрелде, кызыгы да бетте, ә шунсыз андый эшкә тотынудан файда юк. Ә нигә кирәге бар анын? Мина бит күп кирәкми. Мин Чечнядан тагын бер әйләнеп кайтырга телим, ә элекке урыннарымда булып, үземә тиешле

акчамның тагын бер өлешен алып кайтмакчы булам. Инде ике атналап шул эш белән шөгыльләнәм, бөтен ваклыкларына кадәр уйлап бетердем шикелле инде. Вакыт та минем файдага эшли, менә-менә Чечня белән сугыш башланыр, дип сөйлиләр бит.

—Анысы дөрес,—дип бүлдерде аны дулкынланган Аргентинлы.—Мин бит соңгы вакытларда Барвихада уйнадым, анда җыелган зур түрәләр шул сугыш турында гына лыгырдый, аннары инде Чечня сылтавы белән кесә калынайтып өлгергәннәре такылдый тагын...

—Яңа ел борын төбендә генә,—дип дәвам итте Тоглар.—Минем өчен бу иң уңайлы вакыт, сугыш та башланып китсә, тагын да уңайлырак булыр иде—ыгы-зыгы, ут-төтен арасында, диюем. Миңа анда бер көн, күп булса, көн ярым торырга кирәк. Һәммәсе дә бик тиз, көтелмәгәндә һәм, әлбәттә, бик оешкан төстә эшләнергә тиеш.

—Мин дә синең белән барам,—дип, яшьләрчә дәртләнеп әйтеп салды Аргентинлы һәм хәтта, гәүдәсен турайтып, кәперенгән дә булды.

Менә кадәр житди сөйләшеп утырган Тоглар түзмәде, кычкырып көлеп җибәрде.

—Их, Аркадий, көзгегә бер карап бак үзеңә. Бетте инде, поезд китте, без йөрисебезне йөреп бетердек. Мин дә бит гаҗизлектән генә барам, миңа берәү дә китереп бирмәячәк. Юк, син өеңдә кал инде, ләкин син миңа булыша аласың.

—Ничек итеп?—дип аптырабрак сорады бу юлы Аргентинлы.

—Мин барысын да уйлап-исәпләп бетердем, әмма берүзем генә ерып чыга алмаячакмын. Миңа тагын ике-өч кеше кирәк, ләкин миннән яшь булсыннар, элекке десантчылар, спортчылар, коралны яхшы тотучылар, нәрсәгә барганнарын белеп баручылар. Ә иң мөһиме, аларга ышанырлык һәм ничек тә булса үзләрен тикшереп торырлык булсын иде, шулкадәр күп акча күргәч, теләсә кемнең башы әйләнергә мөмкин. Акча—кеше рухы өчен зур сынау ул.

—Хәер, вакыты җиткәнчегә кадәр син аларга нәрсә урларга барганыңны әйтми дә тора аласың бит,—диде Городецкий. Ул инде үзен Тогларның бу эштә ярдәмчесе итеп тоя башлаган иде.

—Нигезле, бик нигезле тәкъдим,—дип ризалашты хуҗа.—Акчалар махсус әзерләнгән төргәкләрдә саклана, һәр төргәктә икешәр миллион доллар, тыштан караганда алар төрле бухгалтер исәп-хисап бланкларына охшашлар. Яхшылап бәйләнгәннәр, үтә күренмәле юка элпә-пленка белән тышлаганнар. Хәтта кулыңа алгач та андый төргәкнең яшерен контейнер икәнлеген тиз генә аңлый алмыйсың. Аларны уйлап табып, ясау өчен бик акыллы кешеләр дә бер ел сарыф иттеләр. Ә синең миңа менә нинди ярдәмең кирәк, син бүгенге көнгә кемнең кем икәнлеген яхшы беләсең, менә син миңа шундый команданы җыеп бир. Барып чыкмаса, Хавтаннан ярдәм сорарбыз, аның да үз кешеләре җитәрлек. Син Мәскәүдә каласы булгач, эшебез уңышлы барып чыкса, минем ышанычлым булырсың, синең кулыңда минем белән хәвефле юлга чыгучыларның һәркайсы турында да тулы мәгълүмат булырга тиеш.

Тоглар бер минутка тынып калды, күрәсең, Городецкийның бу очракта тагын нинди ярдәме тиярлеге хакында уйланды булса кирәк.

—Минем кырык биш меңем бар, мин аларны синең операцияңне әзерләргә бирергә телим,—дип, Аргентинлы аны уйларыннан аерды.

—Рәхмәт, алар миңа бик ярап куяр,—диде Тоглар, дустының соңгы акчаларын тәкъдим иткәнен аңлап.—Ләкин мин үзем дә бөтенләй ук буш түгел, хатыным качып китәр алдыннан гына...—ул бераз тәртәлеп торды,—мин Эйнштейнга ниндидер бик җитди уен өчен йөз мең биреп торган идем, ул да бик үтенеп сораган иде, үзенә фарт киләсен тойганын сөйләп, мине ышандырырга да тырышты хәтта. Аннары ул каядыр озакка югалып торды һәм, син беренче тапкыр килеп киткәч үк, кинәт килеп керде дә, кулыма йөз илле меңне тоттырды: «Бу—синең өлеш, ди, зур отышлы булдым»,—ди. Димәк, Ходай бар, мин шул акчалар белән юлга

әзерләнәм дә. Ләкин минем белән баручыларның һәркайсына егермешәр мең булса да аванс бирергә туры килер, шулай булгач, синекеләр дә артык булмас...

Алда торган хәтәр эш турында кинәш-унаш итә-итә, алар әле тагын ике сәгатьләп утырды. Аргентинлы тора-тора кабынып китә дә Тогларның үзен дә алып баруын кабат сорый, ләкин тегесе ул ялынган саен, «Бар, үзенне көзгегә барып кара!»—дип кенә куя. Соңгы тапкыр шулай кире каккач, Городецкий түзмәде, коридордагы борынгы венециан рамлы, кеше биеклегендәге зур көзге янына чыгып китте. Кинәт шул яктан аның көлгән тавышы ишетелде, әйләнеп кергәч, ул кызганыч тавыш белән әйтергә мәҗбүр булды:

—Әйе, Костя, син хаклыдыр, Чечняләргә барып йөрергә яраклы түгел икән мин хәзер...—Шуннан соң Городецкий командада үзенә урын даулавыннан туктады.

Тогларга үз эшләре белән Переделкинодагы дачасына барып кайтырга кирәк иде. Шулай итеп, төш житеп килгәндә, алар аерылышты. Городецкий да өенә ашыкты, ләкин хәзер инде ул башка кәеф белән кайтып бара иде—хәерлегә булсын, яшенле янгыр үтеп китте шикелле.

## 9

Дүшәмбе көн иртән Аргентинлы Македонский белән очрашырга рухи әзер иде инде. Үзенең оттырышы өчен икеләтә-өчләтә түләү мөмкинлеге аңа ышаныч бирә, Городецкийның ышанычлылары буласы кешеләр дә җәмәгатьчелек алдында абруйлылар. «Матросская тишина» качагы моны белергә тиеш иде. Македонский янына ул «сааб»ына утырып китеп барды, чөнки үзендәге курку хисен яндырып бетергән һәм очрашып сөйләшкән-килешкәннән соң, ныклап торып Тоглар эше белән шөгыльләнә башларга тели иде. Вакыт һәм вакыйгалар кыса. Менә-менә яна ел житә, эше уңышлы чыкса, Тоглар ниятләгәнчә, ул инде утыз беренче декабрьгә табышы белән Ростовка кайтып житәргә тиеш. Ул чагында Городецкий белән Тоглар өчен яна елдан тормышның яна исәбе ачылыр һәм оттырыш афәте дә, Натальяның акча урлап качып китүе дә артта калыр иде.

Хәзер Аргентинлы үзен ышанычлы һәм тыныч тота, әмма бу ышаныч аек акыл эше түгел, ә бары тик Тогларның аңа таяныч ясавыннан, үзенең абруйлы кешеләре ярдәме белән Аргентинлыны бу бәладән йолып калачагыннан туган куаныч кына иде. Шуңа күрә карт кәрт уенчысы ни үзенең сүзләренә һәм хәрәкәтләренә анык җавап бирерлек хәлдә түгел, ни Македонскийның тагын нинди хикмәтләр китереп чыгарасын белми—абайламый иде. Шундый халәттә булмаса, ул кузгалып китүгә үзен озата барганнарын да, кунакханәнең алтынчы катында кемнеңдер лифт көтеп торганын, ә чынлыкта Аргентинлыны каршы алганын да сизенер-аңлар иде. Әмма ирек, муенга салынган элмәктән котылу шатлыгы аны исерткән, акылын томалаган, тормыш аңа хәзер капкын-тозакларсыз, тиздән дусты Тоглар алып кайтачак астрономик зур суммалар яктылыгында балкып күренә иде.

Македонский бу юлы да номерында ялгызы гына иде. Ләкин, номер хуҗасы буларак, бүген ул кунакны алай ук ачык йөз белән, табыннар җәеп көтеп тормаган, әмма Городецкийның моңа эче пошмады—бирелә озаклап утырып торырга җыенмый да иде ул. Аргентинлыга кул хәрәкәте белән генә кәнәфигә утырырга боерды да Македонский, үгезне мөгезеннән эләктереп, сорады:

—Документларыңны китердеңме?

—Юк,—дип нык, хәтта малайларчарак бер егетлек белән җавап бирде Городецкий. Үзе туп-туры «киллер № 1»нең күзенә карады. «Матросская тишина»дан серле рәвештә качкач, матбугат кайвакытларда

Македонскийны шул кушамат белән йөртә башлаган иде.

—Ни өчен?—дип, гаҗәпләнүен яшерә алмый сорады Македонский.— Димәк, син акча китерден?

—Юк, акча да китермәдем, әмма ике атнадан миллион итеп кайтарырга әзер.

Македонский, нәрсәдер уйланып, бүлмә буйлап әрле-бирле йөреп алды.

—Синең закладың бармы?—Македонский Городецкий кебек атаклы каталаның бурычын кичектереп торырга хакы барын белә иде. Хәер, ул үзе күптән инде караклар кануннарын да, дәүләт кануннарын да танымый, бернинди абруй-дәрәҗәләрне хөрмәт итми, ул бары тик Библия кануны белән генә яши: үзенә беркемне дә Алла итмә.

—Закладым да, ышанычлы кешеләрем дә бар,—дип ваемсыз гына җавап бирде Аргентинлы, аякларын чалыштырып куеп һәм бармаклары белән кәнәфи култыксасына бәргәли-бәргәли.

—Миңа заклад булса, яхшырактыр,—диде Македонский, һаман да бүлмә буйлап йөрүеннән туктамыйча.

—Заклад—Кутузов проспектында нәкъ шундый ук квартира, әмма күпкә яхшырак, үзгәртелеп эшләнгән.

—Хуҗасы кем һәм ни өчен ул үзенең квартирасын закладка салырга бирә?—Македонскийның соравы тиз һәм кырыс булды.

—Син, мөгаен, аңламассыңдыр... Ул минем иске дустым, кушаматы Тоглар, бәлки, ишеткәнең бардыр?—дип, инде бөтенләй ахмакларча кәпрәеп җавап бирде Аргентинлы.

—Тоглар?—Македонский йөрүеннән кырт туктады, әйтерсең лә, киртәгә килеп бәрелде, үзенең гаҗәпләнүен яшерергә теләмәгәне дә күренеп тора.—Ул моннан дүрт ел элек автомобиль һәлакәтендә үлмәдемени?

—Юк, Аллага шөкер, ул исән,—дип бәхетле итеп бер сулыш белән әйтте Городецкий.—Хәер, ул вакытта кемнәрдер аны күмүне оештырган, анысы хак. Востряков зиратында әле дә кабере тора...

—Хикмәтле хәл!—Номер хуҗасы элекке тыныч кыяфәтенә кайткан иде инде.—Андый кешенең исән калуына мин дә бик шат. Димәк, язмыш аңа озын гомер юллаган.—Һәм шундук, Городецкийга аңга килергә дә ирек бирмичә, аның тагын кемнәргә аркаланганын суырып алырга тырышып, сорады:—Ә ышанычлыларың кемнәр булыр?

—Әйтик, шул ук Тоглар, ул гына житмәсә—Дантес, Сапер, Шаман...—дип тезеп китте уңышлардан башы әйләнгән Аргентинлы.

—Җитди кешеләр, җитди...—Македонский тәрәзә буена китеп, янә уйга чумды.—Син беләсең бит, мин үз кануннарым буенча яшим, каракларныкын хөрмәт итмим, әмма бу—аерым очрак, синең арканда бөтен «күкшелләрне» дә үземә каршы куясым килми. Ләкин мин синнән ышанып кабул итеп ала алмыйм, син аны исраф итеп бетерден инде.— Аргентинлы, ачуы кабарып, кәнәфиендә бөтен гәүдәсе белән тартышып куйды, әмма хуҗа аны, кул хәрәкәте ясап, урынына сылады. Иртәгә көн дәвамында син әйткән кешеләрнең берәрсе миңа шылтыратсын һәм үзе синең өчен ышаныч белдерсен.

—Сатулашып, базар ясап тору юк, иртәгә шылтыратырлар,—диде Аргентинлы, урыныннан кузгалып, ул инде үзе өчен җитди бу сөйләшүне беткәнгә санаган иде.

Ләкин шунда Македонский, шикләнгәндәй итеп, тагын бер гаепсез генә кебек сорау бирде:

—Ни өчен Тоглар шулай җиңел генә үз квартирасын закладка сала? Ике атна эчендә бер миллион доллар табу җиңел эш түгел бит, син үзең ай буе эзләнеп дүрт йөз меңне дә таба алмадың.

Шунда Аргентинлы, игътибарлырак һәм үзен кысыбрак тоткан булса, туры җаваптан качарга тырышыр иде, чөнки бөтенесе дә хәл ителгән иде ич инде, әмма ул, уйлап та тормастан, шатланып ярып салды:

—Курыкма, табарбыз... Берничә көннән Тоглар Чечняга барып кайтачак, элекке бурычларын исләренә төшереп, кайберәуләрне дер селкетәчәк һәм акча мәсьәләсе хәл ителәчәк...

Македонский, әйтерсең компьютер, килеп туган хәлне яшен тизлегендә башыннан үткәрде дә, легендар Тогларның юк-бар өчен генә хәвефле Чечнягә борынын тыкмаячагын аңлап алды. Дүрт йөз мен урынына миллион вәгъдә итәрлек ул акчаларның кайдан алынасын белү бик мөһим иде. Ул ишеккә юнәлгән Городецкийның юлына котмәгәндә генә аркылы төште һәм тыныч кына итеп әйтте:

—Ашыкма, Аркадий Ильич. Йәле, утыр, тәфсилләбрәк сөйләп бир әле: Тогларны Чечнядә нинди акчалар көтә?

Городецкий, кызып китеп, Македонскийны аты-юлы белән еракkарак озатмакчы булган иде, әмма тегенең соргылт-корыч күз карашына төртелеп, шып булды. Ә Македонский, ни өчендер пышылдауга ук күчте, аның сызгырып-чыжылдап чыккан тавышыннан Аргентинлының аркасына салкын йөгерде. Македонский аның исенә төшереп әйтте:

—Син бер бик мөһим нәрсәне оныткансың: син миңа йортыңны гына түгел, тормышыңны да оттырдың, әгәр бирелән исән-сау чыгасың килсә, Тогларның уй-ниятләрен җентекләп сөйләп бир. Алар минем өчен дә кызыклы булыр шикелле...

Городецкий, үзенең тозакка эләккәнен аңлап, Македонскийны этеп җибәрде дә бикләнмәгән ишеккә ташланды, ләкин номер хуҗасының оста гына итеп аяк чалуыннан шапылдап идәнгә барып төште. Башын күтәреп караганда, Македонский белән янәшә тагын бер әзмәвер басып тора иде инде. Аргентинлы үзенең биредән, чынлап та, исән-сау чыга алмаячагын ачык аңлады.

Аргентинлы җавапларында бөргаланып, дүрт сәгатькә түзде, ә кичкә сынды. Сындырдылар аны... Македонскийдан ул, ана Тогларның Чечнягә баруына кагылышлы барлык хәлләрне хәбәр итеп торырга вәгъдә биреп, кыйналган эт шикелле кайтып китте.

## Кем өлгер, ә кем елгыр?..

### I

Париждан йөреп кайткач, Карлен Татлян бик нык үзгәрде, моның сәбәбе—көтмәгәндә генә Тогларның хатыныннан алган акчаларда иде. Билгеле, ул аларны, дүртенче каттагы гангстер дуслары шикелле акылсыз туздырып бетерергә җыенмый, юкса, бу акчалар ана Абрек белән Крис эләктергән акчалардан да җинелрәк эләкте. Карленда, үзе һич ярлы булмаса да, һәр тиенен исәпләп тота торган типик американ гадәте уянды. Ул агалы-энеле Цуцаевларның төпсез саквояжыннан чумырып-чумырып алган акчаларны унга-сулга юмарт сибеп, хәтта вакыты-вакыты белән, кавказлыларга хас булганча, җилбәзәкләнеп тә җибәрә иде, ул мона үзе дә игътибар итеп килде. Ләкин, тегеләрдән алган акчалардан шактый күп булса да, үз акчаларын алай җинел генә җилгә һич очырасы килми иде. Хәтта Оля да анардагы бу үзгәрешне сизенде, ләкин ул, булачак киявенең бу саранлыгын хатын-кызларча аңлатты: өйләнергә җыена бит, гаиләгә акча кирәк булачагын белә, диде.

Әле «Эйр-Франс» самолеты салонында ук, Париждан җинеп кайтуыннан башы әйләнгән Карлен «Әллә соң Оленька белән туйны яна елга ук ясыйк микән?»—дип уйлаган иде, әмма, суына төшкәч, бу уеннан кайтты, Тоглар эше мөһимрәк һәм аны озын-озакка сузарга һич ярамый иде. Ләкин Карленның өйләнү уе җитди икәнлегенә ни Ольга, ни аның әти-әниләре аз гына да шикләнмәде: әнә бит, булачак кияү сөеклесенә нинди генә бүләкләр төяп кайтмаган, ә инде туй күлмәге

исең-акылларың китәрлек иде! Оля еш кына кичләрен үз бүлмәсенә кереп бикләнә дә, шул күлмәкне киеп сәгатьләр буе көзге алдында утыра, күлмәк ана ошаганнан-ошый бара иде. Тагын да зуррак бүләкне Карлен Париждан кайтып бер атна үткәч ясады. Ямский кыры урамында, Олялар торган йорт янәшәсендә генә тугыз катлы йорт төзелеп бетеп килә, инде тыштан-эчтән бизәкләү-матурлау эшләре генә калган. Йорт дисәң дә йорт: җир асты гаражлары, йөзү бассейны, спортзалына хәтле бар, йорт үзе генә түгел, бөтен тирә-юне яхшы саклана—кыскасы, ул бик бай кешеләр өчен генә исәпләнгән һәм аның һәр квадрат метры биш мең доллар чамасы тора иде. Андагы квартиралар ирекле сатыла икән, Карлен янә дә үзен бәхет басканын төшенде. Кәләшеннең әти-әниләре янәшәсендә квартираң булу—шәпнең дә шәбе инде: балалар туар, үсә башлар, кирәк чакта, әби-бабаларында калдырып тормыйсыңмы? Аннары районы да бик әйбәт, ул төбәккә Карлен күнеккән дә иде инде. Һәм ул, сузып тормыйча гына, Ольга белән аның әти-әниләренә теләгеп әйтте дә, булачак хатыны исеменә яздырып, дүрт бүлмәле квартира сатып алырга булды. Харитоновлар өендәге шатлыклы шау-шуны, ыгы-зыгыны күрсәгез икән—кызларының язмышы шундый тиз һәм бәхетле хәл ителә бит! Карлен бары бер генә нәрсәне үтенеп сорады: Яңа елга кадәр аның эше бик күп, үзен бер өч атна бимазаламый торсыннар иде: «Үзегез барып карагыз, сайлагыз, тиешле кәгазьләреннең эшен бетерегез, ә акчаны мин теләсә кайсы көнне, теләсә кайсы сәгатьтә түләргә әзермен!»—диде.

Ә Татлянның, чынлап та, вакыты һич юк иде—Мәскәүдәге вакыйгалар әллә ничек сәер якка үзгәреп китте. Наталья алдамаган. Фешин Константин Николаевич дигән кеше, дөрестән дә, Кутузов проспектында яши һәм ул августның бер матур көнендә «Пекин» рестораныңда туй үткәргәндә Карлен фотога төшереп алган шул кияү иде. Тоглар телефоннан бик аз файдалана, аңа да еш шылтыратмыйлар, булса да, һаман бер үк кешеләр: Аргентинлы белән купшы-көяз нindидер Георгий гына. Беркөнне Карлен Тоглар йорты янында машинасында, күзен күгәртеп, дүрт сәгать көтеп утырды—ул үзенә бүген Тогларны, һичшиксез, күрергә, аның көн тәртибен ачыкларга, әгәр барып чыкса, килгән-киткән кунакларын да танып калырга дип бурыч куйган иде. Барып чыкмады. Күренеп тора: Тоглар бикләнеп, хәтта дәрвишләрчә, кешеләр белән аралашмый яши икән.

Ул көнне, «гравер» өеннән төш вакытында гына чыкты, Карлен аны кая булса да ашап алырга китерме дип уйлаган иде, юк, теге, күршедәге «Украина» гастрономына кереп, сырлап-бизәкләп эшләнгән бәллүр шешәле ике әрмән коньягы гына сатып алды. Ул шешәләр эчемлекнең саф-чиста булуын раслап тора иде. Аның артыннан кибеткә кергән Карлен легендар Тогларны якыннан күрде. Сизелеп тора: «гравер» берничә көн тыелгысыз эчүгә сабышкан, күрәсең, хатынының качып китүен,—житмәсә, акчаларын урлап, аны бөлдереп бит әле!—бик тирән кичерә-кайгыра иде. Гастрономда шул бер күреп калуыннан Карлен шундый фикергә килде: ялган долларлар баса торган станок, мөгаен, Фешинның үзенеке түгелдер, ул әле бөтенләй Мәскәүдә дә булмас, юкса, көйләп куелган станокта биш яки ун миллион долларны басып ташлап, кайгы-хәсрәтләренне оныту өчен ике көн житәр иде.

Икенче вакытта Карлен «гравер»ны иртәнге якта көтеп алды... Бу юлы инде Тоглар, «Украина» гастрономыннан әрмән коньягы алган исерекбашка һич охшамаган, ул эчүеннән туктаган, аңардан эчке бер көч-җегәр бәреп тора, үзен тотуы да бөтенләй башкача, яшәреп тә киткән, менә дигән итеп киенгән—«Ягуар-стиль» салоныннан алынган кием-салымны бернәрсә белән дә бутарга мөмкин түгел. Менә бу кыяфәттәге Тоглар югары класслы «гравер»га охшаган да охшаган—үзен тотышында, сөйләшү рәвешендә үк аның шул осталар кешесе икәнлеге күренеп тора. Беренче карашка вак-төяк, әһәмиятсез тоелган шушы нәрсәләр Карленның туры юлга чыгуы турында сөйли иде.

Тоглар, гаражыннан үзенен «порше»сына утырып чыгып, шәһәр читенә таба юл тоткач, шатлыктан Карленнын йөрәге сикереп куйды, «гравер» шәһәрдән читтәге яшерен акча басу цехына юнәлде, дип уйлады ул һәм анын артыннан алга ыргылды. Бер-бер артлы Переделкинога килеп кергәч, Карлен янә шатланды; әгәр дә акча басу станогы биредә булса, шуннан да яхшырак һәм куркынычсызрак урынны таба да алмас иден. Карлен Тогларнын унганлыгына тагын бер сокланды.

Биек агач койма белән әйләндереп алынган ике катлы йортнын ишек алдына кереп киткәч, Тоглар өй эчендә бик озак торды. Карленнын машинасы һәртөрле шпионлык итә торган нәмәрсәләр белән шыплап тутырылган булгач, ул ин әүвәл йортта тагын кем дә булса бармы-юкмы икәнен белергә теләде—булса, сөйләшкәннәрен тынлап тору бик жинел иде. Әмма Тоглар ялгызы гына иде: Карлен анын адымнарына кадәр ишетеп торды, нәрсәдер шакылдады, «гравер» ниндидер көйне сызгыргалап йөри иде, Тогларнын колагына аю басмаган, күрәсен. Карлен берәр сәгать-сәгать ярымнан йортнын идән астындагы кайсыдыр бер бүлемтегендә менә-менә акча басу станогы эшли дип көтте—ул аны иркенләп тотып алыр иде, чөнки андый станок зур электр энергиясе суыра һәм аны белүе дә кыен түгел иде. Ләкин бер сәгать, ике сәгать үтте, ә шымчынын акыллы прибор угы ник бер якка селкенеп карасын! Шуннан сон Карлен машинасы белән читкәрәк китте һәм төзелеп ята торган, ләкин кешеләрсез бер вилланы абайлап алды. Тоглар йортынын икенче каттагы тәрәзәләре нәкъ шул төзелеп бетмәгән виллага каршы икән, Карлен вилланын икенче катына күтәрелде дә көчле бинокль аша «гравер»нын йортын күзәтә башлады. Ул шундук Тогларга барып төртелде: теге зур, якты бүлмәдә мольберт каршында басып тора һәм мавыгып рәсем ясый иде. Татлян хәтта анын ниндидер көйне яратып шыншыштыруын яки сызгырынуын да күреп торды.

Шул көнне үк кич белән Карлен янадан Переделкинога килде: ул һаман да яшерен акча басу станогы Тоглар йортынын подвалында, кайсыдыр төштәдер дип уйлый иде. Шәһәрдән чыгып киткәнче, ул башта Тогларнын квартирасына шылтыратты, анын өйдә икәнен белгәч, язучылар шәһәрчегенә элдерде. Коеп көзге салкын янгыр ява; көннәрнен кыска, төннәрнен ин карангы чагы—буш йортка сиздерми-нитми генә барып керү өчен менә дигән вакыт иде бу. Разведка мәктәбендә аларны бик күп нәрсәләргә өйрәттеләр, теләсә нинди өй басучы оста карак та Карленнын сәләтенә көнләшерлек иде. Йортка ул бер авырлыксыз үтеп керде, кесә телефонынннан әледән-әле Тогларга шылтыратып, анын үз квартирасында жылыда рәхәтләнеп утырганын тикшереп тора-тора, биредә ике сәгать чамасы эзләнеп булашты. Биредә акча басу станогынын юклыгына һәм беркайчан да булмаганлыгына ул бик тиз ышанды, калган бөтен вакытын ул, тырышып-тырышып, долларлар яки доллар баса торган клише-мазарлар яшереп куелган урыннар эзләп үткәрде, ләкин монысы да барып чыкмады—юк иде андый урыннар. Аннары ул рәхәтләнеп остаханәдә тагын бер ярты сәгатьләр чамасы «К. Фешин» дип кул куелган рәсемнәрне карап йөрде—рәссамнын ныклы кулы, үткен күзе, төсләрне искиткеч оста тоя белүе әллә кайдан күренеп тора, Карлен үзе дә «гравер»нын бу рәсемнәрен сатып алудан баш тартмас иде. Разведкада, фәндәге кебек үк, «кире нәтиҗә» дигән төшенчә бар, ана кайвакыт унай нәтиҗәгә караганда да ныграк шатланалар. Чыгып китәр алдыннан Карлен, бәлки, кирәге чыгар дип, төрле җирләргә тынлый торган «конгызлар» («жучки») төртеп калдырды, гүя ул биредә озакламый мөһим вакыйгалар булачагын сизенә иде.

Аргентинлынын телефоннан сөйләшүләрен тынлаганнан сон, шактый нәрсә ачыклана төште. Ул бит Тогларнын якын дусты. Городецкий бик нык оттырган икән дә, аз да түгел, күп тә түгел—дүрт йөз мен доллар эзләп Мәскәү буйлап чабып йөри икән. Әгәр дә Тогларнын станогы кул астында гына булса, бер авырлыгы юк бит: бер-ике сәгать долларларны

шапылдатып аласын да кореш-тамырдашынны бу бәладән коткарасың. Аргентинлының өметсез гажизлеге раслап тора: димәк, Тогларның акчасы да, кул астында гына станогы да юк икән.

Кайвакытларда Карленның бу хәлләрне дүртенче катта яшәүче гангстер дусларына сөйләп бирәсе дә килә, алар белән бергәләп Тогларны урларга һәм ялган долларлар турындагы бөтен серләрен сыгып-сыгып чыгарырга дип тә хыяллана. Әмма аек акылы җинә, эчке тоемы-сизенүе аңа: «Ашыкма, син «гравер»ның үзенә чыктың бит инде, үз сәгатең сукканны түземлек белән көт. Иртәме-соңмы, Тоглар үз станогы янына яки үзенең хуҗаларына, ә бәлки, әгәр булсалар, компаньоннарына барачак һәм үз «өлешен» йә сорап, йә көч белән талап алачак»—дип пышылдый. «Граверлар» һичкайчан да үз һөнәрләрен алыштырмый, кагыйдә буларак, бик кырыс, рәхим-шәфкатьсез була. Соңгы мәртәбә Тоглар да әнә шундый булып күренде.

Әмма Карленның түзәрлеге калмаган иде шул инде. Ул хәзер Тоглар белән Аргентинлының телефоннан сөйләшкәннәрен өендә генә тыңлап утыра алмый башлады, тыңлый торган аппаратурасын машинасына ук күчерде һәм еш кына Тогларны йорты янында сәгатьләр буе сагалап тора торган булды. Ул кинәт кемдер «граверны» ашыгыч чакыртып алыр да, артыннан өлгерә алмый калырмын, дип курка иде. Һәм бервакыт аның бу үҗәтлеге нәтиҗә бирде. Иртәнге якта, гадәтенчә, Тогларның бай ишек төбен сагалап торганда, Аргентинлының телефон аша сөйләшкәнен эләктереп алды ул.

Күрәсең, сөйләшү яшерен эчтәлекле иде, Аргентинлы нәрсәләрнедер әйтеп үк бетерми, әмма сөйләшүләренең мәгънәсе, Тогларга гына түгел, Карленга да аңлашылып торды. Аларның сөйләшүләреннән соң, Карленның ирексездән бу күпне күргән ике дуска—Тоглар белән Городецкийга кинәш бирәсе килеп китте: куегыз үзегезнең телефонна-рыгызга тавышны томалый торган скрэмблер, алар сезне бик күп бәхетсезлекләрдән коткарыр, дияр иде ул. Ләкин картлар—теге заман кешеләре шул, андый хикмәтле нәрсәләрне ишетеп тә белмиләрдер әле.

Исәнләшкәннән соң, Аргентинлы тезеп китте:

—Синең белән «чехлар» янына барырга әзер егетләрне таптым мин. Икесе дә синең таләпләреңә җавап бирәләр: спецназ, менә дигән әзерлеклеләр, яшьләр, югары белемлеләр. Берсе бернечә ел ментларның махсус бүлекчәсендә эшләгәч, хәзерге мент тәртипләрен белә.

—Ни өчен икәү генә?..—дип кинәт бүлдерде Тоглар.

—Әлегә икәү, алар армиядә бергә хезмәт иткән. Өченчесен иртәгә табачаклар, сайларлык кешеләр бар, мин аларга шартларыңны әйттем,—дип дәвам итте Аргентинлы,—һәркайсына егермешәр мең аванс, ә кайткач, эш пешеп чыккан очракта, һәрберсенә тагын берәр «лимон». Аларның бурычы нәрсәдә икәнен сөйләп тормадым, үзләре дә бик төпченмәде. Барысы да синең кулда. Синең исемнән кайда һәм кайчанга очрашу билгелик?

Тоглар озак уйланып тормады:

—Берсекөнгә. Минем өйдә кирәкмәс дип уйлыйм, Переделкинода әйбәтрәк булыр. Син аларны кичкә табарак алып килерсең, сәгать бишләр тирәсенә. Хәзер иртә карангылана.

Сөйләшү шунда өзелде.

Карлен беравык аңына килә алмый утырды, ул теләгенә иреште, беләсе килгән нәрсәсен белде. Тоглар ниндидер чехлар янына барырга команда җыя. Ләкин Карлен, хәтерен эшкә җигеп, никадәр исенә төшерергә тырышмасын, Чехиядә ялган акча ясаучылар турында берни дә хәбәр дә юк иде. Кинәт кылт итеп башына бер уй килде, тиз генә Абрекның телефон номерын җыйды һәм, аның тавышын ишеткәч, кабат үтенде:

—Абрек, коткар... «чехларга барып кайтырбыз» дигәнне ничек аңларга? Чехиягәме, әллә Словакиягәме ул?

Абрек башта көлеп җибәрде, аннары борчылып сорап куйды:
—Син әллә чеченнәр белән берәр бәлагә тардыңмы?
—Чеченнәрнен монда бер катнашы да юк. Мин чехлар турында сорыйм,—дип сүзен ачыклады Карлен.—Бер бәлагә дә тармадым.
—Алайса, Аллага шөкер ит,—дип җинел сулап куйды Абрек.—Хәзер Мәскәүдә алар бик көчле. Ә «чехлар»—чеченнәр дигән сүз.
—Ә-ә-ә, эш менә нәрсәдә икән! Рәхмәт!—дип гаҗәпләнде Карлен.
Димәк, Россиянең яшерен акчалар басу урыны Чечнядәдер дигән күптәнге фаразы раслана Карленның. Һәм Тоглар бер банда белән шунда барып керергә уйлый, ахрысы.

## 2

Самурай кушаматлы Герман Кольцовның эшләре хөрт чагы иде—бөтенесе кырыла-җимерелә шикелле чагы.
Самурай белән Мәскәүгә махсус отрядта эшләргә дип килгән егетләрнең сигезе инде һәлак булды, дүртесе яраланды, ул үзе дә берничә тапкыр пуля эләктерде. Берсе артыннан берсе егетләр эштән китә тордылар. Бу китү-качу, спецназның иң кәттә егетләрен Чечнягә—Җаһар Дудаев сараена һөҗүм итәргә җибәрәчәкләр икән, дигән хәбәр чыккач, аеруча киң таралды. Берәүнең дә ни өчен һәм кем өчендер сугышып үлеп каласы килми иде. Владивостоклылардан соңгы кеше булып Самурай үзе эштән китте. Яна команда белән эше дә пешми, ул егетләрне ни янәшәсендә, ни артында тоя алмый, ә монысы беренче җитди засада яки һөҗүмгә кадәр генә яшисен калган, дигән сүз. Башлыклары аны теләр-теләмәс кенә җибәрде: майор Кольцов милициядә танылган кеше иде, андый кыю һәм тәвәккәлләрне Россиядә эзләп кара хәзер! Күбрәге үз кесә ягын кайгыртып кына эшкә килә, андыйлар юк-бар тиеннәр өчен генә пуля астына керергә бик ашкынып тормый иде шул.
Бервакыт иртән телефон чылтырады. Ниндидер таныш түгел кеше аның белән очрашырга, бергә ашап-эчеп алырга һәм шунда, бер унайдан, бер әйбәт кенә эш турында сөйләшергә тели иде. Самурай монда бер дә гаҗәпләнмәде—аның кем икәнлеген күпләр яхшы белә бит. Шул ук көнне «Пекин»да очрашырга сүз куештылар. Самурай, алда торган эшнең, гадәттәгечә, ашыгыч һәм җитди икәнлеген аңлап алды—хәзер кытай ресторанында әбәт ашап чыгу өчен генә дә күп акча чыгарып салырга кирәк, ике россиянлының уртача эш хакын кушсаң да, җитмәячәк.
Очрашу билгеләгән кеше залның аргы башында, эстрада сәхнәсе янында ук утыра иде. Ул утырган өстәл кайчандыр җитмешенче елларда Слава Япончикныкы саналып, ул шунда КПСС Үзәк Комитеты Академиясе янындагы комиссион кибет тирәсендә уралучы фарцовщиклардан ясак җыеп тора торган булган, дип сөйлиләр.
—Аркадий Ильич Городецкий. Дус-ишләрем Аргентинлы дип тә йөртәләр,—дип, мәгънәле генә итеп кул бирде илле яшьләрендәге ир кеше. Яхшы киенгән бу кеше, кереш сүз-нисез генә, чәркәләргә «Абсолют» аракысы сала башлады, күрәсең, ул инде Самурайның нәрсә эчәргә яратканын да белеп өлгергән иде.
Аргентинлы табынны бай эшләткән, кызык, ни өчен шулай икән? Самурайның «Пекин»да беренче булуы иде. Ашап-эчкәндә эш турында сөйләшмәделәр, күбрәк тормыш хәл-әхвәлләре, рестораннар, хатын-кызлар, сыйфаты яхшырак аракылар турында сүз барды. Кайвакыт кинәт кенә, бөтенләй көтмәгәндә, милициядә эшләү һәм, гомумән, хакимият турында да сөйләшеп алдылар. Городецкий, күрәсең, шомарган мужик, шуңа күрә бер темадан икенчесенә җинел генә сикерә дә куя һәм аның нәрсә теләгәне әлегә һич аңлашылмый иде. Самурай болай юк-барны сөйләштергәләп утыруның акыл-зиһененне сынап карау өчен эшләнгәнен чамалый иде, билгеле.
Ресторанда озак утырмадылар, тәмле ризыклар ашап, җиләк-

жимешеннән авыз иткәч, яшел чәй эчтеләр дә урамга чыктылар. Ак «Сааб-900» шунда ресторан каршысында ук тора иде—эш турында сүз машина эчендә башланды.

—Сезне миңа уртак дустыбыз Хавтан тәкъдим итте,—дип, Германга таба ярым борылып, сүзне Городецкий башлап җибәрде, ул кыска-кырыс җөмләләрен кадак каккандай тезеп китте.—Хәзер үзем дә күрәм—сезгә ышанырга була. Ә безнең эш менә мондый: минем бик яхшы бер иптәшем белән,—Хавтан аны да белә,—бик абруйлы кеше, шуның белән Чечняга барып кайтырга кирәк. Юлын исәпләмәгәндә, сез анда бер тәүлек, күп дигәндә, ике тәүлек торырсыз. Шуннан кайбер әйберләрне алып, Мәскәүгә әйләнеп кайтырсыз. Бу эш бик җентекләп уйланылган. Хәер, аны әзерләү өчен бераз бирелә дә мәшәкатьләре булыр әле. Команда кирәк—өч кеше, сезгә тиң дәрәҗәдә: яшь, көчле, җитәрлек тормыш тәҗрибәсе булган егетләр. Үзем барырга җыенган идем дә, картаебрак кителгән.—Аргентинлы, үзе дә сизмәстән, кырыслыгын югалтып, малайларча үпкәләгәндәй әйтте соңгы сүзләрен, әйтерсең лә, аны мавыктыргыч бер уенга алмый калдырганнар.

—Ул хәтәр эш өчен безгә күпме түләячәкләр? Чечнядә бүген-иртәгә буталыш башланырга тора. Чеченнәр бернәрсәне дә сугышсыз бирми, алар Мәскәүне дә бугазыннан алган, ә инде үзләрендә...—дип, күз буяу өчен генә шикләнгәндәй итте Кольцов.

—Барысын да беләбез,—дип бүлдерде аны Городецкий.—Сочига сәяхәт түгел икәнен дә аңлыйбыз, шуңа күрә һәркайсыгызга зур калҗа: егермешәр мең бакс авансны хәзер үк алырсыз, килешсәк, эш уңышлы барып чыккан очракта, өстәп берәр миллион булыр. Ярыймы шулай?

—Бик ярый. Кешеләрем дә бар...—Кольцов тыштан тыныч күренсә дә, эчендә шатлык кайный иде: миллион, хыялланган миллион янәшәдә генә икән ләбаса! Бу сумма аны исәңгерәтеп җибәрде, булырга мөмкин хәвеф-хәтәрләр дә онытылды. Һәм күптәннән инде нәрсә тәкъдим итсәләр, шундый эшкә алынырга әзер Самурай килешергә ашыкты.—Ике кеше инде бар дип исәпләгез, ә өченчесен мин бер тәүлек дигәндә сайлап алып килермен. Ышанычлы команда кирәк бит, шундый акчалар түләрлек булгач, сизеп торам—эш житди,—дип күнеллеләнеп әйтте ул.—Ничек әзерләнергә? Нәрсәләр алырга? Нинди документлар кирәк булыр?

—Ашыкма, атаңнан алда утка кермә,—дип кырт кисте аны Аргентинлы.—Бу сөйләшү әле белдереп куя гына. Мин ул эшне бәйнә-бәйнә үзем дә белеп бетермим әле, вакыты җиткәнче, диюем. Хәвеф-хәтәр, әлбәттә, булырга мөмкин, ләкин алып кайтасы әйбернең хуҗасы сезнең белән үзе дә бара, ул да, сезнең кебек үк, тәвәккәлле. Аның белән очрашып сөйләшкәнчегә кадәр, минем кулда өчегез һәм якын туганнарыгыз турында җентекле мәгълүмат булырга тиеш. Монысы—ул-бу була калса дигәндәй, үзегезнеке булмаган әйбергә кызыгып ымсынмас өчен кирәк. Бик кыйммәтле әйбер алырга барачаксыз, ләкин аның хуҗасының гомере барысыннан да кыйммәтрәк. Сез аның белән исән-сау әйләнеп кайтырга тиешсез. Нәрсә турында сүз барганын аңлыйсыздыр дип ышанам.

—Аңламыйча соң!—Безнең язмыш та хуҗа язмышына бәйләнгән,—дип, кырыс-катгый шартлар белән ризалашты Самурай.

—Хавтан белән без дустыбызның иминлеген тәэмин итәргә тиешбез,—дип ачыклый төште Аргентинлы.—Бары тик шуңа иманыбыз камил булгач кына мин сезне хуҗа белән очраштырырмын, ә ул калганын үзе аңлатыр. Йә, ничек, алынасызмы?

Самурай ризалык белдереп баш какты. Һәм алар, телефон номерларын алышып, аерылыштылар—һәркайсының кичектергесез эшләре бар иде.

Городецкийның машинасыннан төшеп калгач, Герман Кольцов Тверской урамы буйлап җәяү атлады, алда торган ул хәвефле-хәтәр эш турында ныклап уйланырга кирәк иде. Аргентинлыга: «Икәү бар инде»,—дип, ул хәйләләде, күңелендәге теләген генә чын итеп күрсәтте. Күз алдында

тотканы армия дусты Славка Неделин иде—Картье. Кеше гомеренә торырлык тәвәккәл эшкә анардан да ышанычлы—туры кешене Самурай эзләп таба алмас иде. Картьега ул үзенә ышанган кебек ышана. Аннары бик сайланып кешеләре дә калмады ич Самурайның: кем бәрелешләрдә һәлак булды, ә кемнәрдер эштән китеп бетте. Самурай берәр карарга килеп, урамдагы телефон-автоматка керде.

Неделин өендә иде. Герман, ни өчен икәнен әйтеп тормастан:

—Синең белән бик күрешәсе килә иде...—диде.

Картье, аның чылтыратуына артык шатланмаса да:

—Ярый, кил,—дип, Кутузов проспектындагы адресын әйтте.

Ул төндә Самурай Неделинда куна калды. Германның, бер «лимон» хакына Чечнядән йөреп кайтырга кирәк, дигән тәкъдиме Картьены кызыксындырды, билгеле.

Чечня Неделин өчен болай да күптәннән күңелендә йөри иде: ул бит Россиянең банк системасында бик зур афера-алдашулар әзерләнүе, аның эзе Грозныйга сузылуы, ә Мәскәүдә чечен мафиясенә килеп тоташуы хакында тиешле органнарны кисәтә килде. Соңрак ул афера «Чечен авизосы» дигән исем алачак һәм Россия казнасына алты триллион сумга төшәчәк. Россиягә каршы янә дә шундыйрак яки анысыннан да зуррак ялган-хәйлә әзерләнмиме икән? Ниндидер серле нәрсәне Мәскәүгә алып кайту өчен миллионнар түгәргә әзер торгач, булуы да бик мөмкин. Миллионнар вәгъдә итмәсәләр дә, Неделин үзен кызыксындырган бу эштән баш тарта алмас иде. Димәк, безнең контрразведка тагын ниндидер бик мөһим нәрсәне күз уңыннан ычкындырган. Ул бит әле житәкчеләр белән күптән түгел генә очрашкан, Чечня турында, Россиянең бөтен банк системасы диярлек «чехлар» кулына төшүе турында сөйләшеп утырган иделәр. Әмма Ичкериягә башкаладан ниндидер банда барырга җыенуы хакында ымлаучы да булмады ичмасам.

## 3

Бер көн үткәч, кичкә таба Городецкий Тогларның Переделкинодагы дача йортына Самурайның командасын алып килде. Аларның үзен Неделин дип таныштырганын Аргентинлы ара-тирә «Пекин»да дәрәҗәле кешеләр арасында күргәли иде, әмма «күкшелләр» арасында түгел. Ул үзенең килеш-килбәте, сөйләшүе белән Самурайдан нык кына аерылып тора һәм матур тәэсир калдырган иде. Өченчесе—кара-кучкыл йөзле, тыгыз гәүдәсе кай ягы беләндер тау халыкларына охшаганы, анысы үзен гади генә итеп, Леха дип таныштырды.

Тоглар кунакларны икенче каттагы остаханәсендә көтеп тора, анда биш кешелек табын да әзерләнгән иде инде. Ләкин башта утыннары шарт-шорт килеп янып торган камин янындагы тирән күн кәнәфиләргә утырыштылар. Аргентинлы йорт хуҗасына аның булачак командасын тәкъдим иткәндә, Тоглар да Неделинга игътибар беләнрәк карап алды, кызыксынып сорады:

—Ә сез, гомумән, нәрсә белән шөгыльләнәсез?

—Мин бизнесмен, үз фирмам бар.—Картье Тогларга үзенең визиткасын сузды, тегесе аны игътибар белән укып чыкты.

—Әллә сезнең эшләрегез бик шәптән бармыймы? Ни өчен шушындый хәтәр юлга чыгарга ризалык бирдегез?—дип, Неделинга текәлеп һәм шикләнебрәк карап сорады Тоглар.

—Юк, киресенчә. Эшләрем бик әйбәт бара, зарлану гөнаһ булыр.—Неделинның йөзендә ягымлы елмаю чагылды.—Ә баруым—армиядәге элекке хезмәттәш дустым чакырган өчен. Житди ирләр эше, диде. Гонорары да саллы гына икән, тәвәккәллим әле, дип уйладым. Әмма иң мөһиме, үземне эштә сынап карыйсым килә: без бит Герман белән хәтта спецназ өчен дә аерым булган әзерлек үткән идек, безне шундый хәтәр эшләргә әзерләделәр!—Ул көрсенеп куйды.—Яшьлек үтеп бара, мин инде

утызны узган кеше, ә өйрәнгән күнегүләрне тормышта чынлап торып кулланырга туры килмәде әле. Бер биш-ун елдан аларның кирәге дә калмаска мөмкин...

—Әйе, ир кеше өчен житди дәлил бу,—диде уйчанланган Тоглар.—Ләкин сез ялгышасыз, Вячеслав, өйрәнгәнегез теләсә нинди яшьтә кирәк булачак. Мин үзем дә сезнең десантында хезмәт иттем, шул сез хезмәт иткән якларда ук. Мин сезнең биографияләрегезне игътибар белән укып чыктым. Мин дә сезнең белән барам бит, ни кызганыч, инде кырык кына яшьтә дә түгелмен. Ләкин мин үземә ташлама ясауны сорамыйм һәм сезнең яшь җилкәләрегез артына посарга да җыенмыйм.

Ул бардан бер шешә коньяк чыгарды һәм һәрберсенә берәр чәркә төшереп куярга тәкъдим итте. Бөтен команда унайлабрак утырышып беткәч, Тоглар игътибар белән тынлауларын үтенде.

—Ә хәзер мин сезне эш белән таныштырам. Без Грозный янындагы авылларның берсенә барып чыгарга, шунда сак астында булган йорт подвалыннан алтышар килограммлы төргәк-төргәк ниндидер йөкне алып китәргә тиешбез... Төргәкләр кырык-илле, бәлки бераз артыграк та йә кимрәк тә булыр, ана карап сезгә түләү хакы кимемәячәк. Шул йөк белән Мәскәүгә яки, һич булмаса, Ростовка кайтырга кирәк, анысы янәшә генә. Басым ясап әйтергә тиешмен, бу хәтәр юлга әзерләнгәндә һәркем тигез хокуклы тавышка ия, әгәр дә без нәрсәне булса да уйлап, исәпкә алып бетермәсәк, бәйнә-бәйнә биредә—Мәскәүдә үк хәл итеп куймасак, безгә йә юлда, яки Чечнядә ул бик кыйммәткә төшәргә мөмкин. Бер ялгышыбыз барыбызның да гомерен өзүе бар—шулай булгач, уйлашыгыз, тәкъдимнәрегезне әйтегез. Әмма Чечнягә бару һәм кайту юлы, әгәр без аннан исән-сау әйләнеп чыксак, безнең өчен житди куркыныч тудырмас, хәер, хәзер һәр чакрым саен диярлек туктатып тентиләр-тикшерәләр, ә Грозныйга якынайган саен, ГАИдан тыш, хәрбиләрнең һәм казакларның блокпостлары тора. Ләкин мин, уйлана торгач, безне бөтенләй туктамый яки бик сирәк туктата торган бер әмәл таптым шикелле.

Бөтен команда, хәтта Городецкий да түземсез бер дулкынлану кичерә иде. Тоглар ашыкмый гына, тәфсилләп сүзен дәвам итте:

—Минем хәйләм—махсус транспорт булдыруда. Яшермим, мин аны үзем Тын Океан флотында хезмәт иткән ерак елларым арасыннан искә төшереп, эзләп таптым. Менә шунда безнең белән янәшәдә генә химик гаскәрләрнең кечкенә бер часте тора иде. Ул частьнең «рафик» машинасы бар, аның ян-якларына аркылы-торкылы ике сөяк өстенә кеше баш сөяге сурәте сугылган һәм сурәт астына «радиация» дип язып куелган, бу куркыныч билге белән язу үлем дигәнне аңлата. Ә машинаның шоферы—бик елгыр-үткен егет иде, аның бер якташы исә безнең белән хезмәт итә. Армиядә якташың булуның нәрсә икәнен сезгә аңлатып торасы юк, үзегез хезмәт итеп кайткан егетләр, ә инде егерме биш ел элек ул, гомумән, туганың кебек якын була иде. Шуның белән шул, дигәндәй, бездән кемнең дә булса, рөхсәт-нисез генә Владивостокка барып кайтасы бар икән, шуның ярдәменә таянабыз. Ә без шәһәрдән илле чакрымнар ары торабыз, Владивосток үзе дә ул кырыс елларда аеруча яшерен, ябык шәһәр—патруль өстендә патруль була иде. Кайвакытларда ике-өч кеше шул машинага кереп тулабыз, өстебезгә авыр кургаш накидка эләбез, алларыбызда—шлем-скафандр—җилдерәбез генә шәһәргә! Шоферыбыз Толик машинасын туктата башлауга, без тиз генә шул шлем-скафандрларны киеп куябыз да куркыныч бер өрәк шикелле тын гына утырабыз. Кайвакыт патруль егетләреннән берәр бик тырышы ишекне ачып карый да, безне күргәч, өркеп, шалт итеп кире ябып та куя. Кайтканда да, Толик безне алдан сөйләшенеп куелган урында җыеп ала да янә шул кыяфәтләребезгә кереп, кайтып китәбез.

—Чая егетләр! Яшерен-ябык шәһәргә мондый сәфәр, житмәсә, спецчастьтән—тотсалар, өч еллык хезмәтегезгә тагын бер биш елны чәпәп

тә куяр иделәр,—дип сокланды Леха.—Чая егетләр!—дип янә бер кабатлап куйды.

—Чәпәргә дә мөмкин иделәр,—дип ризалашты Тоглар.—Безнен яшьлек кырыс заманнарга туры килде. Ләкин теләк-дәртне тыеп буламы сон? Мәхәббәт, кызлар безне шундый тәвәккәллеккә этәрә иде... Йә, ничек, бик искергән алым түгелме бу?—дип сорады ул, камин тирәсендә утыручыларны күздән кичереп.

Барысы берьюлы дәррәү сөйләргә тотынды. Хәзерге көндә, Чернобыль һәлакәтеннән сон, радиацион тамгалар сугылган машина элеккегә караганда да тәэсирлерәк булыр, диештеләр.

—Ләкин андый машинаны безгә кайдан табарга?—дип, башкалардан алда ашыгып сорады тынгысыз Леха.

—Машина табу кыен булмас. Биредә, Мәскәү тирәсендә шундый ук бер часть бар, безнен гаскәрләрне Германиядән кайтаргач, шунда куелган. Ул машиналар арасында,—ә алар хәрбиләрнен махсус заказы белән эшләнгән,—безгә яраклы берничәсе дә бар, теләсә кайсысын хет иртәгә үк алырга була. Бу вариантны улай дип тапсак, билгеле...

—Алыйк, әйбәт фикер бу. Ләкин машинаны ерак сәфәр өчен бик ныклап әзерләргә кирәк булыр,—дип сүз кыстырды бизнесмен Картье.

—Мин дә шулай дип уйлыйм,—дип аны куәтләде Тоглар,—ләкин, сез әйткәнчә, әзерләү генә житмәс әле. Мин машинанын тышкы кабыгы гына калыр—гаскәрләрнен куркыныч төренә караган билгеләре өстенә радиациягә каршы кием-салым да кирәк булыр. Ә калган бөтен эчке әгъзаларын алыштырырбыз: бик көчле, тизләтелгән двигатель табарга, дүрт көпчәгенә дә пулялардан, очраклы тишелүләрдән саклый торган камерасыз шинлы көпчәкләр куярга һәм хәтта машинаны шып туктатырлык махсус чаралар да күрергә кирәк булыр.—Тоглар, бармакларын бөгә-бөгә, янә санап китте.—Пуля тишә алмый торган пыялалар куярга, машинанын ян-якларын броняларга, унайлы-көйле джипларнын амортизаторларын табарга—машина шалтыр-шолтыр йөрмәскә, тавышсыз гына шуып барырга тиеш. Жылыткыч калорефер да кирәк булыр, урамда кыш, кар, ә безгә, бәлки, төнлә салкын жилдә өч-дүрт сәгать көтеп торырга да туры килер.

—Анлашылды, командир! Кыскасы, химик гаскәрләр калдырчасын броняланган, тиз йөрешле джип итеп үзгәртеп ясыйсы бар,—дип, күнелле генә йомгаклап куйды Самурай.

—Ләкин онытмагыз, машина тышкы яктан элекке кыяфәтендә калырга тиеш. Аны сәфәр чыгарга шундый итеп әзерләүне кем үз өстенә ала?

—Мин алына алам,—дип жавап бирде Картье.—Шундый бер автомастерскойны беләм, анда кирәкмәгәнне төпченеп-сораштырып тормаячаклар, андый эш аларга таныш та.

—Яхшы,—дип ризалашты Тоглар.—Ләкин кемдер шунда һәрвакыт күзәтеп торырга тиеш, бер унайдан машина белән дә таныша торыр.

—Мин анда көннәр буе тора алмам, ике-өч смена эшләп, бик тиз дигәндә дә, ул кимендә дүрт көнгә сузылачак,—дип тиз генә жавап бирде Картье-Неделин.

—Ә сезгә анда тору кирәкми дә, рәхмәт, мастерскоен таптыгыз. Без моны...—Тоглар тиз генә Самурай белән кара-кучкыл йөзле егеткә карап алды һәм хәл итеп, әйтеп тә бирде: ... Лехага тапшырырбыз.—Бу егет ана башкалардан ышанычлырак күренә иде.—Каршы килмисенме?

—Әзерләргә икән—минем куллан килерлек эш, автомобильләрне яратам мин. Жиренә житкереп эшләрбез, борчылмагыз,—диде Леха.

—Менә бик әйбәт,—диде Тоглар һәм беренче мәртәбә елмаеп куйды.—Ләкин, табын янына утырып, кинәт кенә оешкан дуслыгыбызны билгеләп үткәнче, тагын бер-ике сүзем бар. Рәсми рәвештә без Бамут шәһәрчеге тирәсенә командировкага барабыз, анда, тау астындагы шахталарда «жир—жир», «жир—һава» класслы ракеталарны сүтеп алганнан

соң кайбер яшерен җиһазлар-приборлар калган. Безнең командировка кәгазьләренә язылган максат—әнә шул куркынычлы җиһазларны махсус контейнерга тутырып, контейнер машинада булыр, алып китү. Ул контейнерга төп йөкнең бер егермеләп төргәге сыяр. Безнең кулда оборона министрлыгының шуны раслый торган приказы һәм һәркайсыгызда хәрби хезмәткәр документлары булыр. Моның өчен сезгә күрше бүлмәгә керергә кирәк, анда төрле хәрби дәрәҗәле берничә китель эленеп тора, шуларны сайлап киярсез дә, мин сезне машина йөртү таныклыгы, хәрби билет, махсус пропусклар, радиация объектларына керү хокукы бирә торган документларга ябыштыру өчен фоторәсемгә төшерермен—без бит үтә яшерен хәрби часть вәкилләре, безнең махсус вәкаләтләребез һәм хокукларыбыз бар, шуна күрә беркем дә шикләнмәслек документларыбыз булырга тиеш. Соңрак, алар әзер булгач, үзегез яхшылабрак танышырсыз. Ә хәзер—табын янына рәхим итегез, бүгенгә житеп торыр,—дип, Тоглар кәнәфиеннән күтәрелде.—Әзерлек буенча барлык эшләрне Аргентинлы дустым аша гына хәл итәрсез, минем белән бәйләнешкә керергә кирәк булмас.

Табынга утырганчы, Картье диварларга эленгән картиналарны да, мольбертлар һәм станоклардагы әлегә эшләнеп бетмәгәннәрен дә карап чыкты. Ләкин: «Болар кем эшләре?»—дип сорарга кыенсынды, чал чәчле ир үзен Константин Николаевич дип таныштырса да, дачаның аныкы булуына Картье ышанып бетмәгән иде. Камин янында Неделин хуҗаның янәшәсендә утырды, рәтләп анын йөзен күрмәде дә диярлек, бары тик хәрбиләрчә ачык-кырыс тавышын гына тынлап торды. Инде өстәл янына килгәч, ул Тогларга бераз кыеклабрак урнашты. Аларны бергә, Переделкинога алып килгән Аргентинлы кушаматлы кешене Неделин еш күргәли иде: «Пекин»да, «Трефовый туз» казиносында, төрле очрашуларда. Аның элекке буын җинаятьчеләрдән икәнен дә белә иде ул. Ә менә Чечнягә бергә барырга туры киләчәк анын дустын Картье беренче күрә. Константин Николаевич истә калырлык шәхес: зур тормыш тәҗрибәсе булган, нык куллы, салкын канлы, аналитик акыл-зиһенле һәм кырыс табигатьле күренә. Шулай булмыйча соң: җебегән-йомшак кеше хәзерге вакытта Чечнягә борын тыгарга батырчылык итәр идеме? «Чечен авылындагы күзгә ташланмый гына, әмма нык сак астында булган йорттан нәрсә табып алып чыгарга җыена икән ул?»—дип уйланып утырды Картье табын янында.—Бәлки, бу эш уран белән бәйледер, аңа хәзер дөньяда сорау зур, ә нииндидер «яшерен йөк» дигәне, үзе белән баручыларны өркетмәс өчен, игътибарларын читкә тарту өчен генә кирәктер? Радиоактив әйберләр салынган контейнер машинадан ташлап калдырылмый бит... Уйланырлык хәлләр бар иде бирегә. Һәр очракта да алда житди-хәтәр эш тора, ана бик ныклап уйлап, жентекләп әзерләнәләр. Самурайның Неделинны эзләп табуы да яхшы булды әле.

«Ә бәлки, шефка, Виктор Степановичка сөйләп бирергә кирәктер? Ул-бу була калса, саклау чарасы күрүләрен, ярдәм итүләрен сорарга дыр?»—дигән уй да чагылып китте Неделинның башыннан. Әмма анык кына җавабы юк иде, чөнки ул бит әле иң кирәклесен белми: нәрсә алырга баралар, ни өчен, кем бу абзый? Бу эштә Аргентинлының да актив катнашуын исәпкә алганда, бәлки, бер хәйлә-мазар гынадыр. Хәер, ашыкмаска булыр. Неделинның бит спутник элемтәсе бар, кирәге чыкса, сөйләшеп алырга, кайда икәнлегенне әйтеп яки ярдәм сорап, пейджерга мәгълүмат яздырырга мөмкин. Ростовта анын элек яшерен мәктәптә бергә укыган ике иптәше яши, аларның ярдәменә дә исәп тотарга була, ул үзе аларга ничектер Мәскәүдә ярдәм иткән иде. Әйбәт егетләр, күпне булдыра алалар.

Әлбәттә, шикләндермәслек итеп кенә бу командага Самурайның ничек килеп эләккәнен белергә иде, ул бит әле күптән түгел генә үзе милициядә эшли һәм әнә шул Аргентинлы кебек китларны аулап йөри иде. Кыскасы, ул кичне Переделкинодагы дачада Картье күп нәрсәләр белде, ләкин тагын да күбрәк ачыклыйсы сораулары да калды, Чечнягә сәяхәтне озакка сузмаячакларын да аңлады...

## 4

Аргентинлы белән Тогларның телефоннан сөйләшүен тыңлап, аларның Переделкинода очрашачакларын белеп алган Карлен да ул көнне түземсезлек белән көтте. Рәссамның остаханәсендә төрле жирләргә «коңгызлар» төртеп калдырган булгач, ул андагы сөйләшүне Ямский кыры урамындагы үз йортыннан чыкмыйча гына да тыңлап утыра алган булыр иде. Ләкин ул шулай да, машинасындагы көчлерәк аппаратурасына күбрәк ышанып, Тогларның дачасы янына иртәрәк килеп туктады һәм Аргентинлының үз «сааб»ында очрашуга өч ир-атны алып килгәнен күреп торды.

Дачадагы сөйләшүләрне тыңлау Карленның сизенүен раслады: Тоглар Чечнягә сәфәргә җыена, шуның өчен житди команда җыя һәм жентекләп, бик хәйләкәр план кора. Бары тик кайчан китәсе көннәре генә әйтелми калды, ләкин аның якын көннәрдә булачагына Татлян шикләнми иде. Димәк, ашыгыч кына үз командасын җыярга кирәк булачак. Һәм ул, Тоглардагы мәжлеснең әкренләп гади кәеф-сафа корып утыруга әйләнә барганын төшенгәч, кайтып китәргә ашыкты.

Дуслары бу юлы өйдә булып чыктылар, кичкелеккә әрмәнчә ит кыздырганнар, Карленны гына көтеп утыра иделәр. Абрек белән Крис әзерләгән тыйнак кына табын янында ашап-эчеп, сөйләшеп утыра торгач, төн уртасы житкәнен сизми дә калдылар. Барысын да сөйләп бирергә бик теләмәсә дә, Карленга ачылырга туры килде: Американың дәүләт сере, супербанкнотлар ясаган легендар Тогларның сере, Парижга ни өчен барып кайтуы,—дөрес, ул Натальяның Мәскәүдән урлап киткән акчаларны үзе белән бүлешүен әйтми калдырды—һәммәсен дә төкми-чәчми сөйләп бирде. Үзенең Россиягә ни өчен килүен, репортерлык аның өчен түбә-ышыклану өчен генә икәнлеген дә әйтте. Әгәр дә Тогларның табышын тартып ала алса, газет эшен дә, шымчылыгын да ташлаячагын шулай ук яшереп тормады. Тогларның Чечнягә сәфәргә җыенуын әле берничә сәгать элек кенә белгәнен сөйләгәч, гангстер дусларының күзләре бигрәк тә кызды.

—Бәлки, безгә тагын берәр кешене алырга кирәктер?—дип сорады Карлен. Абрек белән Криснын «гравер»ны ауларга барачакларына ул бер минут та шикләнмәде.

Гангстер дуслары күңелләреннән генә Лондондагы «Лейнсборо» кунакханәсеннән әйләнеп кайтты һәм Карленның, алар кылган җинаятьне белә торып та, ул террорлык һөҗүмен үз житәкчеләренә әйтми калдыруын, аларны сатмавын аңлады. Үзләре еш кына үртәштереп-көлгәләп йөргән журналист алар күз алдында шундук үсеп китте. Ә хәзер, житмәсә, атаклы Тоглар бандасына искәртмәстән кыю һөжүм ясарга да жыена.

—Юк, дүртенче кеше кирәкмәс—ул бит тагын бер өлеш чыгару, дигән сүз,—дип, беренче булып Крис сүз башлады.—Моннан да әйбәтрәк эш кайчан булса да тагын чыгармы-юкмы әле, өчәү генә барабыз, Каро!

—Ә безнең өчәү генә булуыбызга борчылма син,—дип сүзгә кушылды Абрек.—Син дә гади генә журналист түгел, өстенлек безнең якта: без аларның кемнәр, ничәү икәннәрен беләбез... көтмәгәндә һөҗүм итәрбез яки засада оештырырбыз... Тик һәммәсен дә уйлап бетерергә, әйбәтләп әзерләнергә кирәк. Синең сөйләвеңә караганда, Тоглар бөтен ваклыкларына кадәр исәпкә алган, хәтта көпчәкләрен алыштырырга кирәклеген дә онытмаган. Ә тагын күпме әйтми калдырган яшерен уй-ниятләре бардыр әле! Ул бит командасына хәтта кайсы авылга, кайчан һәм нинди йөк алып кайтырга барасыларын да әйтеп бетермәгән.

Аннары алар тагын бер өч сәгатьләп көтмәгәндә Чечнягә булачак сәфәрләренең нечкәлекләре хакында фикерләшеп утырдылар. Машина, кирәк-ярак, корал—болары барысы да җиңел хәл ителер. Үзләренең Чечнягә бару сәбәбен ничек итеп рәсмиләштерү юлын таба алмый бик озак азапландылар. Әнә бит Тоглар нинди оста хәйлә тапкан! Хәзер юлда һәр багана төбе саен туктатып тикшерәчәкләрен, Чечнягә барып

кергәндә, хәрбиләрнең блокпостлары да булганлыгын алар да белә иде. Ә хәйлә-сылтау тәки табылды бит! Аны Абрек уйлап тапты. Карлен, танылган журналист, «Лос-Анджелес таймс» газетына үзлегеннән бәйсез Ичкерия республикасы игълан иткән президент Җаһар Дудаевтан интервью-әңгәмә алырга Грозныйга бара. Крис белән Абрек исә аның шоферы һәм сакчысы итеп рәсмиләштереләчәк, аларга корал йөртү хокукы бирелә, мондый документлар булганда, машинаны да энәсеннән-җебенә хәтле тикшереп тормаячаклар. Алдагы ике көндә болай эшләргә булдылар: гангстер дуслар машина белән мәшгуль булачак,—күп урынлы, көчле джип—«гранд-чероки»ны сайладылар,—ә Карлен Тоглар командасын күздән ычкындырмаска тиеш. Шулай итеп, алар Чечнягә ыргылырга ашкынып таралыштылар.

Әмма Карлен үзенең алтынчы каттагы бүлмәсенә күтәрелгәч, алда торган сәфәрнең никадәрле куркыныч, хәтәр булуын беренче мәртәбә чын-чынлап төшенде. Ул, уңышсызлыкка тарыган яки һәлак булган очракта, үзенең абруйлы исемен саклап калу һәм әти-әниләренә, күпсанлы Татляннар ыруына ФБР белән ЦРУ ның кырын карамаулары турында да уйланды. Һәркайда, бөтен дөньяга гомер-гомергә хыянәтчеләргә һәм аларның туган-тумачаларына шикләнеп вә җирәнеп карыйлар. Россиядә генә ул хыянәтче Суворов белән Гордиевскийларның китапларын йотылып укыйлар, аларны телевизорлардан күрсәтеп, сөйләтәләр. Америкада мондый гамәлләр үз исеме белән атала: хыянәтче! Бетте-китте! Шуңа күрә Карлен компьютерына кыска гына текст язып калдырды, әгәр үзе әйләнеп кайтмаса, иртәме-соңмы ул язуны аның американ хуҗалары алып укыячак. Шуның белән ул, Америка алдындагы бурычын үтәп, кайда һәлак булуы мөмкинлегенә ишарә ясап куйды.

Язуы мондый иде:

*«Уйланып торырга, бу операцияне әзерләргә вакытым калмаганлыктан, кичекмәстән Чечнягә китәргә мәҗбүрмен. Сез күрсәткән сериядәге супербанкнотларны яшерен рәвештә басып ята торган урынны таптым шикелле. Ул долларларның бер төргәге хәзер минем кулымда. Үзем хакында юлдан яки Грозныйдан хәбәр итәргә тырышып карармын. Миңа уңыш теләгез.*

*Норман».*

## 5

Аргентинлы, Самурайның командасын Мәскәүгә алып кайткач, янадан Тогларга—Кутузов проспектындагы квартирасына сугылды. Алар, Переделкинодагы очрашу нәтиҗәләренә йомгак ясап, команда тулысынча әзерлекле, тәҗрибәле, бигрәк тә Кольцов белән аның дусты Леха шәп, дигән фикергә килделәр. Озын-озакка сузмыйча, Тогларның сәфәргә чыгу вакытын да билгеләделәр—30 декабрь. Ерак юлны хәвеф-хәтәрсез үтү һәм Чечнягә керү өчен шуннан да унай вакытны таба алмас иден. Ләкин китү көнен әлегә командага әйтми торырга булдылар: команданың дәртен сүндермәү хәерле—Яна елга кадәр ике атна калган иде әле. Шуннан соң гына Аргентинлы үзенә кайтып китте... Ул Тогларның уй-ниятләре белән шулкадәр мавыккан иде, Македонский хакында бөтенләй онытып җибәрде. Бары тик бүлмәсенә кереп, өстәлдәге телефонга күзе төшкәч кенә, өметсезлектән гаҗиз булып, кәнәфигә утырды. Телефон аппаратына мәгънәсез караш белән текәлеп, ул шулай тагын бер ярты сәгатьләп утыргандыр әле, аннары тәки телефонга барып тотынды һәм «Украина» кунакханәсендәге кирәкле номерын җыйды. Тегендә, әйтерсең лә, көтеп кенә торганнар, ышанычлы тавыш шундук җавап бирде:

— Тыңлыйм сезне...

## 6

Сәфәргә кызып-кызып әзерләнеп йөргән Самурайны, бер көннән соң, Тоглар янә үз янына чакырып алды. Хужа анардан берәр бинадагы банданы ничек тотып алу, нинди дә булса притонга яки катранга ничек һөҗүм итү, андый гамәлләр вакытында нинди махсус чаралар кулланылу, кыска-кискен бәрелешләрдә нинди корал иң унайлы, засадаларны ничек алдан белү, хәзер һәр йортта, бигрәк тә шәһәр тирәләрендәге авылларда этләр күп, аларны ничек юк итү турында бәйнә-бәйнә сораштырып утырды. Ике көн шулай бик тәфсилләп аңлашканнан соң, Тоглар, биек кирпеч койма белән уратып алынган утар планын кәгазьгә сызып, Самурайга күрсәтте. Утарның бер читендәрәк җәй көннәрендә йөзем куаклары арасында күмелеп утырган «П» хәрефе рәвешендәге тәбәнәк кенә бер катлы бина бар иде. Аның сул канатында йортның ирле-хатынлы карт хужалары яши, уртада һәм уң канатта коралды сакчылар даими тора, ә подвалында нәкъ Тоглар алырга тиешле йөк саклана.

Тоглар подвалда тагын бер яшерен ишек барын, шуннан гына яшерен лаборатория белән типографиягә кереп булганын, үзенең шунда нәкъ өч ел эшләгәнен Самурайга әйтеп тормады. Тогларның да ул бүлмәгә кереп торырга вакыты булмаячак. Тоглар бу ишегалдын хужаларыннан һәм еш алышынып тора торган сакчылардан да яхшырак белә. Йорт хужаларының оныгы Шамил генә, бәлки, ул белгән һәр почмакны беләдер, чөнки үсмер егет, бик кирәкле әсирне каравыллаудан битәр, күбрәк хужалыкны карый иде. Тоглар да бакчадагы һәр агачны, һәр түтәлне хәтерли, төнгә бәйдән ычкындырыла торган этләрнең өчесенең дә исемнәрен онытмаган—ул этләр Тоглар качып китәргә бер ел кала пәйда булган иделәр. Тоглар аларны бик әйбәтләп ашатып, үзенә ияләштерә торды, яңгырлы-карлы көннәрдә кайда кереп ышыкланганнарына хәтле белә иде. Сакчыларның кайсы бүлмәләрдә, кайсы тәрәзә яннарында иртәнгә кадәр торганнарын хәтерли. Хәер, ул качып китеп, типография эшләүдән туктагач, бәлки, сакчыларны киметкәннәрдер дә инде. Әмма аларны бөтенләй алып бетермәүләренә ул шикләнми иде. Лабораторияне дә күчерә алмаслар, чөнки ул бик нык итеп, нигезләп эшләнгән. Аннары, качып китәр алдыннан, Тоглар компьютерның барлык басу программасын буташтырып-бозып бетерергә өлгерде, кәгазь исә бик тырышып, җентекләп кулдан эшләнә, ә аның ни-нәрсәләрдән нинди нисбәттә һәм нинди температурада әзерләнгәнен бары тик ул үзе генә белә иде. Басылган әзер акчаларны даими алып китеп торалар, ләкин шунда—подвалда ук яшерен бер урын да ясадылар, төргәк-төргәк долларларны анда озак сакларга дип салып куя иделәр. Алихан: «Болары сугыш чыга-нитә калган очракка, Чечнянең кагылгысыз запасы»,—ди торган иде, хәер, хәзер ул запасны да яртылаш киметкән яки бөтенләй алып бетергән булулары бик мөмкин. Әмма Тоглар үзенең өметенә ышана, аннары бит, аның башка сайланыр мөмкинлеге дә юк иде. Үзенең икеләнү-шикләнүләре турында ул Самурайга, әлбәттә, авыз ачып бер кәлимә сүз дә ычкындырмады.

Поселок зур түгел, анда бер биш меңләп кеше яшидер, әмма йортлар, каралты-куралар, утарлар үзләренең архитектурасы, зурлыгы, берничә катлы булулары белән исләренне китәрерлек иде. Алты сутыйдан артмаган ишегаллары, бер катлы йортлардан гына диярлек торган ярлы Россиядән соң, Константин Николаевич бирегә килеп эләккәч, аптырап калган иде: «Ничек болай соң бу? Бер иллә, бер үк законнар буенча яшәдек ич...»—дип баш ватты ул. Чеченнәр—бер дигән төзүчеләр, алтмышынчы-җитмешенче елларда Казакъстанның чирәм җирләрендәге авыл-поселокларны, нигездә, алар төзеде. Тогларны өч ел әсирлектә тоткан йорт урам чатында тора—алгы ягы Ленин урамына караган, ә подваллы уң канаты үтәли тыкрыкка чыга. Моның шулай булуы Тоглар командасының эшен җиңеләйтәчәк, һөҗүмне ике төрле ясарга мөмкин

булачак иде. Майор Кольцов яшерен йөкне алып чыгу әмәленең алты вариантын да эшләгән иде, ләкин Тоглар барысын да кире какты, егетләр белән бергә җыелышып янадан уйларга тәкъдим итте.

Йортның планын алган Самурай Чечнягә сәфәр чыгарга тиешле машинаны ябык аерым бокста кызып-кызып әзерләп яткан автомастерскойга юл тотты. Анда Леха гына түгел, Картье да бар иде, ул атаклы инглиз фирмасы «Томпсон»да ясалган камерасыз киң шин көпчәкләр алып килгән, алар текә таулы юлларда машинаны тагын да тотрыклы, чайкалмаучан итәчәк—Неделин анысын да истә тоткан. Переделкинода Картье ышандырган дүрт көндә осталар, ничек кенә тырышсалар да, эшне ерып чыга алмый иделәр. Шуңа күрә Картье Германның бу хакта Тогларга хәбәр итүен үтенде.

Булачак машинаны яратып өлгергән Леха:

—Без әйләнеп кайткач, бу супермашина кемгә калачак инде,—дип кызыксынып сорады.

—Сиңа спецмашинаниемә кирәк?—дип көлеп җибәрде Самурай.—Кешеләрне өркетеп йөрергәме?

—Янадан матур төскә буярмын, бу контейнерны чыгарып атып, йомшак утыргычлар куярмын, аннары җилдер генә—пассажирлар йөртәсеңме, йөк ташыйсыңмы—рәхәтләнӏ—дип кайнарланып, үзенең хыялый уйларын әйтеп салды Леха.

Шул чагында Самурай, барып кереәсе утарның Тоглар компьютерда сызып биргән ике планын кесәсеннән чыгарып, берсен Лехага сузды:

—Менә объектның планы...—диде.—Әгәр син тавыш-тынсыз шуннан яшерен йөкне алып чыгуның иң яхшы ысулын уйлап тапсаң, машина синеке! Мин шефтан аны үзем сорап алып бирермен.—Икенче планны Неделинга биреп, Кольцов:—Мин, әлбәттә, шаярттым гына. Әмма уйлашырга кирәк: бу утарны ничек басып алырбыз? «Чехларның» коралларында тавыш сүндергечләр юк, әгәр алар бер генә атса да, безнең качып китү юлын ябып куячаклар—аларның саклану чаралары Кремльнекеннән начар булмастыр. Ә машина хакында, Леха, инде күңелең төшкән икән, чынлап та, шеф белән сөйләшермен, бәлки, бүләк итеп тә куяр. Мин бүген аның өендә булдым, ул ярлы мужик түгел, карунлыгы да сизелми. Ләкин аны төнтек-томана бер лох дип уйларга да ярамый,—бүген ул минем алты вариантымны кире какты, үзенең дә, безнең дә гомерләребезне бик саклап каласы килә аның,—диде.

Автомастерскойдан Самурай Неделин белән бергә китеп барды. Алар Язучылар йортының ресторанына кереп, Имән залда ашап алдылар, анда Картьеның эшлекле бер очрашуы билгеләнгән булган икән, ул бер ун минутлап вакытны алды, аннары Славик аны Солнцевога илтеп куйды, Самурай шунда бер бүлмәле фатирда тора иде. Вакытны алар бушка үткәрмәскә тырышты, хәтта ресторанда утырганда да шул план хакында киңәш-уңаш иттеләр. Бу минутларда автомастерскойда калган Леха да шул турыда баш вата иде.

## 7

Аргентинлы Чечнягә сәфәргә әзерлекләрдә, әйткәнебезчә, Тоглар белән элекке өч спецназчы арасында элемтәне тота, автомастерскойга да берничә мәртәбә килеп китте, күрексез генә, әмма ышанычлы «УАЗ» машинасының күз алдында үзгәрә барганын күрде. Ул Тогларның зиһене үткенлегенә тагын бер кат инанды—мондый машина белән теләсә нинди эшкә барырга була, хәйлә менә дигән иде. Дөрес, бу хәйләне бер генә кабатларга мөмкиндер—бер күзгә чалынгач, аны эләктерергә дә күп сорамаслар. Тоглар белән көн саен диярлек очрашып торган Городецкий, менә-менә җае чыгар, ул, туп-туры яки читләтеп булса да, дустына алар артыннан койрык булачагын һәм хәтта Македонскийның «лендровер» машинасын сөйләп тә бирергә уйлап, изаланып

йөрде. Әмма көннәр эри тордылар, Чечнягә сәфәр якынлашканнан-якынлаша барды, ә ул тәки ачылып сөйләргә унайлы вакыт таба алмады: әле тегесе комачаулый, әле монысы, дигәндәй, ә ин дөресе, куркаклыгы иде. Кайвакытларда һәммәсе дә үзеннән-үзе чишелер кебек тоела... Ул еш кына һәлак булган Боря-киллерны хәтеренә төшерә, менә хәзер янадан кирәк булыр иде ул минер. Аргентинлы Македонскийга яна һөҗүм оештырырга да әзер, нәрсә булса да эшләргә йөрәге житми, үзе артыннан ул бандитнын шымчылары гел генә күзәтеп тора шикелле. Дөрес, күнелен юатыр өчен булса да, инде машина бөтенләй әзер булып, аны егетләр Тогларга күрсәтергә жыенганда, Аргентинлы Самурайны бер яккарак алып китте дә унайсызланып кына сөйли башлады:

—Гера, миннән көлмә, яме, мин сина сөйләгәннәрне Константин Николаевичка да әйтмә.—Самурай кулын күкрәгенә куйды: нинди сүз булырга мөмкин, мин—кабер, янәсе.

Аргентинлы сүзен дәвам итте:—Мин ырымнарга ышанучан, Тоглар бу унайдан мине гел үртәп, көлеп йөри... Бүген начар төш күрдем... Имеш, сезнен артыгыздан юлда нинди дер бер машина ияргән, кара төстәге чит ил джипы... Алар, имеш, сезнен Чечнягә алтын алырга баруыгызны белгәннәр икән дә, табышыгызны талап калу өчен унайчак көтәләр икән. Машинада алар өчәү... Әйе, өчәү бугай... шуннан... хәтерләмим, шуннан мин, мөгаен, уянып киткәнмендер...

—Әйе, юлга чыгар алдыннан мондый начар төш күргәненне шефка сөйләргә ярамас. Начар ырым, кәефен бозарга мөмкин,—дип ризалашты Самурай.—Рәхмәт, мин моны исемдә тотармын, саграк булырмын. Белмәссен, безнен биредә нинди дер машина хәстәрләп ятканыбызны кемнәрдер күреп тора бит, кызлар утыртып йөрергә түгеллеге керпегә дә анлашыла...

Тогларнын егетләр белән юлга чыгып китәренә өч көн кала, Аргентинлынын өендә телефон чылтырады. Исәнләшеп тә тормастан, Македонский кистереп әйтте:

—Ин төгәл—дөрес мәгълүмат шул: бүген иртәнге якта безнен самолетлар Грозныйны бомбага тотачак, ә төш вакытында шәһәргә танклар колоннасы керәчәк. Чечнягә барып керү өчен шуннан да унай вакыт табылмас. Кыймылда...—дип, трубкасын ташлады.

Аргентинлы шундук Тогларга чылтыратып бу хәбәрне туп-туры әйтеп бирде.

Команда сонгы ике көндә беренче әзерлектә тора иде инде, Тоглар, барысын да дачасына жыеп, килеп туган хәлне фикерләшергә уйлады. Күп кинәшеп тормадылар. Кичекмәстән чыгып китәргә карар кылынды, әгәр иртәгә Чечнягә каршы сугыш хәрәкәтләре башланып китү турындагы хәбәр расланмаса, Ростовта бер-ике көн ял итеп, Ичкериягә, үзләре уйлаганча, Яна ел төне алдыннан барып керергә булдылар.

## 8

Телефон аша сөйләшенгән ике хәбәрне дә—Македонскийнынкын да, Аргентинлынынкын да—Карлен өендә тынлады һәм шундук дүртенче катка йөгереп төште: андагы егетләр дә казарма тормышына күчкән һәм «Ч» вакытын көтеп кенә тора иделәр.

## 9

Македонский Тогларнын шундый карар кабул итәчәгенә һич кенә дә шикләнмәде, чөнки бу акыллы гына түгел, бердәнбер дөрес тә карар иде—сугыш ут-төтене астында Чечнягә керергә дә, аннан чыгып ычкынырга да ин жайлы вакыт бит. Ләкин ул аларнын юлга чыгуларын каравыллап тормады—юл озын, көчле моторлы «лендровер» коточкыч тизлек белән жиллерә. Аннан сон, Аргентинлы Тогларнын

машинасын юлга әзерләгән мастерскойның адресын әйткәч, Македонский анда үзенең бер кешесен дә жибәргән һәм ул адәм броня тышлык арасына күзгә чалынмый торган гына маяк та ябыштырып кайткан иде. Кайчандыр Аргентинлы Македонскийның үз машинасына да шундый нәрсә ябыштырган иде, әмма бу атаклы бандитның маягы күпкә куәтлерәк һәм аның таба алмасыннар өчен саклану чарасы да бар иде.

Нәкъ өч сәгатьтән, кичкә таба, Мәскәүдән Төньяк Кавказга таба бер-бер артлы өч машина кузгалды. Бик тиз эңгер-меңгер төште, юеш кар ява башлады, тайгак юл тиз йөрешле машиналарның да моторларын бар куәтенә эшләтергә мөмкинлек бирми иде.

## 10

Явып-томалап торган елак көн булгач, Карленның «гранд-чероки»е Тоглар машинасына якынрак булырга тырышты—әрмән егетләре аны күздән яздырудан курка иде, юкса, ана бары тик Чечнягә кереп житәр алдыннан гына сыланырга, шунда югалтмаска кирәклеген дә анлый үзләре. Хәйләкәр «гравер» үз командасына барасы юлның төгәл маршрутын тәки әйтмәде бит, Татлян аларның телефоннан сөйләшкәннәренең дә, Переделкинодагы кинәшмәдән язып алынган язмаларын да кат-кат тынлап карады: юк булгач, юк инде! Шуңа күрә Тогларны һич күздән ычкындырмаска кирәк, чөнки ул теләсә нинди хәйлә корырга, әйтик, юлда машинасын алыштырырга яки ниндидер аннан да остарак-акыллырак берәр гамәл кылырга мөмкин.

Македонский исә бераз ваемсызрак күренә иде. Ул белә: аның сәгате әле алда, аның өчен житди эш бары тик йөк машинага төялеп, «гравер» чечен авылыннан чыгып сызгач кына башланачак. Аның стиле шундый иде: ул һәрвакыт үзенең корбаннары инде беркемнән курыкмый һәм беркем кумаячагын белгәннән соң гына, көтмәгәндә һәм иң соңгы мизгелдә генә һөжүм итә. Үзе дә, артыннан куа килсәләр яки облава ясап, инде һәръяктан камап алдылар, дигәндә, иң соңгы хәлиткеч минутта чыгып ычкына белә, аның башы нәкъ шундый чакларда шәп эшли иде. Ул хакимият кешеләренен—ментларның да, жинаятьчеләрнең дә котын алып тора, чөнки тегеләре дә, болары да беләләр: бу ялгыз бүренең үз хөкеме!

Ләкин бу юлы Македонский ялгызы гына түгел, юл озын һәм ялыктыргыч, Чечнягә берүзең генә бару да кулай булмас, сугышчылар кирәк, үзе әйтмешли, «пехота». Ул ышанычлы кешеләрне, рэкет белән шөгыльләнүче «үгезләрне» сайлап алды. Аларның әле үз командалары юк, Мәскәү тирәсендәге Воскресенск шәһәрен кулында биетеп тоткан Анзорга хезмәт итеп йөрүләре иде. Анзор ул егетләрне утыз грамм героин бәрабәренә Македонскийга бер атнага биреп торды. Анзор өчен дә, «үгезләре» Влас белән Митя өчен дә Македонский читтән очып килгән «үрдәк» Станислав-Стас иде. Ул шулай дип таныштырды үзен. Ашарга-эчәргә, тартырга, хәтта спиртлы эчемлекләрне дә юлга иң яхшыларын алдылар. Музыкаль аппаратураның да дистәдән артык компакт-дискы бар—теләгәнчә тынла гына. Шуңа күрә егетләрнең кәефе күтәренке иде. Алар инде: «Әллә соң саранрак Анзордан шушы аз сүзле Стаска күчикме икән?»—дип уйлый да башладылар, чөнки Стас аларга отыры ошый бара иде.

Мәскәүдән «лендровер»ны Македонский үзе тотып барды, сонрак, төнлә рульне ул егетләрнең берәрсенә тоттырырга жыена иде. Машинада музыка уйный, Македонскийның да күнеле йомшабрак киткән чагы. Фонотекасын ул бик тырышып, үз зәвыгы белән сайлап кына жыйды, Париждамы, Лондондамы булсын, аның өчен вакыт таба иде.

Кар буй-буй булып ява, кайчагында бер-ике сәгатькә бөтенләй туктап та ала. Вакыт соң булуга карамастан, юлда машиналар тыгыз агым булып ага, Россиянең көньягына—Кубань һәм Краснодар ягына да, Мәскәүгә таба да сыпырталар гына, тегеләре дә, болары да, мөгаен,

Яна елны өйләрендә каршы алырга ашыгалардыр.

Влас анын янәшәсендә, алгы утыргычта утыра, ә Митя—артта. Ике утыргыч арасындагы юл өстәлчеген ачып куеп, алар акчага кәрт суга башладылар, үзләре бер-бер артлы «Карлсберг» сырасын бушатып кына тора. «Пехота»ны яраткан уеннарыннан аерасы килми, Македонскийнын үз уйлары да житәрлек иде. Ул юлда йөрүне ярата, ялгыз минутларда кинлекләр буенча очасын гына бит. Ниндидер үжәт бер кызыл «жигуленок», аларнын «лендровер»ы өстенә юлдагы пычракны сиптерә-сиптерә, ике мәртәбә куып узды инде, Македонскийнын ул машинада нинди тәвәккәл-әрсез кешеләр барганын беләсе килеп китте. «Алтылы»нын койрыгына тагылып, магнитофонын сүндерде дә, махсус тынлавыч техникасын кабызып жибәрде. «Лендровер» салонына шундук ят авазлар, көлешүләр килеп керде. Тәэсире шундый көчле булды ки, әйтерсен лә, күрше бүлмәнен ишеген шар ачып куйдылар. Бу көтелмәгән хәлдән сискәнеп китеп, «үгезләр» кәртләрен ташладылар да, «тылсымчы» Стаска сокланып карадылар—әле монын шундый хикмәтле мөмкинлекләре дә бар икән! Ә «жигуленок»та бераз төшереп алган егетләр-кызлар бара, кызларнын яннарында булуы егетләргә, әлбәттә, кыюлык өсти иде.

—Алдагы өченче булып баручы «Волга»ны тынлап буламы?—дип сорады Влас. Анын исе-һушы киткән иде—мондый техникан булганда, шәһәрдә чиксез мөмкинлекләр ачыла бит: машинада утыр да тынлап бар, утыр да тынлап бар—акчалы кешеләр икән, юл читенә кысып туктат та тала, бәрдереп алырга да була.

Македонский, приборнын ничек эшләвен күрсәткәч, ерактан идарә итә торган пультны Власка тоттырды, үзе егетләрнен, балаларча куана-куана, тынлау белән мавыгуларын көлемсерәп карап утырды, ә бит юкса бу «үгезләр» ничәмә-ничә кешенен канын койган инде.

Прибор бер йөз метрлар ераклыкта сөйләшкән тавышларны да тота, әмма, күп кенә машиналарда бер генә кеше утырып барганлыктан, тынлар нәрсә юк иде, шуннан Влас бер егермеләп машинаны узып китәргә сорады—алдарак берәр кызыклы сөйләшү тотып булмасмы, янәсе. Бер-ике мәртәбә шулай эшләп карадылар, кеше серләрен аулау Македонскийны туйдыра башлаган иде инде, шунда салонга кемнендер: «Тоглар... Чечня... баксалар...»—дигән сүзләре килеп керде. Башта Македонский, «гравер»нын машинасына артык якынайдык бугай, дип уйлаган иде, алай булып чыкмады—сөйләшү алдарак барган «джип-гранд-чероки»дан ишетелә иде. Ул Влас кулыннан пультны алды да игътибар беләнрәк тынлый башлады. Теге машинада өч егет бара икән, акцентларына караганда—кавказлылар. Македонский аларнын да Тогларнын серен белгәннәрен һәм аны ауларга барганнарын шундук анлап алды. Македонский приборын сүндерде, анын йөзе үзгәреп китте, баягы ваемсызлыгынын эзе дә калмады. «Пехота»нын кызыксынып тынлап барулары эшнен бозылуыннан саклап калды, менә шуннан сон очраклылык галиҗәнаплләренә ышанмый кара инде син! Ул көндәшләрне тизрәк юлдан алып ташларга кирәк, иртәнгә кадәр үк, иртәгә эш тагын да катлауланырга мөмкин, ә Македонский табышын беркем белән дә бүлешергә теләми иде. «Үгезләр» дә, Стаснын кәефе алмашынуын тоеп, сагаеп калдылар. Алар сәфәрләренен максатын да, шефнын уй-ниятләрен дә белми иделәр, чөнки ул аларга бернәрсә дә анлатып тормады, бары тик, күрсәтмәләр эш барышында бирелер, дигән сүзләр белән генә чикләнде. Егетләр Стасны куәтле «джип»тагы үзләренә анлашылмаган сөйләшү борчыганын сизенде, ә теге машина алардан өч машина аша алдарак бара иде, ләкин бернәрсә дә сораштырмадылар.

Сөйләшми-нитми, музыка да уйнатмыйча, бер ярты сәгать чамасы баргач, Стас, кинәт уянып киткәндәй, кискен генә сорады:

—Сез кара «джип-гранд-чероки»ны күрдегезме? Андагы егетләрнен сөйләшүләре кәефемне бозды...

—Күрдек,—дип баш какты Влас, ә Митя өстәп куйды:

—Әмма бернәрсә дә аңламадык...

—Ул безнең көндәшләр машинасы, шулар аркасында безгә бик зур күңелсезлекләр булырга мөмкин. Һич аңлый алмыйм, безнең юлга чыкканны алар каян белеп алганнар, әмма хәзер аңысын төпченеп торырга вакыт юк, Мәскәүгә кайткач ачыкларбыз,—дип усалланып әйтеп куйды Македонский. Аннары, шундук тавышын үзгәртеп, тынычрак дәвам итте:—бераз баргач, урман полосаларына житәрбез, алда-артта машиналар да булмас, тегеләр шәп җилдерә—йөз егермешәр километр белән куалардыр. Шунда яннарыннан узып киткәндә, ике «муха» гранатометыннан берьюлы бәрересез. Шул житәр дип уйлыйм.

—Житәчәк, Стас,—дип җөпләп куйды Митя.—«Джип» зур тизлек белән бара, алардан бернәрсә дә калмаячак.

Тагын сәгать ярымлап юл үттеләр, ә уңайлы вакыт һич кенә дә килеп чыкмый, киресенчә, каршыга килүче машиналар ташкыны тагын да куерды, ә һөҗүм итәргә җайлы урыннар һаман артта кала барды. «Пехота»ның киеренкелеген йомшату өчен Македонский аларга эчеп алырга, берәр нәрсә чәйнәп куярга тәкъдим итте—терәп диярлек атканда барыбер тидерми калу кыен булыр иде. Егетләр, аның тәкъдименнән бик риза булып, эчеп, нәрсәдер чәйнәштереп утырганда, Македонский машинага бензин өстәп алу да комачауламас, дигән фикергә килде һәм ярты сәгатьтән соң, ниндидер район үзәгенә житәрәк, юл буендагы бензостанцияне шәйләп алды. Алда баручы «гранд-чероки» да шунда борылды. Барып житкәч, Македонский Тогларның «УАЗ»ын да күрде, аларның чираты житеп килә иде инде. Беренче сыйныф дәреслегендәге кебек, барысы да дөрес: өч машина да Мәскәүдән бер үк вакытта диярлек кузгалды, хәзер инде дүрт йөз чакрымлап юл үтелде, һәрберсенә бакларын тутырырга вакыт житкән иде.

«Үгезләр» рәхәтләнеп ашап-эчеп утыра, шотланд виские «Джонни Уокер» шешәсенең төбенә төшеп киләләр һәм тиздән үзләренең гранатометтан атачакларын да оныттылар, күрәсең, әллә аңа артык әһәмият тә бирмиләрме? Алар да үзләреннән алда чиратта торган «джип»ны күреп алдылар, ләкин бернинди кызыксынулары да сизелмәде. Ул машинада кемнәр бара, ни өчен аларны атып юк итәргә кирәк? Алар өчен барыбер иде. Алар шулай бернәрсә уйламыйча, кушкан әмерне үтәргә әзер булып кына үскәннәр инде. Чират бер ун-унбиш минутлык бар иде, Македонский чыгып, бераз гәүдәсен язып алырга булды, әгәр җай чыкса, «джип» эчендәгеләргә дә күз салырга кирәк: кемнәр икән алар? Аннары, бензин өчен дә түлисе бар бит әле. Арткы утыргычта «үгезләр»нең берсенең чуар куртка-бушлаты белән солдат бүреге ята иде, Македонский шул бушлатны җилкәсенә элде дә машинадан чыкты, аны хәзер танырлык та түгел иде.

Яңадан кар ява башлады, ләкин төн уртасына таба салкынайткан, кар тыгыз ята, хәтта аяк астында шыгырдый да иде.

Тимер рәшәткәле тәрәзәчеккә илле литр бензин өчен түләгәч, Македонский чиратны күздән кичерде. Өстенә кар яуган, пычранып беткән «УАЗ»ик янында прапорщик погоннары тагылган бушлатлы, төп кебек тәбәнәк, әмма нык бәдәнле егет үзләре алдындагы соңгы машинадан шлангны үзенә бирүләрен көтеп тора иде. Ә «джип»тан әле беркем дә чыкмаган, чыгарга җыенганнары да күренми, күрәсең, колонкага килеп житкәч кенә кемдер йөгереп чыгачак, Македонский кавказлыларны яхшы белә—байларча кыланалар.

Прапорщик шлангның тимер очлы башын бензобагына тыккан иде инде, кинәт Македонский бер тәвәккәл уйга килде. Ул прапорщик янына барды да ярым пышылдап, тиз-тиз, серле итеп сөйли башлады:

—Тыңла әле, братан, мин дә сезнең арттан Мәскәүдән үк киләм, Ростовка барышым. Бер-ике сәгать элек юл буендагы кафега сигарет алырга дип сугылган идем, анда «джип-гранд-чероки» да тукталган икән,—ул Карлен машинасының номерын әйтте,—минераль су алырга кергәннәр-

ме шунда. Колагыма кайбер сөйләшкән сүзләре кереп калды, алар сезнен спецмашина турында сөйләште булса кирәк, сезне сагалап бармыйлармы икән? Саграк булыгыз. Алар өчәү, чеченнәр бугай, ә бәлки, дагстанлылардыр, алар бит барысы да бер төсле. Минем энем дә армиядә, синен кебек прапор, үзем дә стройбатта хезмәт иткән идем...—дип сүзен тәмамлады Македонский. Жилкәсендә эленеп торган бушлатын сикертеп, борынын тартып куйды, бу бик табигый килеп чыкты: кеше кешегә дус, иптәш, туган, янәсе.

Прапорщик бу ябыграк гәүдәле ир кешегә игътибар белән карап алды, аны-моны сизенмәде, елмаеп жавап кайтарды:

—Мөгаен, сез ялгышкансыздыр. Без хәрби лаборатория, радиация белән шөгыльләнәбез, безнен талатыр нәрсәбез юк, шулай да барыбер рәхмәт сезгә.—Шлангны үз артында чират торган шоферга тоттырып, Леха житез генә итеп машинасына кереп чумды. «Уазик»нын руле хәзер Картье кулында иде, ул Самурайны алмаштырды, ә анын янәшәсенә Тоглар үзе утырды. Леха, төннен калган өлешен Самурай белән бергә үткәрәчәген белгәч, шатланып куйды; Картены ул белми, анын белән автомастерскойда гына аралашты, ә тегесе аз сүзле егет булып чыкты. Дөрес, аны машинада да Мәскәүдән спутник элемтәсе буенча эзләп табалар, ләкин ул һәрберсенә: «Ял итәм, башкалага ике көннән—Яна елга кайтып житәрмен»,—дип жавап биреп бара.

Леха шундук үзенен элекке командирына, бер сәер кешенен, ул бензин алган чагында, нindидер сәер кисәтү ясаганын сөйләп бирде. Самурайнын хәтерендә Аргентинлынын «начар төше» янарды, барысы да төгәл туры килә: «джип», өч кавказлы... Һәм ул турыдан-туры сөйләп бирергә Городецкийга нindидер тормыш хәлләре комачаулагандыр, мөгаен, ул үзенен дусты Тогларны Чечнягә сәфәрдә артларыннан койрык тагылачагы турында искәртергә теләгәндер, дип анлап алды. Ләкин Самурай Аргентинлыны телгә алмаска карар кылды. Ничектер шәрекьчәрәк боргалап-сыргалап булса да кисәткәненә рәхмәт. Ул тиз генә машина салонын кабинадан аерып торган бүлемне шакыды. Тоглар тәрәзәне этеп ачты, Самурай ана әлеге күнелсез хәбәрне сөйләп тә бирде. Тоглар да ул «джип»ны әле Мәскәүдән чыкканда ук, якты чакта күреп калганын исенә төшерде, ул машина инде күптән үзләрен куып узгандыр яки берәр жиргә туктап калгандыр, дип уйлаган иде, андый куәтле машиналар, эчендә кавказлылар да утырганда, артта сөйрәлергә яратмый.

Яктырырга өч-дүрт сәгать калып килә иде, ә яктыргач бу мәсьәләне хәл итүе артык катлаулы яки, гомумән, сон булуы мөмкин. Тоглар, озын-озакка сузмыйча, әлеге кисәтүне тикшерергә кирәк тапты, ул бит командадагыларнын берсен дә рәтләп белми, безнен заманда кемгә булса да ышануы кыенлашканнан-кыенлаша бара, бәлки,кайсысы булса да кемгәдер «тишкәндер»—кем белсен?..

—Димәк, егетләр, вакыйгага карап эш итәбез,—дип, үз уй-ниятен анлата башлады Тоглар.—Син, Слава,—дип Картьега таба борылды ул,—жилдереп барсан да, як-ягынны игътибар белән күзәтеп бар. Казак станцаларына борылып керә торган берәр буш юлны күрсән, үндамы ул, сулда булырмы—барыбер, шунда борыл да унайлырак жирдә туктап, машинадан чык. Мин синен урынга күчеп утырам да авыл юлы буйлап алга куам, ә син телефонын белән берәр агачмы-куакмы артына яшеренерсен. Әгәр «джип» безне эзәрлекләп килә икән, ул, әлбәттә, безнен арттан борылып керер, син мина шылтыратып, хәбәр итәрсен. Шуннан эшкә Гера белән Леха керешер: мин аларны гранатометлар белән берәр унайлы жирдә төшереп калдырам да, үзем артык ашыкмый гына юлымнан дәвам итәм, кавказлылар мине күрә килергә тиешләр. «Джип» сезнен турыга килеп житкәч, егетләр, туп-туры атып шартлатасыз. Шартлау тавышларын ишеткәннән сон, мин кире әйләнеп киләм, сезне бер-бер артлы жыеп алам да, Алла боерса, без ярты сәгатьтән төп юлга чыгып та житәрбез. Ну, ничегрәк булыр бу тозак? Нинди тәкъдимнәрегез бар?

Команда каршылыксыз ризалашты, һәркем үз өлешенә төшкән эшкә әзерләнергә тотынды.

Нәкъ бер сәгатьтән Ярмолинская станицасына илтә торган юл өстендә, иртәнге сәгать биштә, кар баскан чөгендер басуларын янгыратып берьюлы ике шартлау ишетелде, бераздан Израиль автоматы «узи»дан кемдер бер тапкыр гына атып куйды. Машина шартлаганнан соң күтәрелгән ут баганасы тагын әле бераз вакыт сүнми торды, ләкин Ярмолинская юлы буш, ә янып яткан «джип» олы юлдан күренми. Юл буендагы урман куе, үзгәртеп кору чоры башланганнан бирле сирәкләнмәгән, ул инде кыргый чытырманлыкка әйләнеп беткән килеш тора, өстенә әкрен генә кар ява иде. Шартлау дулкыны шул урманга бәрелеп тынды да.

Тоглар, унайлырак урын эзләп барды-барды да, фермага таба аерылган юл чатында кире борылып, Леха белән Самурай янына ашыкты.

Әле ерактан ук, фаралары һәм янгын уты яктысында, ул барысы да, үзе уйлаганча, уңышлы килеп чыкмаганын күреп алды. Тирә-якка әче төтен таратып, «джип» әле һаман да янып ята иде, ара-тирә патроннар да шартлап-шартлап куя, күрәсең, кавказлыларның да коралы аз булмагандыр. Самурай исә кем өстенәдер иелгән дә, әллә ярдәм күрсәтеп маташа, әллә кемнендер соңгы сүзләрен ишетеп калырга тырыша иде. Леха беркайда да күренми. Самурай янына йөгереп килгәч, Тоглар кар өстендә яткан кешенең Леха түгел икәнен күрде. Бу—яхшы киемле, яшь бер кавказлы, башында бүреге дә юк, ул һич тә бандитка охшамаган, авыртудан чытылган йөзендә нindидер зыялылык бар иде. Тоглар бер карауда аның тиздән үләчәген аңлап алды, Самурай да моны аңлый, шуңа күрә бу кешедән, үлем алдыннан булса да, нәрсә булса сорашып калырга тырыша иде. Ләкин кавказлы егет бик авыр сөйләшә, сынып чыккан сул кулын күтәрмәкче була, мөгаен, кесәсеннән нәрсәдер алырга телиме, әллә каядыр күрсәтмәкчеме, әмма булдыра алмый. Шуннан ул кинәт пышылдап сөйли башлады:

—Мин—американ... Кесәмдә паспортым бар, документларымны алып китмәгез, мин исемсез үләргә тиеш түгел.—Ул акцентсыз, яхшы сөйли иде.

—Әгәр дә ни өчен безне әзәрлекләгәнегезне әйтсәң, калдырырбыз, алмабыз,—диде Тоглар кырыс кына, аннары егетне карт тупылның бозланып каткан кәүсәсенә сөяп куйды.

—Әйтәм, әйтәм...—дип гырылдады теге.—Хәзер инде сер яшереп торудан мәгънә юк, үлеп барганымны тоям. Мин ЦРУның «граверлар» аулаучы шымчысы, ә син—Тоглар, син бер детектор да тота алмый торган супербанкнотлар ясагансың.

—Син моны кайдан белдең?—дип, аның йөзенә үк ятып дигәндәй, кычкырып сорады Тоглар—егетнең тавышы сүнгәннән-сүнә бара иде.

—Мин синең акчаңны урлап качкан Натальяны эзләп таптым... Ул Парижда, нindидер модельерга кияүгә чыккан. Ул сине сатты да... Ә калганын... үзең аңлыйсың... Документларымны, зинһар, алма, әтиәниләрем мине үз куллары белән жирли алмасалар, кайгыдан үләчәк.

—Вәгъдә итәм...—дип кенә әйтеп өлгерде Тоглар, американ шымчысы жан бирде.

Тоглар шулай да аның документларын алып карады—егет алдамаган, ул, чынлап та, ЦРУ шымчысы һәм «Лос-Анджелес-таймс» газеты хәбәрчесе булган. Командировка кәгазенә «Жаһар Дудаевтан интервью алырга бара» дип язылган иде. Тоглар аның документларын урынына салып, эчке кесәсен төймәләп тә куйды. Егетне ул юл читенәрәк күчермәкче булды, әмма янәшәсендә Самурай юк иде. Тоглар кычкырып аны чакырды. Самурай юлның икенче ягыннан жавап кайтарды. Тоглар Леха белән дә нindидер бәла булганын аңлап алды. Шымчыны юл читенәрәк сөйрәп чыгаргач, ул Самурай янына йөгереп килеп житте.

—Мене, кайсысыдыр атып өлгерде, туп-туры йөрәгенә тигән. Мөгаен, алар безнең арттан коралларын әзер тотып куа килгәннәрдер,—

дип әкрен генә әйтте Самурай. Аннары өстәп куйды:—Ул сездән, эш унышлы чыкса, үзебезнен машинаны сорап алмакчы иде.—Кольцовнын тавышы калтыранып китте.

—Нишләтәбез инде аны хәзер?—дип сорады Тоглар, бередән тизрәк китеп ычкынырга кирәк иде.

—Кыш бит, мәжүсиләрчә күмәбез,—дип күрсәнде Самурай.—Ул безне гафу итәр дип ышанам. Кайсыбыз исән калса да, үлгәннәребезне искә алсын, чиркәүдә дога укытсын, шәм куйсын, хәзер андый гамәлләрне кылу кыен түгел.

—Ярый, әйдә, үзенчә эшлә...—диде Тоглар һәм борылып үз машиналары янына китеп барды...

## 11

«Лендровер», инде бер сәгатьтән артык Ярмолинскаяга кереп киткән юл борылышыннан ерак та түгел бер читтәрәк туктап тора иде.

—Бераз ял итик, әйдәгез, капкалап та алыйк, мин дә сезнен белән эчеп куярмын, арыдым,—диде Македонский, «уазик» белән «гранд-чероки»нын станицага таба борылып кереп киткәннәрен күргәч.

Ураза тоткан мөселманнар сәхәр ашаган шикелле, тан алдыннан ашап-эчеп утырганда, борылыш чатыннан олы юлга Тогларнын «уазиг»ы жилдереп килеп тә чыкты, Ростов ягына таба ажгырып китеп тә барды. Кара «джип» исә биш минуттан да, ун минуттан да күренмәде. Македонский Власка әйтте:

—Утыр рульгә, кузгалдык, ә мин бераз черем итеп алыйм, «гранд-чероки»га ау тәмам,—диде.

## 12

Иртән Тоглар үзенә таныш юлдан жилдерә иде инде. Узган ел Ставропольдән Андрюханын «Волга»сында үткән бу тирәләр анын күнелендә гомерлеккә уелып калды бит. Ирекә чыккан беренче көн иде ул! Ул вакытта Тоглар һәр авылны, юл буендагы һәр йортны комсызланып күзәтеп килгән иде. Һәм менә янә үз ирке белән Чечнягә китеп бара, юкса, теге чакта ул, Кавказга ике аягымнын берсен дә атламам, дип ант иткән иде бугай. Чит ил Кавказ, хәтта рус рухы өчен хәвефле дә. Аны тарихи яктан Россиягә ничек кенә бәйләргә тырышмасыннар, нинди генә уртак тамырлар һәм уртак стратегик мәнфәгатьләр эзләмәсеннәр—барыбер чит. Тогларны бу фикереннән берәү дә кире кайтара алмаячак. Шул кавказлылар турында бит инде, кайчандыр төрмәдә утырганда, Тогларнын беренче Остазы әйткән иде: «Бүрене бүреккә салсан да—урманга карый»...—дигән иде. Вакыт Остазы сүзләренен дөреслеген раслады. Сүз унаеннан шунысын да әйтергә кирәк: шактый еллар үткәч, Остазны нәкъ шул кавказлылар суеп чыктылар да.

Рульне Картье тоткан иде, станица юлындагы вакыйгадан сон, сөйләшми генә бардылар, чөнки сүз жилеме юк, ябышмый иде. Үз кулында үлгән кавказлынын сөйләгәннәренә шикләнми ышанган Тоглар һаман да ул шымчыны кем аны әзәрлекләргә юнәлткәнлеген уйланып бара торгач, көтмәгәндә кинәт кенә әйтеп куйды:

—Беләсенме, Слава, «джип»тагыларнын берсе америкaн булып чыкты бит, «Лос-Анджелес таймс» гәзите хәбәрчесе...—диде, ләкин анын үлем алдыннан ачылып сөйләгән сүзләрен әйтми калдырды.

—Анын исеме Карлен Татлян идеме?—дип, уйлап та тормыйча, шундук сорады Картье. Бу сорау Тогларны гажәпләндерде:

—Әйе, шулай. Ә син аны каян беләсен?

—Узган ел ул ни өчендер минем белән бик кызыксынып йөрде, ачыктан-ачык түгел, билгеле, әмма мин аны сизенә идем,—дип сөйләп

китте Неделин, юлдан күзен алмыйча гына.—Кая гына бармыйм, һәркайда ул иде. Мәскәүдәге бер генә житди очрашу-жыелышларны калдырмый йөрде, шуннан мин аның Америка газеты хәбәрчесе икәнлеген белеп алдым. Аның бер сәер гадәте бар иде, ул «крутойлар» жыелган һәм күп акчалар әйләнгән жирләрдә—казинода, катраннарда, «Пекин»да, төнге бар һәм рестораннарда булырга тырыша, ә инде Хавтанның «Золотой петушог»ында даими йөри иде. Мин Леонид Андреевичны ана күз-колак булырга кисәтеп тә куйган идем әле. Аннары ул американ һәрвакыт ике әрмән гангстеры белән килә иде. Ни өчен минем белән шулай кызыксынганын тәки аңламадым,—дип, сүзен төгәлләде Картье, аннары өстәп куйды:—Бәлки, шул ереванлы бандитлар аны сезнең эзгә бастырганнардыр, ә?

Тогларга хәзер һәммәсе дә ачык иде. Константин Николаевич американ шымчының—«граверлар» аулаучының ни өчен Неделин артыннан күзәтеп йөргәнен төшенде—шымчы Картьены ялган долларларга катнашы бардыр дип шикләнгән. Ә Картье шикләндерерлек тә шул: акыллы, купшы-көяз, типтереп иркен яши, ярлы түгел.

Ләкин Тоглар сүздә башкачарак әйтте:

—Кызык... Рәхмәт, эшнең нәрсәдә икәнен ачып бирдең, юкса, мин интегеп уйлап килә идем: нәрсәгә, ни өчен?

Картьеның шулай чишелеп сөйләве Тоглар күңелендәге шикне юып төшерде. Ул бу егеткә беренче мәртәбә ихлас караш ташлады, Неделин ышанычлы егет икән.

Чечнягә барып житәргә ике сәгать чамасы ара калгач, Тоглар туктап ял итәргә, ашап алырга карар кылды һәм юл буенда кала барган авылларны карый килде. Тиздән алар тукталырдай бер авыл күренде. Юл буенда гына ашханә-трактир шикелле бина тора, аның ишеге янына ук калмык далаларыннан китерелгән курдюклы өч сарык түшкәсе эленеп куелган, алъяпкычы иткә-канга буялып беткән ит чабучы тукталган халыкка үзләре теләгән кисәкне кисеп алып бирә иде. Шар ачык ишектән тәмле исләр бөркелә, ә арттагы бер почмакта, аулаграк урында ачык мангалда шашлык кыздырганнары күренә. Трактир хужалары әрмәннәр булып чыкты—Горбачев заманында Бакудагы чуалышлардан соң качып киткәннәр икән.

Үткән-сүткәннәрнең күзенә артык чалынып тормасын дип, машинаны ишегалдына ук кертеп куйгач, тәмәке төтене тулган залга үттеләр.

Үзләре каршысына йөгереп килгән хуждан Тоглар:

—Ә биредә чыш-пыш пешерәләрме?—дип сорады. Андый азыкчы бары тик Бакуда гына пешергәннәрен белә иде ул.

Хужа Тогларны игътибар белән күздән кичерде дә, елмаеп жавап бирде:

—Нинди сүз булырга мөмкин? Вакытыгыз бар икән, әзерләрбез. Үземнең дә кинәт шуны ашыйсым килеп китте әле,—дип өстәп куйды Элвис Преслига бик тә охшаган юан хужа.—Ә хәзергә аш бар, күфтә ашы, кыздырылган бәрәнгеле сарык кабыргалары, төрле шашлыклар—иттән кирәкме, бавырданмы, мәрсин балыгыннан да эшли алабыз—Донда балык бетмәгән әле. Аракы янына аз тозланган уылдык белән тагын балык кисәкләре бирергә була.—Бу кешеләр кай яклары беләндер хужаның күңеленә хуш килгән иде.

Тогларның шундук кәефе күтәрелеп китте:

—Вакытыбыз житәрлек,—диде ул.—Ераграк бер почмакта табын әзерлә, яна тотылган мәрсин балыгы булса, шашлык та кыздырыгыз, кискәләп тә пешерегез, ни-нәрсән бар—һәммәсен китерегез, бигрәк тәмле итеп сөйлисең. Чыш-пышны да онытма, егетләрне сыйлыйм әле бер. Хәзер аларга Бакуга барулар бик тәтемәс инде, бөтенләй аерылып беттек бит.

Табын янында утырганда, ул Самурай белән Картьега чыш-пышның нинди ризык икәнен сөйләп бирде: аны сарыкның эче-бавыры, картасы кебек нәрсәләреннән пешерәләр икән—теленне йотарлык тәмле була, ди.

Трактирда һәркемнең авызында бер генә сүз: Чечня... Сугыш

башланган икән инде, моны иртәнге якта юлдагы машиналарның икеләтә-өчләтә артуыннан да чамалап була иде. Машиналар тоташ бер ташкын булып агыла—халык кача... Леханың якты истәлегенә сүзсез генә эчеп куяр алдыннан Тоглар Грозный шәһәренең карта-схемасын җәеп салды да, игътибар белән өйрәнә-укый башлады: аларга Чечня башкаласы аша республиканың эченә—тауларга таба үтеп китәргә кирәк иде.

Карангылангач, алар кунакчыл трактирдан чыгып киттеләр, артык утырырга унайсызландылар. Хуҗа үзе озата чыкты, төн куна калуларын үтенде, әмма кунакларның риза булмаганнарын белгәч, аларга уныш теләде һәм кире кайтуларына бер дуңгыз баласын шундый тәмле итеп кыздырып куячагын әйтте, егетләрнең андый ризыкны әле гомергә ашаганнары юктыр, диде. Китканда Тоглар хуҗадан, җиде-сигез кисәккә бүлгәләтеп, бер ун килограмм чамасы чи ит сорап алды. Егетләр башта аңлап бетермәгән иде, аннары төшенделәр: алар барып керәсе йорт ишегалдында бәйдән ычкындырылган өч эт булачак бит—күчтәнәч ит шулар өчен иде.

Грозныйга керү юлындагы Россия гаскәрләренең блокпостына төн уртасына ярты сәгатьләр кала килеп төртелделәр. Документларын бик ныклап тикшерделәр, яшерен командировка язуын да күрсәтергә туры килде, «уазик»ның эченә дә кереп чыктылар. Кизүдә торган майор Тогларга иртәнгә чаклы көтәргә киңәш итте, шәһәр эчендә бик каты сугыш бара икән. Чеченнәр, танклар колоннасын бер каршылыксыз шәһәргә үткәргәннәр дә, аннары һәр кварталда алдагы танкны яндырып, калганнарын бүлеп куйганнар—ни алга, ни артка юл калмаган, шуннан соң танкларны гранатометлардан атып берәм-берәм кырырга тотынганнар, хәтта Россиянең иң яңа коралы «шмель»ләр—«шөпшә» белән дә яндырганнар—аларны Мәскәүнең хыянәтче генераллары һәм казна караклары Чечнягә калдырып киткән икән. Шәһәр эченә шулкадәр танк кертеп тутыруны чеченнәр өчен бүләк кенә дип санарга да була, йөзләрчә яшь танкистларны күрәләтә үлемгә җибәргән генералның исемен ил бирәр вакыт белә алырмы икән? Әмма Тоглар кизү майорга үзенең төнгә генә исәп тотканын, иртәнгә инде, яшерен йөкне төяп, майор алышынганчы бирегә кайтып җитәргә чамалаганын әйтте. Шуннан соң майор, Тоглар кулындагы картаны алып, Грозныйның хәвефсезрәк үтәрдәй урамнарын кызыл карандаш белән билгеләп бирде. Ул билгеләнгән урамнар шәһәр читендәгеләр—Тоглар трактирда чамалап куйганнары белән тәңгәл килә диярлек иде.

Шәһәргә килеп кергәч, чеченнәр аларны ике мәртәбә туктатып карарга маташтылар, һәрберсенә Тоглар ерактан ук, аларның әмерен үтәргә җыенгандай, машинасының йөрешен әкренәйтә дә, килеп җиткәндә генә, патруль тикшерергә әзерләнеп юл читенә төшеп баскач, кинәт кенә тизлеген арттыра да алга ыргыла—көчәйтелгән мотор мондый хәйләне эшләргә мөмкинлек бирә иде. Арттагы көпчәкләргә һәм броняланган ишеккә чеченнәрнең сонлап атып калуларыннан бер зыян да килми. Грозныйда алар сугышның ни-нәрсә икәнен чын-чынлап тойдылар. Якты ялкыннар бөркеп, шәһәрнең төньяк чите, андагы нефть эшкәртү заводы яна, үзәктә шартлау тавышлары, автомат тырылдаулары, танк пушкаларыннан аткан тавышлар ишетелә, тозакка эләккән танкистлар янып яткан машина эченнән дә бар көчләренә сугышып азаплана иде. Әйтерсең лә, ниндидер коточкыч «бәйрәм» төне: күккә минут саен яктырткыч ракеталар чөелә, төшкәндә алар явып торган карны матур итеп җемелдәтә, әмма бу төндә ул матурлыкны кем дә булса күзәтеп тора алдымы икән?

Рульне Тоглар тотып бара иде, төнге сәгать икенче яртыда, Грозныйдан исән-имин чыгып шактый юл үткәч, тау итәгендәге ниндидер авыл башында бер караңгы һәм кешесез-нисез тыкрыкта машинаны акрынайтып, ул кинәт кенә Картьега әйтеп куйды:

—Менә без килеп тә җиттек, Картье,—диде.

Неделин, уңга карагач, биек таш койма белән әйләндереп алынган йортны күреп алды, төн булуга карамастан, йортның уң канатындагы ике тәрәзәдә дә ут күренә иде. Картье шундук диварларына кышлык

суган бәйләмнәре эленгән тар коридорны күз алдына китерде, аннары ике бүлмә булырга тиеш, шуларның берсендә подвалга төшә торган капкач бардыр—бу сызым-планны алар ятлап бетергән һәм ул яшерен подвалга дөм карангыда да барып керә алырлар иде, мөгаен.

Картье, артындагы тәрәзәне ачып, килеп життек дип, Самурайны кисәтергә җыенган иде, Тоглар аны тыеп калды:

—Ашыкма, әле иртәрәк. Тук корсакка бераз йоклый торсын, без ана бер яналык та әйтмәячәкбез. Мәскәүдә уйланган план үз көченде кала. Тәрәзәдәге утларга караганда, йөгебез урынында булырга тиеш. Ләкин без тагын бер-ике сәгать көтеп утырырбыз әле, житди эшләр, иртәнге сәгать өч-дүртләрдә башкарыла, уңышлы чыга, үз тәжрибәмнән беләм. Ә хәзергә, бер квартал ары китеп, тегермән янында туктарбыз, атлар куяр өчен түбәсе каплаулы ышык-куләгә урын бар, шунда керербез. Аннан безгә йорт эчендә кайчан ут сүнгәне күренеп торыр.

Тоглар сүзләрен әйтеп тә бетермәде, гүя бер тылсым белән тәрәзәләрдәге утлар кинәт сүнде һәм йорт тирәсе карангыга күмелде. Шуннан сон, әйтерсен лә, бәла киләсен сизгәндәй, бер эт елаган сыман улап жибәрде, Тоглар, тынлый төшеп, анын Казбек икәнен абайлап алды.

Тегермән янына кереп туктагач, Тоглар белән Картье машинаның салонына—Самурай янына күчтеләр, тегесе уянган һәм тиешле урынга килеп житкәннәрен анлаган иде инде. Мәскәүдә кабат-кабат тикшерелгән план буенча, сонгы өлешендә эшнен юан башы Самурайга төшәргә тиеш иде. Тоглар исә егетләр подвалга барып житкәч кенә ишегалдына керәчәк иде. Леха үлеп калганнан сон, хәл үзгәрде, хәзер Тоглар аларны машинада көтеп утырмаячак, урамда саклап торачак, ләкин барыбер, егетләр сакчыларны хәл иткәннән сон, ул үзе дә йорт эченә керергә тиеш була. Самурай Аргентинлының кырыс кисәтүен исендә тота—хужаның исән калуы бар нәрсәдән дә кадерлерәк.

Алдан уйлаганча, этләргә ашатырга агуланган итләр әзерләделәр, инструкциясендә бер сәгать чамасы кала агуларга кушылган иде. Аннары һәркайсысы үзенең кечкенә генә респираторын киеп карады, бауларын жайлап куйды—спецназ егетләре аны «борынчык» дип кенә атап йөртә. Пассажирлары-ние белән самолет яки автобус кулга төшерелгән террорчыларга каршы Израиль коммандослары куллана торган нерв параличлаучы газ файдаланырга килешеп куйган иделәр. Газнын төсе дә, исе дә юк, ул радиация шикелле, аны һич сизмисен, әмма бик тиз һәм көчле тәэсир итә, биш-ун минут дигәндә, өч-дүрт сәгатькә теләсә кемне һушыннан яздырып тора.

Тагын бер сәгатьтән сон, алар йорт янына жилгә каршы килеп туктадылар, монысы сак этләр алдан сизенмәсен өчен шулай эшләнде. Аннары Тоглар үзе ишегалдына әкрен-тын гына кисәк-кисәк ит ыргытырга тотынды. Бары тик дүртенче кисәктән сон гына этләрнең, кар өстендәге ит кисәкләрен тоеп, шатланып чинашканнары ишетелде. Барлык итләрен дә ташлап бетергәч, ул, игътибар белән тынлый-тынлый, койма буйлап китте һәм өч этнен дә шытырдата-шытырдата итле сөякләрне ашаганнарын ишетте. Янадан машинага кереп утырдылар—этләр бик тә түзем жанлы була, әмма, тәжрибә күрсәткәнчә, берсе дә бер сәгатьтән артык тора алмый, егетләр исә агуны кызганмыйча сипкән иде. Шулай да көтәргә булдылар—вакытлары житәрлек иде әле.

Тоглар: «Килеп життек»,—дип белдергәннән бирле Неделин анын серен чишәргә, анларга тырышып баш ватты: тау итәгендә утырган бу аулак авылда нинди бик кыйммәтле йөк булырга мөмкин икән? Әмма бер генә анлаешлы жавап та таба алмады. Ә бит монын сере, һичшиксез, бар, дәлиле—американ шымчысы, ЦРУ офицерынын үлеме. Бәлки, алтындыр? Россиянен алтын приискаларында, әле патша заманнарыннан бирле үк, алтын кабул итүче һәм аны саклаучылар булып буыннан-буынга ингушлар белән чеченнәр эшләгәнен Картье яхшы белә иде. Алтын комы яки саф алтын кисәкләре ике чечен авылына жыела килгән,

алар һәрвакыт дәүләт казнасындагы алтыннардан да ким булмаган, хәтта аларны килограммлы кирпечләр итеп тә койганнар. Бәлки, Тоглар чеченнәрнең шул алтын серләренә төшенгәндер? Ләкин алтын тагын да ышанычлырак, ныграк сакланырга тиеш, аннары килеп, Җаһар Дудаев идарә итә башлагач, ул алтыннар, һичшиксез, Швейцариянын ин абруйлы банкларына күчерелгәннәрдер. Ничек кенә баш ватсаң да, Тогларнын серен әлегә чишеп булмый, аны соңрак барыбер чишәргә туры киләчәк иде.

Машинада тагын бер кат коралларын һәм фонарьларын тикшереп алдылар. Көчле ябыштыргыч жилемле кечкенә газ балоннарын бик игътибар белән карап чыктылар, ул балоннарны шул жилемнәре белән теләсә нинди ярыкка яки йозак тишегенә ябыштырып куеп була иде. Йортның уң канатындагы ике тәрәзәдә ут сүнгәнче үк, Тоглар Неделинга тәрәзәләрнең форточкалары ачык икәнлегенә ымлады, алардан салкын урамга пар чыгып тора иде. Уртадагы карангы бүлмәнен бердәнбер тәрәзәсендә дә шундый ук форточка бар. Авыл йортларынын форточкалары кечкенә-тар, ике рам арасына газ балоннарын ябыштырып кую—бер минутлык эш. Газ басым белән керсә дә, тавыш-тынсыз була, бары тик форточкаларны тышкы яктан ябып, биш-жиде минут көтәргә генә кала. Шул арада Самурай белән Картье уң канаттагы һәм уртадагы тышкы ишекләрне отмычка, ягъни теләсә нинди йозакны ача торган ачкыч белән ачарга тиешләр. Ишекләрнен берсе ачылса, икенчесен ачып торасы да юк—бүлмәләр эчтә коридор белән тоташкан.

Сәгать төнге дүртенче яртыда алар йорт янына ук машина белән килеп туктадылар. Самурай, «уазик»нын түбәсеннән биек таш койма аша ишегалдына төшеп, капканың эшермәле бикләрен ачты да кечкенә капкадан Картьены кертте. Картье газ балоннарын уң канаттагы тәрәзәләргә, ә Самурай уртадагы тәрәзәгә куярга юнәлде. Тоглар, бандитларның хыялы булган кыска автомат тотып, машина янында калды, урамны күзәтүдән бигрәк, аның игътибары ишегалдында иде. Самурай тиз генә балонын эчкә ябыштырып куйды да форточканы япты, аннары ишеккә китте. Ишекне ачу иң кыены булырга мөмкин иде, әмма ишек, шыплап ябылган булса да, аны бикләмәгәннәр икән. Әллә онытканнар, әллә кемдер төнлә үз йомышы белән тышка чыгып кергән, әллә кичтән үк кемнедер көткәннәр—уйланып торырга вакыт юк. Самурай ымлап кына Картьены чакрып алды һәм ишекнен ачыклыгын күрсәтте. Ишек янында ук кулдан ясалган зур гына чана сөялеп тора икән. Мөгаен, анын белән сарайдан йортка утын-күмер ташыйлардыр,—самурай чананы болдыр янына ук китереп куйды. Әгәр дә, Тоглар уйлаганча, төргәкләр урынында булса, аларны тиз генә чанага төяп, капкадан алып чыгып китәргә дә булыр, шулай тагын өч-дүрт минутны отарга жай чыга. Бу серле йорт яныннан никадәр тизрәк сыпыртсан, исән калу мөмкинлеге дә шулкадәр үк артачак иде.

Вакыт акрын үткән шикелле. Самурай әледән-әле сәгатенә карап ала. Ниһаять, ул: «Вакыт...»—диде һәм дуслар, кигән борынчыкларын төзәткәләп, ишекне сак кына ачтылар. Аллага шөкер, ишек шыгырдамады да. Тоглар сызып күрсәткән план буенча, алар каравылчыларнын кайсы бүлмәләрдә булырга тиешлеген белә иделәр. Берсе уң якка, икенчесе сул якка кереп китте. Ишек төбеннән үк бүлмәдәгеләрнең гырылдап йоклаганнары ишетелеп тора. Уң канаттагы бүлмәләрнең берсендә тимер караватларда өсләренә спорт костюмы кигән ике егет йоклап ята, һәркайсынын янында идәндә иске генә автоматлары да бар, бүлмә диварына таба борылып йоклаганынын мендәре астыннан ТТ» пистолеты күренеп тора. Картье, ышанычлырак булсын өчен, каравылчыларга газ сиптерде дә, коралларын алып, тәрәзәсез икенче бүлмәгә кергәч, утны яндырды. Шул бүлмәнен уртасындагы тапталып беткән иске келәм астында подвалга төшә торган капкач булырга тиеш. Картье келәмне күтәреп ачып куйган арада Самурай да килеп керде, капкачны күргә, ул йөгереп чыгып

китте. Тогларга хәбәр итәргә кирәк!—Хәзер эшкә тотынырга аның чираты житкән иде.

Тоглар, Самурайның гажәпләнүенә каршы, кулына фонарь тотып подвалга төшеп киткән Картье артыннан ашыкмады, ә диварга элеп куелган бер иске келәм янына килеп, аның бер почмагын күтәрде дә, шундагы ут кабызгычка басты. Подвалда ниндидер механизм эшли башлады, иске таз, камыттыр-иярдер, йөгәндер-фәләндер, киптерелгән кызыл борыч бәйләмнәре, башлы кукурузлар элеп куелган диварларның берсе шаулап ачылып китте. Шул дивар артында чечен акчаларының көтмәгәндә, кирәге чыкканда тотыла торган бер өлеше сакланучы яшерен урын бар иде. Шуннан соң Тоглар, бүлмәдәге тагын бер кабызгычка басып, подвалда ут яндырды һәм шуннан соң гына Самурай белән Картье янына төшеп китте.

—Яртысын алырга өлгергәннәр...—дип, үзе дә сизмәстән сүгенеп куйды Тоглар. Калын идән такталарыннан ясалган киштәләрдә төргәк-төргәк ниндидер кәгазьләр өелеп тора иде.—Утыз ике,—дип, аларны тиз генә санап алды ул.

Тиз-тиз генә алып чыгарга кушып, үзе берьюлы дүрт төргәкне эләктерде дә баскычка ташланды. Аның артыннан күтәрелгән Самурай Тогларга янадан подвалга төшеп тормаска, ә машина янына барып, үзләрен урам яктан сакларга кушты—йорт эчендә аларга хәзер бер куркыныч та янамый иде инде. Төргәкләрен күтәргән килеш, Тоглар өйдән чыгып китте, калганын егетләр үзләре дә майтарачак иде. Төргәкләрен машина эченә ыргыткач, ул урам уртасына чыкты, почмакка кадәр барып, тыкрык ягына карады—чечен авылы ваемсыз йокыда шикелле иде.

Төргәкләр үтә күренмәле таза пленкалар белән пөхтәләп төрелгән, Картье белән Самурай ул төргәкләрнең бары тик ниндидер бухгалтер бланкалары икәнлеген генә күрделәр—мондый йөк өчен миллионнар түләп, гомерләрен куркыныч астына куеп тормас иде Тоглар, димәк, янә ниндидер сере бар моның. Төргәкләрне ачып карап та булмый, алар бик ныклап нейлон баулар белән бәйләп куелган. Егетләр, сөйләшеп тә тормастан, бәлки, эчләрендә нәрсәдер яшерелгәндер дип, аларны селкеткәләп тә карадылар, әмма авырлыгы да гел кәгазь генә икәнлеген күрсәтә иде шикелле. Әлбәттә, бухгалтер кәгазьләре түгелдер инде, нинди дә булса үтә яшерен архив, ниндидер документлар булырга мөмкин. Кремльнең совет чорыннан соңгы хурлыклы серләрен Чечнядән алып чыгу өчен кеше гомерләре дә кызганыч түгелдер, дип уйлады Самурай белән Картье.

Калган егерме сигез төргәкне тиз генә чанага төяделәр дә, ишекне ябып, чананы капка ягына өстерәп китеп бардылар. Картье машина эченә керде һәм Самурай биреп торган төргәкләрне пөхтәләп контейнерга тезә торды—барысын тутырып бетергәч тә бераз буш урын калачак иде әле.

Самурай Картьега соңгы төргәкне биргәндә, тыкрыктан кинәт кенә бер кеше килеп чыкты—хужаларның оныгы Шамил иде ул. Иптәше белән көне буе Грозныйда булган да, бер сәгать элек кенә кайтып, иптәшендә ашап чыккан, хәзер өенә ашыга, иртәгә янадан башкалага китәргә кирәк иде—ул кайтасы булганга күрә, ишек тә бикләнмәгән икән.

Үз йортлары янында автомобиль торганны күреп алды егет, нинди дә булса машина килү турында көндез бер сүз сөйләшмәгән иделәр бит. Машина янында бер кеше дә шәйләнә иде. Шамил усал гына тавыш белән чеченчә сорады:

—Сез кемнәр?!

Кем килеп чыкса да, аны атып үтерергә тиешле Тоглар, егетне тавышыннан танып, бер мизгелгә югалып калды, аннары шулай ук чеченчә җавап бирде:

—Шамил, бу мин, Тоглар... кире кайтырга уйладым, Россиядәге тормыш минем өчен түгел икән хәзер...—дип, сөйләнә-сөйләнә, ул Шамилгә таба килә башлады. Исәбе—егетнең игътибарын алып, якынайгач,

сугып мингерәтү иде. Аны атып үтерергә кулы күтәрелмәде Тогларның, бу чечен егете ана бик кешелекле карый иде бит.

Бәлки, шулай барып та чыккан булыр иде... Шамил шатланып нәрсәдер әйтте дә Тоглар каршысына китте, ләкин нәкъ шул вакытта машина артыннан Самурай күренде, чечен егете, үзенә куркыныч янаганын сизенеп, Самурайга беренче булып атып җибәрде. Үзеннән берничә адымда гына торган Тогларга атарга өлгерә алмый калды Шамил: йомшак кына аткан тавыш ишетелде—Картье да төз ата иде, егет шундук авып төште. Картье белән Тоглар икесе дә Самурайга ташланды... Аны-моны уйлап тормыйча, Самурайның гәүдәсен машина эченә күтәреп салдылар да, кабаланып кабинага кереп утырдылар—«УАЗ»ның моторы эшләп тора иде, берничә минуттан машина Грозныйга бара торган юлга ажгырып килеп чыкты...

## 13

Яна маршрут белән Грозныйдан чыгып ычкыну кыенрак иде—хәтта шәһәрнең кырый урамнарында да сугыш бара, кайбер урамнарда ашыга-ашыга баррикада коралар, һәркайда патруль өстенә патруль: спорт курткалары кигән чечен егетләре, хәнҗәр һәм кылыч таккан, инде күптән онытылган агач кобуралы маузерлар аскан, папахалы чечен картлары... Бер чаттагы янган БТР янында үтерелгән өч солдат ята иде, Картье тоныш тавыш белән әйтеп куйды:

—Әйдәгез, Германны да шулар янәшәсенә салып калдырыйк. Сугыш тынгач, күмү командасы мәетләрне җыеп алыр, кешечә итеп җирләрләр,—диде. Неделин Грозныйны рус гаскәрләре бүген булмаса, иртәгә басып алыр дип ышана иде.

Алар туктадылар, тиз генә машинадан өстерәп алып, Кольцов-Самурайны пычрак кар өстендә яткан яшь солдатлар янәшәсенә сузып салдылар. Күңелләреннән генә аның белән хушлашкач, янә урамнар буйлап борыла-борыла, шәһәрдән тизрәк Ростов ягына чыгып китәргә ашыктылар—яктырып килә иде инде.

Бер сәгатьтән соң, инде бөтенләй яктырып беткәч, чеченнәрнең күп тапкырлар атып калуларына карамастан, алар үзләре Чечнягә килеп кергән юлдагы таныш блокпост янына барып чыктылар. Андагы чиратның очы-кырые күренми иде. Тоглар, үзләренең биредә ике дә, өч тә сәгать тоткарлану мөмкинлеген чамалап, төнлә озатып калган таныш майорны күрү өмете белән, җәяүләп кенә аны эзләп китте.

Тогларны күргәч, майор шатланып сорады:

—Өлгердегезме?—Соравына унай җавап алгач, ул радиацион лаборатория хәрбиләрен чиратсыз һәм тентүсез-нисез бик тиз үткәреп җибәрергә боерык бирде.

Чечнядән бер илле чакрымлап юл үткәч, Тоглар машинасын туктатты да, урынын Картьега калдырып, арыган тавыш белән әйтте:

—Бәлки, безгә берәр тынычрак урында туктап, өч-дүрт сәгать йоклап алыргадыр. Югалтулар белән булса да, без үз өстебезгә төшкән бурычны үтәдек, ә кайтасы ара якын түгел, юлы да бозлавыклы, тайгак, җитмәсә, кары явып тора, алда тагын төн дә бар бит әле...—диде.

Картье, бераз уйланып torгач:

—Теге әрмән трактирына барып җитсәк, яхшырак булмасмы? Анда кадәр тагын бер өч сәгатьлек юл калгандыр, шунда ашап, төнгә кадәр йоклап та алырга булыр иде,—диде.—Хуҗа машинабызны да аулаккарак кертеп куяр, үзебезгә дә тыныч урын табар дип ышанам, ул мина бик матур тәэсир калдырган иде,—дип өстәп тә куйды.

Шулай хәл иттеләр. Урыннарын алышып утыргач, юлны дәвам иттерделәр. Тоглар, башын артка ташлап, гел йокымсырап барды, күрәсең, киеренке халәттә булу, хәвеф, озынга сузылган төн үзен сиздерә иде, аннары яше дә бар бит инде, ул күз алдында ябыгып киткәндәй булды.

Ә Картье һаман да радиацион контейнерда нинди яшерен-серле әйбер алып кайтулары турында, Мәскәүгә кайтып житкәнче ул кәгазьләрнең серен белеп булырмы икән, дип уйлануыннан туктамады. Хәзер инде аны башкасы да кызыксындыра: бу хәтәр сәфәр өчен түләргә миллионнарны Тоглар кайдан алыр икән? Чечнягә үзләренең йә акча, йә ниндидер бик кыйммәтле әйбер алырга барганлыкларына Картьеның иманы камил иде. Тормышларын куркыныч астына куеп, иптәшләре үлеп кала-кала, чечен авылыннан алып чыккан әйбер хисабыннан түләрләрдер инде аңа. Кыскасы, Картье тәмам буталып бетте, ул нәрсә кылырга да белми иде... Бәлки, ашап-эчеп, ял итеп алганнан соң, Тоглар үзе ачыклап сөйләп бирер әле.

Юл буендагы әрмән трактирына төш вакытында гына килеп життеләр. Хужа абый, аларның икәү генә кайтып кергәннәрен күргәч, хәвефләнеп сорады:

—Ә өченчегез, Герман кая? Ул теге чакта бавыр шашлыгын бик яратып ашаган иде...—диде.

—Калдырырга туры килде аны, шулай килеп чыкты инде,—дип, хәрбиләрчә кыска гына җавап бирде Тоглар.

—Ә мин, вәгъдә иткәнемчә, дуңгыз баласын әзерләп куйдым. Хәзер мин аны кайнар мичкә тыгып пешереп алам да бер кырык минуттан табында булыр,—дип кабалана башлады хужа.

Шуннан Тоглар аны бер читкәрәк алып китте дә: «Ашап-эчкәннән соң, йоклап аласы иде, төнлә генә юлга чыгар идек»,—дип әйтте.

Әлбәттә алар, Леха белән Самурайны янә искә төшереп, сүзсезнисез генә эчеп куйдылар, аннары трактир хужасы аларны үз өйләренә алып кайтып китте. Казак станцасының бер кырыенда ул үзенә ике катлы таш йорт та салып куярга өлгергән, аны биек таш койма белән әйләндереп алган, гаражы да, мунчасы да, каралты-куралары да житешле икән.

—Рәхәтләнеп ял итегез. Без хатын һәм бала-чагалар белән барыбер төнгә кадәр трактирда чуалабыз,—диде киң күңелле әрмән. Тогларның юмарт түләгәнен истә тотып булса кирәк, аңа йорт һәм гараж ачкычын да биреп калдырды.—Йоклап туйгач, трактир янына килеп туктарсыз, юлга чыгар алдыннан тагын ашап-эчеп, житәрлек бензин алып, Мәскәвегезгә кайтып китәрсез...—диде.

Әлегә һәммәсе дә бик унай гына килеп тора иде. «УАЗ»ны тимер капкалы бетон гаражга кертеп, бикләп куйдылар да хужаның кунаклар өчен икенче катта калдырган йокы бүлмәсенә күтәрелделәр. Ярты сәгатьтән алар үлеп йоклый иделәр инде.

Бер өч сәгатьләп йоклагач, Тоглар икенче ягына әйләнеп ятарга теләгән иде, кинәт кенә инсәсенең каты авыртуын тойды. Әле уянып житәр-житмәстән, үзенең ниндидер тозакка эләккәнлеген аңлап алды: сул кулының беләзегеннән богаулап куйганнар икән аны... «Кем эше?—дигән ачынулы уй йөгереп үтте.—Эзәрлекләүчеләрме, трактирчымы, Картьемы?» Күзен ачкач, Тоглар келәм жәелгән бүлмәдә йомшак күн курткалы, уртача буйлы бер кешенең әрле-бирле йөренгәнен күреп алды. Ул кешене трактирда да шәйләмәгән иде, чеченнәргә дә охшамаган үзе. Күз кырые белән генә карап алгач, гырлап йоклап яткан Картьеның да салынып төшкән бер кулының жылыткыч батарея тимеренә богаулап куелганын күрде, егет әле, үзенә килгән бәлане сизенмичә, йоклап ята иде.

Тоглар, кискен йолкып, богау чылбырын өзәргә тырышып карады—беренче карашка богауның чылбыры нечкә генә күренә иде, әмма бик нык икән. Аның уйларын укыгандай, дөбердәгән тавышка теге таныш түгел кеше борылып карады.

—Уяндыңмы?—дип сорады.—Ә менә богауны өзәргә маташырга кинәш итмим, сыналган... Немецларның атаклы «Крупп» фирмасы ясаган аны, алар ясаган һәр әйбер ышанычлы.—Бу кешенең соравында да, калган сүзләрендә дә ясалмалылык, мыскыл итеп көлү сизелеп тора иде.

Тогларның башыннан яшендәй ярып бер үк уй үтте: бу адәмне ул

әллә беләә, әллә аның турында ишеткәне бар инде. Тегенең тәкәбберлеген жуярга теләп, ул катгый итеп сорау бирде:

—Син кем? Миннән сиңа нәрсә кирәк?

Бүлмәдәге тавышка Картье да уянды. Тогларга ярдәмгә ташланмакчы булып, караватыннан ыргылды, ләкин шунда ук кулының каты авыртуыннан кычкырып жибәрде. Тоглар Картьеның бу вакыйгага бернинди катнашы да юклыгын төшенде.

—Мин кемме?—дип, һаман да тыныч, ясалма көлемсерәп сорады теге адәм.—Һәм жавабын да көттереп тормады:—Мин—Македонский...

Тоглар шундук Аргентинлының бу атаклы бандит турында чынын да, ялганын да кушып сөйләгәннәрен исенә төшерде. Үзенең өметсез хәлгә тарганын, ничек булса да, сиздермәскә кирәк иде—инде югалтасы нәрсәсе калмаганлыктан, Тоглар да тыныч кына жавап бирде:

—Ишеткәнем бар... Синең әкәмәтләреңне беләм. «Матросская тишина» төрмәсеннән сиңа кадәр берәүнең дә кача алмаганын белгәч, үзенә сокланып та куйган идем әле. Ләкин ике мәртәбә утырып чыккан, дип сөйләгәч, син дә минем хакта ишетеп беләсеңдер?—диде ул.

—Әйе, син хаклы. Мин синең легендар Тоглар икәнлегеңне беләм. Мин беренче качканда, сиңа тапшырырга дип, Соболь бер язу кисәгә—малява сырлап биргән, синең миңа ксива белән ярдәм итүеңне үтенгән иде...

—Мин сине хәтерләмим...—дип бүлдерде аны Тоглар.

—Ә мин сиңа барып житә дә алмый калган идем шул, мине Төмәндә үк яңадан тотып алдылар, кемдер саткан...

Тоглар үртәлебрәк сорады:

—Сиңа бездән нәрсә кирәк соң?

—Акчаларыгызны алмакчы булам. Ышаныгыз, алар сиңа караганда миңа күбрәк кирәк.—Македонский Тогларның күзенә керердәй булып карап тора, үзе аны гүя күрми дә иде.

—Тончыкмассыңмы соң? Анда бит миллионнар,—дип кызып китте Тоглар, аннары бөтенләй усалланып өстәп әйтеп куйды:—Син бит беләсең, безнең законнар буенча, ул минем табыш, синең аны тартып алуың хурлыклы түбәнлек, кабахәтлек, западло булачак. Бу вакыйга кайчан да булса бер тишелеп чыгар, озак яши алмаячаксың бит. Бик күп абруйдәрәжәле кешеләрнең сиңа үче бар, ә минем канны коюың братваның түземен төкәндерергә бик мөмкин...

Аларның сүз көрәштерүеннән Картье өсләренә кем килеп кергәнен аңлады—Македонский турында ул, әлбәттә, ишетеп белә иде. Үзләре алып чыккан төргәкләрдә акчалар, хәтта доллардардыр, дигән уй да аның миенә барып житте. Ләкин хәзер Чечнядән алган табыш турында түгел, ә гомереңне саклап калу турында уйларга кирәк иде. Үзләренең бары тик акча артыннан гына шундый хәтәр юлга чыкканлыкларын аңлагач, Тогларның да КГБ мәгълүматларында күптәннән инде автоавариядә һәлак булган, «гравер» булып хисапланган кеше икәнлеген төшенде.

—Кайнарланма, Тоглар,—дип, бүлмә буйлап йөренеп, янадан Македонский сөйләп китте.—Аңлыйм сине, борын төбеңнән генә шундый табышыңны йолкып алсыннар да, тыныч калып буламы соң? Ләкин, мин сине хөрмәт итмәсәм, братва өчен кылган яхшылыкларыңны белмәсәм, үлек булган булыр идең инде. Миңа сезнең икегезне дә атып үтерү берни тормый бит, ә контейнерыңны ачкычсыз да ача ала идем, хәзер бит лазерлы кискечләр бар. Акчагызны алырмын, ә сине Ростовта төшереп калдырырмын. Дустыңны шушында бетерермен, артык шаһитлар булуын яратмыйм, житмәсә, ул безнең кан кешесе дә түгел шикелле...

—Юк!—дип, сискәнеп китеп, кистереп әйтте Тоглар.—Бу эшкә аны мин күндердем, аны миңа бик абруйлы кешеләр тәкъдим итте.

Аннан соң, ул мине үлемнән саклап калды: әгәр ул вакытында төз атып екмаган булса, мине чечен егете чәрдәкләп бетергән булыр иде, мин үлемнән ике адымда басып тора идем... Үтерергә булсаң, икебезне дә үтер...

—Ярар алайса, аны үз өстенә аласың икән—яшәсен әйдә,—дип кенә ризалашты Македонский һәм пистолетын курткасының эчке кесәсенә яшереп куйды.—Ә хәзер базарны бетерербез, тиз генә—машиналар янына! Богауларыгызны Ростовта гына алырбыз. Гараж, машина һәм контейнер ачкычлары кайда?

Тоглар ишек буена эленеп куелган полковник погонлы курткасына күзе белән генә ымлады.

Македонский ишек ягына карап:

—Влас!—дип кычкыруга, бүлмәгә шундук үгез муенлы бер егет килеп керде, аның нинди вазифа башкарганлыгы сүзсез дә аңлашыла иде. Македонский ана ачкыч бәйләмен ыргытты:—Ачкычларны Митяйга бир, «УАЗ»ны гараждан чыгарсын. Ә син, богаулы килеш, бу кешеләрне берәм-берәм машина эченә кертеп утыртырсың. «УАЗ» руленә үзем утырырмын, ә син болар белән—салонда, кара аны: ике күзең дүрт булсын! Митяй «лендровер»да безнең арттан килер...

Ярты сәгатьтән соң, тиз йөрешле ике машина, юлдагы төн караңгылыгын көчле галоген фаралары белән яктырта-яктырта, Ростов ягына таба җилдерә иде инде. Әллә төн салкынайткан, әллә Чечнядәге сугыш гаишникларның кикрикләрен шиңдергән,—хәзер бик үҗәтләнеп-тентеп торсаң, маңгаена пуля утыртулары да бик мөмкин чак,—шуңа күрәдерме, Ростовка барып кергәнче аларны бер дә туктатмадылар. Еракта Ростов тирәләрендәге шәһәр яңы утлары күренә башлагач, «УАЗ» туктады, Македонский, тәрәзәне ачып, Тоглардан аларны кайда төшереп калдыру җайлырак булырын сорады. Тоглар, бераз уйланып торгач, «Редиссон-Ростов» кунакханәсе янында, дип җавап бирде. Чечнядән кайтуы янә шул кунакханәгә килеп тәртелде.

—Ә мин сине, Тоглар, буш кул белән иреккә җибәрмим бит,—диде Македонский, кулларын руль өстенә куеп.—Мәскәүдә ике еллап инде Новокузнецкийдан килгән банда котырына, «күкшелләрне» дә, банкирларны да, ментларны да өркетеп бетергән алар. Банданың соңгы башлыгы Шкабара Көнбатышка гаять күп акчалар күчереп өлгергән, мин синнән тартып алганнан да күбрәктер. Ләкин ул үзе Вена шәһәренә чыгып таяр алдыннан гына аны кулга алганнар һәм ул соңрак төрмәдә асылынып үлгән. Акчаларының кайсы кайда икәнлеген энәсеннән җебенә кадәр белгән бухгалтеры качкан, ә акчаларны алырга кирәкле кәгазьләре юкка чыккан. Мин, бу хикмәти вакыйганы белеп алгач, бухгалтерның эзенә төштем—аның кушаматы Гном икән, ул сезнең бер братвагызда сак астында булган, мин аны аңардан урлап алдым, хәзер ул минем кулда. Документ кәгазьләренең очы-башы бөтенләйгә югалган бугай. Әмма Гномда аларның ксерокс күчермәләре калган, мин аларны җентекләп өйрәнеп чыктым. Иртәме-соңмы, мин барыбер сиңа килгән булыр идем, шул күчермәләрдән тиешле ышанычлы документларны ясап бирүенне үтенеп. Мин сиңа шул күчермә кәгазьләр-ниләре белән Гномны бирәм, калганын үзең майтар, өлешенә кермәскә вәгъдә итәм. Миңа тагын чыгып качарга туры килсә, бәлки кайдадыр Женева күле буендагы вилланда миңа да җылы урын табарсың. Тормыш итәр өчен бик уңайлы, бик матур урыннар бар анда. Мин, качканнан һәм яраланганнан соң, шунда дәваланып, ял иттем, көч җыйдым...

—Кызык...—диде Тоглар, үзенең җинелгәнен таныган иде бугай инде. Әлбәттә, Шкабара һәм аның бандасы турында ул ишеткән, хәтта Македонскийның Гномны кемнән урлап алып киткәнен дә белә иде, ләкин бу хакта сүз куертып тормады.—Әйт әле, шушы хәтле күп акча сиңа нигә кирәк булды?—дип, кинәт кенә сорап куйды ул.—Бик зур сумма бит. Бәлки, сиңа егерме-утыз миллионы да житәр, ә?

—Юк, Тоглар, миңа йөз миллион да житмәячәк,—дип аңа каршы төште Македонский.—Саранланма, мин сиңа күбрәк бирәм. Иртәгә син ул кәгазьләрне кулыңа алырсың һәм моңа ышанырсың.—Македонский Картье белән Тогларның богауларын ачып алды да, Тогларга Гном сак

астында тотылган йортның адресын һәм ачкычын суздың.

—Син соравыма җавап бирмәдең,—диде Тоглар.—Яки ул серме?

—Миңа акчалар нигә кирәкме?—дип, көлемсерәп кайтарып сорады Македонский.—Мин сиңа шундый теория сөйләп бирә алам... Антантаның 1918 елда Россиягә каршы ачыктан-ачык хәрби интервенциясе дә бүген хакимият башына үрмәләгән кабахәт-сатлык җаннарның ил-дәүләткә китергән зыяннары белән чагыштырырлык түгел. Мин кем? Әйе, бандит... Ләкин үзем туып-үскән җирем-ватаным өчен йөрәгем авыртa минем. Бер мин генә шундый түгел. Минем фикердәшләрем дә бар, аларга мин ышанам, алар да илебез язмышына битараф түгелләр. Сүз уңаенда әйтеп узыйм, «Матросская тишина» төрмәсеннән качарга алар ярдәм итте миңа. Шуннан соң мин үземә-үзем ант иттем: хыянәтчеләр һәм һәртөрле кабахәтләр белән аяусыз көрәшәчәкмен, дидем. Ә минем кулдан күп нәрсәләр килә, син моны беләсең. Ләкин моның өчен акча кирәк, бик күп акча, бик тиз, кичектергесез, бүген үк...

Шул арада «УАЗ» кунакханә каршындагы мәйданчыкка йомшак кына килеп туктаган иде инде. Влас сораулы карашын хуҗага төбәде: ары таба нишлибез, янәсе.

—Ярар, хушыгыз,—диде Македонский һәм, ишекне ачып, әсирләрен төшереп калдырды.

Тоглар белән Картье, борылып та карамыйча, бер егерме адымнар китеп баргач, аларны янә Македонскийның тавышы куып җитте:

—Тоглар, тукта әле! Мин синең чал чәчләрең алдында бераз гаделсезрәк кыландым шикелле. Мә, ал...—Македонский ике төргәк «бухгалтер кәгазьләрен» ыргытты да, «УАЗ», аның артыннан «лендровер» бер чаттан борылып, төн караңгылыгына кереп югалды...

Тоглар Картьега карап алды, егетнең күз карашында ышанмаучан мыскыллы елмаю чагыла иде. Димәк, ул да Македонскийның әкиятләренә ышанмаган... Нинди Ватан, нинди ил ди ул бу ата бандит өчен?! Ул бүрегә ил-Ватан шайтаныма кирәкме? Акча—карак өчен дә, кабахәт сәясәтчеләр өчен дә шул гына—Алла. Шул акчалар аркасында, имән кебек Леха чыгарып ташланган эт кебек кар астында ятып калды, утны-суны кичкән Самурай да шул акчалар аркасында үлде, аны-моны уйламыйча, артларыннан куа чыккан әллә әрмән, әллә америкaн Карлен Татлян һәм аның дуслары да шул акча өчен Аллаһы Тәгаләгә җаннарын тапшырдылар. Йә, чиратта тагын кемнәр?

Тоглар бер урында басып катып калган килеш, кар өстендә яткан төргәкләргә таба Неделинның ашыкмый гына атлап барганын күзәтеп торды—бу ике төргәк аларның зур уныш вә өметләренең кыйпылчыклары гына иде шул...

Ә Тогларның артында утларын балкытып, музыка яңгыратып, зиннәтле-бай «Редиссон-Ростов» кунакханәсе тора. Һичкемгә, һичнәрсәгә карамастан, анда, беркайчан да өзелеп тормыйча, туктамыйча, тормыш туе дәвам итә иде.

*Марс Шабаев тәрҗемәсе.*



## Марат Закир

### ВАКЫТ АТЫ

**Уян!**

**... Һай, ай-һай,**
**Татлы да соң йокы...**
**—Уян!—**
**Яңгыратып төчкерде ТАҢ—**
**Исәнлеккә бу!—күрерсең,**
**Олы Төнгә өлгерерсең,**
**Уян, дускай, тор син, тор син!**

**Вакыт аты кешни анда.**
**Вакыт аты,**
**Вакыт аты!**
**Солы сыман сибелеп кала**
**Асыл көннәр бер-бер артлы...**

~

**Базар читендә бер карт—**
**Ап-ак кәфендәй бер карт—**
**Юмарт кына елмая:**
**«Сатам!**
**Хагы да—юк хак...**

**Гомер буе тупладым,**
**Алыгыз, хәләл малым:**
**Хаталарымны сатам,**
**Алтындай хаталарым...»**

---

Марат ЗАКИР (1969)—*шагыйрь, прозаик. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

## Фәрештә

*Яшьли вафат булган әниемнең якты истәлегенә.*

Коръән язуыдай изге сырлар иңгән иде аның күз төпләренә. Корьән битләре сыман иде куллары да ул фәрештәнең.

Рөхсәт итә иде ул безгә гел канатларын алып торырга. Һәм без күтәрелә идек ул канатларда йолдызларга—югарыга!

Әй, шатлана иде ул әнем белән минем болытларда мәтәлчек атканны күреп. Карын ачкач, без дә кайта идек әзер табынга җилкенеп. Без биектә-биектә кичергәнне бер-беребезне бүлдерә-бүлдерә сөйләгәндә йотлыгып-йотлыгып тыңлый иде ул тын гына, сыйпый-сыйпый өстәл ашъяулыгын. Әмма без аңламый идек, әле без аңламый идек шул безнең өчен бу дөньяның сүздән түгел, СИНнән башланганын.

Беркайчан да сөйләмәде үзе, бахыр, канатларының каян килүен сөйләмәде. Сөйләмәде беркайчан да—без йоклаганда, безне калдырып, ни өчен күккә күтәрелмәвен—сөйләмәде...

Сизенгәнсеңдер. Сизенгәнсеңдер... Очып калсыннар!—дигәнсеңдер...

## Көзге манзара

Шәмдәй каеннарга Кояш
Ялкын үрләтеп мәш килә...
Әйтерсең лә көя төште
Урманның алтын шәленә—

Сыдырды да көяз җилкәй
Шәлнең бер куәнәгеннән,
Хушлашты урман
сул-кыл-
дап,
Хушлашты көзге ямь белән.

## Хәер соранучы

Йә Хода!—
Кып-кыска кул сузган икмәкне
Алыр өчен дә, кара:
Никадәрле озын икән бит,
Озын икән бит... ара.

## Матурлык

1

Затлы итеп бизәлгән биек сәхнәгә гади генә киенгән бер кыз бала чыгып басты. Башта ул шигырь сөйләде, аннары ул җыры белән аларның күңелен ачарга тырышты. Залда утыручы түрәләрнең, яңа байларның кашы җыерылды:

—Кая матурлык? Кая монда, ә натуре, матурлык?!

Аның күңеле түгелде.

Үзен танымаганнарына Матурлык гаепле түгел иде...

**2**

**Тагын да затлырак сәхнә түрендә (менә бу—да-а, ичмасам!)—жем-жем—кызыл күлмәге!—Тыпыр-тыпыр биш баса! —Иреннәре тәмләп татырлык!—Күчмә Кызыл Байрак шикелле, кулдан-кулга китте Матурлык...**

## Көзге халәт

*Күзләреңне зәңгәр томан сарыр*
*Иделләрдән күзең алмасаң...*

**Дымлы көзләр китте—**
**Дымлы күзләр...**
**Томан сарган Идел буйларын.**
**Йөрисеңдер син дә аргы ярда**
**Уйларыңның тыңлап юк-барын!**

**Йөрисеңдер син дә ерак ярга**
**Дулкыннарны кире озатып.**
**Йөрисеңдер син дә, минем сыман,**
**Еракдагы ярга күз атып.**

**Кавыштырмас ярны-ярга дулкын,**
**Дәвам итәр Идел йоклавын.**
**Дымлы күзең йомып елмай да син,**
**Уйларыңның ташла юк-барын.**

**Дымлы күзең йомып елмай да син,**
**Оныт инде, оныт һәммәсен!**
**Тик онытма, зинһар, бергә кичкән**
**Мизгелләрнең асыл мәгънәсен.**

**Җансыз суда үрсәләнгән ялгыз**
**Сары яфрак зарын тыңлама!**
**Дымлы күзләр аша дымлы көздә**
**Дөнья үзе тоташ дымлана.**

**...Дымлы көзләр, күзләр—бар да дымда,**
**Иләсләнгән маллә бу дөнья?**
**Тыпырчына дымлы ярлар анда**
**Әйләнергә теләп бөтенгә.**

**Дымлы күзләр, көзләр—һаман дымда.**
**Киптералмас барын мең кояш!**
**Исе дә китми син елмайганга—**
**Башкаларга килә бүген ЯЗ!**

## Капка төбендә

**Яфрак кебек коела көннәр, коела көннәр... Ә өйдә мәңгелек белән бәхәсләшә мич артындагы чикерткә...**

**Нигә икән бу җанга мең елга җитәрлек, бушанмаслык САГЫШ иңгән... Нигә икән?!**

**Бөгәрләнгән гәзит диярсең: бөгәрләнеп бетте яктылык. Аннары: «иртәгә, бәлки әле, төшәрмен дә», дигән сыман гына, сабыр атлап, тирәк яфракларына баса-баса, баскыч буйлап югарыга менеп китте яктылык.**

**Эңгер-меңгер... Бабайларның гына башы—якты-ак.**

## Бер ачыш

Сынганчы гына,
Сынганчы гына
Дәһшәтле икән
Сөңге очы да...

## Ирек

Ачып чыгардылар кенәрине читлегеннән иркен залга. Әмма талпынды ул ирек өрәге артыннан иксез-чиксез дөньясына! Һәм... Бәрелеп үлде тәрәзә пыяласына...

Була мени ярым-йорты ИРЕК—йә бар ул, йә юк. Бәхет сыман, сөю сыман ул—йә бар, йә юк!

Язмыш каршында—Татар иле... Ә ирек?

## Татар тормышы

Бер тарафтан бер тарафка, җил уңаена таралышып, агып бара гамьсез болытлар...

Көлә-көлә көләч ал таңда чалгы җырын тыңлый үләннәр...

Төшләрендә балта-пычкы күреп, шомланышып шаулый имәннәр...

Шулай яшәгәннәр. Шулай яшәделәр... Оныклар да шулай яшәрме?

## Караңгылык

*Күрәп алырлык, күрәп алырлык*
*Күрәгең булса—караңгылык.*

Дөм караңгы тарафлар...
Әллә бу
Алла каһәрләгән якмы соң?
Коры хыял сыман тыпырчына
Ерактагы йолдыз яктысы.

Якты көтә кавем ничә гасыр—
Хәттин ашкан мәнсез сабырлык.
Бу кавемнең мәнсез сабырлыгы
Җенне хәтта егып салырлык.

Мәрткә киткән илнең күзен беркөн
Караңгыдай кара кан баса.
Килә!—
Җитә!—
Сыта!—
Кара язмыш,
Чакма чагар затың калмаса.

Кара таңнан кара төнгәчә ул
Кара тиргә батып бил бөгә.
Кемдер аны каулый караңгыдан—
Арттан кага кемдер дилбегә.

Бүлгәләргә teлəп бу кавемне
Төрле яктан аңа кем дәшә?—
Әрле-бирле йөри караңгыда,
Корбан эзләп йөри каһкаһә...

Бүлгәләргә теләп, кара затлар
Аны йөртә упкын тирәли.
Нигә бу кавемгә караңгыда
Тавык күзле күзнең кирәге?!

Бүлгәләргә теләп, кара җаннар
Бутап куйган аның кыйбласын.
Адаштырмас юлга тартыр затың,
Чакма чагар затың кайда соң?!

Сыңар очкын җитәр иде бәлки
Киптерергә канлы күз яшен.
Әмма күрәчәген бик шәп күрә:
Белә кавем гүргә керәсен.

Кара янып көйгән бу кавемне
Кара хөкем, кара үч баскан.
Каһәр суккан мәлгунь караңгыны
Озатырга иде ичмасам—

Бармы караңгыны тансыклаган,
Бармы җирдә шундый бер халык?!
Ыргытырга иде күрәп алып,—
Тик...
Күрәп алып ыргытырлык
Күрәге юк шул, күрәге юк...

## Мамык дивар

Сөйләдем кайгыларымны—
Елмаялар төркем-төркем.
Шатлыгымны чиштем сезгә...
Чиштем—тыңламады беркем.

Җырлап үттем сезнең яннан,
Җылап үттем, сүгенеп үтәм...
Ишетмәде мамык дивар!—
Әйтмәс булдым сүзне бүтән.

Әй, бичара—битарафлар,
Әйтмәм сезгә сүзне бүтән!
Әйтерсең лә кала тулы,
Кала тулы—күзле бүкән.

Бу дөньяда үлемнән дә
Җан өшеткеч тагын ни бар?—
Тупыл мамыгыдай йомшак,
Салкын кардан салкын дивар!

—Нишлисең син, җүләр,—диеп
Бармы берәү кызыксынган?
—Дөрләтергә бу диварны,
Ут төртергә шырпы сызам...

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Әсгать Салах

# СОҢГЫ ВАЛЬС

ПОВЕСТЬ

*Чернобыль атом электр станциясе һәлакәтенә юлыгып вафат булган энем Әгъдәснең якты истәлегенә багышлыйм.*

Автор.

Авырсынып кына килүенә карамастан, бу курорт Газизгә ошады. Сигез катлы бина борынгы Болгар иленең диңгез кебек җәелеп киткән кин һәм мул сулы олуг Чулман елгасы буенда, кояшка йөзе белән яткан иркен калкулыкта урнашкан иде. Әле автобуста чагында ук балконнары кызыл төскә буялган ак кирпеч бинаны күреп, әллә нидән тынычланып калды ул. Ә инде ишекне ачып керү белән пөхтә, ак киемле, ачык йөзле кызлар аның юлламасын алып бүлмәгә дә урнаштыргач, алдагы шөбһәләнүләреннән җилләр исте. Сирәк булса да, курортларның төрлесендә дәваланырга туры килде аңа. Төрлесендә төрлечә кабул иттеләр, төрлечә дәваладылар. Биргәннең битенә карама, диләр. Кайсыннан ярыйсы гына канәгать булып, кайсыларыннан игътибарсызлыкка гаҗизләнеп, ачка какланып кайткан еллары да булды. Ә монда... Кызларның гел үз итеп каршы алулары эретте дә салды. Якты йөз, тәмле сүз. Үзеннеке үзәктә икән шул. Үз җирең, үз кешеләрең, үз телең...

—Әйдә, абый җаным, түрдән уз, тартынып торма. Юлда талчыккансың да бугай, нигәдер бик йомшак атлыйсың...

Адымнары йомшарды, авырайды аның соңгы вакытта—бусы хак. Сәламәтлеге шаптан түгел—бөтен сәбәп шунда. Яшьнәп торган яшьлеге үтте инде. Илле яшь—ир уртасы, дисәләр дә, Газиз Солтанов өчен түгел

Әсгать САЛАХ *(1935)—язучы, публицист; «Аккан сулар», «Балыкчы малайлар» һ.б. китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

бу сүз. Күкрәге көчсезләнеп китте әле аның. Авыртмаган жире юк хәзер. Кояш күрмәгән гөл сабагыдай, көннән-көн югара, хәлсезләнә бара.

Шуны аңлап, яшь табибә аңа аерым игътибар күрсәтте, озак итеп хәлен сорашты, тикшермәгән, тыңламаган жирен калдырмады. Аннары мөмкин булган барлык дәваларны аның курорт кенәгәсенә язып куйды.

—Тормыш мәшәкатьләрегез турында бөтенләй онытып, кайгылы уйларыгызны ташлап, тыныч күңел белән дәваланыгыз, ял итегез, абый. Процедуралар алу чорында бер-бер хәл туса, турыдан-туры үземә керегез. Сәламәтләнеп, Алып батыр кебек тазарып, көч жыеп китәрсез бездән, иншалла,—диде ул, олыларга хас теләктәшлек күрсәтеп.

Дистәләгән минераль матдәгә бай шифалы суы, югары дәрәжәдәге дәвалау ысуллары белән танылган бу шифаханәдә яшәү өчен дә, дәвалану, ял итү өчен дә бөтен шартлар бар икән. Кечкенә булса да, якты, уңайлы бүлмәләр, һәрберсендә телевизор, жылы суы, ваннасы, бинаның беренче һәм икенче катларында төрледән-төрле процедура алу бүлмәләре, минераль су ванналары, бассейны, коры мунчасы, ашханәсе, кинозалы... Газиз кебек сырхаулар өчен бу бигрәк тә мөһим, һичберкая чыкмыйча дәвалан да ят. Ашау—байдан, үлем—Ходайдан...

Бүлмәдәше дә үз кеше булып чыкты—Арча ягыннан Габделфәт атлы, үз яшендәге тыйнак, сабыр холыклы авыл кешесе. Ул инде бер атна дәвалана икән бирелә, шифаханәнең эчке тормышы, тәртибе белән дә яхшы ук танышкан. Газизне дә үзе белән алып, дәвалану урыннарын күрсәтеп керде. Аннары алар бергә иртәнге ашны ашарга, дәвалар алырга төшеп киттеләр.

Газизнең тормышында, әнә шулай, үзгә көннәр башланды. Көндезге ике-өчләргә кадәр төрле процедуралар ала, шул арада төшке ашка да кереп чыга, вакыт эләксә, аннары бүлмәсендә бераз ял итә, кичен исә дәвалану мәшәкатьләреннән арынып, беравык телевизор карап ята.

Ә бу вакытта бүлмәдәше Габделфәт киенеп-ясанып концерт яисә спектакль карарга төшеп китә, шөкер, шифаханәнең тамашачылар залында һәр көн күрше калалардан килгән артистлар чыгыш ясап торалар— берсеннән икенчесе кызыграк көлкеле спектакльләр дә, жырлы-биюле концертлар да өзелми анда. Ә алардан соң ял итүчеләрнең олысы-кечесе ашханәгә бару юлындагы киң һәм озын коридорда даң-доң килгән музыкага иркенләп бер биеп, танцы итеп ала. Габделфәт аларны да калдырмый. Тик ул Газизне боларның берсенә дә чакырмый, кыстамый, аның үз хәле үзенә житкәнен күреп тора.

Шулай көн артыннан көн дигәндәй, беренче атна үтеп тә китте. Режимлы дәвалану, тәмле ашау-эчү, дөнья мәшәкатьләрен онытып ял итү нәтижәсез калмады күрәмсең, Газиз арык тәненә ит кунып, үзенә хәл кергәнен сизә башлады. Кәефе дә күтәрелде. Моны Габделфәт тә абайлады:

—Күз тимәсен, матураеп барасың, курорт килешә үзеңә,—диде ул аңа чын күңелдән. Ә кичен аны танцыга кузгатты:

—Әйдә, ятма пыскып, хәрәкәттә—бәрәкәт. Биючеләрне күрерсең, үзеңне күрсәтерсең...

Өстерәп алып чыккан кебек булды ул аны. Габделфәттән күрмәкче, киемнәрнең дә пөхтәсен киде Газиз. Ашханәгә бару юлы халык белән тулган, даң-доң килеп бар көченә ниндидер чит телдә колагына чөй тыксаң да чыдый алмаслык каты тавышлы музыка яңгырый, бернинди калыпка сыймас мәгънәсез тамаша бара: кайсы аякларын чалыш-полыш китереп бөгелә дә сыгыла, кайсы кыеш-мыеш килә, кайсы анасы сөтенә туенган кәжә бәтие кебек тук-тук сикерә, ә кайсылары бер урында таптанып тора. Шулар арасында, әнә, Габделфәт тә баскан килеш ике якка чайкала.

Газиз бер почмактагы йомшак эскәмиядә танцы дигән шушы тамашаны гажәпкә калып карап утырды-утырды да, аптыраганнан көлемсерәп, урыныннан кузгалды. Өске катка, бүлмәсенә менеп китәргә иде аның исәбе.

Шулчак залда таныш музыка яңгырый башлады. Чү, вальс түгелме соң бу? Йә Хода, вальсны да уйната беләләр икән бит әле биредә, вальсны да онытмаганнар. Газизнең яшьлек юлдашы, мәңге ашкынулы, мәңге дәртле, мәңге яшь вальс. Йөзләгән уен коралларыннан торган зур оркестр башкаруындагы бу музыка бер-бер артлы йөгерешкән тынгысыз дингез дулкыннарын хәтерләтеп, көчәйгәннән-көчәя барды һәм су буйлык озын һәм киң ашханә юлын, аннан вестибюльне, баскычлар мәйданын, шифаханәнең икенче, өченче, дүртенче катларын яулап алды. Газизнең кинәт аяк бармакларыннан алып баш тиресенә, чәч төпләренә чаклы кайнар чымырдау үтте, әйтерсең лә аны кинәт кенә көчле электр тогына тоттылар. Әмма рәхәт, ләззәтле чымырдау иде бу. Вальс... Күптән ишеткәне юк иде аның мондый таныш, җанга рәхәт музыканы... Туктале, тукта, нинди вальс соң әле бу? Һичшиксез, Штраус, Йоһан Штраус вальсы. «Вена урманы әкиятләре», «Язгы авазлар»... Та-та-та, та-та-та... Кайсысы соң әле боларның? Тик «Гүзәл зәңгәр Дунайда» түгел, аны Газиз аерым хәтерли.

Яшь чагында Газиз боларның барысын да белә иде, чөнки аз биемәде ул вальска. Бу яктан колхоз авылыннан чыккан мишәр егетенең бәхете булды. Бер килмәсә, бер килә, диләр бит. Армиядә хезмәт иткәндә кино карарга аларны гарнизондагы бердәнбер Офицерлар клубына йөртәләр иде. Шунда ул клуб мөдире, Новосибирск егете Рәшит белән танышты. Ике татар баласы дуслашып киттеләр. Рәшит клубта танцы түгәрәгенә дә алып бара икән. Авиация полкы очучылары, башка офицерлар, аларның яшь, гүзәл хатыннары, җитеп килә торган сылу кызлары атнасына ике тапкыр кичкырын танцыга өйрәнәләр.

—Мин монда чагында танцыга өйрәнеп кайтып кит, үкенмәссең,— диде Рәшит.

Аның нинди талантка ия егет булуын Газиз шунда гына белде. Биюче дисәң дә биюче, чын танцмейстер икән бит. Хәрби округ ансамблендә төп биюче булган ул башта. Аның түгәрәгенә йөргән кеше биюче була алмый калмагандыр. Истә, һаман истә ул түгәрәк. Рәхмәт Рәшиткә, ул булмаса, ямьшәеп беткән кирза итекле кече сержант Солтановка түгәрәккә йөрү дә тәтемәгән булыр иде әле.

Газиз үзе дә сер бирмәде, танцыга тиз өйрәнде. Бигрәк тә бал танцыларын ярата иде ул. Вальс кына түгел, танго, фокстрот, кадриль, краковяк, полька, падеспань, падеграс—барлыгы уникe төр биюгә өйрәнде егет. Бар кимсенгәне—ямьшәйгән итекләр булгандыр, тик аның белән парлап чыгарга телгән гүзәл затлар мона артык игътибар да итмәделәр бугай. Кичәдән кичәгә остарып барган мишәр егетенең түгәрәккә йөргән иң аксөяк сылубикәләр арасында абруе зур, аларның һәркайсы Газиз белән танцы итүне мәртәбәгә саный, алдан ук ниятләп тора, хәтта сөйләшеп куя. Чөнки егет танцыны бию залындагы иң сәләтле кавалерлардан да остарак башкара иде.

Хәзер исә соңгы тапкыр кайчан танцы иткәнен дә хәтерләми, ана кимендә унбишләп ел үткәндер, кайда ул яшьлектәге вальсларның исемен хәтердә калдыру?

Ул шулай уйланып торган арада, бер-бер артлы вальска әйләнә башлаучылар да табылды. Музыка Газизнең үзен дә җилкендереп җибәрде: «Әллә берәрсен чакырып карарргамы?» Ул күзләре белән үзе тирәсендә утырган хатын-кызлар арасыннан ошардай пар эзли башлады. Мондый чакта вакыт кыска була, кайчак беренче кул астына туры килгән хатын-кызны да чакырасың. Ләкин Газизнең күзе үзеннән-үзе ике-өч кеше аша утырган утыз-утыз биш яшьләрдәге бер хатынга төште. Түгәрәк, ачык йөзле, җилкәсенә төшеп торган тузынкырак кара чәчле, куе кызыл төстәге озын күлмәге тыгыз гәүдәсенә сыланып тора. Газиз торып, ана каршы килеп басты һәм яшь чагында өйрәнгән, чын кавалерларга хас гадәт буенча башын иде: «Мин сезне вальска чакырам...» Хәзер хатын сикереп торыр да, алар парлашып вальс әйләнә башларлар сыман иде.

Газиз ялгышты: хатын гаҗәпкә калып карап торды да, «юк» дигән мәгънәдә башын чайкады...

Газизнең кәефе, кырау суккан чәчкә кебек, кырылды да төште. Ул кире урынына барып утырырга уңайсызланып, икенче якка чыкты һәм аптырап дивар янына барып басты. Беренче коймак төерле булды ла! Әш нәрсәдә, нигә ул чыкмады? Һич сәбәп юк иде кебек. Газиз ап-ак күлмәктән, пөхтә итеп үтүкләнгән кара чалбардан, туфлиләре дә ялтырап тора, гәүдәсе дә төз, килешле әле аның. Әллә соң шулай бик олы күренәме ул авыру килеш? Юк, бүген башка берәүне дә чакырмаячак ул вальска. Менә, музыка гына тәмамлансын да, бүлмәсенә менеп китәр. Үз-үзенне кимсетеп...

Кинәт диварга сөялеп басып торучылар арасыннан бер яшь хатын кузгалып, Газизгә таба килә башлады. Газиз аны үтеп баручыдыр дип уйлаган иде, алай булып чыкмады, аның янына тукталып:

—Абый, сез вальс биисезме?—диде.

Газизнең яшьлегендә ир-атны хатын-кыз ак вальска гына чакыра торган иде. Хәзер, әнә, башка гадәт икән.

—Яшь чакларда ярата идем вальсны,—диде Газиз.—Әле менә берәүне чакырган идем дә, чыкмады. Кәефе юкмы...

—Ә мин күрдем аны. Шуңа сезне чакырдым да. Белдем сезнең вальс танцевать итәсегез килгәнне.

—Рәхмәт...

Башта алар салмак кына әйләнделәр, чөнки Газизгә вальсның инде онытылып беткән нечкәлекләрен искә төшерәсе бар иде. Аннан темпны тизләтә төштеләр. Вальслар шундый инде алар, биегән саен син тизрәк әйләнә, дәртләнә, җилкенә барасың, кәефең, рухың күтәрелә. Вальс ашкындыра сине, сиңа каяндыр көч, куәт килә. Хәтта соңгы вакытта чир белән йончыган Газизне дә кодрәтле музыка, әнә, илһамландырып җибәрде, ул парын әле уң, әле сул якка әйләндерә-әйләндерә бию залын ерып аркылыга-буйга чыкты, тиргә батты. Ләкин музыка төгәлләнмичә парын ычкындырмады.

—Сез бик оста танцевать итәсез икән бит. Шулкадәр җинел, рәхәт сезнең белән,—диде аңа пары.—Каршы булмасагыз, мин сезнең белән тагын биер идем. Башка вакытта да, дим. Минем бөтен яратканым—вальс, кич буена танцевать итәргә дә риза...

Ләкин бу кичне бию залында башкача вальс янгырамады.

Бүлмәдә Габделфәт:

—Күрдем, күрдем синең бер чибәр белән ничек әйләнгәненне. Шәп чыкты, сезгә сокланып карап торган кешеләр дә аз булмады бугай. Афәрин!—диде.

* * *

Иртән курорт кабат үз тормышында кайный башлады. Аның ике катында халык ыгы-зыгы килә, бер процедураны алып чыга да, икенчесенә, өченчесенә чаба. Дәваланып йөргән арада Газиз күзләре белән нигәдер йә бер, йә икенче дәвалану урынында процедурага чират көтеп утыручылар арасыннан кичә танцыда аның теләген кире каккан хатынны эзләде. Чибәр, ләкин артыгы белән горур хатын иде ул—Газизгә шулай тоелды. Кичәге хәлдән соң Газизнең күңел түрендә кимсетелү, рәнҗетелү кебек хис калды. Әллә соң чынлап та горурланырлыгы бармы? Горур, димәк буш хатын түгел. Шулай да күзгә-күз карап бер-ике сүз алышасы иде үзе белән, гәрчә танцыга чыкмаса да. Кем икән соң ул тутый кош, кайсы яклардан, кайсы елга аръягыннан? Ләкин Газизнең күзенә ул хатынны хәтерләткән бер генә кеше дә чалынмады.

Кичен тагын танцы булды. Репертуар тагын шул ук: тавыш көчәйткечләрдән бар куәткә янгыраган музыкага барысы да кубарылып үзенчә бии. Газиз исә сабыр гына вальсны көтте. Бүген аның пары

булачак инде, әнә бит, кичә анын белән биегән яшь хатын алдан ук әйтеп куйган иде. Тик кайда соң әле үзе, һич залда күренми.

Ниһаять, вальс... Ах, аның күңелләрне тибрәндергеч, йөрәкне ашкындыргыч көче!

Газиз халык арасыннан, сабырсызланып, кичәге парын эзли башлады. Ә ул нишләптер юк. Инде парлашып әйләнүчеләр дә күренде. Шулай ук кич буена бер тапкыр уйната торган вальска әйләнә алмый менеп китәрмени соң ул?

Газиз күзләре белән әле бер, әле икенче якны айкады. Ниһаять, тапты ул аны—кичә кара костюмнан чыккан яшь ханым бүген аяз көндәге күк сыман үтә ачык зәңгәр төстәге, өрфия кебек жинел, озын, бераз гына купшы, ләкин искиткеч килешле күлмәктән ишек катында басып тора икән һәм, Газизнең аны эзләвен күрепме, ана кулы белән ишарәләр ясый: «Мин бит биредә, күрегез мине...» Газиз дә ана ым ясады: «Әйдә, чыгабыз...» Һәм алар тиз-тиз бер-берсенә каршы атладылар. Шулчак һич көтмәгән, уйламаган бер хәл булып алды. Әллә каян анын каршына башка бер хатын атылып чыкты:

—Сезнең белән мөмкинме?

Гаҗәпләнүдән Газизнең күзләре шар булды: бу бит кичә анын белән вальска чыгудан баш тарткан ханым! Шул ук ачык йөз, шул ук ярымтузгыган кара чәчләр, шул ук үзенә килешеп торган куе кызыл төстәге күлмәк. Кичәгедән аермалы буларак, ул бүген нигәдер авызын ерган. Газиз исә бу хәлдән кинәт каушап китте. Шулай да үзен кулга алды:

—Гафу итегез, әнә, килә бит инде,—диде һәм бераз ясалма тәкәбберлек белән ары атлады.

Зәңгәрсу өрфия күлмәкле яшь ханым зал уртасына килеп житә иде инде. Алар бер-берсенә каршы ашкынып килделәр дә, мизгел эчендә житәкләшеп, көчле музыканың «Та-та-та, та-та-та» дигән өчле тактына ялкынланып вальс бии башладылар. Бу күренеш залдагылар өчен шулкадәр көтелмәгәнчә, хәйран калырлык матур, чын сәнгатьчә, нәзакатьле килеп чыкты ки, күбесе бу парга чын күңелдән сокланып, ә кайберәүләр исә хәтта көнләшеп куйдылар. Бигрәк тә төз, зифа буйлы, арыслан ялыдай күпереп торган чәчле партнерның үзен вальста виртуозларча оста тотуы, аның яшьләрчә жинел гәүдәлелеге, темпераментлы әйләнүе шаккаттырды аларны. Кичә чирканчык алганнан сон, чыннан да Газиз бүген танцыда һич ялгышмады—яшьлегендәгечә дәртле, хис белән жилтерәтте ул кочагындагы яшь бикәсен. Хатын да төшеп калганнардан түгел икән. Газизгә әле тәмам сыланып, әле кулга кул гына тотышып, анын һәр хәрәкәтен тоеп, үзенең хәрәкәтләрен аныкына тәңгәл китереп, анын белән бербөтен булып, коштай канатланып уңга да, сулга да әйләнде дә әйләнде...

Вальс хозурына бирелсә дә, Газизнең башында бер үк вакытта тынгысыз уйлар да гизде. Кичә бөтен халык алдында чакырып та вальска чыкмаган ханым бүген үзе анын каршына килде ич: «Сезнең белән мөмкинме?» Һич мантыйкка сыймый әле бу хәл. Хикмәт нәрсәдә? Бу гүзәл затларны гел анламассың: бер карасаң ялындыралар, икенче карасаң үзләре күзгә керәләр. Шулай да, бу хәлдән соң Газизнең бераз үпкәсе басылгандай булды.

Вальстан соң татар көен—бию көен уйната башладылар—ул да һәр көнлек репертуарда иде. Яшьләр дә, урта яшьтәгеләр дә, олыраклар да атылып чыгып биергә тотынды, берсе икенчесен чакырып, авылдагыча култыклашып әйләнгәләп ду-у килделәр.

Бу вакытта Газиз вальстан соң хәле бетеп, диварга терәлеп тора иде. Әллә ничек шунда, күз аллары әлҗе-мөлҗе итте, йөрәге тыпырчынды, башы әйләнде, тын житмәде. Нәкъ шул вакытта бии-бии кызган халык арасыннан тагын теге кызыл күлмәкле ханым коштай очып чыкты һәм көчкә сөялеп торган Газизнең аягына китереп басты. Газиз исә, аптыраганнан, монсу итеп елмаеп кына куя алды...

* * *

Хәлсезлек, баш әйләнүе икенче көнне дә бетмәде. «Чамаңны белмисең, танцыга чыккан буласың тагын»,—дип үз-үзен битәрләп йөрде ул көне буе. Хәлен аңлап, Габделфәт аны төштән соң һава сулап керергә чыгарып җибәрде:

—Башың җиңеләер, кислород җитми сиңа, дустым, бинадан чыкмый ятасың,—диде ул чын кайгыртучанлык белән.—Бар, бар, әйләнеп кер...

Ә тышта, чыннан да, һава саф, кислород артыгы белән иде. Сентябрьдә сирәк була торган жылы, йомшак көннәр. Теплоходлар, үзйөрешле баржалар, башка төрле суднолар йөреп торган киң елга ягыннан талгын җил исә. Рәхәт! Газиз бераз вакыт күкрәген киереп саф һава сулап басып торды.

Курортта ял итүчеләрнең шактые урамда икән. Сигез катлы ак бина янынннан төрле якка бетон плитәләр түшәлгән берничә сукмак китә. Һәр сукмак—үзе бер маршрут. Берсе каен, икенчесе нарат урманына, өченчесе елга буена юнәлә ул юлларның. Барысында да кеше, кеше—парлап та, төркемләп тә. Ялгызлар да җитәрлек. Газиз дә әнә шул юлларның берсенә төшеп, ашыкмый гына нарат урманына таба китте. Нәкъ менә шул урман аланындагы зәвык белән эшләнгән күңелле чатыр-беседкада утырып ял иткәндә аның янына кабат Кызыл Күлмәк килеп чыкты. Башта ул, исәнләшеп, үтеп китәргә уйлаган иде. Ләкин ике-өч адым киткәч тә, кырт кына борылды да, тәвәккәл атлап чатырга керде.

—Мин дә ял итеп алыйм әле янығызда. Рөхсәттер бит?—диде ул елмаеп.

—Үтегез, утырыгыз, урын җитәрлек,—диде Газиз, ә үзе ханым турында: «Чая, хәерсез»,—дип уйлады.

—Нәрсә, хәлегез китеп торамы әллә? Төсегез үзгәргән...

—Юк, болай гына... Ял итәм,—дигән булды Газиз.

—Сез авырыйсыз, әйеме?

Газиз иңнәрен җыерып куйды: «Белмим инде, бәлки авырыймдыр»...

—Авырыйсыз. Миннән яшерә алмассыз, мин бит табибә. Әйтегез дөресен, нәрсә сезнең?

—Ике сүз белән генә аңлатып булса икән,—диде Газиз, ниһаять.

Бер-берсенә карашып шактый гына эндәшми утырдылар алар. Соңгы ике-өч көндә тәмам тынгысын алган, хәзер исә янына ук кереп утырган бу таныш булмаган чая хатынның күзләренә карады Газиз. Коңгырт төстә икән алар. Елмаеп җибәрергә күп сорамый торган түгәрәк, якты йөзле. Күзләренә, йөзенә караганда акыллы, киң күңелле, шәфкатьле булырга охшый. Үзе сөйкемле.

Гомер агышында Газизнең яратып йөргән, һич югында аңа бик ошаган кызлар, хатыннар булмады түгел, булды. Тик ул һәрбер тәүге очрашуда ук килеп ябышырга әзер җилбәзәк, җиңел акыллы шаталаклардан ерак йөрде. Тышкы бизәк, тышкы матурлык аны тартмады, чөнки бер-ике мәртәбә авызы пешкәч, чибәрләргә шикләнеп карарга өйрәнде ул. Аның күңел дәфтәрендә кайсыдыр бер мәшһүр шәхеснең әйткән сүзләре язып куелган: «Есть красивые девушки, которые напоминают красивый дом, окна в котором никогда не светятся...» Ә бит, чыннан да, бар гүзәлләрнең гүзәле, тик якынрак килеп, танышып киткәч, бу гүзәлнең буп-буш булуына, анда он суы да, тоз суы да юклыгына төшенәсең. Юк, тышкы бизәк белән түгел, ә эчке дөньясы белән матур кеше! Шуңамы, кызлардагы үтә матурлыкка караганда аларның сөйкемлелеген артыграк бәяләде Газиз, чөнки сөйкемлелектә үзенә бер аерым күркәм сыйфат, тирән мәгънә күрә ул. Йөзләрендә сөйкемлелек балкыган хатын-кызлар гына нечкә, шигъри күңелле, бай табигатьле, көчле рухлы, гүзәллек, садәлеккә омтылышлы, төпле акыллы, сабыр холыклы була алалар. Газизне дә әнә шундый гүзәл затлар гына кызыксындырды. Әмма андыйлар күп

булмыйлар. Элек тә аз, бик аз иде алар, хәзер исә бөтенләй сирәк.

—Йә, карап бетердегезме? Бәлки берничә сүз катарга рөхсәт итәрсез?—диде Коңгырт Күз.

Аның тел төбендә, сөйләү рәвешендә шаянлык-шуклык бар икән, үзе гел елмая.

—Рөхсәт,—диде шундый ук шаян тонда Газиз дә. Ә хатын кинәт житдиләнеп:

—Абый, исемегезне белмим, гафу итәсез, телибезме, теләмибезме, безгә танышырга насыйп булган ахры,—дип башлады.—Әлбәттә, әдәби әсәрләрдәгечә сандугачлар сайраган салкын чишмә буенда, яфраклары шыбырдашкан карт тирәк астында танышу килеп чыкмады. Эт талашмый танышмый, диләрме әле? Талашуын талашмадык, тик шулай да... Мин сезне бик үпкәләттем бугай. Ялгышымны төзәтим дип, үзем килеп вальска чакырдым—башка белән чыгып киттегез, биергә китереп типтем—бөтенләй мине санга сукмадыгыз. Мин бит теге кичне сезне бер карт жилбәзәк, танышыр өчен генә чакыра, дип белдем. Сезнең мине чын күнелдән вальс биергә чакырганыгызны, үземнең ялгышканымны бик тиз аңладым. Хәзер инде терсәкне тешләп булмый. Белсәм икән сезнең вальска шулай оста булуыгызны? Ә сез әнә нинди, бөтен курорт халкын шаккатырдыгыз. Әкәмәт биюче икәнсез, суда балык та шулай оста йөзә алмый торгандыр. Чын менә...

—Гажәп матур сайрыйсың икән, сеңлем...

—Айсылу минем исемем, Ай-сы-лу...

Ул, сөйкемле елмайган килеш, Газизнең күзләренә текәлде. Газиз аны аңлады:

—Газиз. Газиз абыең Солтанов...

—Кем соң сез? Бик серле, гадәти генә кеше түгел бугай сез. Һәм авыруыгыз нидән гыйбарәт, Газиз абый? Бәлки минем профильдер һәм сезгә булыша алырмын? Чын менә...

—Чернобыль дигән сүз таныштыр бит?—диде Газиз һәм Айсылуга сынаулы караш ташлады.

—Ма-ла-ка-ем!—Айсылу кычкырып ук жибәрде.—Әйтәм... Күнелем сизгән иде аны сездә нидер барлыгын. Әстагъфирулла!..

Айсылу бераз, аңына киләлмәгән кеше кебек, өнсез-тынсыз уйланып утырды. Аннары гына сүзен дәвам итте:

—Ничек соң ул якка барып чыктыгыз, нинди хәерсез жилләр ташлады сезне ул Алла каргаган жиргә?

—Үзем дә еш кына шул турыда уйланам. Архитектор мин, проект бүлегендә эшлим. Бер көнне ашыгыч рәвештә хәрби комиссариатка чакыртып алдылар: «Атом станциясендәге авария турында ишеткәнсеңдер инде, аны туктатыр өчен ниндидер архитектура корылмасы эшләргә белгечләр кирәк»,—диделәр. Белгән булсам икән нинди корылма кирәклеге турында! Тәүге тапкыр балта тоткан кеше дә эшли алырдай бетон булып чыкты ул. Без бит теге еллар тәрбиясен алып үскән балалар. Патриотизм, интернационализм... Ил өстенә куркыныч килгән, тар муенлы чүлмәккә утыртылган пәри бөкене бәреп чыккан да, котырына хәзер. Мин бармасам, башканы алып китәчәкләр... Башымда төрле уйлар гизде. Гаиләдә дә аңлашу юк иде ул көннәрдә. Күнелдә төшенкелек. Шулай, киттем дә бардым. Елап калучы булмады, кая барасың дип тә сорамадылар...

Газиз тынып торды, тагын Айсылуга таба борылды. Йөзендә аптырашлы елмаю иде аның. Аз аптыраган елый, күп аптыраган көлә. Газизнең хәле дә шундыйрак хәзер. Үзе ябык, йөзендә йөзләрчә вак бүразна, карашы моңсу. Югыйсә чибәр генә кеше икән, әлеге халәтендә елмаюы да аның йөзен ачып жибәрә.

Кинәт Айсылу аңа таба шуышты да, бик якын, терәлеп үк утырды:

—Сөйләгез, Газиз абый,—дип пышылдады ул Газизнең колагына.—Сөйләгез, минем сезне тыңлыйсым, юк, ишетәсем, әйе, ишетәсем килә, Бушану үзегезгә дә зыян итмәс. Чын менә...

—И-и, Айсылу сеңлем, андагы мәхшәр турында сөйләргә көн дә, төн дә житмәс. Чернобыль хәзер дә төшләремә керә. Саташып, бастырылып, куркудан кычкырып, шабыр тиргә батып уянам...

* * *

—Без барып житкәндә саркофагны төзи башлаганнар иде инде, дип башлады хикәятен Газиз.—Дүртенче блок... Жәһәннәм уты... Болай күзгә күренми, билгеле. Атом ярсуын күргән кешеләрмени без? Томаналар, аңламыйбыз, гәрчә нидер сизенсәк тә. Атом уты көйрәгән корылмалардан ерак та түгел бер-ике мәртәбә файдаланып ташланган санап бетергесез автомашиналар, тракторлар һәм башка төр техника зираты. Аварияда хисапсыз уртаазиялеләр—төрекмәннәр, үзбәкләр, тажиклар, кыргызлар, казакълар. Һәм без—татарлар, башкортлар, удмурдлар, марилар... Мин соңыннан бу турыда бик күп уйландым... Урыс бик аз, юк диярлек дәрәҗәдә аз иде. Империя сәясәтенең мәкерлелегенә исең-акылың китәр. Гомер буе шулай булды—хәтәр жиргә һәрвакыт башта башка халыкны тыктылар. Тарих шул хакта сөйли. Урта Азиядәге басмачылар хәрәкәтен Татбригада кулы белән бастырганнар. Ә бит басмачылар милли азатлык өчен көрәшкән. Әфган сугышында исә Ислам динендәге илгә каршы күпчелек мөселман республикалары балаларын жибәрделәр. Чечняда да шул ук хәл кабатланды. Бер-берсен кырсын, дигән сүз бу. Төрки кабиләләрне, ислам динендәге халыкларны бүлгәләү, бер-берсенә каршы кую, котырту, ызгыштыру империянең элек-электән калган сәясәте ул.

Әржәне чират торып төзедек. Үзебез яшәгән зонадан блок өстенә санаулы вакыт эчендә килеп житәбез. Һәрберебез маскхалатлардан, авызда респиратор, кулларда балта, пычкы, чүкеч, кадак, такта... Кыскасы, кемгә бәлеш, кемгә шеш: алдан кемгә нәрсә алып барырга кушылган булса—шул. Блок өстендә нәкъ унбиш минут эшлибез—бу безнең көнлек норма. Без килгәнче башта жиде, аннан ун гына минут эшләткәннәр. Монда да безне бәхет читләтеп үтте. Көннәр кызу, ә безнең өстәге киемнәр авыр, респиратор аркылы суларга һава житми, күзлекләр булана—күреп булмый. Һәрберебез манма тиргә батып эшли, мунчадан да кызурак. Ашыгабыз, кабатланабыз, ялгышабыз, тик ялгышны төзәтергә вакыт юк. Тизрәк, тизрәк...

—И-и, Газиз абый, сүзегезне ефәк белән бүләм. Ул саркофаг дигәнегез телевизордан гел киртләч-киртләч булып күренә иде. Чыннан да шундыймы соң?—дип сорады Айсылу.

—Менә, менә шунда да хикмәт. Әйтәм бит, ялгышны төзәтергә вакыт житмәде, дип. Кая инде аны хасиятләп тору! Коелган тимер-бетон измәсен тотамы әржә? Тота! Шул житкән...

Газиз сөйләвеннән туктап торды. Сөйләр сүзләрен барлыймы күңелендә, әллә йомгак очын югалттымы? Чатыр астыннан каядыр еракка, елга аръягына карап, уйланып утыра бирә. Айсылу да эндәшми, кабат бүлдерүдән яхшысынмый.

Юк, йомгак очын югалтмаган икән Газиз. Елга аръягына караган килеш, ул сүзен дәвам итте:

—Анда эшләү—тәмугъ газаплары белән бер. Вакытны бер-беребездән сорашып кына торабыз: «Күпме калды? Ничә минут? Ничә секунд?» Вакыт чыгуга, эшне ташлап чабабыз—хәтәр учактан ераграк булуың хәерле. Кесәдәге дозиметрлар безнең нормадан ике-өч мәртәбә артык рентген радиация алуыбызны күрсәтә. Ләкин дозиметристлар: «Юк, алай түгел, сезнең дозиметрлар дөрес күрсәтми»,—дип безнең белән жан талашалар, хәрәмләшәләр, алдашалар. Шулай һәр көн. Бигрәк тә Урта Азия республикаларыннан килгән халыкны нык алдыйлар иде. Алар үзләре дә Аллам сакласын!—акча өчен жаннарын сатарга әзер. Жимерек блок кабат атом өермәсен тышка, һавага ташлагач, без вакытлыча блок янына барудан баш тарттык. Бу инструкция буенча да шулай каралган: радиация фоны

күтәрелгән очракта блокта эшләү тыела иде. Хәтта безне куркынычсызрак жиргә күчерергә дә тиешләр иде. Ләкин ул көннәрдә һава торышы үзгәрде, жил исә башлады һәм радиация фоны без торган жирдән бер якка авышты. Без күчеп йөрмәдек инде.

Шулай да, безне эшкә куарга маташып карадылар. Пәри оясының авызын томаларга кирәк бит. Анлыйбыз: катлаулы, четерекле хәл. Ләкин кемнен күрәләтә кабергә керәсе килсен? Көйләп-чөйләп тә, янап-куркытып та карадылар, бик күп акча да вәгъдә иттеләр—булмады, без күнмәдек, жинә алмадылар. Шуннан соң бер төркем тажикларга, шулай ук бик күп акча бирәбез дип, төрлечә юмалап, алдап-йоллап, боларны блок өстенә жибәрделәр. Алар әлеге атом-төш ягулыгы урнашкан скважинаны тимер-бетон измәсе белән томаларга тиешләр иде. Белмим, нәрсә, күпме эшли алганнардыр, шул керүдә иллешәр рентген радиация белән зарарланып чыкты мескен тажиклар. Чатырга кайтканда кара туткыллы тажикларнын йөзләре ак китән кебек иде. Чәчләре, кашлары-керфекләре, сакаллары-мыеклары күз алдында касмак-касмак булып коелып төште. Өрәк тә өрәк, тажиклар да өрәк, яннарында басып торырга, йөзләренә карарга да куркыныч иде. Барысын да ашыгыч рәвештә Киевкә, госпитальгә озаттылар. Күбесе шунда беренче көннәрдә үк жан тәслим кылган, калганнары сонрак берәм-берәм дөнья белән бәхилләшкән.

—Чынлап та шулай булдымы, Газиз абый? Дөресме сон бу?—Айсылу гажәпләнүдән Газизнең беләгеннән тотып алды. Газиз исә сүзен жөпләп тормады. Малай чакта булса ул: «Валлаһи, жир йотсын, ике мәчет арасында кысылып үлим»,—дип ант иткән булыр иде. Гүя ул Айсылуның сүзен колакка да алмады, үзенекендә булды:

—Әсрар исемле тажик әле дә күз алдымнан китми. Нык бәдәнле, кин жилкәле, чибәр, кара мыеклы утыз биш яшьләрдәге бу тажик белән танышып киттек без.

—Татарларны хөрмәт итәм мин. Минем дә янга татар, бик унган, яхшы хатын,—ди.

—Кем сон ул «янга?»—дим.

—Абыйның хатыны.

—Ә, жинги, димәк.

Янга-жинги... Бер үк сүз бит, тик ике телдә, ике әйтелештә генә икән, гәрчә татар теле белән тажик теле ике тел төркеменә керсә дә. Сөйләшә-сөйләшә әллә никадәр уртак сүз таптык: килен, кәнди, табак, каймак...

Блок өстенә жибәрелгән көнне мин Әсраргга (тажиклар үзләре ана Осрор диләр иде):

—Нигә риза булдыгыз, ялгышасыз бит, тормышыгызны, гомерегезне куркыныч астына куясыз, уйлашыгыз тагын бер кат,—дидем. Ул аптырап, кулларын жәйде:

—Уйлаштык инде, мин генә аерылып кала алмыйм иптәшләрдән...

Мин аларны буар елан тарафыннан сихерләнгән, гипнозланган куян халәтендә күрдем: үзе чиный, үзе һаман авызына таба бара...

«Ашыгыч ярдәм» машинасына утыртып жибәрер алдыннан әле унбиш-егерме минут элек кенә дулкын-дулкын кара чәчле, куе кара кашлы, кара мыеклы Әсрарны күреп шаккаттым: ул да өрәк кебек шәп-шәрә калган иде...

Газиз авыр сулап куйды һәм шактый вакыт тын торды. Уйлары да авыр иде бугай аның. Айсылу аны бүлдермәде, сүз катмады, ул да уйлана иде.

Аннары Газиз тагын кабынып китте:

—Әгәр шул вакытта аварияне бетерү буенча штаб вәкилләренен сүзен тынлап блокка менгән булсак, Газиз абыен синен янында менә шулай юк-бар сүз сөйләп утыра алмаган булыр иде, Айсылу ханым...

Безнен смена житәкчесе кипкән таракан кебек ябык Гончаренко дигән бер украинлы иде. Украинлылар, гомумән, матур, таза халык. Ә

бу ябыклыкның артына чыккан. Саргылт йөзле, очлы күзле, кылыч борынлы, ачы тавышлы. Шул инде безне утка да, суга да кертергә әзер торучы. Безнең илдә, гомумән, кеше хакын хаклау, кеше кадерен белү юк. Бу түрә кисәге дә шул күзлектән чыгып эш итә торганнардан. Синең турында кайгыртуны белми дә ул, ә менә эшләтеп жаныңны ала. Көнлек норманы үтәргә кеше житмәде исә, инде бер мәртәбә эшләп кайтканнарны кабат блок өстенә жибәрә. Бу—инструкцияне ачыктан-ачык бозу. Безнең белән бер сменада Николай дигән керәшен эшли иде. Бәлеш төбе кебек йомшак, тыңлаучан, сабыр, аз сүзле. Гончаренко моны бер мәртәбә жибәрде икенче катка, ике жибәрде... Мин түзмәдем:

—Что вы делаете с человеком, хотите прежде времени в могилу загнать?—дидем.

—Не твое дело, здесь я начальник смены,—ди бу.

—Ах, вы начальник смены? Тогда пойдем в штаб, доложите, как соблюдаете инструкцию...

Шөлләде, кабәхәт, Николайга да, башкаларга да бәйләнми башлады.

Теге вакытта реактор коесын авызлыкларга барырга үгетләп, янап, куркытып йөрүче дә ул иде. Шул чакта мин аңа:

—Хорошо, мы согласны, но только пойдем вместе с вами,—дидем.—Без вас—ни шагу!

Корт чактымыни, күз ачып йомганчы Гончаренкобыз юк булды.

Газиз тынып калды. Айсылу исә аның атом мәхшәре турында шулай тыныч, олы сабырлык белән сөйләвенә шаккатты. Нинди зур ихтыяр көченә ия бу кеше! Юк, гади кеше генә түгел, чын каһарман утыра икән Айсылу янында. Ул гомер буе батыр, кыю, фидакарь кешеләр турында укып, аларны телевизордан карап, кылган гамәлләренә сокланып яшәде, әмма үзләрен болай якын, янәшәдә генә күргәне булмады. Ниһаять, шундый кеше белән дә очраштырыр икән аны язмыш...

—Менә шулай, Айсылу сеңлем,—дип дәвам итте сүзен Газиз.—Тажиклар Чернобыль жиреннән ерак китә алмадылар, гүр иясе булдылар, ә мина Ходай үз жиремә кайтып үләргә насыйп иткәндер. Картлар әйтмешли, хәерле булсын инде. Нишлисең бит, язмышың шундый булгач. Артыгын да сөйләп ташладым инде, гафу ит...

—Юк, юк, минем өчен зур ачыш ясадыгыз, Газиз абый. Чернобыль турында бик аз беләм икән. Чын менә.

—Бөтен ил халкы бик аз белә бу тиңсез һәлакәт, аның күләме турында. Аны бит гади, бәләкәй, зыяны да зур булмаган бер авария итеп кенә күрсәтергә тырыштылар башта. Чынында исә дөньяда атом белән бәйләнешле иң зур катастрофа булды ул. Хиросима белән Нагасаки өстенә ташланган бомбалар да, Тоцк полигонындагы сынап карау да атом-төш мәхшәренең балалары гына булган. Газеталар, телеканаллар, әнә, бу һәлакәткә юлыккан, аны бетерүдә катнашкан, шул төбәктә яшәп радиация белән зарарланган алты йөз мең кешенең вакытыннан алда вафат булуы турында хәбәр итәләр. Алты йөз мең! Һәр ел саен бу сан алтмыш-житмеш меңгә арта бара. Чернобыль жире, аның тирәсе әле озак еллар кан косачак...

Инде соң, кичке ашка кайтырга вакыт житкән иде—алар кузгалдылар. Нарат урманының һавасы Газизгә килеште, ул үзен әйбәт хис итә иде. Бетон плитәләр салган тигез сукмактан алар ашыкмый гына шифаханәгә таба атладылар.

—Язмышыгыз бик үзенчәлекле икән, Газиз абый. Кызганыч та, соклангыч та. Ходай сәламәтлек бирсен үзегезгә. Сез мона лаек кеше,—диде Айсылу һәм һич тартынмыйча Газизне култыклап алды.

—Яхшы сүзенә рәхмәт, сеңлем, тик сәламәтлекнең ни дәрәжәдә икәнен үзем генә беләм...

—Алай димәгез әле. Менә курорттан тазарып, көч жыеп, яшь егетләр кебек күкрәк киереп кайтып китәрсез—мин сезгә шуны телим. Безнең әле сезнең белән вальс биисебез бар—аны да онытмагыз. Мин дә бик яратам

бит вальсны. Бүген шәт, сезнен белән парлап чыгарбыз, мин сезнең белән вальс әйләнмичә моннан китмим. Беркайчан да сезнең чакыруны кире какмам. Ялгышуым яшьлегем аркасында булды, диләрме әле?

Айсылу күнелле елмайды да, башы белән Газизнең җилкәсенә җинелчә кагылып алды.

Ишектән керә-керешли ул Газизнең җиңеннән тартты һәм үтеп-сүтеп йөрүчеләр ишетмәсеннәр дигәндәй, шыпыртлап:

—Газиз абый, танцы алдыннан тагын һава суларга чыгарбыз әле, яме. Мина бик рәхәт булып китте сезнең белән. Күпне күргәнсез, меңне беләсез, мавыктыргыч итеп сөйлисез. Мин бит ялгыз...

Лифт белән үз катына күтәрелеп, бүлмәсенә таба атлаганда, Газиз Айсылуның: «Мин бит ялгыз»...—дигән сүзләрен кабат исенә төшерде. Нәрсә әйтергә теләде ул моның белән? И-и, җаным, бер син генә ялгызмыни бу дөньяда? Тирәнтенрәк уйласаң, кеше тумыштан ук ялгыз, көчсез, ярдәмгә мохтаҗ, мескен ул. Чернобыль вакыйгасы моның шулай икәнлеген Газизгә артыгы белән исбатлады. Шуның өстенә эчкечелеккә сабышкан хатыны... Ул да ялгыз иде бу дөньяда һәм ялгыз үлеп тә китте. Әнә шулай, хәсрәт өстенә хәсрәт Газизнең. Бар шатлыгы—тормыштагы кызы һәм яна туган оныгы. Бар булганын, бар тапканын шуларга тота хәзер. Ә үзе ялгыз, һәркем кебек ялгыз ул. Болар турында сөйләп тә, көйләп тә бетерә торган түгел...

* * *

Кичен алар каен урманына таба киттеләр.

—Ә син мина артык кәттә, горур булып күренден башта,—дип башлады Газиз.

—Әйе, мин шундыйрак, Газиз абый, сез дөрес сиземләгәнсез,—диде Айсылу.—Мин балачактан ук үпкәчел һәм горур булып үстем, яшьтән үк буем җитмәс биеклекләргә үрелдем. Мәктәптә әйбәт укыдым мин, бәлки, шул мина үземне горур тотарга нигез биргәндер. Беренче мәхәббәт мәктәптә килә, дигән булалар. Мин сыйныфташларым арасыннан мәхәббәт тотарлык егет тапмадым, гәрчә артымнан ияреп йөрүчеләр аз булмаса да. Көчкә-көчкә «өчле» билгесенә өстерәлгән малай-шалайны санга да сукмадым. Яхшы укып, югары белем алып, принц кебек егетне сөеп, аңа кияүгә чыгып, ханбикә кебек галәттән тыш шартларда тормыш итәсе идем. Чын менә. Унынчы сыйныфта безне астрономиядән әле шушы елны гына институт тәмамлап килгән Зөфәр абый укытты. Аның безнең класска беренче керүендә үк мин һушсыз кала яздым. Зифа буйлы, дулкын-дулкын күпереп торган кара чәчле, олы зәңгәр күзле, сүзендә дә, эшендә дә чатнап торган яшь егет. Менә ичмасам принц! Дәресләрен шундый кызык, мавыктыргыч итеп үткәрә, кырык биш минутның ничек үткәнен дә сизми калабыз. Дәрес буена анардан күзләремне ала алмый утыра идем. Әллә нинди тормышка ашмас хыялларга чумам һәм төн саен диярлек төшемдә күрәм. Тик Зөфәрем күтәрелеп мина күзен генә дә сирпемәде. Ә минем аңа хисләремне җиткерергә кыюлыгым җитмәде. Ул елларның кызлары тыйнак иде бит, кая инде хисне белдерү? Тик ул елларда да кызларның төрлесе булган икән. Шул ук Зөфәр абыйга: «Яратам»,—дип килгән кыз безнең сыйныфта гына укыган—соңыннан ишеттек. Зөфәр абый акыллы иде шул, шөпшә кебек әзер балга төшмәгән, ул кыз белән әйбәтләп кенә сөйләшкән, син дә мина ошыйсың, ләкин син яшь әле, алда мәхәббәтең көтми булмас, ә минем яраткан, ярәшкән кешем бар, дигән. Булганмы, юкмы аның яратканы-ярәшкәне, тик без урта мәктәпне тәмамлап чыккан елны Зөфәр абыйны армиягә алып киткәннәр. Хәрби самолетта укчы-радист булып хезмәт иткән һәм катастрофага очрап, экипажлары белән һәлак булганнар. Менә шундый инде минем «беренче мәхәббәт». Үзем ярар инде, менә Зөфәр абый юк, ул кызганыч. Нинди шәп егет иде бит!

Аннан соң миндә беркемгә дә көчле хис кабынмады, йөрәгемдә ут дөрләмәде. Институтта укыганда да принц очрамады, эшли башлагач та...

Берәү белән торып карадык, тик, урыс әйтмешли, «не сошлись с характером».

Мин үземне әллә кемгә санап, гадәттән тыш мәхәббәт көтеп йөргән арада иң гади, һәркем өчен мөмкин булган мәгънәле генә тормыш минем яннан узып китеп бара икән. Ханбикә, имеш! Гади бер хатын булып, бер оя балалар табып, шуларны үстереп, ир хатыны исемен йөртеп яшисе калган.

Хәзер бар юанычым—эш: хастаханә, авырулар, моң-зар, хәерчелек, бетмәс-төкәнмәс проблемалар. Ярый инде, эш көне ыгы-зыгыда үтә. Ә кичен мин берүзем, дуадак каз кебек ялгыз.

—Беркемең дә юкмыни?

—Апам бар. Тормышта. Әлбәттә, ире, балалары. Без әни белән яши идек, былтыр жирләдек, хаста иде. Әнине карамадым түгел, карадым, миңа рәнжеп китмәде. Хәзер менә ялгыз башым. Ялгызлык интектерә...

—Тукта әле, Айсылу, күңел төшенкелегенә бирелмә, сиңа охшамаган бу. Син бит яшь әле...

—Каян яшь булыйм инде, Газиз абый, утыз өч бит миңа.

—И-и, жаным, Бальзак яше ул утыз өч. Иң ялкынлы чагың. Үзең чибәр—гүзәлләрнең гүзәле, үзең акыллы. Юкка гына борчыласың. Барысын да яңабаштан башларга сиңа һич тә соң түгел.

—Яңабаштан башларга ышанычлы юлдаш, өметле кеше кирәк, Газиз абый. Аны хәзер каян табасың? Бөтен дөнья сәрхүш белән тулган, аек ирне көндез чыра яндырып та таба алмыйсың. Сүзеңне уртаклашырга, сереңне тапшырырга, эчеңне бушатырга да ышанычлы кеше кирәк бит. Менә без, Газиз абый, сезнең белән... Гафу итегез, минем сезгә «син» дип эндәшәсем килә...

—Эндәш, әйдә, мин каршы түгел.

—Рәхмәт якын иткәнең өчен! Менә без синең белән һич уйламаганда очраштык, таныштык, фикер сөрешебездә, тормышка карашыбызда уртаклык таптык. Син игътибар белән тыңлыйсың, мин сине. Бер-беребезне аңлыйбыз. Шулаймы, Газиз абый?

—Әлбәттә!

—Иң мөһиме, мин, Газиз абый, синдә сер сыйдырырдай кеше таптым. Минем күптән болай ачылып сөйләшкәнем юк иде. Һәркемне жәлләп итә торган, сөйкемле, әйбәт кеше син. Ләкин шуны да беләм: тагын берничә көн аралашырбыз да, аерылышырбыз. Син мине белмәссең, мин сине. Икебез ике якка китәрбез дә, шуның белән вәссәлам!..

Газиз бу сүзләргә каршы ни дип әйтергә дә белмәде. Һәркемнең үз хәсрәте, үз кайгысы. Шул ук вакытта, «синдә сер сыйдырырдай кеше таптым» дип, бу ханым нәрсәгәдер өмет тә итә кебек. Аның кемгә дә булса сыенасы килүе күренеп тора. Бу да табигый. Бер-беренә сыенып яшәгәндә генә жанына тынычлык, ялгызлыктан качу жаен табарга мөмкин. Газиз үзе сыенмас идемени Айсылуга? Чын мәгънәсендә сылу, сөйкемле, чатнап торган чая, теле белән жанынны эретә, күңеле дә саф булырга охшаган...

—Газиз абый, менә син тормышның ачысын да, төчесен дә күп татыган кеше. Мәхәббәттә дә тәжрибәң бардыр. Әйт әле: чын мәхәббәт нинди булырга тиеш? Зөфәр абыйга булган бер яклы хисләремнән башка чын мәхәббәтнең нәрсә икәнен дә белми яшим бит мин.

—Мәхәббәтнең, Айсылу, чыны яки ялганы, яхшысы яки яманы, тегендие яки мондые юк. Чын мәхәббәт дип әйтү, минемчә, үзе үк дөрес түгел. Мәхәббәт бер ул. Бар мәхәббәт—ихлас хис, утлы-ялкынлы тойгы. Инде ике гашыйк арасында мәхәббәт нинди булырга тиеш дип сорасаң, уртаклык, аңлашу, гармония булырга тиеш—минем менә иманым камил. Ике сөйгән кеше арасында гыйшык уты сүнмәсен, көйрәп торсын.

Кышын өйдә жылы тотар өчен пичне ягалар бит. Мәхәббәт тә сүрелмәсен, суынмасын өчен шундый «пич» янып, көйрәп торырга тиеш. Чәчәкләр—яз белән, мәхәббәт—наз белән. Шунсыз тормышның мәгънәсенә, ике арадагы тигезлеккә, татулыкка өмет юк.

—Ә синең үзеннән беренче мәхәббәтең ничек булды? Сөйлә әле, Газиз абый,—диде Айсылу ялынган, үтенгән тавыш белән һәм астан гына елмаеп куйды.

—Хәйләкәр син, кызый,—диде Газиз дә, күңеле булып. Аннан житди төс белән эләктереп китте:

—Кызганычка каршы, мин үзем дә сиңа, шулай булырга тиеш, дигән фараздан чыгып кына җавап бирәм. Син хыялланган, күңелендә йөрткән «чын мәхәббәтне» мин үзем дә күрмәдем бугай. Тәүге тапкыр сөю хисе белән белән янганда мин әле бик яшь идем. Төзүчеләр техник училищесында укый идек ул чакта. Төзелешкә күнегүләргә, практикага йөри башладык. Шунда кранда эшләүче бер чибәр кызга күзем төште бит. Күпереп торган, ике калын толымга үреп салган кара чәч, зөбәрҗәт кебек зәңгәрсу күзләр, бөрелеп торган алсу иреннәр... Төн йокыларым качты. Ярый әле ул да минем хисләремне кабул итте. Очраша башладык. Сөйгәнем миңа фоторәсемен дә бүләк итте. Сәрмәдиянең—исеме шулай иде аның—үзеннән башка үткән сәгатьләрдә шул рәсемне туксан мәртәбә алып карыйм, йокларга да мендәр астына куеп ятам. Күп тә үтмәде, кызым өйләнешү мәсьәләсендә сүз кузгатты. Соң, мин әйтәм, миңа унсигез генә бит әле, быел армиягә дә алып китүләре бар. «Ул чагында мин синең армиядән кайтканыңны көтеп тора алмыйм, кияүгә чыгам»,—ди. Мин курка калдым: сөйгәнемнән коры калам бит...

Беләсеңме, яшь чактагы сөю-яратулар бала-чага уены кебек. Әле төптән уйларга өйрәнмәгәнсең, тормыш кануннары белән санашу кирәклеге турында белмисең, тәҗрибәң юк, аягыңа сыер басмаган, гел үз фикереңне генә фикер дип санийсың, үз сүзеңне генә сөйлисең, синеңчә барысы да дөрес дип уйлыйсың һәм, әлбәттә инде, бик нык ялгышасың.

Миңа да ул вакытта яхшылап уйлыйсы калган. «Синең кайтканыңны көтеп торалмыйм»... Юкса сиңа хисләренең, мәхәббәтенең юклыгын ачыктан-ачык әйтеп тора кеше. Торалмыйсың икән, дүрт ягың кыйбла, дип кенә әйтәсе бит. Сине яратып, синең өчен өзелеп торган кыз сиңа бөтенләй икенче төрле сайрар иде: «Ничә ел хезмәт итсәң дә көтәрмен. Син минем өчен берդәнбер. Синсез миңа авыр булыр, ләкин түзәрмен...» Кая ул? «Кайтканыңны көтеп торалмыйм...» Шулар турында уйларлык баш житмәгәнме, әллә сөю хисе белән томанага әйләнгәнменме?

Хәтеремдә, бер көнне олы абый чылтырата. Ана инде егерме биш яшь, армиядән дә күптән кайткан, үзе җан-фәрманга буровойда эшли, авылдагы әнигә, туганнарга булыша, анда өй салалар, абый бер үк вакытта читтән торып университетта да укый башлаган. Аның өйләнергә әле уенда да, вакыты да юк. Ә мин, җүләр, өйләнергә йөрим. «Башыңа тай типтеме әллә?»—ди абый. Тыңлыйсы бит, югыйсә. Юк, тыңламадым. Өйләнештек. берничә айдан мине, чыннан да, армиягә алып киттеләр.

Никадәр тинтәк булуым турында мин соңыннан гына аңладым. Әлбәттә, өйләнешү фәкать минем ярату аркасында гына булды. Сәрмәдия өчен иң мөһиме мәхәббәт тә, ярату да түгел, ә үз вакытында иргә чыгып калу, чөнки яше бара—ана ул вакытта егерме ике яшь иде инде. Ләкин ул да ялгышкан, ул бит моннан бернәрсә дә отмады. Мин ничек кенә матур гаилә кору турында хыяллансам да, тату тора алмадык, чөнки аңлашу юк иде.

Кем гаепле? Яшьлек, тәҗрибәсезлек, җавапсызлык... Мин беркайчан да үземне гаепсез санамадым. Гаепле, әлбәттә...

—Әллә аерылыштыгыз?

—Юк, аерылышмадык. Минем армиядән кайтуыма ук ул миңа шактый суынган иде. Бәлки аның башка кешесе булгандыр, гәрчә ул

вакытта андый уй минем башыма да килмәде. Мин аны элеккечә ярата идем. Ләкин тора-бара миндә дә хис калмады. Сөю, ярату бер яклы гына булмый икән шул. Ул үз эченә бикләнде дә, тымызык кына салгалый башлады. Мин үз дөньям, үз тормышым белән яшәргә мәҗбүр булдым. Укып, югары белем алдым, яна эшкә күчтем. Архитектура—иҗат эше бит ул, кызыклы, мавыктыргыч эш. Иҗат белән янганда гаиләдә анлашу житешмәсә дә яшәргә була. Мин әллә нинди борынгы төзелеш стильләрен камилләштереп, матур-матур йортларнын проектларын сызып, хыялланып бетә идем эштә дә, өйдә дә. Тик теге елларда минем сызымнар буенча нинди дә булса бина яки йорт төзү генә мөмкин булмады. Зәвыксыз чор иде бит ул. Гел соры солдат казармаларына, колхоз фермаларына охшаган килбәтсез торак йортлар, шыксыз административ биналары төзелде ул елларда. Мин ясаган проектлардан сөяк-санак кына кала иде, чөнки «экономика» чоры иде ул. Ә менә хәзер иҗат кешесенә хөрлек килде. Тормыш яна ермактан ага. Малкуарлар, эшкуарлар, бизнесменнар, кәсәбәчеләр пәйда булды. Барысы да икешәр-өчәр катлы, мунчалары, бассейннары, спортзаллары белән йорт житкерә. Мин мона унай карыйм. Мөмкинлекләре бар икән, төзесеннәр. Безнен эше хыялый архитекторларга да эш муеннан, фантазиян генә эшләсен. Мин унлап проект эшләп бирдем инде, һаман киләләр. Проектларым ошый, шуна киләләр. Мин аларга йорт проекты сызам, ә үзем турында шәһәрдә истәлек калыр. «Бу матур йорт кем проекты белән төзелгән?»—дип сораганда, «Газиз Солтанов проекты белән төзелгән»,—дисеннәр. Бу дөньяда беркем дә мәнгелек түгел. Минем исә... без Чернобыльдә жидәү идек. Дүртебез юк инде, өчәү генә калдык. Кайсыбыз чиратта—беркем дә белми. Кызганыч, әлбәттә, дөньякүләм шедевр төзеп калдырып булмады, гәрчә хыяллансам да. Шулай да, минем турыда истәлек булып мин сызган проект буенча төзелгән йортларым кала икән—шуна да бик риза. Зур эштә жанын чыкса, данын калыр, диләр бит... Син тагын бу картлач мактана дип уйлый күрмә. Мактанудан үтте. Сонгы елларда эшемнән канәгать мин, шуны гына әйтәсе идем.

—Газиз абый, жаным...

Айсылунын Газизгә әллә нәрсәләр әйтәсе килгән иде, тик ул, артык хистән, бер сүз дә әйтә алмады. Анын бу минутларда йөрәге дөпдөп тибә, күнеле ярсулы, ә конгырт күзләре мөлдерәмә яшь белән тулган. Ул шул яшьле күзләре белән Газизнен күзләренә карады, аннары кысып кочаклап алды һәм алар беравык шулай икәүдән-икәү өнсез-тынсыз басып тордылар.

Инде карангыланып килә. «Сон инде, сезгә кайтырга вакыт»,—дигәндәй, сукмак буенда яшь усак яфраклары гына шыбырдашалар иде...

* * *

Газизнен Чернобыльгә китү хәлләре анын Айсылуга сөйләгәненчә үк түгел иде. Гел генә дөп-дөрес итеп сөйләве дә мөмкин түгел шул. Нәрсәгә үз жанынны үзен әрнетеп артык сүз куертырга? Булган-беткән, өстенә мүк үскән.

Ай-һай, беткән микән? Алай булгач, нигә сон, торып-торып бер амин, дигәндәй, һаман искә төшә, анын жанын бимазалый, тынгылык бирми?

... Әле яшьлегендә, техник училищеда укыган елларында ук анын бер иптәше бар иде. Орчыктан аз гына калку гәүдәле, эченә сәнәк белән төртсән дә каны чыкмас ябык, керпе сырты кебек тырпайган аксыл чәчле, торна күзле бу Тансык исемле малай белән бер партада утырып укыдылар. Исеменә күрә жисеме—училище малайлары ана «Торна күз» дигән кушамат та тактылар, чөнки төркемдәшләре Тансыкны һич кенә дә тансыкламады, дус түгел, хәтта рәтле иптәшкә дә санамадылар. Һәркемгә яраклашырга, тәлинкә тотарга күнеккән малайнын абруе булмауга

гажәпләнәсе дә юк иде. Шуна да Тансыкка йомшак бәгырьле, кин күнелле, беркатлы Газизгә сыенудан башка юл калмады. Шулай, артык дус булмасалар да, бергә әвәрә килделәр. Укуны тәмамлаганнан сон, Газиз Торна күзнен кай тарафларга китеп югалуын да искәрми калды. Бар иде—юк булды. Әгәр кабат очрамаса, Газиз анын дөньяда барлыгын да белмәгән булыр иде. Еллар агымсу кебек акты да акты. Инде шактый тормыш сикәлтәләрен үтеп, дүрт дистәсен тутырып барган бер чорда, Газиз урамда подполковник погонлы хәрбидә ике ятып бер төшенә кермәгән яшьлек иптәше Тансыкны танып алды. Белсә икән бу тануынын үкенечкә буласын!

Читек чаклы малайдан кукамай сакчысыныкы кебек җәелеп киткән юан корсаклы, кыска муенлы, төп кебек бер әфисәр чыккан лабаса. Менә бит гомерләр! Торна күз генә димә, бу вафасыз дөньяда вакытны ота белгән—хәрби юлны, мундирны сайлаган, карьера ясаган. Төрле җирләрдә җилсез-янгырсыз хезмәт юлын үтеп, ниһаять, туган төбәгенә кайтып төшкән. Һәм кем булып диген әле—каланын хәрби комиссары, олы түрә булып. Тәлинкә тотып үсү ярап куйган үзенә. Ул гына да түгел. Училищеда укыган беренче айларда ике авыз да урысча белмәгән Тансык ана телен бөтенләй «оныткан» булып чыкты.

Озак еллардан сон ике иптәшнен очрашып сөйләшүе якынча менә шундый рәвештә барды.

Газиз:

—Тансык, Тансык, бу син түгелме сон?

Торна күз, Газизне танымаганга, татарчаны анламаганга салышты:

—Говорите по-русски!

Газиз:

—Сон, Сарачев бит инде син...

Торна күз:

—Да, я—Сарычев.

Газиз:

—Тансык...

Торна күз:

—Нет, Анатолий Иванович.

Газиз:

—Тукта әле, Тансык. Сон, син мине танымыйсынмыни? Мин бит Газиз, Газиз Солтанов. Без синен белән техник училищеда бер партада утырып укыдык, хәтерлисенме?

Торна күз:

—Да, вроде припоминаю...

Газиз...

—Да-а, парень, үз-гәр-гән-сен! Сарычев... Анатолий Иванович... Нәрсә, документларында да шулаймы?

Торна күз:

—Угадал.

Газиз:

—Алай булгач, хатынын да маржадыр инде?

Торна күз:

—А что тут удивительного?

Газиз:

—Бик күп удивительного, малай. Артыгы белән удивительно әле бу...

Торна күз:

—Такова жизнь... Только ты на меня не обижайся. Давай поговорим: как ты, где работаешь, кем стал?..

Сөйләштеләр, әлбәттә. Газиз тәмам онытылып беткән яшьлек иптәше белән сагынганнан түгел, ә гыйбрәт өчен сөйләште.

Менә сина Тансык, менә сина Торна күз! Маржага өйләнеп, теленнән, милләтеннән качып, дененнән язып, иманын сатып, үзе дә

тулысы белән сатылып беткән бит. Этлеккә башы житкән үзенең—Сарачев фамилиясен Сарычевка алмаштырган. Тегеләй татар фамилиясе булып калыр иде, ә болай урысныкына әйләнгән: сарыч! Елак ябалакны урыслар «сарыч» диләр. Елак булса да, ябалак бит әле ул, тавык яки чебеш кенә түгел. Фамилиясен алмаштырганда берьюлы исемен, атасының исемен дә үзгәрткән. Имам улы Тансыктан Анатолий Ивановичка әйләнгән. Маржасы: «Тансыккаем!» димәс бит инде. Әйттерерсең син алардан...

Ах, кая бара соң бу дөньялар? Без үзебез кая барабыз? Мондый галәмәт, мондый аяныч хәл бер Тансык белән генә булса икән! Әнә бит, Газизнен үзенең тераннары да... Саранскидан мукшы маржасына өйләнеп, Гариф тормышының астын-өскә китерде. Гаиләдә ике милләт кешесе арасында аңлашу табып буламыни? Вакыт-вакыт үз милләтең кешесе белән дә аңлашу жиңел түгел бит әле ул. Ике милләт, ике тел, ике дин, ике төрле гореф-гадәт, йолалар. Аларны бер итеп яшәве ай-һай авыр. Юк, Гариф белән хатыны да уртак тел, аңлашу таба алмадылар, аерылыштылар. Улы Тимур да, кызы Венера да татарча ике сүз дә белә алмый киттеләр—мукшы аналары татар телендә сөйләшергә рөхсәт итмәде ул сабыйларга. Балалар үсеп житкәч тә паспорт алдылар, тик «милләте» дигән графага аналары «русский», «русская» дип яздырды. Менә бит нинди хикмәтләр бар бу дөньяда: татар белән мукшыдан туган ике нарасый урыс кавемен арттырсыннар инде! Тимур Гариф улы Сәгыйтов—урыс, Венера Гариф кызы Сәгыйтова—ул да урыс маржасы...

Газизнең башка туганнары да шулай йә урыс, йә чуаш, йә белорус белән буталып беттеләр. Аларның да киләчәге юк хәзер, алар да сатылган, алар да үз халкы тамырыннан читләшә, ераклаша барачак...

Тансык—Анатолий Иванович та әнә шул юлны сайлаган. Горур Ак Барс нәселеннән бөтен кыйтгаларга таралган мәшһүр төрки-татар халкының сатлык улы кираксә-кирәкмәсә дә койрык болгап торган нәселсез эт хөкеменә калган. Аның да балалары урыс булырлар. Бүген Толя, Толик, Анатолий Иванович булуга карамастан, Валентина маржасы аңа гел үзенең кем булуын искәртеп, мыскыллап «татарин» дип кенә тора. Үзе тапкан балаларга да «татарин» димәс бит инде...

Дус-ишкә гомер бакый мохтаж Тансык—Анатолий Иванович Газизгә тагын чытырдап ябышты. Балта остасы гына булып калган булса, абруен төшереп ябышмас та иде. Архитектор бит! Андый иптәш белән өстәл артында утырырга да оят түгел. Алар кабат очраша башладылар, хәтта гаилә бәйрәмнәренә, зәм-зәм суы чөмерүле башка мәжлесләргә дә йөрештеләр, гәрчә бу очрашудан Газиз үзе һичбер рухи канәгатьләнү тапмаса да. Гаиләсендә ышык, жылы, аңлашу булмаганга, тормышына ямь кертергә маташудан гына аралашырга мәжбүр иде ул үз телен әкренләп «исенә төшерә» башлаган Торна күз белән.

Әшнәлекнен янарып, үрелеп барган көннәрендә булган Чернобыль һәлакәте ике танышның язмышлары уртасына төбе черегән агач кебек дөпелдәп ауды. Хәрби комиссарга тиз көннәрдә авариягә утыз кеше жыеп жибәрү бурычы йөкләнгән иде. Сарычев үзенең аппараты белән тиресеннән чыгардай булып халык жыя башлады. Берәм-берәм запастагыларны чакыртып үгетләделәр, тик «атом» дигән сүз күбесен шиккә салды. Берсе дә тиктомалга чыгып китәргә ашыгып тормый иде. Билгеләнгән көнгә утыз кеше түгел, унны да жыя алмадылар. Күрсәтмәнең өзелү куркынычы туды. Өстән исә гел кымтырыклап тордылар: «Чего тянешь? В отставку хочешь?..» Тансыкның төн йокылары качты...

Хәерчегә жил каршы: нәкъ шул көннәрдә, уйламаганда-нитмәгәндә, Газиз белән Торна күз урамда очраштылар.

—Әйдә әле, миңа кереп чыгыйк,—диде Тансык бик житди төстә. Керделәр. Тансык шкафтан бер шешә аракы, рюмкалар алды. Очрашу хөрмәтенә берәрне кабып куйдылар. Шуннан соң гына хужа:

—Пропадаю, малай. Все валится, спаси,—диде һәм хәлен сөйләп бирде. Аннары нәрсәдер исенә төшкән кебек:

—Архитектор кирәк, диделәр. Какое-то важное сооружение төзергә. Выручай! Әгәр барсаң, мин сина, близкому другу, военную пенсию выхлопочу: «За выполнение особого задания перед Родиной». Бездә андый права бар,—дип алдашты.—Шуның өстенә, син анда заработаешь на всю жизнь,—дип өстәде һәм, акча санаган итеп, баш һәм имән бармакларын ышкыштыргалап күрсәтте.

Тансыкның сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмәде Газиз. «Якын дустым» дигән кеше алдашмас бит инде? Акчасы да, пенсиясе дә—алары әле суга сәнәк белән язылган. Ә менә архитектор кирәк булуы... Нииндидер мөһим корылма, ди бит. Бәлки ул чынлап та шулайдыр?..

Гомере буена хәләл көче белән, маңгай тирен түгеп тормыш иткән, намуслы яшәгән, гадел, балалар кебек һаман беркатлы, хәйләсез Газиз ялган яшь койган Торна күзнең хәйләсенә әнә шулай эләкте. Чыкты шобага—төштем тобага...

Торна күзнең нинди ялганчы, ике йөзле кеше булуын Чернобыльгә барып төшкәч тә аңлады Газиз. Кереп ашымны ашый, чыгып башымны ашый, диюләре хак икән. Мөһим архитектура корылмасы төзүме соң анда? Гади эшче, балта остасы, йөк ташучы, бетон салучы, кол кебек башын иеп эшләүче кирәк анда. «Бери больше, кидай дальше»,—ди урыс бу очракта.

* * *

Катастрофаның никадәр катлаулы, куркыныч булуы турында Газиз юлда ук белде. Бөгелмә вокзалында поезд көтеп утырганда, алар янына хәрби киемле, капитан погонлы төп кебек таза, кин җилкәле, каратуткыл бер кеше килде. Бер төрле милләт кешеләренең өерелеп: «Чернобыль, Чернобыль»,—дип сөйләшүләрен ишетеп торганга килгән икән ул алар янына. Танышып киттеләр. Исеме—Василий, фамилиясе—Емельянов. Шонталы районының Баландай авылында туып-үскән чуаш егете икән. Эчке эшләр министрлыгы челтәрендә хезмәт итә. Катастрофа алдыннан гына ул Киевка квалификация күтәрү курсларына укырга җибәрелгән булган. Укулары башланганга ун гына көн үткән, төнге сәгать икедә аларны тревога белән күтәргәннәр, егерме минут кына элек Чернобыль атом электростанциясендә әллә инде авария, әллә диверсия булуы турында хәбәр иткәннәр. «Шушы минуттан сез Украина ССР Эчке эшләр министрлыгы карамагына күчәсез»,—дигәннәр.

Күпмедер вакыт әзерләнергә кушалар. Ләкин ничек әзерләнергә?—беркем белми. Тулай торак ишеге төбенә бер-бер артлы дистәгә якын олы автобус килеп туктый. Шуларга төялеп, илнең төрле почмакларыннан квалификация күтәрергә җыелган ике йөз иллеләп кеше, ничек эләкте, шулай әзерләнеп, юлга чыга. Төркем хәтта махсус химик саклану чаралары белән дә тәэмин ителми.

Алар Чернобыль шәһәренә килеп җитәләр, шәһәрдән унсигез чакрымдагы атом электр станциясенә якынлашалар, тик аларны якын җибәрмиләр, туктаталар. Бу вакытта гаять зур тырышлык һәм югалтулар хисабына янгын сүндерелгән була. Кая барырга, ни эшләргә? Озата килүче җитәкчеләр авария штабын эзләп китәләр, ә курстагылар, автобуслардан чыгып, күз күремендәге хәлгә тап булып, хәйран калып торалар. Алда—гаять зур атом электр станциясе. Ләкин ул инде янган-көйгән, бер блогы җимерелгән, каралып беткән, аннан хәзер дә төтен чыгып тора, уңлаган югары вольтлы электр линиясенең терәк баганалары аркылы-торкылы авып төшкән. Тирә-юньдә тәртипсезлек, чуалчыклык. Атом электр станциясе өстендә уннарча көчле хәрби вертолетлар оча, аларның гөрселдәп чыккан каты тавышыннан һава гына түгел, җир селкенә, колаклар тона. Һәр җирдә кызыл, сары, яшел һәм башка төстәге түгәрәкләр эленеп тора.

Бу түгәрәкләрнең нәрсә икәнлегенә төшенә алмаган егетләрнең икенче көнне үк үзләренә дә шулар белән мәш килергә язган икән. Аларны ашыгыч рәвештә Полесье дигән бер авыл мәктәбенә урнаштыралар да, иртән иртүк җимерек блок янына китереп, эш кушалар. Ерактан вертолетларга эленеп куйган төрле төстәге матур-матур түгәрәкләр булып күренгән нәрсәләр гап-гади хәрби техника парашютлары икән. Курстагылар ике көн буе иртәдән кичкә кадәр шул парашютларга ком, чуерташ, доломит калдык-постыклары, кургаш, аккургаш коелма кисәкләре салып, вертолетларга тагалар, ә тегеләр аларны дүртенче блок җимерүгә өстенә парашюты-ние белән илтеп ташлыйлар. Җәһәннәм тишегенә, йөкнең кайсы туры килә, кайсы юк. Иң төп бурыч — тирә-юньгә берөзлексез радиация ташкыны атып яткан реактор коесын томалау. Тик син теләгәнчә генә эшләп буламыни аны? Моның өстенә, вертолетлар белән ташланган кургаш һәм аккургаш коелма кисәкләре реактор эчендә эреп, кабат агулы болыт булып тышка чыга, һавага күтәрелә һәм өстәмә мәшәкать тудыра.

Ниһаять, дозиметрия хезмәткәрләре дә килеп төшәләр. Моңарчы җимерек станция тирәсендә мәш килгән халык атом радиациясенең ни дәрәҗәдә булуын да белми.

Аннары Василий Емельянов һәм тагын җиде-сигез кеше авария булган беренче төндә үк ярты сәгать эчендә халкы эвакуацияләнгән энергиячеләр шәһәре Припятьне сакларга җибәрелә, чөнки чүлдәге борынгы шәһәрләр кебек, буп-буш калган шәһәр урамнарында мародерлар күренә башлый. Бу — Белоруссия авылларыннан тиз йөрешле мотоциклларда килгән, өйләреннән фәкать өс киемнәре белән генә чыгарып җибәрелгән халыкның байлыгына кул сузучы яшьләр булып чыга.

— Безгә, ул малайларга кисәтеп тә тормый, атарга күрсәтмә бирелде, — ди Емельянов. — Ләкин без алай эшли алмадык. Әле бит ялгышу да мөмкин иде, чөнки төнлә өй хуҗалары үзләре дә кием-салым, ятак әйберләр, онытылып калган документларын алырга кайткаладылар. Шулай да, «мотоциклчылар» кайбер фатирларны, кибетләрне, аптекаларны таларга өлгергәннәр иде.

Ул көннәрдә ташландык кала урамнарында коточкыч күренеш күзәтелә. Өйдән чыгып китү уңаенда халык суыткычта, кухняда булган бар азык-төлекне балконнардан, тәрәзәләрдән урамга ташлый, чөнки ул инде радиацияләнгән, ашарга ярамый. Аларны яртылаш йоны коелган, параличланган, арт саннарын өстерәп йөргән этләр, мәчеләр ашап йөри. Бигрәк тә буш урамда авыру мәчеләрнең кычкыруы йөрәк өзгеч янгырый. Парк, сквер, аллеялардагы элек ямь-яшел булып утырган агачлар, декоратив куаклар, чәчәк клумбалары саргаеп, йә булмаса алсу төскә кереп, корып төшкән, кибеп беткән. Урамнарда ташлап калдырылган автомашиналар, мотоцикллар, башка техника.

Ә бу вакытта хөкүмәт житәкчеләре нәрсә эшләргә дә белми, аптырап утыралар. Катастрофадан соң бишенче тәүлек узгач кына Горбачев үзәк телевидениедән чыгыш ясап, Чернобыльдә авария турында хәбәр итә. Ләкин авариянең зыяны зур түгел, куркыныч юк, тыныч, аварияне бетерү өчен бөтен чаралар күрелә, дип ялганлый илнең иң олы түрәсе.

Әлбәттә инде, катастрофаның масштабы, аның дөньякүләм һәлакәт булуы, беренче этапта да дистәләрчә кешеләрнең ут, радиация эчендә һәлак булуы, шул исәптән берничә станция хезмәткәренең беренче шартлау вакытында ук җимерек астында кысылып калуы, аларның ярдәм сорап ялвару авазлары, ләкин аларны коткарырга мөмкин булмавы, кысылган килеш калулары турында әйтми ул.

Тугызынчы көнне генә курска килгән хезмәткәрләр алдында атом электр станциясе тирәли утыз чакрым радиуста урнашкан авыл халкын башка җиргә күчерү бурычы куела. Башта аларның үзләрен шушы радиустан читкә чыгаралар, ниндидер бер авылга күчерәләр.

— Эвакуацияләнәчәк халыкка дөресен сөйләмәскә әйтелде безгә, — дип сөйли Василий Емельянов. — Ике-өч көнгә генә китеп торыгыз, озакламый яңадан өйләрегезгә кайтырсыз. Берничә көнлек ризык алыгыз да...»

Юк, халык ышанмый. Ул инде Припять шәһәре халкы белән булган хәлне яхшы белә. Белә, тик башка чара калмый, буйсына. «Сез хет алдашмагыз инде, дөресен сөйләгез. Без дә бит бик үк надан түгел, анларга тырышыр идек»,—диләр аларга. Ләкин буйсынмаганнар да була. Икеме, өчме гаилә урыннан кузгалырга катгый каршы килә, авылда кала: «Шунда тудык, шунда яшәдек, шунда үләрбез»,—диләр алар.

—Андагы хәлне сөйләп тә бетерерлек түгел. Үзебезнен дә кычкырып елап жибәрәсе килгән чаклар еш булды. Халыкнын йорт-хайваннары урамда калды. Дуңгызларын тоталмыйлар, алары чиный-чиный кире якка чаба. Умарта кортлары ояларын күтәреп китәрдәй булып гөжләп утырып калдылар. Кайсылары хәтта этләрен баудан ычкындырырга да онытып киткән иде. Телеграф баганаларында, моржа түбәләрендә, агач башларында йөзләгән ләкләк авылдагы шау-шу, ыгы-зыгынын сәбәбен белергә тырышкан сыман, тирә-якка аптырашлы караш ташлап, башларын әле бер, әле икенче якка боргалап, монаеп утыра бирәләр. Коточкыч!..

Поезд килмәгән булса, Емельяновнын тагын әллә нәрсәләр сөйләргә исәбе бар иде. Саубуллашканда ул гадәттәге уртак аралашу теле—урысчадан татарчага күчеп:

—Эх, тутар юлдашларым, зинахар сак пулыгыс, үсекесне саклакыс! Анта кәлләр пит начар,—дип калды. Ул үзе дә Казанга, госпитальгә тикшеренергә юл тота иде, чөнки шул сигез-тугыз көндә дә радиация белән бик нык зарарланып кайткан икән.

Соныннан Газиз катастрофаны, андагы аяныч хәлләрне Емельянов сөйләгәннәрдән бик күпкә артык күрде. Күреп кенә дә калмады, ә үз жилкәсендә, үз тәнендә, үз язмышында татыды. Анын Айсылуга сөйләгән хикәяте исә үзе күргән, үзе татыганнарнын чеметеме генә иде әле.

* * *

Чернобыльдән тәмам арып-талып, йончып, авыруга сабышып кайтты Газиз. Бер атна беркая да чыкмыйча ял итте, ваннада жылы, рәхәт суда чупырдады. Шулай тынычланып ял итү, суда коену белән ул һәлакәттә алган авыр тәэсирдән, нурланыштан, башка проблемалардан ансат кына арынырмын бәлки, дип уйлады. Элек сәламәтлеге нык иде анын. Яшьтән физик эш эшләп, спорт белән шөгыльләнеп, буыннарын ныгытып үсте, аннары да көрәк, балта кебек коралларны еш тотарга туры килде ана. «Авырыйм»,—дип хастаханәгә яки сырхауханәгә барганын хәтерләми ул. Бәлки анын нык организмы бирешмәс?..

Берничә көн ял иткәч, Газиздә дөньяга чыгып керү теләге туды. Анын киенгәнен күреп, Сәрмәдия:

—Кая жыенасын?—дип эндәште.

Гадәттә ул Газизгә битараф булып яши иде: чыгып китсә дә, кайтып керсә дә ана барыбер. Бу юлы исә нигәдер кызыксынды хатыны. Әллә бер-бер сүзе бар идеме?

—Военкоматка, Тансык дус янына барып кайтыйм, дигән идем,—диде Газиз, тыныч булырга тырышып.

—Тансык дус, дисен инде. Жыен хәшәрәт белән дус булып йөрисен шунда...

—Каян белдең әле анын хәшәрәт икәнен? Әлегә кадәр син дә аны якын күрәдер иден шикелле? ·

—Синен күнелен булсын дип үз күргән булып кыланганмындыр. Кабахәт...

—Әйт, нәрсә булды?

—Син киткәч тә, күчтәнәчләр тотып килеп керде. Әйдә, икәүдән-икәү калып сыйланыйк әле, ди. Бу турыда мин күптән хыялланам инде, ди. Кыскасы, мина мәхәббәте төшкән икән, минем кочакта кунып китәргә иде исәбе. Капкалый дигәч тә, бер азгын дип уйлаган иде ахры, хәсис. Коньяк шешәсе белән башын ватып чыгара яздым, качып котылды. Менә нинди ул синен дустын...

Газиз, салкын суга манчып алган бала кебек, өнсез калды. Кара инде бу Торна күзне! Нинди әшәкелек, нинди затсызлык! Әллә барып үз кабинетында бәреп үтерергәме бу адәм актыгын? Һич югында кикриген шиндереп алырга...

Эчендә ут уйнады, кыбырсынды, тик бер сүз әйтә алмады. Уйлары чуалган иде аның бу минутта.

—Нәрсә катып калдың? Теленне аркылы тешләдеңме әллә? Әллә сиңа барыберме? Минем урында бер азгын хатын булса, син нишләр идең? Ишетәсеңме?

—Ишетәм,—диде Газиз, ниһаять, һәм кайнап чыгып китте...

Сарычевның кабул итү бүлмәсенә кызып барып керде ул. Секретарь кыз аны күптән белә, шуңа күрә тоткарлап тормады: «Ул үзендә». Ишек ачып кергәндә Торна күз янында икеме-өчме хезмәткәре утыра иде. Ишектә Газизне күреп, Торна күз аптырабрак киткән иде, ләкин югалып калмады. Нәрсәдер сизенеп:

—Мы заняты пока,—дип Газизне туктатмакчы булды.

—Мин дә бик занят. Тем не менее из Чернобыля привез вам горячие приветы,—диде Газиз хәйләле русчалатып һәм кыю-кыю басып Торна күз янына килде. Хуҗа икеләнеп кенә торып басты һәм исәнләшү нияте белән кулын сузган иде, шул мизгелдә Газиз яшен тизлеге белән кулын күтәреп Торна күзнең яңагына ялтыратып җибәрде. Ул шулкадәр көчле чәпәде ки, тегенең күзеннән утлар очты. Бу хәлне күреп торган хезмәткәрләре сикереп торып Газизгә ташланмакчылар иде, Газиз урысчалатып:

—Если не хотите великого скандала, не подходите,—диде тешен кысып.—Этот подонок заслуживает большего...

Урысча әйтсәң, ярыйсы гына тупас, эт җаннарның зиһененә барып ирешерлек, тәэсирле килеп чыга бит ул: тегеләр шып булдылар.

Газиз башын горур чөеп кабинеттан чыгып китте. Башкача ул бу җирәнгеч адәм актыгы белән булган мөнәсәбәтләрне дә, бүгенге хәлне дә һичкайчан искә алмаска, җанны борчымаска, мәңгегә онытырга сүз бирде үз-үзенә. Әйе, биргән иде. Ләкин йөрәк ярасы тиз генә төзәләмени ул?..

* * *

Чернобыльдән кайткannан соң, барлык дөнья мәшәкатьләрен онытып, тынычлап яшәргә иде исәбе Газизнең. Казанда тикшеренү үтеп, ике ел рәттән курортка дәваланырга барды. Берсе—соцстрах, икенчесе үз хисабына. Алып кайткан акчасы шуның белән бетте дә.

Аннан биреп җибәргән белешмә буенча ул егерме дүрт рентген нурланыш белән зарарланган иде. Егерме биш булса, аңа өченче төркем инвалидлык бирергә тиешләр. Чынында исә аның утыздан да ким түгел, ә бәлки кырык, хәтта илле дә булгандыр. Чернобыльдә дозиметрчылар бик нык алдаштылар. Алдашмасалар, аларны анда утыртмаслар да иде шул. Каһәр төшкән Чернобыль җирендә Газиз үзенә күрә ачыш ясады: элек һәр адымда «Все—во имя человека, все—для блага человека» дип шапырынган бу совет, бу урыс җирендә бер изге гамәл дә, бер иман да юк икән бит. Барысы да шапырынкы ялган. Һәр җирдә—алдашу, һәр адымда—мәкер, икейөзлелек. Кеше тормышы, кеше язмышы ике тиенгә дә тормый бу башбаштак илдә. Бөтен дөнья җәмәгатьчелеге алдында СССР дигән бөек илнең йөзенә кызыллык китермәс өчен атом-төш һәлакәтен гади авария дип күрсәтергә маташтылар, аның эзләрен яшерер өчен гадел һәм гадел булмаган бөтен чараларны кулландылар, меңнәрчә кешене нурланыш утына илтеп тыктылар...

Һәлакәтне бетерүдә катнашкан һәр кеше инвалид хәзер, чөнки ул анда кырык, илле, аннан да күбрәк рентген нурланыш-радиация алып кайтты. Тик аларның берсенә дә: «Син чынында бик күп, фәлән чаклы рентген нурланыш алдың бит»,—дип әйтмәячәкләр, диагнозыңны да расламаячаклар. Чөнки син ялганчылар, алдакчылар дөньясында яшисең. Һай, йөзен ачасы иде бу алдашулы, әчкерле, икейөзле дөньяның...

Газиз кайтып-кайтып уйлый болар турында. Тынычлап яшәүме соң монда?..

Бер кичне ул, эштән кайтып, телевизор каршына утырды. Тапшыру Казаннан, Чулман буенда төзелеп яткан атом электр станциясенең расланмаган проекты буенча, сейсмик яктан тыныч булмаган тектоник ярылу урынында төзелүе, бу гамәлгә киң җәмәгатьчелекнең, халыкның ризасызлык белдерүе турында иде. Димәк, тагын ялган, тагын мәкер булган. Газизнең янә ачуы чыкты. Ничек түзеп тормак кирәк? Ул яхшы белә: каладамы, саладамы, иң зарарсыз корылманы төзер өчен дә синең проектыңның расланган булуын кат-кат тикшереп җаныңа тияләр. Ә бередә дөньякүләм зурлыктагы атом электр станциясе төзиләр, аның инде яртысы төзелеп бетеп бара, аңа исәпсез-хисапсыз халык акчасы тотылган, шул тирәдәге авыл халкы инде булачак энергиячеләр шәһәренә күчерелгән, ә иң гади таләп, ягъни проектны раслау турында уйлап та карамыйлар. Нинди башбаштаклык! Бу бит түзеп тормаслык хәл! Юк, моны болай калдырырга ярамый! Татар дөньясы уртасында шундый куркыныч корылманың төзелеп ятуы турында Газиз элек ишетсә дә, аңа ул ничектер битараф яшәде. Бүген исә, Чернобыль мәхшәренең авырлыгын үз җилкәсендә татыган, кайгы-хәсрәтен үз күзләре белән күреп кайткан кеше буларак, әлеге хәбәрне йөрәгенә якын алды. Юк, һәлакәттән гарантиясе, ышанычы булмаган мондый төзелеш Чернобыль җиренә дә кирәк булмаган, Татарстан яки Башкортстан җиренә дә, башка җиргә дә кирәк түгел! Чернобыльдә чакта ул үзенең язмышын уртаклашкан мескен иптәшләре белән сүз кузгаткан саен, безнең илдә атом-төш электр станциясе төзү җинаятькә тиң, ә аны төзетүчеләр исә җинаятьчеләр, дип әйтә килделәр. Чулман буенда беркемнән дә рөхсәт сорамыйча, бигрәк тә шунда яшәүче ил-атның фикере белән санашмыйча, аның ризалыгын алмыйча АЭС төзи башлау—икеләтә җинаять.

Газизнең төн йокылары йокы булмады, шул турыда уйланып, кайгырып чыкты. Аның максаты хәзер ачык—атом электр станциясен төзүгә каршы хәрәкәт сафына басарга! Ләкин эшне кайдан, кемнән башларга? Үзенең теләге турында кемгә барып мөрәҗәгать итәргә? Шул турыда уйлап утырганда, кинәт аның исенә хезмәттәше Әнис Җамалиев килеп төште. Милли хисле, бик зәвыклы, укымышлы бу архитектор Татар иҗтимагый үзәгенең калада оештырылган бүлеге эшендә катнашып йөри. Ул бу төзелеш хакында белми калмас...

Иртән конторага барып керүгә, Газиз озын коридор буйлап Җамалиевне эзләп китте. Ул эшли торган бүлмә коридорның урта бер җирендә. Эш сәгате башланырга шактый вакыт булуга карамастан, Әнис ак күлмәк, чем-кара түбәтәйдән өстәл артында, проект эшләп утыра. Уңган, эшлекле кеше шул. Милли хәрәкәт эшендә катнаша башлау белән, ул үзенең татарлыгын таныту, үз халкының мәнфәгатен кайгыртып йөрүче кеше икәнлеген искәртү йөзеннән бик килешле кара түбәтәй киеп йөри башлады. Газиз вакыт-вакыт үзе дә чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, шундый кара түбәтәй киеп йөрергә кызыгып куя иде.

Әниснең йөзе якты, елмаюы матур. Сөйләшүе дә төпле, мәгънәле. Газизнең гозерен белгәч, шатланып:

—Менә бусы әйбәт, Газиз малай! Безгә синең кебек көрәшче егетләр кирәк. Нишләп соң әле синең турыда онытып җибәрдек?—диде. Аннары: —Иртәгә безнең оешмада җыелыш була. Кил, тыңлап утыр, эшнең асылына төшенерсең. Аннан соң карарбыз,—дип өстәде.

Иҗтимагый үзәк бүлеге әгъзаларының җыелышы театр бинасының кече залында үтте. Анда утызлап кеше җыелган иде. Күбесе олы яшьтә, яшьләр исә санаулы гына—Газиз шуңа игътибар итте. Бүлек җитәкчесе, инде алтынчы дистәсен тутырып килгән озын, какча гәүдәле, пөхтә киемле, гомере балаларга тарих фәне укытып үткән Хәйдәр ага Шәһитов олы сүзне үзе башлады:

—Чернобыль фаҗигасенә быел дүрт ел тула. Без бу көннәрдә йөз елларга газаплы үлем китерүче, кеше үзе уйлап тапкан дәһшәт көче турында

уйлыйбыз,—диде ул турыдан-туры конкрет темага күчеп. Тәҗрибәле укытучы үгезнең мөгезеннән эләктерергә кирәклеген белә.

—Үзенә-үзе кул күтәрергә аны нәрсә мәҗбүр иткән соң? Кем этәрә аны мона, нинди көчләр? Хәлбуки, бар андый көчләр, халык фикере белән бөтенләй исәпләшергә теләмәгән тун акыллы ведомстволар. Без, хокуклары чикле автономияле җөмһүрияттә яшәүчеләр, аларнын көчләп тагылган мәҗбүрияттән һәр адымда үз тирәбездә татып яшибез... Әгәр инде социаль гаделлек хакында каршы әйтергә теләп авыз ачабыз икән, чыбыркы гына шартлап куя, анын саен безгә, язмыш хөкеме белән икенче сортлы саналган халыкка, башны түбәнрәк иярргә генә кала...

Хәйдәр ага кыска гына вакытта тынып торды, күзлеген төзәтте, тынлаучылар өстеннән күзләрен йөртеп чыкты. Һәм сүзен дәвам итте:

—Бүген татар милләте өстенә жиде башлы аждаһа булып килгән шундый мәҗбүриятнең берсе—Татарстанның гүзәл бер почмагында, зур-зур кала-салалары халык белән кайнап торган урында, горурлыгыбыз Иделгә коя торган, бай тарихыбыз кебек мул сулы Чулман елгасы буенда баш калкытып килә торган атом электр станциясе... Бу үтә хәвефле вакыйганы тагын бер мәртәбә уртага салып сөйләшик әле, жәмәгать! Монын сәбәбе дә бар. Мәгълүм булганча, СССР хөкүмәте күптән түгел, Фәннәр Академиясе каршындагы Сейсмология буенча эксперт комиссиясе нәтиҗәсенә таянып, Татарстан АЭСын тиз арада сафка кертелергә тиешле корылма сыйфатында финанслау турында карар кабул итте. Ул гына да түгел, республика хөкүмәтенең үтенеч-мөрәҗәгате дә эзсез калды. Әлеге көндә Казанга килеп ирешкән бердәнбер рәсми документта—СССР Министрлар Советынын Татарстанда атом электр станциясе төзүгә каршы жәмәгатьчелек хатына биргән жавабында—бу корылманы төзү дәвам иттереләчәк, диелгән. Республикабызнын Югары Советы АЭСның производство максатындагы объектларын төзүне туктату турында карар кабул итте. Ләкин, ни аяныч, әлегә бу документнын да юридик көче юк. Бу унайдан СССР Министрлар Советынын жаваплы әһелләре академик В. Н. Страхов житәкчелегендәге дәүләт комиссиясе төзеп, аны янә калкан рәвешендә файдаланырга ниятләделәр. Әлеге комиссия эшендә үзебезнен кеше, нефть берләшмәсе баш геологы, минералогия фәннәре докторы Мөслим Хәлиуллов та катнашты. Бүген ул безнең арада. Комиссиянен эше нинди шартларда һәм юнәлештә барган? Мөслим әфәнде безгә шул турыда сөйләп бирергә жыена. Рәхим итегез...

Мөслим Хәлиуллов та яшь кеше түгел, чәчләренә күптән чал сарган, Шәһитов кебек үк озын гәүдәле, ләкин анардан кинрәк, затлы аксыл-яшькелт костюмнан, тик бер жилкәсе бераз төшеп, анын гәүдә рәвешен чак кына бозып тора. Ул да сүзгә кеше кесәсенә керүчеләрдән түгел икән.

—Утыз өч галимнән торган эксперт комиссиясенең эше гаять киеренке шартларда барды,—диде ул авыр сулап.—Анын эшендә республикадан без барлыгы дүрт галим катнаштык. Чулман буенда АЭС төзүнен нинди зур хата булачагын һәм афәткә китерәчәген никадәр генә дәлилләргә тырышсак та, хакимият мәнфәгатен якларга тиешле галимнәр үзләренең безгә көчләп тагарга тырышкан экспертиза актына бернинди төзәтмә кертергә юл куймадылар. Ә дәлилләребез бәхәссез, кисәтүебез төпле иде. Ике көн буена уникешәр сәгать барган «якалашуларда» минем үземә генә дә егерме тапкыр сүз алып сөйләргә туры килде. Ин төп дәлилләребез итеп АЭСның тектоник ярылу урынында төзелүен, анда махсус тикшеренүләр уздырылмавын, анын сейсмология, геология, гидрология шартлары өйрәнелмәвен күрсәтеп карадык. Ләкин боларнын берсе дә Мәскәү тарафдарларына тәэсир итмәде. Киресенчә, бер галим-сейсмолог Татарстан жире Әрмәнстаннан ике мең чакрым читтә тора, анда бернинди дә жир тетрәүләр булырга мөмкин түгел, дигән акылсыз фикер белән чыкты. Станция жирле органнар белән бернинди килешүсез, расланмаган, үзен начар яктан күрсәткән иске типтагы проект нигезендә төзелә, ана инде ярты миллиард сум акча тотылган. Менә ни өчен тарткалаша атом ведомствосы. Дөресен әйткәндә, галимнәрчә бәхәс килеп чыкмады. Безнен аргументларны читкә кактылар. Ахыр чиктә без, комиссия тәкъдим

иткән актка кул куюдан баш тартып, аерым фикеребезне язмача бәян итәргә мәҗбүр булдык. Менә шул...

—Мөслим әфәнде, гомумән, сез атом электр станцияләрен төзүгә, атом энергиясен хуҗалыкта куллануга ничек карыйсыз?—дип эндәште ана залдагыларның берсе.

—Безнен илдә бүген атом энергиясен халык хуҗалыгында куллануга ихтыяҗ юк, дип саныйм. Су-елгалар, шарлавыклар энергиясен куллану безнең ил өчен күпкә кулайрак, чөнки ил буенча андый елгаларның, андый шарлавыкларның исәбе-хисабы юк. Иң мөһиме—аларны көнкүрештә эксплуатацияләү беркемгә дә куркыныч янамый. Моннан тыш ягулык белән эшли торган станцияләр өчен дә чимал житәрлек—күмер, мазут... Ә атом электр станцияләре... Чернобыль катастрофасы үзен күрсәтте инде. Минемчә, бездә атом электр станциясе кебек артык җаваплы корылмаларны төзүгә хәзерлекле көчләр, ведомстволар әлегә юк. Ә катастрофага килгәндә... Бу бик куркыныч. Шуны гына әйтим: атом станциясе реакторының аерылгысыз компоненты—плутонийның таркалуы миллиард еллар буена дәвам итә. Күз алдына китерә аласызмы? Шуна күрә катастрофаның ахыры нәрсә белән бетәсен әйтүе кыен.

Хәлиуллов сүзен тәмамлап, урынына барып утырды.

Аннары Газизнен хезмәттәше Әнис Җамалиев торып басты. Үзе тыныч булса да, сүзләре тәэсирле иде аның:

—Без коточкыч афәт алдында. Өстәвенә, безнен күршебездә генә, үпкәбезгә терәп диярлек, Башкортстан АЭСы төзелеп ята. Кыскасы, бер карыш җирдә—ике станция. Шундый ук станцияне төзү икенче бер чигебездә—Удмурд республикасында планлаштырыла. Күрше Ульян өлкәсендә инде андый станция эшләп ята. Чернобыльдәге кебек һәлакәт була калса, бер безнең республика гына түгел, бөтен Идел-Каспий бассейнындагы халыклар, гомумән, тереклек юкка чыгачак...

Җыелышка килгән кешеләрнең чыдамлыгы бетте. Аларның әле берсе, әле икенчесе торып, ярсый-ярсый сүзен әйтте, тәкъдимен кертте:

—Төзелешкә каршы халыктан имза җыярга!

—Кисәтү забастовкасы ясарга!

—Һәр җирдә митинглар үткәрергә!

—Халыкны җыеп, төзелеш барган җиргә барырга, анда да митинг оештырырга!..

Татар иҗтимагый үзәгенең бүлек җитәкчесе җыелышка нәтиҗә ясады:

—Фикеребез, теләгебез, позициябез бер безнен. Рәхмәт! Мондый шартларда халыкка каршы юнәлтелгән ведомство мәнфәгатьләре белән без башкача килешеп яши алмыйбыз. Тереклек хакына, килер буыннарның имин язмышы хакына без җитди адым ясарга тиешбез. Әгәр безнең таләпләргә колак салмыйлар икән, беренче чиратта Чернобыль һәлакәте булган көнне массакүләм митинглар үткәрү мәгъкуль булыр. Кем бу гамәлне яклап тавыш бирә?

Барысы да дәррәү кул күтәрделәр. Газиз исә кулын беренчеләрдән булып күтәргәндер, чөнки җыелыш, аның эчтәлеге, кайнарлыгы, анда каралган мәсьәләнең артык дәрәҗәдә мөһим булуы аны тирән дулкынландырды, дәртләндерде. Менә бит ул ничек: халык йоклап ятмый, халык үз язмышына, киләчәгенә битараф түгел икән, халык көрәш юлына чыгып баскан, ул ярсый...

Таралышыр алдыннан Әнис Газиз янына килеп басты:

—Ничек?

—Шәп!—диде Газиз, дулкынланып.

—Митингта чыгыш ясый алырсыңмы? Син Чернобыль һәлакатенен тере шаһиты. Синең чыгыш анда иң көчле яңгыраш табачак...

Бу тәкъдимнән Газиз аптырап, хәтта каушап калды:

—Ә ничек?

—Тегендә күргән-белгәннәреңне бәйнә-бәйнә сөйлә дә сөйлә. Синнән башка нәрсә таләп ителми.

—Риза,—диде Газиз, гәрчә башта икеләнеп торса да.

Газиз митингка көн буе да, кичен дә, иртән дә әзерләнде. Исәбе—Чернобыльдә күргән-белгәннәрен озак итеп, тәфсилләп сөйләргә иде. Ләкин митингта һәр чыгыш ясаган кешегә өч-дүрт кенә минут бирәләр икән. Бу турыда ул каланың үзәк мәйданына килгәч белде. Җирле радиодан, телевидениедән белдерү ясалгандыр, үзәк мәйданга халык күп җыелган иде. Һәр җирдә шигарьләр, алтакталар, транспаратлар, плакатлар, карикатуралар: «Икенче Чернобыльгә—юк!», «Атом корбаннары булырга теләмибез!», «Башбаштаклыкка юл куймабыз!», «Атом—ул һәлакәт!», «Долой АЭС!»...

Мәйданда халык дулкыны әле бер, әле икенче якка чайкала. Менә Мәдәният сараеның колонналар рәтенә куйган микрофон янына кабат Хәйдәр Шәһитов күтәрелде, тамак кырды һәм оста ораторларга хас алым белән кабат үгезнең мөгезеннән эләктерде:

—Чернобыль һәлакәте материянең иң бәләкәй кисәкчеге булган атомның бөтен табигатькә чикләнмәгән зур афәтләр китерә алуын күрсәтте,—диде ул ачык тавыш белән. Мәйдан чайкалып, гүләп куйды.—Бу АЭСның бер генә блогында булган авария нәтиҗәсендә таралган радиоактив изотоплар миллионлаган кешеләрнең сәламәтлегенә зур зыян китерделәр һәм бүген дә китерәләр. Әлеге һәлакәт белән көрәшкә дистәләрчә миллиард сум акча тотылды инде. Ә безнең Чулман буенда төзелә торган атом станциясендә сигез блок планлаштырылган. Ишетәсезме, сигез!..

Мәйдан кабат чайкалып куйды, «ух» итте.

Митингны алып баручы сөйләргә теләгәннәргә бер-бер артлы сүз бирде. Һәр сөйләшүченең чыгышы ачынулы, дәлилле, кайнар иде.

—Түбән Кама ГЭСы суының биеклеге алтмыш метр белән, ә Чулман буенда төзелә торган АЭС илле метр биеклек белән билгеләнә,—диде милли үзәк эшлеклесе, табиб Ильяс Ямаев.—Димәк, АЭС ун метрга түбән урнашкан. Әгәр буа, әйтик, җир тетрәүдән яисә башка бер очракта ычкына калса, АЭС тулысы белән су астында калачак.

Халык тагын гүләп куйды.

Шулчак микрофон янына урта яшьләрдәге, тәбәнәк буйлы, пеләш башлы, күзлекле бер кеше йөгереп килде һәм микрофонга:

—Җәмәгать, җәмәгать, миңа да ике генә сүз әйтергә рөхсәт итегез,—дип эндәште. Җыелган халык арасыннан: «Сөйлә, әйдә!» «Бирегез рөхсәт, сөйләсен!»—дигән сүзләр яңгырады. Митингны алып барган Шәһитов та, әлеге кеше белән бер-ике авыз сүз алышкач, каршы килмәде.

—Мин үзем, җәмәгать, физика укытучысы һәм, мәгълүмдер, атом-төш энергетикасы турында хәбәрдар. Мин атом электр станцияләрен төзүгә каршы түгел, аларны кирәк дип саныйм, чөнки дөньяда хәзер алар гына иң арзан электр энергиясен бирә. Экологик яктан да алар иң зарарсызлар...

Физика укытучысының шушы сүзләре дөрләп янып торган учакка бензин сипкән кебек булды—халык шаулаша, кычкырыша башлады: «Әй, син, физик, нәрсә лыгырдыйсың? Дөньяга күзлегеңне салып кара! «Чернобыль афәте турында ишеткәнең юкмы әллә синең, пеләш баш?» «Кайтып хатыныңны үрәт, үрәтник!..»

—Туктагыз әле, җәмәгать! Мин дә, Чулман Аланында АЭС төзесеннәр, димим бит. Аның урынын ялгыш сайлаганнар—бусы хак. Ләкин АЭСсыз да булмый, чөнки газ да, нефть тә бик кыйммәтле байлык бит ул, аларның запасы да хәзер күп түгел...

Укытучы тагын нәрсәләрдер әйтергә теләгән иде, тик кызганнан-кыза барган митингтагылар ана сөйләргә ирек бирмәделәр:

—Кит әле, кит, майламаган арба көпчәге кебек сайрама...

—Син ылучшы кайтып дәресенә әзерлән, балаларың надан калырлар...

—Житте, абзый, саескан бүтәкәсен санап утырма...

—Өйдән торып кибәк сукма...

Мондый мыскыллаулардан соң физика укытучысына микрофон яныннан ничек итте, шулай тиз шылудан башка чара калмады.

Чират Газизгә житте.

—Мин Чернобыльдә, ягъни авариягә дучар ителгән дүртенче блокка саркофаг төзүчеләрнең берсе,—диде ул тирән дулкынланып. Митингка

жыелган меңләгән кеше шып булды. Меңләгән кеше алдында олы һәлакәтне бетерешүдә катнашкан тере шаһит, гап-гади бер кеше басып тора. Ул нәрсә сөйләр? Шуна да, әнә, мәйдандагы халык тып-тын калды.

Гомерендә тәүге тапкыр шул кадәр күп кеше алдында чыгыш ясарга микрофон алдына килеп баскан Газиз башта каушады, тирләп-пешеп чыкты, кирәкле сүзләрен тапмый азапланды. Аннары ул әкренләп тынычлана барды, ана ышаныч килде, чөнки халык аны тын да алмый, йотлыгып тыңлый иде. Газиз үзе күргәннәрне дә, Емельянов сөйләгәннәрне дә исенә төшерде: торба астында кысылып калган станция хезмәткәрләре, арт сансыз өстерәлгән мескен этләрнең улавы, мәчеләрнең кычкыруы, йоннары коелган әтәч-тавыклар, утырган жирендә кәеп каткан алмагачлар, каражимеш, котырып гүләгән умарта кортлары, алдакчы дозиметрчылар, ватылып төшкән вертолетлар... Барысы турында да ашыкмый, исенә төшерә-төшерә сөйләде ул халыкка. Һәм аны беркем, хәтта жиелышны алып баручы үзе дә бүлдермәде, тынын кысып тыңлап торды.

—Чернобыль һәлакәте китергән зыянның иге дә, чиге дә юк. Без реактор коесын томаладык, дип кайттык. Ләкин тынычланырга бернинди дә гарантия юк. Реакторда калган атом кыза, аның температурасы һаман күтәрелә һәм көннәрдән бер көнне өстенә капланган меңнәрчә тонна авырлыктагы «капкач»ны атып бәреп, аның кабат жир өстенә чыгуы мөмкин. Ул чагында һәлакәтнең нинди масштаб алуы турында әйтүе дә кыен. Бәлки мин ялгыша торганмындыр, ләкин ихтыярымда булса, беркайда да, беркайчан да һәм бер кешегә дә атом электр станциясе төзергә рөхсәт бирмәс идем, чөнки атом—гаять дәрәжәдә куркыныч, аның соңы ничек бетәсен дә белүе мөмкин булмаган хәтәр матдә ул. Атом—һәлакәт, үлем, ана каршы дәва да булмаган төрледән-төрле авыр чир, гүзәл табигатебезнең бик озакка зарарлануы, суларга саф һава, эчәргә чиста су житмәү, тереклекнең тәмам төкәнүе, иксез-чиксез бәхетсезлек чыганагы ул. Шәхсән мин үзем Чулман буендагы корылманы төзетмәс өчен башымны куярга да әзер...

Митингка жыелган халык беренче тапкыр шаулатып кул чапты, кемнәрдер: «Дөрес әйттең, афәрин!» «Халык рөхсәтеннән башка АЭС төзетүчеләрне судка бирергә!»—дигән репликалар ташланды. Газиз үзе исә жиңел сулап куйды.

Митингта катнашучыларның барчасы атом-төш электр станциясен төзүгә каршы резолюция кабул итте.

—Әйбәт сөйләдең, афәрин! Иң яхшы, иң тәэсирле чыгыш—синеке булды, диде соңыннан Жамалиев Газизгә. Юк, салпы якка салам кыстырудан әйтмәде ул аны, чөнки Әнис ике төрле сөйләүчеләрдән түгел, ихлас кеше. Шәһитов үзе дә, Газизгә якын килеп: «Рәхмәт энем, бик дәлилле, тыңлаучыларның күңел түренә барып житәрлек итеп сөйләдең»,—диде һәм кулын кысты. Аннары өстәп куйды:

—Бәлки тагын сөйләрсең? Митинглар әле башлана гына, чөнки хәл киеренке, үзең дә күреп торасың. Күсәк күтәрми булмый. Күлдән шулпа эчкән сиңдәй егетләрнең безнең эштә катнашуы зарур. Уйла әле!

—Нәрсәсен уйлап торырга? Әгәр файда китерә алсам, мин риза,— диде Газиз.

—Менә бусына тагын да зур рәхмәт! Алай булса, көтәбез...

Әнә шул сәгатьтән Газиз өчен яна, чын-чынлап шау-шулы, давыллы, ярсулы тормыш башланды...

* * *

Тимерне кызуында сугып кал, дигән гыйбарәдән чыгып, ижтимагый үзәк бүлеге тагын берничә жыелыш һәм митинг үткәрергә карар кылды. Атом ведомствосының, Мәскәү түрәләренең тиресе калын. Аларга әйттең ни дә, әйтмәдең ни. Салган хатларга да, сугылган телеграммаларга да, республика житәкчелеге жибәргән үтенеч-мөрәжәгатькә дә исләре китмәде. Үз сүзләре генә сүз, үз эшләре генә эш. Төбәк халкының тектоник ярылу урынында расланмаган проект буенча АЭС төзелеп ятуына

ризасызлыгын ишеткәч, алар төзелешне туктату түгел, киресенчә, аны тизләтү турында кайгырта башладылар. Тизрәк төзеп бетерергә дә, «Юк инде, җәмәгать, эш бетте, сонга калдыгыз, станция сафка басты, хәзер аны җимерә алмыйсыз, телисезме-теләмисезме, ул сезнен җирдә эшләп ятачак, ә сезгә тавышыгызны басарга, авызыгызны йомарга кала»,—диярге бугай исәпләре. Төзелешнең бөтен Идел буе бассейны халыкларына, аларнын киләчәгенә һәлакәт китерәчәк афәт чыганагы булуы аларнын туң башларына һич барып житми. Мондый очракта нишләргә? Шайтаннан иман көтеп яту файдасыз, башланган көрәшне дәвам итәргә, күсәкне кулдан төшермәскә кала.

Чираттагы митинг каланың икенче олы мәйданында уздырылды. Биредә дә халык күп иде һәм ул митингнын башыннан ахырына чаклы умарта күче кебек гөжләп торды. Ике митинг арасында иҗтимагый үзәк бүлеге калада АЭСны төзүдә каршылык күрсәтү комитеты оештырып җибәрергә өлгерде. Анын рәисе итеп иҗтимагый үзәк активисты, шәһәр депутаты Гариф Кәрамов сайланган иде. Зур булмаган гәүдәле, әмма бөтерчек кебек хәрәкәтчән, көчле тавышлы кырык биш яшьләрдәге бу кешедә милли хистән тыш тирән акыл, көчле эрудиция дә бар. Сүзгә дә бик оста. Шуңа да, бу юлы сүзне ул башлады.

—Бүген Уфада ике автономияле республика—Башкортстан һәм Татарстан вәкилләренең, Иделне саклау комитеты әгъзалары катнашында, фәнни кинәшмәсе ачылды һәм шуның белән бергә ике республика җирлегендә ике атом гыйфритенең баш күтәрүенә каршы протест маршы башланды,—диде ул гөрләп чыккан тавыш белән. Бу хәбәр барып ирешкәч, җыелган халык шаулап куйды. Кәрамов дәвам итте:

—Чөнки эш үтә тирәнгә кереп китте һәм бу борчулы шартларда бары тик кискен чаралар гына унай нәтиҗәгә китерә алырлар...

Бу вакытта Газиз дә микрофоннан ерак түгел, Шәһитов белән Җамалиев янында басып тора иде. Аңа бүген дә сүз бирәчәкләр.

—Кәрамовтан соң син сөйләрсең. Аннары тагын бер «чернобыльче» сөйлиячәк,—диде Әнис.

—Кем ул?

—Керәшен егете, Питыр Никитин. Ул да һәлакәтнең үзәгендә булган. Әнә ул, танышың түгелме?

Әнис алардан ике-өч адымда гына бер читтә басып торган, үзе буйчан, үзе ябык, нечкә генә кара мыек җибәргән утыз яшьләр тирәсендәге кешегә ымлады. Ул сөйләүчене бик дикъкать белән тынлап тора иде.

—Юк, белгән кешем түгел,—диде Газиз.

Шул арада анын үзенә дә сүз бирделәр. Бу юлы Газиз халыкка өрәккә әйләнгән таҗиклар язмышын бәян итте. Җингәсе татар хатыны булган Әсрар хакында, анын һәм бер төркем башка таҗикларның дүртенче блок өстенә ни төстә менеп китүләре һәм ни төстә, ягъни кап-кара чәчләре, сакал-мыеклары, кашлары һәм керфекләре коелган килеш, шәп-шәрә төшүләре, аларны «Ашыгыч ярдәм» машинасына төяп киткән чактагы кызганыч хәл, таҗикларның башкача хастаханәдән борылып кайта алмаулары, барысынын да вафат булуы турында сөйләде ул...

Аннан микрофон янына керәшен егете килеп басты. Ул да шул чаклы күп халык алдында чыгып сөйләргә өйрәнмәгән иде бугай, тиз генә сөйләп китә алмады. Ниһаять:

—Мин Чернобыльдә бетон болгаткычта эшләдем,—диде ул әкрен тавыш белән. Ана шунда ук: «Начар ишетелә!»—дип кычкырдылар.

—Ул «миксер» дип атала,—диде Никитин тавышын күтәрә төшеп.—Ә безне «смертниклар» диләр иде. Бетон әзерләү заводы АЭСтан унбиш чакрымда, әзер бетон изməсен самосвallardan бетон болгаткычка күчереп төяү пункты сигез чакрымда. Шул бетонболгаткычта без дүртенче блокнын стенасы янына килеп эстакадага менәбез дә, бетон измәсен бушатабыз. Шулай һәркөн ике ай буена сигезәр сәгать эшләттеләр безне. Реакторны шул бетон һәм авыр металл катнашмасы белән томалап, эшен бетергәч кенә кайтып киттек. Ләкин, реактор скважинасын томалап кую әле бөтен бәладән котылдым, дигән сүз түгел. Без ясаган капкачнын күккә очып,

катастрофаның тагын да кабатлануы һәм аның ул вакытта тагын да катлаулырак, фаҗигалерәк булуы мөмкин. Ә андый куркыныч бар, ул Чернобыль катастрофасын үз күзе белән күргән, аны зарарсызландыруда катнашкан һәр кешенең баш миен бораулый. Шулай булгач, кирәкме мондый куркыныч корылма безнең төбәккә, безнең халыкка? Юк һәм юк!

Никитинның чыгышы һичкем уйламаганча төпле, тәэсирле, көчле килеп чыкты. Һәм, иң мөһиме, Никитин да, үткән чыгышында Газиз дә, реактор коесының капкачын алып ташлау ихтималын бер авыздан әйткән кебек халык зиһененә җиткерделәр.

Митинг дәвам итте. Газиз исә Никитин янына килде. Алар таныштылар.

—Миңа әйткәннәр иде синең турыда,—диде Никитин.—Без шәһәр һәм районда барлык «чернобыльче»ләрне барлап, үзебезнең ирекле җәмгыятьне оештырырга уйлап йөрибез. Барыбызга да тупланырга, социаль яклау дәгъваларга вакыт, чөнки без оятсыз рәвештә алданган, һәм матди, һәм физик, һәм рухи яктан таланган халык. Хөкүмәт тә, җирле хакимият тә, хәрби комитетлар да безне Чернобыльгә чакырган вакытта алтын таулар вәгъдә иттеләр. Безгә фатир да, автомашина да, акча да, төрле өстенлекләр дә бирергә тиешләр иде. Ә кайда алар? Вәгъдәне бирергә, алдарга-йолдарга оста безнең түрә. «Родина в опасности, выручайте ребята, она вас не забудет...» Кая ул! Кем ярты, кем аннан да күбрәк сәламәтлеген калдырып кайтты, ә безгә кәҗә тоягы күрсәттеләр. Мин хәзер дүрт ел квартир сорап йөрим һәм дүрт ел вәгъдәдән башка нәрсәне күргәнем юк...

Никитин үпкәле, ачулы иде. Һәм хаклы иде ул. Сөйләгәне дөрес, ташка баскан кебек дөрес.

—Оешуны тартырга-сузарга түгел, вакыт уза. Инде күпме егетләребез китте шул дүрт ел эчендә. Аларны да соңгы юлга «вәгъдәле» килеш кенә озаттык...

Газиз аңлады егетләрнең кая «китүләре» турында.

Алар кабат очрашырга, ирекле җәмгыять оештыру турында тагын бер кат сөйләшергә булдылар.

Иҗтимагый үзәк бүлеге, озын-озак уйлап тормыйча, атом электр станциясен төзүгә каршы халыктан имзалар җыюны башлап җибәрде. Шәһитов үзе дә, бүлек әгъзалары да, активистлар да халык арасына чыгып китте. Бу эштән Әнис Җамалиев та, Газиз Солтанов та читтә калмадылар.

Кыска гына вакыт эчендә шәһәр һәм район буенча АЭС төзүгә каршы меңнәрчә кешедән, ягъни унсигез том имза җыйдылар алар һәм рәсми рәвештә, барлык таләпләргә туры китереп, СССР Президенты һәм Министрлар Советы Рәисе исеменә озаттылар.

Шул ук вакытта митинглар, җыелышлар, фәнни конференцияләр үткәрү тукталмады, дәвам итте. Иҗтимагый үзәк, җитәкчесе Хәйдәр Шәһитов, аның иң якын көрәштәшләре Әнис Җамалиев, Гариф Кәрамов, Газиз Солтанов һәм башкалар ул көннәрдә җан-фәрманга чаптылар, гәрчә аларның да күңелләрендә вакыт-вакыт шик-шөбһә бәргәләнсә дә.

* * *

Атом-төш станциясе төзелешенә каршы иң көчле акция—төзелеш җирлегендә үткәрелгән митинг булгандыр. Төбәкнең барлык гаярь егетләре-кызлары, дистәләгән автобусларга төялеп, шул ук шигарьләр, плакатлар, телекамералар, фотоаппаратлар белән Чулман буена барып төштеләр. Чыгыш ясарга тиеш булса да, кызганычка каршы, Газиз бара алмады. Шуннан алда гына аны чир бәреп екты һәм ул тәүге тапкыр хастаханә пациенты булды. Табиблар, тикшереп, аның бөерләре бавыры, бер бөере һәм үнәче шешенгәнен, ашказанында да шеш барлыкка килүен билгеләделәр. Йөрәк тибеше дә шаптан түгел, кан басымы да югары, сулышы да кысыла. Моның өстенә, аякларын көзән җыера башлады. Боларның барысы да, ниһаять, Чернобыльдә күпләп алган нурланыш нәтиҗәсе иде.

—Көчле акция үткәрдек, Газиз малай,—дип канатланып килеп керде

Җамалиев аның янына.—Төзелеш дирекциясе җитәкчеләре куркып качканнар иде, митингка чыкмадылар. Ләкин без үз вазифабызны йөз процентка үтәдек. Көчле-көчле чыгыш ясаучылар булды, шул ук вакытта төзелешнең үзендә катнашкан егетләр дә сөйләде. Төзүчеләр белән аралаштык, вәзгыятьне аңлаттык. Алар үзләре дә хәлне аңлый, безнең фикерне, без үткәргән чараларны хуплый. Митингны кинога төшердек. Бергә-бергә карарбыз, тизрәк терелеп чык...

Ләкин Газиз тиз генә терелә алмады, ятты да ятты. Бер көнне Әнис, күчтәнәчләр тотып, тагын килеп керде. Авызы колагына җиткән, үзе һавалы:

—Җиңәбез бит, малай, җиңәбез!..

—Нәрсә булды? Әйт тизрәк!

—Республиканың Министрлар Советы АЭСта производство өчен билгеләнгән объектларны төзүне туктату турында карар кабул итте...

—Кит инде! Менә моңа рәхмәт!

Шатлыклары эчләренә сыймаган ике фикердәш ир-егет кочаклаштылар, аркаларыннан кагыштылар. Тынычлана төшкәч, Газиз:

—Ниһаять, республика хөкүмәте дә үз халкының таләбен ахыргача аңлады, аның хакын хакларга алынды. Димәк, боз кузгалды,—диде.

—Дөрес әйтәсең, боз кузгалды. Ләкин көрәшне туктатырга иртә әле. Гасырлар буе кыерсытылган, кимсетелгән, җәберләнгән татар җиренә тагын бер һәлакәт китерергә ниятләгәннәр иде. Тәмам бетерик, тамырын корытыйк бу татарның, дигәннәрдер. Корытмый гына торыгыз әле, сволочьлар! Ул станцияне, ул һәлакәт чыганагын, бик алай хаҗәт икән, үз җирегезгә төзегез! Ә без көрәшне туктатмабыз. Газиз Чулманыбыз буенда ул корылма төзелмәячәк—белеп торыгыз, госпадалар!—диде Әнис ярсып һәм кайсыдыр күренмәс көчләргә йодрык янады.

Алар шулай шатлыкларын уртаклашып, шактый гына сөйләшеп утырдылар. Газиз үзенең һич вакытсыз хастаханәдә ятуына борчылып:

—Чылбырга бәйләнгән эт кебек. Чыгасы иде, сезнең арада буласы иде. Кайнар вакыт бит,—диде.

—Чир сорап килми, Газиз малай. Терелеп бетмичә чыкма инде. Өлгерербез. АЭСны төзүне дә туктатырбыз, башкасына да өлгерербез. Алда гомер бар әле,—диде ул Газизне тынычландырырга тырышып.

—Булсын иде дә бит, ләкин... Минем чир, Әнис, терелә торган чир түгел инде ул. Яшисе бик килә... Нурланыш, радиация үзенекен эшли башлады—мин моны шулай аңлыйм. Аның кая, нәрсәгә алып барганын да беләм. Ләкин киләчәк язмышым ничек кенә булмасын, мин сезнең белән бер сафта атлап, төбәгебездә гаять куркыныч корылма төзүгә каршы үткәрелгән чараларда катнашып йөрүемнән канәгать, бик канәгать, аны мин олы мәртәбәгә саныйм...

—Һәм дөрес саныйсың, Газиз. Мин бит үзем дә шуна канатланып йөрим. Без бик зур эш эшлибез,—дип сүз өстәде Әнис.—Фикереңне бүлдем бугай...

—Дөрес, азрак катнаштым, кызганычка каршы... Чир бит... Белмим, киләчәктә сезнең белән бергә була алырмынмы-юкмы, әмма көрәшеп йөрүебез бушка булмас сыман. Аның нәтиҗәсен күрәсе иде. Ул чагында үлсәм дә үкенмәс идем. Татар җиренә дә, башка җиргә дә атом кирәкмәс. Мин моны атомның нинди һәлакәтле әйбер икәнен үз күзләре белән күргән, үз тәнендә, үз язмышында татыган кеше буларак әйтәм. Кирәкмәс!

Берничә көннән Әнис тагын палата ишегендә күренде. Бу юлы үзе генә түгел, Питыр Никитинны да алып килгән иде ул. Никитин үз яңалыкларын хәбәр итте. Чернобыльчеләрнең ирекле җәмгыятен төзегәннәр икән. Барлыгы ике йөз иллегә якын кеше җыелган.

—Бер зур булмаган кала һәм район буенча шул кадәр кеше... Ә ил буенча күпме була икән?—диде Әнис.

—Бик күп була торгандыр. Һәм гади генә кешеләр түгел бит алар. Шул исәптән Газиз дә, мин дә,—диде Никитин.—Һәрберебез авыр йөк, олы проблемалар белән кайтты. Шулай булмаса, Газиз менә монда ятар идемени?

Бу сүзләрдән соң алар өчесе дә уйга калдылар. Тынычлыкны кабат Никитин бозды. Газизгә карап:

—Үзебезнен исәп-хисапны ачтык, чернобыльчеләр фондын оештырдык. Башкача мөмкин түгел. Безнен турыда партия дә, хөкүмәт тә кайгыртырга ашкынып тормый. Үз-үзебезне кайгыртырга кала. Көчле предприятие, оешма житәкчеләре белән очрашабыз, сөйләшәбез, ярдәм итүләрен үтенәбез. Безнең максат—ин башта һәр чернобыльчене ел саен курортларга дәваланырга жибәрү,—диде ул һәм кесәсенә тыгылды.

—Менә безнен беренче путевканы сина алып киллдек,—диде һәм аны Газизгә сузды. Газиз дулкынланып китте.

—Ай, рәхмәт, Питыр! Уйламаган идем, булдыклы егет икәнсен,—диде ул һәм Никитинны кочаклап алды. Тегесе үз чиратында:

—Рәхмәтенне мина түгел, башта Әнискә житкер. Ул кайгыртып йөрде,—диде.

—Эх, дуслар белән яшәү куаныч,—диде Газиз һәм берочтан Әнисне дә кочаклады. Күнеле тулып, елап жибәрәсе килде анын, тик үзен-үзе кулга алды, тыелып калды.

Әнә шушы юллама белән килеп төшкән иде Газиз әлеге курортка.

* * *

Белдерү тактасында «Бию кичәсе» диюгә карамастан, ул кичне шифаханәдә танцы булмады. Музыка өчен жаваплы кеше авыру әнисе янына авылга кайтып киткән, берничә көнсез килеп житмәс әле, диделәр. Танцыга чыгарга ашкынып торган ял итүчеләр бүлмәдә телевизор карап утырырга мәжбүр булдылар.

Габделфәтне авыл кешесе генә димә—курортка «Тефаль» чәйнеге алып килгән. Буш вакыт булдымы, су тутырып төймәсенә баса. Ике минут та үтми, су гөбердәп кайнап та чыга. Һәр авыл кешесе кебек, Габделфәт тә чәйсез тора алмый. Чәйне куян каны кебек куе итеп эчә ул. Газиз үзе дә каты итеп ясаган чәйне ярата. Габделфәтнен савыты белән балы, кайнатмасы, башка тәм-томы өстәлдән өзелми. Әнә бүген дә өстәле тулы сый-нигъмәт, «Тефал»е дә тиз кайнап чыкты анын. Газизгә дә, үзенә дә чәй әзерләп йөри-йөри, кыюсыз гына:

—Әллә дим, яшьтәш, әз генә «кунак булып» алабызмы бүген?—диде ул.—Инде күпме бергә яшибез, әле бер генә чәркә дә тотмадык шул хөрмәткә...

Гажәп бу дөнья, гомердә күрмәгән-белмәгән кеше белән ничәмә көн бергә яшиләр. Бүлешәсе әйберләре юк, әлбәттә. Ләкин ике кеше арасында да төрле мөнәсәбәт урнашуы мөмкин. Габделфәт белән Газиз арасында үзенә бер аерым, уйламаганча жылы, кайгыртучан мөнәсәбәт урнашты. Күбрәк, авыру бүлмәдәше турында Габделфәт кайгырта һәм ул моны һич авырсынмый, олы теләк белән, ниндидер бер тәм табып эшли. Бөтен шифаханәдә ин иртә торучыларнын берсе—Габделфәттер. Юынып, ул ин элек шифалы су бүлмәсенә төшә һәм жаны кайсын тели, шул температурадагы суны авыз итә. Зәвык белән мәгарә итеп бизәлгән шифалы су бүлмәсендә төрле «чишмәләр» агып тора. Анда сунын салкынчасы да, жылымсарагы да, бик жылысы һәм хәтта кайнары да бар. Аерым бокалда Газизгә дә үзе теләгән суны алып менә Габделфәт. Теләсә, Газизгә кайнар чәй дә әзерләп бирә—һич иренми. Яшьтәшенен хәле үзгәреп китсә, кизүдә утыручы шәфкать туташлары янына да үзе чаба. Беркөн, әнә, Газизне көзән жыерды. Габделфәтнен андый хәлне күргәне юк иде әле. Күршесе күм-күк булып катты, үзе тартыша, сызлана, дер-дер калтырый, каты итеп ынгыраша. Габделфәт атылып икенче катка төште: «Бүлмәдәшемнен хәле начар!..»

Тегеләрнен дә эше бар:

—Үзе төшсен инде...

—Нинди «үзе төшсен», тизрәк, кызлар...

—Нәрсә сон анын?

—Чернобыль! Аңлыйсызмы? Чернобыль һәлакәтен кичергән авыру курортыгызда да бер генә...

Кызларга ике сөйләргә урын калмады. Минут та узмагандыр, алар Газиз янында мәш киләләр иде инде: көчле уколлар кададылар, дарулар эчерделәр, тәнен ышкыдылар, җылы компресс ясадылар, кинәшләр бирделәр.

Әнә шундый кин күңелле кеше Габделфәт. Йөзе ак, кулы ачык. Мондый игелекле җанны ничек якын күрмисең дә, ничек хөрмәт итмисең. Шулай булгач, аның тәкъдименә дә каршы килмәде Газиз, чөнки үзенең дә әрнегән җанын, кимсетелгән күңелен бераз бастырасы бар иде.

—Әйдә, Габделфәт, беткән баш бетсен инде, сал булмаса,—диде моңсу көлемсерәп.—Тик күп түгел, салам калынлыгы чаклы гына. Мин аның белән беркайчан да дус булмадым. Чернобыльгә бик күп ташыдылар аны. Санитар врачлар үзләре дә салдылар, башкаларны да үгетләп йөрделәр: «Радиациягә каршы бердәнбер чара—спирт, аракы. Күпме эчә алсагыз—шуның чаклы эчегез, әгәр вакытыннан алда гүр иясе буласыгыз килмәсә»,—диделәр.

Рәсәй болай дә сәрхүш, болай да эчкечелек баткаклыгыннан чыга алмый азаплана. Атом һәлакәте булган, атом бомбасын сынаган төбәктәге халыкны кыстый-кыстый аракы чөмертәләр. Бер яктан эчкечелеккә каршы көрәшеп маташкан булалар, икенче яктан үзләре кыстап эчертәләр. Менә нинди очы-очка ялганмый торган хәл. Тик, беләсенме Габделфәт, кайткач, үземнең бер таныш врач бөтенләй икенче төрле сөйләде ул спирт, аракылар турында. «Әкият ул, ди. Алкоголь нерв системасын җимерә, ә кеше сәламәтлегенең үзәге—нерв системасы, шулай булгач, радиациягә каршы спирт, аракы эчегез, дигән кеше ул чын-чынлап дошман сүзе сөйли. Бу бахырлар тизрәк аракы сөремендә бетсеннәр, дигән кебек килеп чыга. Мондый чакта, иң сәламәт тормышта яшәүдән дә яхшысы юк!!» Минем Чернобыльдән кайтканнан соң кан басымы нык күтәрелә башлады, йөрәк тибеше дә рәтле түгел. Моның өстенә эчә торган да булсам, әллә кайчан дөньядан киткән идем инде...

—Рәхмәт сүзеңә, Газиз. Минем үземнең дә артык исем китми бу нәрсәгә. Эч пошканнан гына. Менә чыгып киттем дә, сагынам. Авылымны, гаиләмне, карчыгымны-бөрчегемне сагынам. Тукай әйтмешли, эч поша, яна йөрәк, хәсрәт эчендә, уйда мин... Ярый әле иптәш бар. Сине әйтәм...

—Минем иптәшлек инде... Ярты җан. Күркем бар да, бүркем юк...

—Юк, Газиз, син миңа олы иптәш, гыйбрәтле иптәш. Эчең тулы хәсрәт, моң-зар синең. Мин бит үзем шатун кебек, чирнең барлыгын да белмим. Рәисебез: «Бер дә ялга барганың юк, җилләнеп кайт әле»,—дип путевка биргәнгә генә чыгып киттем. Икмәк унды быел, җан тыныч болай.

—Игенченең шатлыгы—икмәк инде. Уңган агроном булырга ошыйсың, Габделфәт. Җитди, төпле...

Габделфәт унайсызланып калды. Үзе, эше турында мактанып сөйли торган гадәте юк аның. Эш эш инде. Авыл җирендә аның беткәне дә, бетәсе дә юк, үлгәч тә өч күнлек кала әле ул. Ә менә Газизнең «төпле» дигән сүзе белән килешә. Эшен уйлап, җиренә җиткереп башкара ул, әвеш-тәвеш кенә түгел. Бу яктан анарда немец төгәллекләре бардыр. Тик сүз бит бүген аның турында түгел.

—Әйдә әле, Газиз, синең турыда сөйләшик. Әйтсәм әйтим инде, сине минем янга кертмәгән булсалар, мин күптән кайтып киткән булыр идем. Монда миңа, урыс әйтмешли, ничу делать. Аллага шөкер, сәламәтлегемнән зарланмыйм. Син генә менә... Сине күрдем дә: «Тукта, Габделфәт, өенә ашыкма әле, бәлки кешегә кирәгең чыгар»,—дидем.

—Чын күңелдән рәхмәт сиңа, Габделфәт! Әйдә, шуның өчен булсын...

Кабып куйгач та, Габделфәт тагын урыныннан кузгалды, суыткычтан бер төргәк чыгарды. Аны сүтеп, ул өстәлгә бик затлы ризык—казылык кискәләп куйды.

—Гел онытып җибәргәнмен бит. Карчыкның күчтәнәче. Әйдә, Газиз, авыз итеп, ашап җибәр. Минем Сөмбеләм үзе ясый казылыкны.

Газизгә симез ат итеннән бик чамасын белеп сарымсак, кара борыч һәм башка тәмләткечләр кушып ясаган казылык бик ошады.

—Теленне йотарлык бит бу,—дип мактап ташлады ул.—Карчыгын бик унган, бик булган ахры. Үзең дә «Сөмбеләм, карчыгым» дип кенә торасың.

—Һи-и, әйтәсең бармы, Газиз малай. Минем Сөмбеләм мировой хатын ул! Дөрес, аз тиле атын мактар, урта тиле үзен мактар, ә шыр тиле хатынын мактар, дигән сүз дә бар. Ләкин мин Сөмбеләмне мактаудан курыкмыйм. Ул аңа лаек.

—Кайсы якныкы соң үзе?

—Бер авылда, бер урамда туып-үстек без, бер сыйныфта, бер партада утырып укыдык. Үземә саклаган кебек сакладым мин аны. Унны тәмамлагач читкә укырга китмәде, балалар бакчасында эшли башлады. Гомере буе балалар тәрбияләде ул—авылныкын да, үзебезнекеләрне дә. Киң күңелле, шәфкатьле, кайгыртучан. Шуңамы, бөтен авыл халкы үз итә, хөрмәтли аны.

Инде минем яратуны белсәң... Казанда авыл хуҗалыгы институтында укып йөргән елларда сагынышып бетә идек. Безнең мәхәббәт хатлары әле дә саклана. Китап язарлык материал бар анда.

Ак күбәләк күрдем, ак күбәләк,
Бәхеткәйләр булсын түгәрәк.
Гомер юлларыннан синең белән
Насыйп булсын үтү бергәләп...

Әнә шуна охшаш шигырьләр, җырлар язып җибәрә иде хатка Сөмбеләм. Шөкер, гомер юлларыннан бергә үтү насыйп булды безгә. Инде егерме җиде ел... Өч балабыз үсте, хәзер исә оныкларыбыз ишәеп килә. Аларның «бабай», дип кочакка килеп керүләре үзе бер зур бәхет ич...

Без бер-беребез өчен туган булганбыз. Беребезнең дә башкага күңеле төшеп йөргән чагы да булмады. Сөмбеләм дә: «Мин сине яратып йөри башлагач та башка егет сәламәләреннән кулымны да тоттырмадым, үземә сүз дә куштырмадым»,—ди.

—Соклангыч икән тормышыгыз. Бәхетле гомер насыйп булсын үзегезгә, Габделфәт, мең яшәгез!..

Алар шулай җылы гына әңгәмә корып, гадәт буенча гына дуслык өчен «капкалап» утырганда ишек шакыдылар. Айсылу икән. Газиз аптырап китте: ул ана кайсы бүлмәдә торуы турында бер сүз дә әйтмәгән иде.

—И-и, Газиз абый, бүген дә парлап биеп булмады. Кая барып бәрелергә дә белмим. Сине дә югалттым, бүлмәгезне көчкә эзләп таптым. Гафу итегез инде,—диде ул унайсызланып.

—Әйдә, сеңлем, үт, утыр, бергә-бергә чәйләрбез. Газиз абыең белән безнең эшләр хутта, Аллага шөкер! Бик вакытында килеп кердең әле...

Габделфәт кыстый-кыстый Айсылуны өстәл артына утыртты, чәй ясап бирде.

—Рәхмәт, Габделфәт абый! Газиз абыйга да рәхмәтем чиксез,—дип дәвам итте Айсылу.—Тик, зинһар, минем турыда начар уйлый күрмәгез, сагыз кебек ябыша, дип. Мин бит ялгыз яшим, күңелем китек, кешеләр белән аралашуым да эштә генә, рәсми дип әйтимме инде. Биредән эчемне бушатып кайтып китәсем килә. Туйганчы бер сөйләшеп, серләшеп диюем.

—Андыйларны таба алсаң,—дип сүз кыстырды Габделфәт.

—Хикмәт тә шунда шул. Сер сыярдай кеше табуы җиңел түгел бу заманда. Бәхетемә, Габделфәт абый, андый кешене таптым мин. Ул, әнә, тыйнак кына елмаеп каршында утыра,—диде Айсылу һәм җылы кулы белән Газизнең беләген тотып алды да, аңа таба авышып, сыенып торды.

—Белдеңме инде, Газиз, бер мина гына түгел, башкаларга да кирәк икәнсең бит. Кирәк, димәк яшисең әле. Бергә-бергә яшибез! Киләсе җәйгә кунакка чакырам үзегезне. Яңа бал өлгергәч тә. Безнең Арча яклары матур, ямьле, җырлы-моңлы, шигырьле. Әйтәсең бармы—Тукай яклары! Ә син эч чәеңне, сеңлем, сыйлан. Самавырыбыз шаулап, өстәлебез гөрләп тора. Әллә бераз шәраб та салып биримме? Анысы да бар бездә,—Габделфәт торып суыткычка юнәлде.

—Юк, юк, Габделфәт абый, мин андыйларны кулыма да алмыйм.

—Менә монысы өчен рәхмәт, сеңлем! Шундый хатын-кызны чын күнелдән хөрмәт итәм мин. Минем Сөмбеләм дә бик аек хатын, иснәп тә караганы юк... Әйе, килегез әле, Газиз, безнең якларга. Умарталыкта бер кошлар сайраганын тыңлап, туйганчы бер серләшеп, җырлап утырырбыз.Ә син, Айсылу сеңлем, беләсеңме Газиз абыеңның ничек җырлаганын?

—Тәүге тапкыр ишетәм, ләкин гаҗәпләнмим,—диде Айсылу.

Габделфәтнең сүзенә Газиз аптырап китте:

—Нәрсә, мин бүлмәдә җырладыммыни?—дип текәлде ул Габделфәткә.

—Юк, җырламадың. Шулай да, ике-өч мәртәбә моңланып алдың. Шуннан мин синең әйбәт җырлавыңны сиздем. Мин үзем җырга һәвәс түгел, Газиз, айга карап шыңшыган эт кебек кенә, ләкин җырлаган кешеләргә мөкиббән китәм. Җырла әле, дустым? Ихлас күңелем белән үтенәм—бер генә җыр...

Әлбәттә, Газиз өчен җырлау берни түгел. Җырлы-моңлы гаиләдән булгангамы, җырны яратып, моңланып үсте ул. Тик менә бүген тиктомалга ничек җырлап җибәрәсең? Тавышы да шәптән түгел инде аның соңгы вакытта, тыны да кысыла. Шулай да... Тагын кайчан җырлап утырырга мөмкинлек туар?

Айсылу да аңа көч бирде:

—Газиз абый, бу моңлы кичәдә бер җырлап җибәрсәң дә гөнаһ булмас. Башлагыз әле, үзем дә кушылырмын.

—Ярар алайса, тырышып карыйк. Тик үпкәләштән булмасын, җырның ертыгы юк,—диде Газиз һәм берничә мәртәбә тамак төбен кырып алды. Аннары ашыкмый гына, ярым ачык тавыш белән сузып җыр башлады:

Күк күгәрчен баласыдай
Күгелҗем булмас инде лә,
Күгелҗем булмас инде;
Сездән аерылып китүләр
Күңелле булмас инде..

Җае чыкса, кушылырга дип торган Айсылу да, Габделфәт тә, Газизгә кушыла алмый гаҗәпкә калып, тынып утырдылар. Җыр әсәрләндереп җибәрде аларны. Үзе нindидер гади дә, ләкин моңлы да, аһәңле дә аерым бер җыр иде бу. Юк, бу көйгә халык та җырламый бугай, моны сәхнәдән башкарган артистлар да юк кебек. Ләкин көе таныш, бик таныш. Әллә соң берәр спектакльдә җырлыйлармы аны? Күңелне яулый торган җиңел, моңлы җыр. Һәм иң мөһиме—Газиз дә аны һәр һәвәскәр җырчы кебек гади генә итеп, Ходай биргән тавышы белән, һич кыстатмый, җайлы гына җырлый. Тамак төбеннән җыр—җыр түгел, йөрәк төбеннән чыккан җыр гына җыр, диләр. Газизнең дә җыры йөрәк төбеннән чыга иде.

Сездән аерылып китүләр
Күңелле булмас инде...

Габделфәт тә, Айсылу да җырчының нинди аерылып китүләр турында искәртүен бик яхшы аңладылар.

Газиз исә, берни булмагандай, җыр сузуын дәвам итте:

Күпер төбе күк томан,
Бу илләрдә күп тормам ла,
Бу илләрдә күп тормам;
Күп тә тормам, аз да тормам,
Сагынырсыз, мин булмам...

Җырның соңгы юлы буасы ерылудан үзен көчкә тыеп утырган Айсылуның әрнегән җанын телгәләде. Габделфәт исә чын күңелдән:

—Әйттем бит, әйбәт җырлый, дип. Рәхмәт, Газиз малай, зур рәхмәт үзеңә, җанга рәхәт булып китте. Мең яшә!—дип дусларча Газизнең аркасыннан сөйде.

Шулай җыр сузып, эчкерсез сөйләшеп, моңланып, чәй һәм мәй белән сыйланып, алар әле тагын бераз утырдылар.

* * *

Айсылу Газизләрдә кич утырудан, дөнья күргән, аны танып белгән ике сабыр табигатьле, төпле ир белән аралашудан гаять зур канәгатьләнү табып чыкты. Бигрәк тә Газиз абыйсы көчле тәэсир ясады ана. Аның белән күбрәк бергә булган, аралашкан саен, Айсылу бу кешедә үзе белгән күп кешеләргә хас булмаган үзгә сыйфатлар ача бара. Үзе гади, үзе игътибарлы, үзе мөлаем, шул ук вакытта кискен язмышлы. Бар бит һәрьяклап килгән, талантлы кешеләр! Сөйли башласа авызына каратып тота, җырлый башласа сине моң дәрьясына алып китә, бии башласа җилләр җилдертә, дәртләндерә, җилкендерә. Үзе архитектор—зиннәтле сарайлар, матур йортлар проектын төзи.

Әйе, искиткеч кеше. Һәм, иң гаҗәбе, шундый кешегә дә чын бәхет йөзен күрү насыйп булмаган. Айсылуның үзенә дә бәхет кояшы көлмәде. Бәлки бар көчен биреп көрәшмәгәнгә көлмәгәндер ул? Ә Газиз аның өчен көрәшкән бит, югыйсә. Бүген дә көрәшә. Яшәү өчен көрәшә! Яшәү—үзе бер олы бәхет, ди ул. Мондый кеше белән тормышыңны бәйләү дә куркыныч булмас иде. Тик... Кем соң әле ана, бәйлә дип, тәкъдим ясаган?

Эх, белмәссең бу дөньяны! Син теләгән кешеләр әллә кайда йөри, син теләмәгәннәр юлыңа аркылы төшәләр. Күзеңне ачыбрак йөрсәң, Газиз кебек бер гади, самими кешене таба алган булыр идең әле син дә, Айсылу ханым, юк, Айсылу туташ! Йә Хода, кем соң инде ул бүген чыннан да?..

... Медицина училищесын тәмамлаганнан соң Айсылуны Чулман буендагы зур булмаган бер авылга фельдшер итеп җибәрделәр. Тыныч кына барып урнашты кыз, кабаланмый гына, училищеда алган белемен барлап эшли башлады. Иң мөһиме—сырхаулап килгән кешеләргә игътибарлы була белде. Бәлки шуңадыр, авыл халкы аны үз итте, яратты.

Бер елны колхозга яна инженер кайтып төште. Шул авылның әле генә институт тәмамлаган үз егете икән. Зифа буйлы, киң күкрәкле, чатнап торган егет. Нindидер йомыш белән медпунктка да икеме-өчме кагылды ул. Тик аралашулары нигәдер гади булмады. Шунамы, Айсылу егетне өнәп бетермәде. Инженер дигәч тә, борының чөя бугай, дип уйлады ул. Ләкин егетнең медпунктка кагылуы сәбәпсез булмаган икән. Бер көнне ул кереп Айсылуны концертка чакырды—Казаннан җырчылар килгән, диде. Ә Айсылу бармады. Егет, үз теләгенә ирешү өчендер, аның янына тагын да ешрак кереп йөри башлады. Ә бер көнне Айсылу янына ата-анасын башкодалап җибәрде. Кыз уйланмады түгел, күп уйланды һәм ризалыгын да тиз генә бирмәде. Егетнең үзенә караганда, күбрәк аның атасы һәм анасы ошады. Олы башларын кече итеп, алар абруе күтәрелеп барган фельдшер кыз янына килделәр, «Бик яратабыз үзеңне, киленебез бул, бергә-бергә матур итеп гомер итәрбез»,—диделәр. Нишләсең, авыл зур түгел, сайланып булмый, вакыт та чыгып бара, утырып калуың мөмкин...

Шаулап туй үтте. Тик зәфаф кичәсе булмады.

—Син гафу ит мине, Айсылу,—диде кияү егете.—Алдан әйтергә кирәк санамаган идем. Безнең институтның хәрби кафедрасы булмаганга, мине бер елга армиягә алалар, запастагы офицер итеп әзерләячәкләр. Бер ел—күп түгел, үтәр дә китәр. Син дә сагынып торырсың, мин дә сагынып кайтырмын. Әлегә мин сиңа тимим. Шулай яхшырак булыр.

—Гаҗәп,—диде Айсылу.—Бәлки мин балага узармын һәм син кайтканчы табып куярмын?

—Юк, мин риза түгел. Мин куркам...

—Нәрсәдән?

—Хыянәт итәрсең, дип.

—Атаң-анаң, туганнарың янында яшәп тәме?

—Барыбер.

Айсылуның күңеле нык төште, кимсенде, кыбырсынды. Сәер хәлдә иде ул. Иргә чыгып, ир хатыны исемен йөртеп шундый хәлдә яшә инде! Дөресен генә әйткәндә, ул бит бу кешегә тормышка чыгарга да теләмәгән иде. Нәрсәседер ошамады, ышаныч, өмет чаткылары бик аз шәйләнде

анын холкында. Айсылу ялгышты бугай. Сайлаган сазга, очраган тазга. Инде нишләргә? Әйберләрен җыеп, чыгып китәргәме? Ичмасам янында бер якын кешесе дә, киңәшчесе дә юк тотып сөйләшергә, киңәшергә. Чыгып китсә, авылда әнисе белән апасы ни әйтер? Әллә бераз түзәргәме?

Ир буласы кеше армиясенә китеп барды, тик Айсылу елап калмады. Өмете өзелгән, күңеле сүрелеп киткән иде анын.

Армиядән хатлар килеп торды. Башта еш килде алар, эчтәлекләре дә җылы гына иде. Аннары хатлар сирәгәйде. Инде кайтырга вакыты җитеп килә, бәлки шуңа сирәк яза торгандыр, дип уйлады Айсылу. Үзе исә бернинди тел-теш тидерерлек гамәл кылмады. Зур булмаган авылда барысы да күз алдында. Медпункттан кайта да, өй, йорт эшендә катнаша. Кайната белән кайнана киленнән ризалар, «кызым» дип кенә торалар. Ләкин Айсылуның беркемгә дә күңеле ятмый, ышанычы да юк. Рәтле тормыш булмас ахры бирегә. Анын күңеле нәрсәдер сизенә иде. Һәм дөрес сизенгән икән ул. Инде бер ел үтте. «Озакламый кайтам»,—дип язган кеше һаман юк.

Бер көнне кайнигәче[1] анын эш урынына медпунктка килеп керде һәм иренең аларга язган хатын бирде. Ул анда үзенең авылга кайтмасын, армиядә офицер булып каласын, хезмәт иткән җирдә башкага өйләнгәнен язган иде. Айсылу шул көнне үк туган якларына кайтып китте. Аннары медицина институтына барып, укырга керде...

Газизгә: «Берәү белән торып карадык та, с характером не сошлись»,— дигәне шул иде инде анын.

Яратусыз кавыштылар, үкенечсез аерылыштылар...

* * *

Иртән Газиз төш күреп уянды. Сәрмәдиясе ап-ак киемнән ниндидер коймамы, әллә бурамы артында басып тора, аңа кул изи һәм: «Кил инде тизрәк, нишләп озакладың?»—дип ап-ачык итеп эндәшә, имеш. Әйтерсең лә өстенә салкын су койдылар—Газиз иләс-миләс торып утырды. Йөрәге тыелгысыз тибә, үзе шабыр тиргә баткан, суларга һава җитми, башы чатный. Гомерендә бер дә төш-мөш, ырым-шырымга ышанмый торган Газиз, әлеге төштән исәңгерәп китте һәм тәүге тапкыр үзенә хәтәр хәбәр юрады. Шулай ук... Ах, нәләт... Нәрсә соң инде бу тагын?..

Габделфәт сабый бала йокысы белән изрәп йоклый иде әле. Сәламәт кеше шул! Тәмам шөбһәгә төшкән Газиз, йөрәк ярсуы басылмасмы дип, полиэтилен шешәдән бокалга шифалы су салып эчте. Тагын ятып йоклау турында уйларга да мөмкин түгел, йокысы качкан, күзләре шар кебек ачылган иде. Шулай да, курортның бер якка ямьшәеп төшкән бәләкәй мендәрләрен төзәткәләп, башын кабат шуларга салды. Һәм аны шунда ук очсыз-кырыйсыз уйлар чолгап алды.

Соңгы вакытта ул Сәрмәдияне төшендә еш күрә. Уйланганга күрә керә торгандыр инде ул анын төшенә. Уйламаса, кермәс иде. Ә ничек уйламыйсың? Утыз ел бергә яшә дә...

«Ах, Сәрмәдия, Сәрмәдия... Бәрәкәтсез үткәрдек шул бергә булган гомерләребезне. Әллә ничек булды безнең тормыш: син мина йокмадың, мин сине аңлап бетерә алмадым. Өйләнештек, бергә тордык, әмма бер-беребезгә гомер юлдашы була алмадык. Үкенечкә калды барысы да...»

Гомеренең соңгы айларында Сәрмәдиянең башына бик нык уй төште. Бер көнне Газиз эштән кайтып кергәндә хатынының елап утырганын күрде. Тезләрен кочаклаган да, тавышсыз-тынсыз күз яшьләрен түгә. Салган баштан балавыз сыгып утырадыр, дип уйлаган иде Газиз, ләкин Сәрмәдия ап-аек, шалкан кебек иде.

—Нигә мышкылдап утырасың әле, нәрсә булды?—диде Газиз йомшак кына һәм анын янына утырды.

—Төш күрдем, бик куркыныч төш...

—Соң, сөйләп җибәр...

[1] Кайнигәче—иренең сеңлесе.

—Үләм мин...,—диде Сәрмәдия һәм кабат яшенә тыгылды.

—Ташла әле юкны! Соңгы вакытта артыгын җибәрәсең, ә ул психикаңа бәрә. Беренчесе түгел, соңгысы да булмас...

—Юк, Газиз, әчем поша... Элеккеге кебек түгел, бөтенләй башкача поша. Күңелдә өметсезлек, бушлык, җаңда упкын... Төшем рас килсә, күп тормам ахры. Аннары... Син дә миннән соң озак яши алмассың кебек...

Бу сөйләшү авыр шом булып ятты Газизнең йөрәгенә. Уртак тел табып, аңлашып, яратышып, хөрмәт итешеп, чөкердәшеп яши алмадылар. Тик ничек кенә булмасын, Сәрмәдиянең үлүен теләми иде ул. Үзе белән бер-бер хәл килеп туса, Сәрмәдия, ниһаять, айнып һәм аларның бердәнбер кызларына терәк булып калыр, дип уйлаган иде. Тормышны танып белергә өлгермәгән, аягына сыер басмаган үнҗиде яшьлек кыз бала шулай ук атасыз да, анасыз да калыр микәнни? Шыр ятим булып...

Кинәт аның исенә чынбарлыкны искиткеч төгәл итеп тасвирлаган бер җыр килеп төште. Моңлы җырлары белән халык күңелен яулап килә торган бер яшь җырчы кыз башкара аны. Гаҗәеп моңлы тавыш ул кызда:

Яшәү, үлем,—бары тик бер сукмак,
Нигә башка сукмак юк икән?
Адаштым, дип кайтып китәр идем,
Яшьлегемә кайсы юл илтә?..

Үзе генә калган, уйландырган-моңландырган минутларда Газиз дә бу җырны сузып җибәрә, күңелен юата, җанын тынычландыра.

Эх, кайтып китәсе иде дә яшьлеккә, барысын яңабаштан башлыйсы, кылган ялгышлыкларны һич кабатламыйсы иде. Юк шул, анысы булмас хәзер. Инде Ходай тагын гомер бирсә, калган елларын ничектер башкача, бәрәкәтле, мәгънәле тормыш көтеп, якыннары белән аңлашып яшәр иде...

* * *

Сәрмәдиянең юраганы, кызганычка каршы, юш килде. Сентябрьнең җылы, кояшлы, матур көннәрендә Газиз иртән шәһәр читендәге җиләк-җимеш бакчасына китеп барды. Ял көне иде ул. Сәрмәдия әле тормаган да иде. Кичтән дә: «Йөрәгем кысыла»,—дип, дару кабып яткан иде. Иртәнге якта да Газиз аңа йөрәк даруы белән су каптырды. Үзе: озак тормам, дип чыгып киткән иде, тик бакчага бер барып төшсәң, тиз генә эшеңне бетерә алмыйсың, көнең үтә. Ул көнне дә шулай булды. Инде төш үтте, кичкә авышты. Шулчак Газизнең күңеленә кинәт пошаман төште һәм: «Син нишләп һаман монда йөрисең, хатының авырып калды лабаса»,—дип, өенә ашыкты. Сәрмәдиянең күңеле булыр дип, кулына бер кочак кашкарый, гладиолус, тәмле ис чыгарып, аңкып торган флокс чәчкәләре алды.

Автобуста кайткан ярты сәгать аңа ярты көн булып тоелды, төшү белән өенә ашыкты, өйгә якынайган саен күңеле тынычсызлана, сабырсызлана барды, әллә ничек, хәтәр барын сизенде.

Ишекне ачып керү белән:

—Сәрмәдия, Сәрмәдия, мин кайттым,—дип кычкырды. Тик җавап бирүче булмады. Ул кабаланып йокы бүлмәсенә узды. Сәрмәдия җинел халат белән идәндә, карават янындагы келәмдә утыра, башын исә караваткырыендагы мендәргә салган. Әллә ничек, унайсыз салган ул башын. Бер кулы да шул мендәрдә... Йоклыймы, әллә уйланып кына утырамы? Газиз аңа килеп кагылды...

Ул инде суынып беткән иде...

Бакчадан алып кайткан бер кочак чәчкәләр Газизнең Сәрмәдиягә соңгы бүләге булды.

* * *

Минераль ванналар блогында ашыкмый гына үз вакытын көтеп, ял итеп утырганда, Газиз янына аның белән вальс биегән яшь хатын килеп утырды. Соңгы кичне танцыга зәңгәрсу өрфия күлмәк белән

чыккан иде ә бүген өр-яңа аклы-яшелле спорт костюмыннан—танырлык та түгел.

—Исәнмесез, абый. Хәлләрегез ничек?

—Ә, әйбәт әле, сеңлем. Син дә ваннагамы?

—Әйе. Минә бераз соңга калганмын, вакыт житми. Берәү белән танышкан идем дә...

—Егет белән дисеңмени?

—Әйе, монда барысы да «егет» инде. Сез дә минә «егет». Вальсны да гажәп матур биисез. Егетнең дә асылы! Теге кичне танцыдан соң үзегезгә кич утырырга чакырмадыгыз бит. Чакырган булсагыз, буш вакытларны да бергә генә үткәрер идек. Хәзер вальска да чыгып булмас инде, теге көнләшеп маташа, «Беркөнге кавалерың белән танцевать итсәң, смотри»,—ди.

—Гажәп икән.

—Былтыр «Казан» санаториенда берәү белән йөрдек, грамм да көнләшмәде. Әле икенчесе белән дә танышырга өлгердем...

—Ирең көнләшәме соң?

—И-и, бер бозау инде шунда. Көнләшә дә, ярата да, назлый да белми. Аннан, кем соң әле аңа кайтып сөйләгән? Повод бирмибез инде...

—Яшәгән жиреңдә дә бармы «егетләр»ең?

—Ә нәрсә? Ба-ар. Хәзер кайсы хатынның сөяркәсе юк? Жизнь дается один раз, диләрме әле?

—Димәк, «коллекция» жыясың?

—Жыела инде,—ул кеткелдәп көлеп куйды.

—Алай дөресме соң ул, сеңлем? Әхлак, намус, әдәп, дигән төшенчәләр дә бар бит әле тормышта,—диде Газиз, көрсенеп.

—И, абый, исең киткән икән иске чикмәнгә. Минә мондый мәзәкне ишеткәнең бармы? Курортка килгән бер ир белән бер хатын танышканнар. Тәүге кичне сөйләшеп утырганнар, икенчесендә ир хатынның кулын тоткан, өченчесендә кулын биленә салган. Хатын түзмәгән: «Син нәрсә, мине курортка бер елга килгән дип уйлыйсыңмы әллә?»—дигән. Мин дә курортка өч кенә атнага килдем. Дөньясында да ике гомер яшәргә язмаган. Әнә, телевизордан рекламаларны күрә торгансыңдыр: «Бери от жизни все»,—диелгән. Мин дә шул принцип белән яшим. Һәм мин генә дә түгел. Кем мина ошый, йә булмаса кемгә үзем ошыйм—шуның белән көн, төн уздырырга риза. Тик «мәхәббәт», «сөям» дигән сүзләрсез генә, буш сүз алар. Тән жылысы, тән ләззәте барысыннан да кадерлерәк, кысып кочакла, суырып үп, төн буе назла...

—Кем белән булса да барыбер, дисең инде?

—Барыбер.

—Ә хис?

—Кочаклашып яткач, хис үзеннән-үзе килә ул.

—Сеңлем, болай яшәп үзеңне бик тиз туздырмассыңмы соң?

—Туза, ди...

Хатын шаркылдап көлеп куйды:

—Мин сезнең ир-атларның күбесенә житәрмен әле. Яшәп калырга кирәк, яшәп...—дип өстәде һәм урыннан кузгалды. Бу вакытта минераль ванналардагы шәфкать туташы, дәваланучыларның фамилияләрен атап, ваннага керергә чакыра башлады. Газизнең чираты житмәгән иде әле. Ул уйланып калды. Тезгененнән ычкынган, намус төшенчәләрен оныткан, аларны танымаган бу яшь хатын белән сөйләшүдән аның хәтере калды, кәефе төште, жаны бимазаланды. Инде мәхәббәт хисен тулысы белән татый алмыйча яшәгән, тәүге тапкыр чын ярату, артык сөю белән шашынып, гомерендә бары бер тапкыр иренә хыянәткә барса—икенче хәл булыр иде, андыйны аңларга тырышыр иде. Бу бит тәмам барып житкән. Мондый азган-тузганның кытыгын качырырдай кеше кирәк тә бит, андыйлар юк, күрәсең. Ире дә «бер бозау» гына ди бит, дөрес булса. Дөрес булмавы да мөмкин. Андый хатыннар сәбәп табарга осталар.

Ах, бу хатын-кызлар! Һич аңламассың аларны. Теләсә ул синең башыңны да катыра, йөрәк маеңны да эретә, күңелеңнең иң серле, иң ләззәтле кылларын

да чиертә белә, теләмәсә, инде һичбер нәрсә булмагандай тупас рәвештә тибәреп, төп башына да утырта, мангаена мөгез дә куя. Син аны шашып сөясен, ә ул сине иненә дә кагылдырмый. Син аннан туеп качарга телисен, ә ул сине баганага бәйләгән аттай йөрәгенә бәйләп куйган да, жибәрми...

Газиз теге кичне әлеге тотнаксыз хатын белән вальс биюенә дә үкенә башлаган иде. Тик аның шундый икәнен каян беләсең? Кем икәнлеге мангаена язылмаган шул...

* * *

«Тәүге тапкыр чын ярату, артык сөю белән шашып, гомерендә бары бер тапкыр иренә хыянәткә барса—икенче хәл булыр иде»,—дип әйтүе белән Газиз үзен акларга маташа иде бугай. Бар ярату, сөю бар. Бу инде йөрәк эше. Йөрәккә боерык биреп булмый, диләр бит. Инде гөнаһ икән... Әйе, беркем дә хали түгел бу дөньяда, булса да, шул сабыйлар гына гөнаһсыздыр.

... Газиз Сәрмәдиясеннән калып, ялгыз каз кебек кангырап йөргән көннәрендә архитектура бүлегенә яна сызымчы алдылар. Күрше калада педагогик-сәнгать техникумын тәмамлап, берничә ел мәктәптә рәсем һәм сызым дәресләрен укытып йөргән, шул арада кияүгә чыгып дөньяга бала китерергә өлгергән, курчак кебек нәфис, нечкә билле, әшкә һич иренмәс яшь бер хатын иде ул. Өстендә гади генә ситсы күлмәк, аягында арзан туфлиләр, томрап торган тузынкырак кара чәчле, кыр чәчәге кебек зәп-зәнгәр күзле, битенә иннек, кершән сөртеп, күзенә сөрмә тартмаса да, күнелләрне тибрәндерә алырдай сөйкемле йөзле. Буянып-ясанып тормаса да, бүлектәге сөрмәле күзле, битенә олтан калынлыгы иннек-кершән сылаган унлап асыл зат арасына килеп керде дә, якты йолдыз кебек жемелдәп, кояш кебек жылытып, ай кебек моңландырып утыра башлады. Инде дүртенче дистәсе белән баруына карамастан, төсе-бите һәм кыяфәте белән ул шактый яшь күренә иде. Кергән-чыккан, килгән-киткән, үткән-сүткән мут ир-атның күзе гел шул хатында иде, тик ул гына беркемгә дә игътибар итми, ул гына башын аска—өстәлгә, ватманга игән дә, тырышып-тырышып сызым сыза, эшли, яна урында үзен күрсәтәсе килә.

Сөйкемле хатын-кызга битараф булмаса да, әлеге хатын—Нурсибә, Газизнен күңел күзенә беренче көннәрдән үк чалынмады. Аның кайгы-хәсрәтле, уйлы-моңлы, моннан тыш өстенә бүлек житәкчесе вазифаларын йөкләгән мәшәкатьле көннәре иде.

Бер көнне ана яна проектның сызымнарын керттеләр. Газиз карап чыкты һәм сызымнарда шактый төгәлсезлекләр тапты.

—Кем сызды моны?

—Әнә, яна сызымчы,—диделәр ана.

—Чакырыгыз әле!

Бүлмәгә түм-түгәрәк йөзле, шундый ук түгәрәк, нәрсәгәдер гажәпсенгән сыман карашлы зәнгәрсу күзле яшь хатын килеп керде.

—Сенлем, нигә бу проект начар сызылган?

Хатын эндәшмәде, анын асылташ күзләре генә челт-мелт итте.

—Син сызган идеңме? Менә кара әле...

Хатын сызымнарын карар өчен Газиз утырган өстәлгә якынрак килде һәм «әйе» дигән мәгънәдә башын изәде. Ул дер-дер калтырый иде. Моны күреп торган Газиз шунда ук тавышын йомшартты:

—Мә, сенлем, ал, төзәт! Эшен беткәч яңадан алып керерсен...

Эшен ул кичкә якта гына бетерде һәм һаман шулай бер сүз эндәшмичә сызымнарын тотып Газиз янына алып керде. Бүлек мөдире ана каршындагы урындыктан урын күрсәтте, тик хатын утырырга теләмәде, басып торуын дәвам итте.

—Утыр, акыллым, утыр! Аякларда дәреслек юк, диләр...

Сызымчы кыюсыз гына урындыкнын кырыена килеп утырды. Газиз сызымнарны кабат тикшереп чыкты: «Бусы ярый, бусы да булган, бусы да әйбәт...»

—Менә бит, булдыргансың. Әйбәт итеп эшләп була, димәк? Иртән нигәдер куркынган идең ахры?

Хатын бу юлы да башын гына изәде.

—Мин таләпчән, ләкин кеше ашамыйм. Менә шулай пөхтә итеп эшләсән, минем сина дәгъвам булмас. Килештекме?

Хатын тагын башын какты, ләкин бер сүз эндәшмәде, чыгып китте.

Бу—Нурсибәнен Газиз белән тәүге тапкыр якын килеп очрашу, танышу көне булды. Шул көнне үк бүлектәге хатыннар җитәкчеләре турында гайбәт тә сөйләп алдылар. Янәсе, ул кайчандыр Зөлфия белән очрашкан. Зөлфия дә шушы бүлектә эшли, тик бу көнне бер төзелешкә чыгып киткән һәм хатыннарга анын сөяген юарга җайлы вакыт туган иде. Зөлфия бернечә яшькә олы булса да, Нурсибәнен күзлегеннән чыгып караганда, анын җитәкче белән «буталуы» чиктән тыш гаҗәпкә калдырды:

—Шул карт беләнме?—дип сорап куюын сизми дә калды ул.

Күңеле белән Нурсибә бу сүзгә бик үк ышанып та бетмәде. Дөрес булса сизелер иде, ә тегеләрнең арасында кыңгыр эш сизелмәде. Утсыз төтен чыкмый, димәк ут булмаган. Хатыннарның усаллык яки көнчелек белән сөйләгән гайбәтләре генә иде бугай ул.

Ләкин тормышта син һич уйламаган, акылына да китермәгән хәлләр дә була икән.

Кыска гына вакыт эчендә Нурсибә үзенен оста сызымчы икәнен танытты. Газиз үзе ясаган проектларны гел аңардан гына сыздыра торган булып китте. Эшенә һәрвакыт иҗади мөнәсәбәттә булган җитәкченен проектлары да мавыктыргыч, кызыклы була. Моннан автор үзе генә түгел, сызымчы Нурсибә дә канәгатьләнү хисе таба башлады. Эчтән генә ул үзенен җитәкчесе проектларын сызганына горурланып та куя, чөнки алар гади генә, төссез генә түгел, ә катлаулы, югары дәрәҗәдәге, камил эшләр. Ә кайбер вакытта сызымчы үзе проектны тагын да камилләштерү юлын күреп ала һәм бу турыда Газиз абыйсы белән уртаклаша, аңа тәкъдимен әйтә.

—Кара син аны! Үзен дә чын архитектор икәнсең бит, афәрин,—ди Газиз абыйсы һәм җинел генә аркасыннан сөеп ала. Аннан үзе белән утырып чәй эчәргә кыстый...

Әнә шушы иҗади бердәмлек аларны шактый якынайтты, дуслаштырды. Башта кырын күз белән генә караган Нурсибә дә Газиздә әкренләп күркәм генә сыйфатлар тапты. Игътибарлы, кешелекле, сабыр, каты орынмый. Кайчагында кызып алса да, ачу сакламый, шунын артыннан ук нинди дә булса кызыклы сүз әйтеп, мәзәк сөйләп, көлдереп, кәефенне күтәреп җибәрә. Инде азау тешен ярган хезмәткәрләр генә түгел, Нурсибә дә җитәкче янына һич тартынмыйча, үз дәрәҗәсендәге кеше, иптәше янына кергән кебек керә башлады. Хәтта аны бер-ике көн күрми торса, Нурсибәнен юксына башлавы да сизелә иде: «Газиз абый нигә күренми сон әле? Берәр кая китте микәнни? Эше күптер инде...»

Кешегә булган мөнәсәбәтеннен үзгәрүе кайвакыт вак кына нәрсәләрдән тора. Унае да, тискәресе дә. Берәү сина бәләкәй генә игътибарлылык күрсәтә дә, синдә ана карата рәхмәт хисләре ташып чыга, йөзен кояш була.

Бер көнне сентябрьдә аларны колхозга бәрәнге алырга җибәрделәр. Иртән көн коры, кояшлы, җылы иде. Шуна да Нурсибә җинелчә генә киенеп чыкты. Бәрәнге җиренә барып төшкәч тә, төньяктан салкынча җил исә башлады, ул болыт куып китерде һәм вак яңгыр сибәләргә тотынды. Кызып-кызып эшләсәләр дә, салкын җил Нурсибәнен юка киеме аша үтә, өшетә башлады. Шулчак Газиз өстендәге күн курткасын Нурсибәгә салып бирде. Нурсибә алмаска маташты:

—Мин аны пычратам бит,—диде.

—Ки, ки, өшисен...

Газиз ана курткасын үзе кидереп, «Менә, начальник булдын»,—дип шаяргалап, бәләкәй Нурсибәне кочагына алды. Моны Нурсибә һич көтмәгән иде. Шулай да, ана шул хәтле рәхәт булды ки, мондый ләззәтле тойгыны анын инде күптән татыганы юк иде. Газизнен курткасы да бик җылы булып чыкты, Нурсибә анын белән көне буе рәхәтләнеп эшләде.

Иртән Газиз Нурсибәгә сызарга тагын бер проект кертте.

—Эшләр ничек? Бүген син тагын да матуррак. Бөтен бер бүлекнең күнел бүләге син...

Бер-ике җылы сүз. Күңелне эретә торган йомшак, ягымлы сүзләр. Нурсибәгә шул җитә калды. Ул энҗе кебек ак һәм тигез тешләрен күрсәтеп, елмаеп җибәрде, әйтерсең лә бүлмәдә бүлек сызымчысы түгел, ә кояш үзе елмайды.

Көннәр үткән саен бүлек мөдиренең Нурсибәгә булган игътибар арта, көчәя барды. Бу аның гүзәл һәм яшь хатын белән чын-чынлап мавыга башлавы иде. Үткәндә дә, сүткәндә дә, аулак вакытны сайлап, Газиз аңа ягымлы сүзләр әйтә, чәчләрен сыйпый, аркасыннан сөя, ягымлы елмая.

Бер көнне эш ахырында кызлар чәйләп алдылар—кайсыныңдыр туган көне иде. Ләкин озак утырмадылар, таралыштылар, чөнки һәркемнең өйдә гаиләсе көтә. Газиз үзе генә калып, нниндидер бер проект өстендә уйланып утыра иде. Ишек шакыдылар. Караса—Нурсибә.

—Син, матурым, кайтып китмәгән идеңмени?

—Әзрәк сызымым бар иде, шуны төгәлләдем. Кайтып киткәнче сезне күреп чыгыйм дидем...

Шушы сүзләре белән Нурсибә Газизне сихерләде дә салды. Димәк, «карт» Газиз абыйсы Нурсибә өчен һич тә чит-ят түгел, якын, үз кеше икән. Газиз, дулкынланып, урыныннан торды һәм, магнит тарткан кебек, Нурсибәгә омтылды. Ә ул, кыр чәчәге кебек зәп-зәңгәр күзләрен Газизгә төбәп карап тора, әйтерсең лә Газизнең кысып кочаклавын, иркәләвен, назлавын көтә. Газизнең үзендә дә шул ук уй, шул ук тойгылар, шундый ук теләк иде. Курчак кебек нәфис, нечкә билле Нурсибәне ул ашкынып кайнар кочагына алып кысты һәм шашып чәчләреннән, маңгаеннан, күзләреннән, битеннән үбәргә тотынды. Шуны гына көтеп торган кебек, Нурсибә дә йомшак куллары белән аның муенына сарылды. Шулчак Нурсибә үзенең әлегә кадәр һичкайчан татымаган сәер халәттә калганын сизде. Газизнең кайнар тәненнән ургып чыккан ниндидер сихри көч аның бөтен тәнен чолгап алды да, аны дәртле ашкындырып, аяк бармакларыннан башлап түбәсенә чаклы рәхәт, татлы, кайнар чымырдау үтте. Бу—табигатьтә сирәк очрый торган хәл—биокыр галәмәте, биотоклар көчешө иде. Нурсибә аны бик озак вакыт үткәч кенә аңлады һәм һәрвакыт: «Менә сина карт!»—дип сокланып искә ала, рәхәт уйларга чума торган иде. Ничә ел ир белән яшәп тә мондый татлы мизгелне татыганы булмады аның. Бәлки ирен яратмый чыкканга шулайдыр ул? Ире үзенең дусты, Нурсибәнең яраткан егетеннән тартып, талап алган кебек алып китте аны һәм көчләп диярлек өйләнде. Бәлки, шунадыр, ул үзенең иренә карата хиссез яшәде һәм кайчан да булса берәүне сөеп алу белән хыялланды. Өлешенә чыккан көмеше аның, әнә, бүлек мөдире Газиз Солтанов булды.

Күпмедер вакыттан соң бүлек хатыннарының Газиз турында Зөлфия белән булган имеш-мимеше Нурсибәнең кабат исенә төште. «Шул карт беләнме?»—дип гаҗәпләнгән иде ул теге вакытта. Менә хәзер үзе, «шул карт»ны ярата башлады, «шул карт» аның яшь йөрәген тәмам биләп алды, «шул карт» көндезен дә, кичен дә аның уеннан чыкмый, ә төннәрен төшләренә кереп газаплый. Сөйкемле сөякләре бар икән бит, ничек яратмый түзәсең...

Ә бит нинди яшь булганмын икән
Илле, алтмыш тулган елларда.
Илледә ил гиздем, алтмышта да
Гашыйк идем әле кызларга,—

дигән шагыйрь хаклы булган икән. Гаҗәп, бик гаҗәп бу дөнья...

Ләкин... Алар шулай якын итешеп, дуслашып, очрашып озак йөри алмадылар. Нурсибә, гаиләсен алып, башка калага күчеп китте. Гүзәл ханым үзе айнымы, акылына киллеме, әллә Газиз суга тирән керүдән шикләндеме—ниндидер без белмәгән хәл булды алар арасында. Тик Газиз бүген дә бер көрсенеп, бер сызланып Нурсибә турында очсыз-кырыйсыз уйлар уйлый, шул уйларында аңа чиксез сораулар бирә, сөйләшә, аннары озын төннәрдә төшләрендә күрә. Өзелеп сагынган көннәрендә аңа атап моңлы җырлар суза:

Белми калдым, күрми калдым:
Киттең... Хушлашмадың да.
Эзең генә калды мина
Йөргән сукмакларында.

Кая киттең? Кемнәр алды—
Давыллармы? Суlarмы?
Эзләреңдә ак чәчәкләр—
Истәлеккә шулармы?..

* * *

Инде китте, югалды, башкача очрата алмам, дип йөргән көннәрнең берсендә алар тагын очраштылар. Андый хәлләр могъҗизага тиң һәм бик-бик сирәк була торгандыр.

Күрше каланың баш архитекторын ялга озаттылар. Хакимият башлыгы тантаналы озату кичәсенә, бүләк тоттырып, Газизне җибәрде. Зур ресторанга алты-җиде дистә кеше җыелган, шау киләләр, музыка уйный. Тантана да шулай шаулап үтте. Ялкынлы нотыклы, затлы, бүләкләр, җыр һәм бию, төрле уеннар... Тәнәфес вакытында кунаклар танцы иттеләр. Газиз дә, һәрвакыттагыча, бу тылсымлы мизгелне кулдан ычкындырмады—күрер күзгә чибәр генә бер ханым белән танцыга чыкты. Һәм шунда танцы итүчеләр арасында Нурсибәне күреп ах итте. Нурсибә дә аны күптән күреп, күзәтеп килә икән. Күзгә-күз очраштылар да, бер-берсенә карап, шатлыкларын һич яшерә алмый, якты елмаештылар.

Тангодан соң музыкантлар вальс уйнап җибәрде. Нурсибә, кемнең дә булса аны чакырып килүен көтеп тормастан, ашыгып-ашкынып Газизе янына килеп басты. Бу минутта аларның икесе дә чиксез дулкынлану кичерделәр. Танцыга парлашу мизгеленнән файдаланып, Газиз Нурсибәне татлы иттереп кочып торды. Нурсибә дә җавапсыз калмады—залда кеше күп, күрерләр, гайбәт сүз сөйләрләр, дип куркып тормады, бер мизгелгә Газизнең муенына сарылды. Аннан тезеп китте, чөнки аны сагынган, аның белән сөйләшергә сусаган иде ул:

—Әллә кемнәр белән танцы итеп... Ә үземнеке янда гына икән. Нинди генә булмасын, үземнеке, тик үземнеке! Моңлы карашы да, чиксез күп җыерчыклы йөзе дә, ягымлы елмаюы да, йомшак кулларының җылысы да—үземнеке. Сагынып беттем. Һичкемнекенә охшамаган жанга рәхәт тылсымлы тавышыңны, күңелне алгысыта торган сөйләшүеңне сагындым. Вакыт-вакыт мин аларны ишетәм сыман. Әллә исәрләнәм инде? Синме соң әле бу, ялгышмыйммы?..

Газиз рәхәтләнеп бер көлеп куйды һәм:

—Мин, мин бу—Газиз абзаң Солтанов,—диде. Шатлыгы эченә сыймый, дәрте ташый, рәхәт иде аңа бу минутларда.

—Нигә соң шунда син бераз яшьрәк, мин исә бераз олырак булып, элегрәк очрашмадык та, бергә була алмадык? Нинди бәхетле гомер кичерер идек...

—Чыгып качтың бит әле, бер дә бергә булу турында уйламадың.

—Шулай кирәк булды. Шулай кирәк! Мина үпкәләмә. Газапларга түзә алмый качтым. Яшерен сөю газапларына... Икегә ярыла алмадым. Ярылып та булмый. Ир хатыны бит мин! Ир хакы бар. Ир хакы—тәнре хакы. Шуның белән бергә яшә, шуннан тапкан баланны үстер, тәрбиялә, ә үзең башканы сөй... Килешми ул алай, һич килешми! Аңлыйсыңмы?

—Аңлыйм, аңлыйм. Мин бит бер сүз дә әйтмим сиңа. Әйтә дә алмыйм, әйтергә хакым да юк...

—Әллә ничек килеп чыкты шунда. Һич уйламаган идем синең белән мавыгырмын дип. Гел сихерләдең. Күңелең кин синең, йөрәгең мәхәббәтле, ә үзеңназлы. Чын күңелем, җаным-тәнем белән яраттым үзеңне. Бүген дә яратам. Тик минем хәлдә сөю-сөелүләр бик хәтәр. Уйланам, сызланам, тәүбә итәм, Ходайның ярлыкавын сорыйм, ә үзем... Хәзер бетте. Тынычландым. Әгәр яшьлегемдә ирем мине яратканымнан тартып алмаган булса, мин шул яратканыма чыккан булсам, бу адымга барыр идеммени? Ә син мина үпкәләмә...

—Юк, үпкәләмим. Мин барысын да аңлыйм. Синең хәлеңне, дим.

Тормышым гына авырайды. Синсез боегам, суга сусаган чәчкә кебек шинә барам. Авыр мина синсез...

—Үзенә тин бер кеше тап, жаным, өйлән, бәлки син дә тынычланырсын. Һәм... сина зур рәхмәт! Бәхетле айлар бүләк иткәнен өчен рәхмәт сина. Һич онытасым юк...

Залда музыка көчәйгәннән-көчәя барды. Ул, дулкын-дулкын булып, танцы итүчеләрне өереп залнын әле бер, әле икенче ягына күчереп, әйләндереп йөртте. Вальс биючеләр арасында пөхтә, килешле костюм кигән Газиз белән анын курчак кебек бәләкәй, бал кортыныкы кебек нечкә билле, ләкин бер кабым су белән йотардай нәфис Нурсибәсе барысыннан да аерылып тора иде. Әллә инде бер-берсен сагынышудан, алар бу кичне аерым күтәренкелек, илһам, дәрт белән биеделәр. Музыка тактын нечкә тоемлап, һич ялгышмый, кин урын билəп, залнын әле бер, әле икенче башына барып чыктылар, алар тирәсендә танцы итүчеләргә һич комачауламый, ялгыш та кагылмый, оста биючеләргә генә хас төгәллек белән, әле бер, әле икенче якка тыелгысыз әйләнделәр дә әйләнделәр. Зур залда бу кичне танцыда чын-чынлап Газиз белән Нурсибәдән дә остарак, шул кадәр пар килгән кеше юк иде.

Кичәнен ахырына кадәр алар бергә булырга тырышты. Рәхәтләнеп танцы иттеләр, сөйләште-серләштеләр, күзгә-күз карашып, монаеп бергә басып тордылар.

Инде кичә дә тәмамланды.

—Озатам,—диде Газиз.

—Юк, озатма,—диде Нурсибә. Аннары Газизне кочаклап, битеннән генә үбеп алды.

—Хуш, сау бул! Сәламәтлегенне сакла! Мин сина шуны телим. Даими телим мин аны сина—иртән дә, көндезен дә, кичен дә. Синен сау-сәламәт булуынны белеп тору мина да көч бирә...

Һәм, артына да борылып карамыйча, ефәк күлмәк итәген жилфердәтеп, коеп куйгандай нәфис, тигез аяклары белән жил-жил атлап китеп барды.

Ай күрде, кояш алды...

Калага кайтып, ялгыз башын кырын салып өенә таба атлаганда, Газиз үзенә бик таныш бер жырны шыншып алды:

Хушлаштын да китеп бардын,  
Аерылу авыр бит...  
Күзләреннен нурын  
Йөрәгемә салыйм,  
Тукта, дустым, сабыр ит!

Юк, туктамады анын Нурсибәсе, сабыр итмәде. Биек үкчәле туфлиләре белән тек-тек басып китте дә барды...

* * *

Курорт... Шифаханә... Дәвалану, сихәтләнү, ял итү урыны. Тик кемгә ничектер инде ул. Жан тынычлыгы таба алмаган кешегә кайда да унайсыз. Кая барсан да, кара сакалын артыннан калмый, чирен дә, хәсрәтен дә, авыр уйларын да сине озаталар. Адәм баласын эш түгел, кайгы-хәсрәт бетерә, дип белми генә әйтми торганнардыр.

Газизнен туган авылы Зирекле Чишмә уртасында мул сулы кизләү бар. Бик борынгыдан килгән кизләү. Авыл аксакаллары анын турында төрле риваятьләр сөйли. Имеш, авыл халкы килеп урнашканчы бу урында үтеп йөри алмаслык кара урман шаулаган, анда аюлар, бүре-төлкеләр, пошиболаннар, башка күп төрле кыргый-жанварлар, жәнлекләр булган. Аларнын барысы да әнә шул ургып аккан чишмә-кизләү суын эчкән. Ләкин тора-бара бу төбәккә килеп йөргән күчмә халык урманны кисеп, агачларны төпләп иген игәргә жир ясаган, кизләү тирәли йортлар салып, утрак тормыш башлаган.

Башка жирдә бик сирәк була торган хәл—бераз гына күкерт тәме,

күкерт исе килеп тора кизләү суыннан. Бәлки аның әнә шулай күкертле булуы аны тагын да саф, эчеп туймаслык тәмле итәдер. Ә аның хуш исе бөтен кизләү тирәсенә тарала.

Бредәге су исе дә авылның кизләү тирәсен хәтерләтә. Газизнең җанын бимазалаган, күнеленә авыр йөк булып сарылган уйлар шул киңлектә, шул хуш исле саф җилдә таркалып китәләр дә, бераз онытылып торалар...

Соңгы вакытта Газиз үзе дә тормыш мәгънәсе турында еш уйлана. Еш кына үткәннәрне искә ала. Яшьлек—киләчәк, картлык—үткәннәр белән яши, диләр. Яшь чагында гел киләчәгең турында гына уйлыйсың, аның турында кайгыртасың. Олыгайгач исә ныграк үткәннәр турында уйлыйсың, шулар белән яшисең, балачагыңны, яшьлегеңне, дусларыңны, сөйгәннәреңне искә аласың, дөрес яшәдемме икән, дип үз-үзеңә сорау бирәсең, җавап эзлисең. Кайчандыр ул урыс язучысы Борис Горбатовның әсәрләрен яратып укыган иде. Бер геройның: «Двадцать два года, а для бессмертия ничего не сделано»,—дип пошынганы Газизнең хәтерендә уелып калган. Егерме ике генә түгел, төгәл илле яшькә җитте ул, тик үлемсезлек өчен берәр нәрсә эшли алдымы соң? Атасыз үскән ачлы-туклы балачак, кимсетелгән үсмерчак, матур кием булмаганнан кызлар янына чыгалмый үткән егет чак... Беренче мәхәббәт—Сәрмәдия... Армия хезмәте... Архитектура факультеты... Проект бүлеге... Чернобыль... Нурсибә... Никадәр каршылыклы хатирәләр! Тик аларның берсе генә дә үлемсезлеккә нигез бирә алмый. Хәтта Чернобыль дә. Киресенчә, ул синең үлемеңне тизләтте генә, Газиз туган!

Әллә ни ерак китмичә, ишегалдында шулай уйланып йөргәндә, Газиз таныш тавыш ишетте:

—Газиз абый!

Арттан болай да тузынкы чәчләрен җилдә туздырып, җил-җил атлап Айсылу килә икән. Йөзе үзгәргән, күзләре дә куркынган кеше күзләре төсле. Ул ашыгып килде дә, ишегалдында йөреп торган курортчылардан да тартынмыйча, Газизнең күкрәгенә капланды.

—Нишләп юк син?... Бөтенләй югалта яздым...

Газиз бу ханымның хискә бирелүчән, тойгылы булуына күнегеп килә. Шулай да, аның бу мизгелдә нәрсә әйтергә теләгәнен бик үк аңлап бетермәде.

—Мин монда...

—Ай, шундый куркыныч төш күрдем! Бүген процедуралардан арып кердем. Бераз ял итеп алыйм дип яткан идем, йокыга киткәнмен. Төшемдә сине күрдем. Зур су имеш, син көймәдә, ә мин яр буенда. «Көймәңә мине дә утырт инде»,—дип кычкырам, имеш. Син ишкәкләрең белән ишәсең, ишәсең, ә көймәң ерагая бара. Агым сине каядыр өстери дә өстери... Уянып киттем—йөрәгем дөп-дөп тибә. Әллә синең белән бер-бер хәтәр хәл булдымы, дип торам. Сикереп тордым да, сезгә чаптым. Габделфәт абый: «Ул һава суларга чыгып китте»,—ди. Шуннан соң гына бераз тынычландым...

—Һи-и, тавык төшенә тары кергән инде,—диде Газиз елмаеп.—Әнә, диңгез, әнә көймәләр, баржалар, теплоходлар, мең төрле башка судноләр... Телисең икән, яр кырыена төшәбез дә, берәр балыкчының көймәсен алып, хәзер үк кереп китәбез диңгезгә...

—Юк, юк! Елга буена төшәргә риза, ә көймәгә керергә—юк. Куркам мин. Үзем өчен түгел, синең өчен куркам. Шундый сәер төш...

—Нәрсә, бүредән куркып урманга бармаска дисеңмени?

—Юк, урманга да бармыйм, елгага да төшмим. Мин элек тә урманнарга да, елгаларга-күлләргә дә йөрмәдем. Йөрткән кешем дә булмады, аңа үкенмим дә. Минем башта хәзер башка уйлар.

—Нинди уйлар инде алар, Айсылу ханым? Сер булмаса, сөйләп җибәрегез, зинһар өчен,—диде Газиз шаян тон белән. Айсылу да аның шулай вакыт-вакыт шаяртып сөйләшүенә күнегеп килә. Шаярта икән, бик әйбәт, димәк кәефе шәп, күнеле күтәренке.

—Мин сине шефлыкка алырга уйлап торам.

—Ничек була инде ул?

—Бик әйбәт була. Син авыру кеше, ләкин синең сәламәтлегең турында кайгыртучы кешең юк. Ә мин—табибә. Башка аргументлар да бар.

—Алары нидән гыйбарәт?

—Күрүемчә, төпле, ышанычлы кеше син, Газиз абый,—диде Айсылу шаяртудан житди сөйләшүгә күчеп.—Син мина чын-чынлап ошыйсын. Юк, ошау гына аз. Мин хәзер гел синен турында гына уйлыйм. Ярата башладым бугай үзенне. Чын менә... Ләкин бел: мин сина тагылырга уйламыйм. Мин бүген үземә тин кешене таптым дип уйлыйм. Инде ялгышам икән,—әйт!

Айсылу Газизнен беләгеннән кысып тотты. Газиз исә уйга калды, ничек итеп хәлен анлатырга белмәде. Юк, Айсылу турында ул яхшы уйда. Әгәр сәламәт булса, ул ана бүген үк тәкъдим ясар иде. Ә болай... Айсылуны өметләндереп, ялгышмасмы ул? Һай, тагын гомер булса икән. Ничек әле теге жырда?

Гомер уза аккан сулар кебек,
Йөрәкләрдә кала ярасы;
Кемнәр әйтер, кемнәр санап бирер—
Тагын күпме калды барасы?

Тагын күпме калды икән сон барасы? Булсын иде ичмасам дүрт-биш ел. Ул чагында Газиз үзе дә каршы килмәс иде, чөнки ул үзе дә бу асыл затны үз итә...

—Син дә мина ошыйсын, Айсылу акыллым. Ләкин мин сине бәхетле итә алырмынмы сон? Гәрчә, мин үзем моңа ышанмыйм, турысын әйтәм. Күреп торасын бит хәлемне. Шулай да, мин синен белән бәхетле бүген...

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә тагын яшь каен урманына килеп житкәннәр иде. Сентябрь кояшы инде кин елганын теге як яры артына яшеренгән, анда кызгылт офык кына күкне бизи. Елга ягыннан һаман талгын жил исә, рәхәт су исе борыннарны татлы кытыклый. Ничек кенә булмасын, Газиз белән Айсылу тормышында искиткеч матур, хәтта күпмедер дәрәжәдә хәлиткеч кич иде бу. Шунамы, Газиз Айсылуны тынычландырып, кочагына алды. Айсылу каршы килмәде. Бу вакытта аларнын баш очында яшь каен яфраклары гына, шыбыр-шыбыр килеп, нәрсә турындадыр сөйләшәләр иде...

* * *

Ниһаять, курортнын музыка өчен жаваплы кешесе эштә күренде. Бу форсатны беренче булып Айсылу файдалангандыр:

—Ринат матурым, вальс кичәсе үткәрик. Халык вальс тели. Туйдык без синен кыргый музыкана сикерүдән. Адәм рәтле бер кичә булсын әле. Музыканны әзерлә. Ин яхшы классик вальслар булсын. Чайковскийны да онытма, үзебезнен татар композиторларын да керт...

«Халык вальс тели»,—дигән сүзгә музыкант каршы килә алмады. Анын эше—ял итүчеләр мәнфәгатен кайгырту, аларнын теләген үтәү. Иртән-иртүк афишалар тактасында эре хәрефләр белән «Вальс кичәсе» дигән белдерү эленде. Баянын фәкать бер төркем ял итүчеләрнен иртәнге гимнастикасы вакытында гына кычкырткалап йөргән егеткә курортчыларны тәмам туйдырып бетергән репертуарны алыштырырга туры килде. Шкафта әрдәнәдәге утын пүләннәре кебек өсте-өстенә өелгән дистәләгән кассеталар арасыннан кайсыдыр бер вальс сөюче курортчынын бүләк итеп калдырган өр-яңа кассетасы килеп чыкты. Бу—«Классика шедеврлары»ннан егерме ин яхшы вальс кергән кассета иде. Анда Штраус та, Шопен да, Григ та, Сибелиус та, Чайковский да, Брамс та бар иде. Кызганыч, егетнен татар вальслары тупланган кассетаны әлегә каләр күргәне булмады, югыйсә, ул кичен татар композиторлары ижат иткән вальсларны да уйнатасы иде. Хәер, әлеге кассетаны табуына да бик шат иде ул, чөнки музыкаль зәвыгы югары булмаган бу яшь егетнен «әрдәнәсе»ндә жыен юк-бар кассеталар гына аунап ята. Татар вальсларын чыгарган очракта да, андый байлыкнын бу егет шкафында булуы икеле иде.

Айсылу иртәдән алып вальс кичәсенә әзерләнде. Ул көнне анын дәвалануы дәвалану булмады, гел ашыкты. Ваннасында да, массажында да,

башкасында да озак тоткарланмады. Бүлмәсенә кайтып, чемоданда бөгәрләнеп яткан яна күлмәген үтүкләде, чәчтарашка төшеп тузгыган чәчләрен төзәттерде. Аннары, көзге каршына утырды, тик үзе белән алып килгән иннеген дә, кершәнен дә сөртмәде, сөрмәсен дә тартмады, чөнки утыз өчтә дә ул әле кияүгә чыкмаган кызлар кебек яшь, сылу иде.

Менә кич булды, вальс кичәсенә төшәр вакыт житте. Ә залда... һичкем көтмәгәнчә халык күп, барысы да, сихерләнгәндәй, кичәгә жыелган, чөнки әлегә кадәр мондый кичәнен бу курортта булганы юк, киләчәктә дә булуы шикле иде. Бу гади вальс кичәсе генә түгел, ә чын бәйрәм кебек—кызкыркын да, егет-жилән дә, гүзәл-гүзәл ханымнар да, ир-атлар да иң күркәм, иң пөхтә киемнәрен киенеп төшкәннәр. Алар арасында Айсылу исә барысыннан да аерылып тора. Ул үзенә бик ошаган, әле беркайчан да кимәгән, ана килешеп, тәненә сыланып, гәүдәсенең сылулыгын аерымачык тәгаенләп торган, затлы тукымадан тегелгән ап-ак күлмәктән, шундый ук ап-ак, биек үкчәле туфлидән, кара чәчләре жинелчә бөдрәләтеп прическага салынган—хан кызы кебек сылу, кызлар бәйгесендә жиңү яулаган туташ кебек гүзәл иде.

Айсылу залдагылар арасыннан Газизне эзләде. Иш—ише, иш—кушы белән дигәндәй, гөлт итеп торган якты, һәр яклап бәйрәм төсе кергән зур залда һәркем үз парын барлап, сөйләшеп, вальска әзерләнә иде. Яшьләр дә, урта яшьтәгеләр дә үз ишләрен караштырдылар. Айсылу исә биредә бер генә кешене үзенә лаек пар итеп таный. Хет биш дистәсен тутырган булсын, авырсын, ләкин анын күнеле фәкать шул кешедә генә. Курортта гына түгел, бәлки бөтен төбәктә, юк, бөтен бер илдә, бөтен жиһанда бердән-бер кеше ул хәзер анын өчен. Һәм башка кеше ана кирәк тә түгел...

Әмма Газиз күренмәде. Ул да танцыга төшәргә тиеш иде бит. Айсылу, нишләптер, аларның бүлмәсенә кагылырга кыймаган иде. Кагыласы калган икән. Ул борчылып көтә бирде.

Залда вальс янгырады. Ашкынулы музыка бөтен бинага таралды, залга жыелган барлык курортчыларның игътибарын жәлеп итте, дәртен уятты, хәрәкәткә китерде. Кайберләре инде парлаша да башлады.

Нәкъ шулчак залнын кин итеп ачып куелган ике яклы ишек уртасында Газиз күренде. Мәһабәт төз гәүдәле, арыслан ялы кебек күпереп торган купшы-калын чәчле, фәрештә кебек ап-ак киемнән—ак күлмәк, аксыл чалбар, ак оек белән шундый ук ак туфлиләр. Айсылу аны күрү белән талпынып куйды. Газиз дә зал тулы халык арасыннан үз кешесен тиз күреп алды. Ул, һәрвакыттагыча, олы тыйнаклык һәм сабырлык белән, ашыкмыйча гына атлап Айсылу янына килеп басты. Һәм, ни гажәп, шул мизгелдә бер мәртәбә авызы пешкән ирнең күнеленә кинәт шик төште: ә бәлки ул бүген дә «юк» дип башын чайкар, ышан син хатын-кызга! Бар нәрсәгә әзер булып тору яхшы...

Юк, бу юлы Айсылу күндәм иде. Алар парлашуга, залдагылар бер нәрсәгә игътибар иттеләр: кавалер белән дама икесе дә пөхтә, матур, ак киемнән, икесе дә төз, сылу гәүдәле, икесе дә жилкенеп вальска бииләр һәм аларнын биюе залдагы башка биючеләрнекенә караганда күпкә дәртлерәк, нәфисрәк, сыгылмалырак иде. Вальсны болай чын күнелдән яратып, аны белеп, бар күнелләрен салып, унга да, сулга да тигез һәм жинел әйләнеп биючеләр дә фәкать алар гына булмагандыр. Ул гынамы сон әле! Музыканың иң күтәренке бер мизгелендә Газиз Айсылуны кочагыннан ычкындырды да, сул кулыннан алып аны үз әйләнәсендә әйләндерә башлады, аннары капма-каршы якка үзе дә әйләнеп китте һәм, өч-дүрт әйләнеш ясап, бикәсен кабат биленнән алды да, аны сул беләгенә салды. Бу валсьнын кульминациясе иде һәм аны, әлбәттә инде, бары тик Газиз белән Айсылу гына башкара алгандыр...

Айсылунын күптән вальска болай биегәне юк иде. Бу минутларда ул үзен чиксез бәхетле сизде һәм, кулын Газизнен жилкәсендә тоткан килеш, шатлыклы елмаеп, конгырт күзләрен Газизгә төбәде. Ә жинел туфлиләр кигән төз, көчле аяклары үзенекен эшләде. Вальска артыгы белән һәвәс Газиз белән танцы итү ана жинел дә, рәхәт тә, залдагылар арасында абруйлы да иде...

Дулкын-дулкын булып агылган музыкага жилләнеп әйләнү уңаенда Айсылу:

—Газиз абый, сина чын күңелдән рәхмәт! Бәйрәм бүләк иттең син миңа. Болай рәхәт итеп күптән вальс әйләнгәнем юк иде. Мин бүген бик бәхетле!—диде.

—Вальсны да бәхеткә саныйсыңмыни?

—Саныйм, Газиз абый. Синең белән танцы итүем мине тирән рухландыра, бәхетле итә. Һәм нинди бәхет әле!..

Айсылу кабынып, дәртләнеп, хисләнеп әйтте бу сүзләрне.

Тик...

Әнә шундый чиксез хозур белән вальс әйләнгәндә, Газизнең кинәт күз аллары караңгыланып, сөрлегеп китте һәм ул бер якка ава башлады. Ярый әле Айсылу аны тотып калды һәм, нидер сизеп, Газизне тиз генә урталан алып чыкты. Газиз:

—Ах, на-чар...,—диде өзеп-өзеп һәм күзләрен йомып диварга терәлде. Гөрләп торган залдагы халык моны күрми дә калды. Айсылу аның хәле шәптән түгеллекне аңлады һәм, тотыштыргалап, залдан алып чыкты да, бүлмәсенә чаклы озата менде. Бу вакытта Габделфәт тә—каян белеп алган диген син аны?—арттан йөгерә-йөгерә килеп керде һәм Газизне күтәреп алып урынына салды.

—Син, Айсылу монда кал инде. Мин шәфкать туташларын алып менәм,—дип, ул кабат аска йөгерде.

Шәфкать туташлары йөгереп менеп, Газизгә укол кададылар, аның кан басымын үлчәделәр. Айсылу да үзенчә ярдәм итеп карады. Ләкин моннан авыруның хәле яхшырмады, «Ашыгыч ярдәм» чакырырга мәҗбүр булдылар. Ярты сәгать дигәндә күрше каладан кош кебек очып «Ашыгыч ярдәм» машинасы килеп җитте. Табиблар төрле ысуллар белән авыруның хәлен яхшыртырга маташтылар, тик ул уңайга үзгәрмәде.

—Мондый хәлдә калдырып булмый, алып китәбез,—диде соңыннан өлкән табиб.—Җыярга кирәк...

Газизнең шундый хәлгә таруыннан аптырап, каушап киткән Габделфәт бу минутта нәрсә эшләргә дә белмәде: тәмам хәлсез яткан бүлмәдәшенең ялан аякларына оекбашлар кидереп маташты, йә күлмәгенә, йә спорт костюмына тотынды. Аннан хастаханәдә иң кирәк буласы киемнәрен бер полиэтилен сумкага җыя башлады. Газизне озата барырга иде исәбе. Моны чамалаган Айсылу кайтгый итеп:

—Юк, Габделфәт абый, үзем озатам,—диде.

—Ә Сез кеме буласыз аның? Без беркемне дә утыртып йөрмибез мондый вакытта,—диде «Ашыгыч ярдәм» табибы. Күпне күргән, күпне белгән Айсылу табибә, шартлатып:

—Мин аның хатыны,—дип ике сөйләргә урын калдырмады.

Габделфәт Газизне күтәрешеп чыкты.

—Тиз терелеп кайт, Газиз малай, мин китмим әле, сине көтәрмен,—диде ул һәм күзләренә бәреп чыккан яшьләрен сөртеп алды. Тик Газиз аның әйткәннәрен әллә ишетте, әллә юк—күзләре йомык иде.

Айсылу машинага, носилка янына кереп чүгәләде, Газизнең өстенә, төзәтә-төзәтә, одеал япты. Ни генә, ничек кенә булмасын, ул аны күз уңыннан ычкындырмаячак хәзер! Газизне озата чыгып Айсылу дөрес эшләде. Ниһаять, ул шуны аңлады: Газизнең хәле авыр, чиксез авыр. Берничә көн аралашканнан соң, ялгызлыктан гаҗиз булган Айсылуның үзе кебек үк ялгыз башы Газиз белән уртак тел, аңлашу табып, аңа сыену мөмкин булмасмы, дип уйлаган иде. Әллә ничек шунда, бөтен нәрсәдән бәйсез, ирекле бу кеше аның бар игътибарын үзенә җәлеп итте, бөтен ягы белән аңа ошады, аны аңлый алды, дәртен уятты, күңелен җилкетте-җилкетте, җанын эретте. Авылда туып, авылда үсеп, соңгы вакытта калада яшәсә дә, холык-фигыле, гадәтләре, саф күңеле белән һаман авыл кызы булып калган Айсылуның Газиз белән аралашкан кыска вакыт эчендә өметләре канатланган иде. «Мин үземә тиң кеше таптым бугай»,—дип уйлаган иде Айсылу. Әйе, сәламәтлегe шәптән түгел. Күп нурланыш алган кешенең хәле ничек булганы,

киләчәктә дә ничек буласы турында бер генә уйламады табибә. Ләкин нурланыш алганнар арасында да төрлесе бар. Әнә, ничек жилкенеп, дәрт белән вальс әйләнә бит Газиз, авыру кешегә һич охшамаган. Әгәр ул исән калса, терелеп китсә, алар шәт бергә калырлар, кушылырлар. Ходай биргән гомернең ахырына чаклы гөрләшеп-чөкердәшеп бергә яшәрләр. Тик Газиз белән генә бер-бер көтелмәгән хәл булмасын. Ә Айсылу табибә үз чиратында аның сәламәтлеге өчен киләчәктә бөтенесен эшләячәк, барлык көчен куячак. Исән генә булсын!!!

Айсылу, одеал астына тыгылып, авыруның салкынча кулын жылы учына алды. Газиз житкән чаклы аның кулын кыскандай итте. «Рәхмәт сиңа!»—дидеме ул, әллә Айсылуның аны якын итеп, үз итеп озата баруыннан канәгать калдымы? Һәрхәлдә, бүген ялгыз түгел ул, аның янында ышанычлы кеше—үз кешесе бар. Хәтта үлә-нитә калса да янында якыны була. Ә үлем... Ул бар, аннан барыбер котылып булмас, ахры. Иртәме, соңмы—барыбер котылып булмас.

Яшәү, үлем—бары тик бер сукмак,
Нигә башка сукмак юк икән?..

Нигә башка сукмак юк икән соң? Һич югында, нигә ул сукмак бераз озын түгел? Алда никадәр эше бар иде Газизнең. Тәгалләнмәгән проектлар, барасы, чыгыш ясыйсы митинглар, күрәсе, сөйләшәсе кешеләр, тагын әллә нәрсәләр...

«Чи-у, чи-у...» «Ашыгыч ярдәм» сиренасы Газизнең колагында хәвеф хәбәрчесе булып түгел, ә ниндидер музыка булып яңгырый. Тик ул музыка, нишләптер, ике тактлы гына, вальс кебек өч тактлы түгел. Ике тактлы гына булса да, ана вальс әйләнергә мөмкин сыман. Әнә... биилр бит әле кешеләр... Ниндидер якты зал. Яп-якты. Көпә-көндез. Тәрәзәләрдән кояш нурлары сирпеп торган, Газизгә әлегә кадәр һич таныш булмаган зал. Залның әле түшәме дә юк, шуңа якты икән. Кайда соң ул, нишләп йөри һич күрмәгән, белмәгән жирләрдә? Зал тулы халык, барысы да ак киемнән. Һәм «чи-у, чи-у» дигән музыкага котырынып вальс әйләнәләр. Шул халык арасында, әнә, Сәрмәдия дә биеп йөри. Гажәп хәл: Газиз элек хатынының вальс әйләнгәнен хәтерләми иде. Сәрмәдиянең өстендә һинд хатын-кызлары киеменә охшаган эленке дә салынкы ак тукыма кием. Чит-ят кешеләр белән ут өереп биеп йөргәнгә, Газиз аны күрмәмешкә салыша, хатыныннан кача, имеш. Ләкин кача алмый кала—Сәрмәдия аны күреп ала һәм биергә чакыра: «Синең дә вакытың житте»,—ди ул. Нинди сүз бу, нәрсәгә «вакытың житте», дип әйтә ул?

Менә алар Сәрмәдия белән вальс әйләнәләр. Кара инде, Сәрмәдия дә бик оста бии икән бит! Тик аның киеме генә, нигәдер, асылынып-асылынып төшә дә, биергә комачаулый. «Монда кысан, әйдә, күккә менәбез»,—ди Сәрмәдия. Һәм алар шулай әйләнә-әйләнә ачык түшәмнән иркен күккә менеп китәләр...

Машина юл сикәлтәсендә сикереп куйды һәм Газиз бер мизгелгә генә аңына килде. Аннары, упкынга тәгәрәгәндәй, кабат аның жуйды. Күпмедер вакыттан соң ул тагын аңга килде, тагын каядыр убылды...

Кызыл Хач билгесе сугылган ак машина олы юлда барлык утларын яктыртып, һаман шулай чыелдый-чыелдый, гаять зур тизлек белән алга чабуын дәвам итте.

Бу минутларда Айсылуның башында очсыз-кырыйсыз уйлар чуалды. Йа Хода, яна бөреләнеп килгән хыяллары, канатланып барган өметләре өзелер микәнни? Бәхеткәйләре аны тагын читләтеп үтәр микәнни соң инде? Нигә шулай мәрхәмәтсез ана бу язмыш?..

Газиз янында чүгәләп утырган Айсылуның мөлдерәп тулган күзләреннән агарынган бите буйлап тыелгысыз кайнар яшьләр тәгәрәде...

## Әгъдәс Борһанов

# ТАТАР! ДӨРЕСЛЕКНЕ БЕЛ!

### 1. Безне йоту дәвам итә

УРЫС ДӘҮЛӘТЕ Казан һәм башка ханлыкларны басып алганнан бирле татарлар башка милләтләр тарафыннан йотыла бара. Безнең көннәрдә бу аянычлы күренешнең тагын да көчәюе сизелә. Россия дәүләте тарафыннан хәзер «славян халыклары кардәшлеге» идеясе ачыктан-ачык гамәлгә ашырыла. Мәктәпләрдә, армиядә, дәүләт оешмаларында православие дине тәгълиматлары, кеше нинди дин тотуына карамастан, көчләп тагыла. Бу диннең йогынтысы дәүләт бүләкләрендә һәм символ-тамгаларында да ачык чагыла. Шул ук вакытта урыстан гайре миллэтләрнең, аеруча ислам динен тотучыларның, мәдәниятенә, тарихына, гореф-гадәтләренә, теленә һәм диненә түбәнсетеп карау сизелә.

Кайчандыр үзләренең тарихи Ватаннарыннан көч кулланып, яки административ рәвештә кысрыклап чыгарылган татарларның тел, мәгариф һәм мәдәни ихтыяҗларын кысу очраклары Россиянең аерым төбәкләрендә бик еш күзәтелә. Татар баласы туган телендә белем алучы мәктәптән мәҗбүри рәвештә башка телле мәктәпкә күчерелә. Кайбер төбәкләрдә татар мәктәпләре бөтенләй юк, булганында исә берничә йөз мең татарга бер-ике генә мәктәп туры килә. Анысында да ана теле дәресләре бик аз керә. Балаларга, аларның ата-аналарына башка милләтнең уку-дәреслек китаплары көчләп тагыла. Бүгенге көндә татар милләтен бүлгәләү, таркату сәясәте дәүләт күләмендә оештырыла һәм гамәлгә ашырыла. Озак еллар дәвамында формалашкан бердәм татар милләтен берничә территориаль, хәтта дини төркемгә бүлгәләргә маташалар. Аларны мөстәкыйль милләт статусы белән дә, яңгыравык-ялтыравык атамалар белән дә кызыктырып карыйлар, үзара милли дошманлык хисе тудырырга, шул рәвешле татар милләтен эчтән таркатырга телиләр. Мондый ясалма юл белән яңа «милләт»ләр оештыру— урыс дәүләтенең мөкерле сәясәтендә башбаштаклыкның һәм законсызлыкның иң ачык чагылышы лабаса!

Урыслар тарафыннан татарларны йоту тарихи Ватаныбызның нәкъ үзегендә—Татарстан җөмһүриятендә дә бара. Әмма татар милләтенең дүрттән өч өлеше җөмһүрияттән читтә яши. Күсекнең юан башы аларга төшә. Милли кысулар, җәберләүләр нәтиҗәсендә, читтә яшәүче татарларыбызның инде бик күбесе, ни аяныч, ана телендә сөйләшә дә, укый-яза да белми. Иң хәтәре шул: Татарстанда һәм аннан читтә яшәүче милләттәшләребез бер-берсе белән

бик аз аралашалар. Алга таба да милли вәзгыятьтә уңай үзгәрешләр кузгалмаса, татарны һәлакәт көтә.

Безгә мәдәни тормышта гына түгел, базар шартларында, кәсеп-кәсәбәчелектә дә үзара аралашып яшәү зарур. Иң мөһиме: милләт иммунитетын (чиргә каршы тора алу сәләтен) югалтмаска тиеш! Ә чирләребез бик күп безнең һәм алар татарга дөньяның этник картасыннан төшеп калу-югалу куркынычы белән яный. Тоталитар тәртиптән демократиягә күчү чорында милләттәшләр арасындагы мөнәсәбәт базар һәм шәхси милекчелек аша да булырга тиеш. Чөнки шәхси милке булган милләт үз язмышына үзе хуҗа, милекче гражданнарын бер йодрыкка туплау сәләте дә хас аңа! Фәкать шул рәвешле генә Татарстаннан читтә яшәүче татарларны милләт буларак саклап калу мөмкин, минемчә. Хәер, бу милли идеяны—төрле акционерлык, кооператив җитештерү, сәүдә, кәсеп һәм башка компанияләр булдырып, татарлардан милекле сыйныф ясау һәм шул рәвешле аларны милләт итеп саклап калу фикерен мин тәкъдим иткән идем инде. Татар эшкуарлары, байлары белән бергә бөтен Россия (киләчәктә—бөтендөнья!) татар милли капиталын туплый башларга вакыт. Хәттә—зарур! Бу гамәлебез милләттәшләрне милекчегә әверелдерер, качак һәм күченергә мәҗбүр ителгән татарларны тарихи Ватаныбызга кайтарырга да ярдәм итәр иде.

* * *

МИЛЛӘТ ЭЧЕНДӘ кайный торган тискәре күренешләргә татарны саклау, яклау өчен оешкан Бөтендөнья татар конгрессы белән Татарларның милли-мәдәни федераль автономиясе (ТММФА) каршы торырга, милләтнең гаҗәеп бай мәдәниятен, җир йөзендәге иң төп 14 телнең берсе булган татар телен саклау өчен һәммәсен дә эшләргә тиеш югыйсә. Әмма нәтиҗәләр һич кенә дә тынычланырлык түгел.

Моңа объектив һәм субъектив сәбәпләр шарт. Төп сәбәпләрнең берсе—тиешле чаралар күрү өчен законнарның булмавы. 1997 елда чыккан «Милли-мәдәни автономияләр турында»гы закон исә кайсы да булса төбәктә милли азчылыкны төшкил итүчеләрнең мәнфәгатьләренә туры килми. Чөнки бу автономияләргә иҗтимагый оешма статусы гына тәгаенләнгән, шуңа күрә дә, законның начар эшләве, милләтнең матди байлыктан, хокуктан ераклаштырылуы—күз алдында. Югыйсә бу оешмаларның дәүләт статусы булырга тиеш! Чөнки тормыш үзе шулай куша. Урысның бөтен милли мәсьәләләре дәүләт бюджетына салынган. Ә бу бюджет, урысның үзеннән гайре, «халыклар төрмәсе»ндәге башка бик күп милләтләрнең сыртын каезлап җыелган акча-салым бәрабәренә тулыландырыла. Соңгы берничә елда дәүләт сәясәте белән идарә итүчеләр урыстан аз санлырак булган милләтләрне кысуның, мәсхәрә итүнең төрледән-төрле мәкерле ысулларын уйлап чыгардылар һәм аны гамәлгә ашыра баралар...

Югыйсә, әле совет чорына кадәр үк Россияне милләтләр берлеге дәүләте итеп үстерү омтылышы туган һәм аны ил белән идарә итүче буржуазия сыйныфы да хуп күргән иде. Ә 1917 елның июлендә Казанда Бөтенроссия мөселманнарының дини, хәрби һәм гомуми корылтайларының берләштерелгән җыены уза һәм анда эчке Россия белән Себер төрки-татарларының милли-мәдәни мохтарияте игълан ителә. 1917 елның 20 ноябреннән 1918 елның 11 гыйнварына кадәр эшләгән Милли Мәҗлес исә бу мохтариятнең конституциясен раслый һәм башкарма органнарын сайлап куя. Әмма Уфада алар тарафыннан оештырылган Милли идарә 1918 елның апрель аенда большевиклар кулы белән юк ителә.

Татарның беренче Конституциясенең төп мәгънәсе-асылы (ул безнең заман өчен дә кулай булыр иде)—милли азчылыкны төшкил итүче халыкка мәдәни автономия хокукы бирү; милли оешмаларны үзәк һәм җирле дәүләт оешмалары белән тигез хокуклы итеп санау, аларның кирәкле законнар чыгаруда һәм үз гражданнарыннан махсус салым җыю хокукын тану; дәүләттән һәм җирле бюджеттан, халык санына карап, аларның мәдәни мәнфәгать вә ихтыяҗлары өчен акча бүлеп бирү.

1998 елда татарларның Мәскәү автономия советы минем тарафтан эшләнгән «Автономияләр турындагы закон» проектын Дәүләт Думасына юллау

тәкъдиме белән чыкты. Бу проект, нигездә, беренче татар Конституциясе белән тәңгәл иде. Әмма бу закон проекты Русиянең милли сәясәт эшләре министрлыгы тарафыннан начар якка үзгәртелеп, 2001 елның 10 маенда гына Дума карамагына тапшырылды. Ни кызганыч, бу закон проектын Бөтендөнья татар конгрессы да, ТММФА да яклый алмады, алар хәтта Татарстан Фәннәр академиясе җыенында кабул ителгән «Милли-мәдәни автономияләр турындагы» закон проектын Татарстан Дәүләт Советының парламент тыңлауларына тәкъдим итәргә»—дигән карарына да битараф калдылар. Милли-мәдәни оешмаларыбызның янә бер яңа зур кимчелеге: татар язуын латин имлясына күчерүне яклап чын мәгънәсендә көрәшмәве. Бу мәсьәлә буенча ни ТММФА, ни Бөтендөнья татар конгрессы Татарстанда гына түгел, диаспоралар арасында да бернинди дә аңлату эшләре алып бармадылар, һәм бу гафу ителмәслек эшсезлекне латинга каршы көчләр бик тиз файдаланды. Аеруча урыслашкан татарлар белән латинга күчүгә каршы торган идарә структуралары бергәләшеп тырыштылар. Югыйсә, һәммәбез дә белә: кирилл язуы лингвистик яктан татарга бөтенләй хас түгел. Шунысы хак: кемнәрдер татарның төрки телле башка кардәш-ишләре белән аралашуыннан бик тә курка. Хәер, кемнәр икәне билгеле инде...

Аяныч ки, Бөтендөнья татар конгрессы белән милли-мәдәни федераль автономиянең эш нәтиҗәләре әлегә әллә ни күзгә ташланырлык түгел шул. Бармы соң аларның киләчәккә карап эш йөртү концепциясе? Татарның этник экология программасын эшләделәрме соң алар? Ни кызганыч, боларның берсе дә гамәлдә юк. Югыйсә, Бөтендөнья татар конгрессының беренче юбилеен үткәрерлек вакыт та узды. ТММФА оешканга да бер генә ел түгел. Әмма аларның «эшчәнлеге» фәкать Сабан туйлары һәм Казан түрәләре катнашында узучы тантаналарда гына чагыла. Татар милли оешмалары, минемчә, көч-куәтле, фидакарь рухлы кадрлардан торырга тиеш. Милләткә хезмәт итүчеләр арасында яшьләрне дә күрәсе килә. Бүгенге болгавыр Россия империясе шартларында милли кадрларның эшлекле һәм әхлаклы булуы милләт бөтенлеге өчен гаять зур әһәмияткә ия.

* * *

ТАТАР МИЛЛӘТЕНЕҢ бүгенгедәй авыр, аяныч хәлдә калуына Татарстан җитәкчеләре дә гаепле. Кайчандыр республика мөстәкыйльлеге өчен байтак эшләр майтарып та, милли азатлык хәрәкәте күтәрелеп килгән дәвердә алар үз милли сәясәтләрен гамәлгә ашыра алмадылар. Хакимияткә В. Путин килгәч, 1994 елда Россия белән Татарстан арасында төзелгән шартнамәдә билгеләнгән хокукларның тиз арада тартып алынуы, юкка чыгарылуы—моңа бер дәлил. Республиканың төп кануны Россиянең камиллектән бик ерак торган кануны белән тәңгәлләштерелә. Бу уен бер капкага—Татарстан капкасына гына каршы уйнала һәм ике якның уенчылары да—бюрократлар. Татарстан халкы исә бу уенда тамашачы булудан да мәхрүм ителгән. Әйтерсең лә аның бу уенга бер катнашы да юк. Миңа калса, татар милли хәрәкәтен республика җитәкчеләре тәмам көчсезләндерделәр. Гади халык исә берни белән дә кызыксынмый. Боларның нәтиҗәсе—күз алдында... Бит гади халыкның байтагы киләчәккә карап фикер йөртми. Аларны: «Суверенитет безнең кебек гади кешеләргә ни-нәрсә бирде?»—дигән сорау гына кызыксындыра. Югыйсә, тирәннән фикер иткәндә, мөстәкыйльлеккә омтылу безне матди яктан да, рухи яктан да ныгытты, баетты. Әмма бу байлыкны кул белән тотып-капшап карап булмый. Югары даирәләр туплаган байлыкны исә бик яхшы «тотып карарга» була...

«...Нефть табудан алынган керемнәргә Татарстанда урта сыйныф оештырмаулары белән республика җитәкчеләре зур сәяси хата ясадылар... 20 миллиард доллар... мөстәкыйль республиканың нигезен ныгытырга, Федераль үзәкнең басымына каршы торырга ярдәм итәргә тиеш иде һәм бу басымнар җәмгыятьтә зур каршылыкка очрар иде. Ә бүген исә җитәкчеләр республика референдумында җиңеп чыгачакларына да икеләнәләр»—дип яза журналист Рәшит Әхмәтов «Звезда Поволжья» (28 февраль,—6 март саны, 2002 ел) гәзитендә. Ул хаклы. Аның фикеренә өстәп мин болай дияр идем: «Әгәр дә бүген Мәскәү безнең кайбер югары даирә вәкилләренә җинаять эше кузгатса, моңа халык каршы килмәячәк. Республикада бу каршылыкны оештырырлык кешесе дә, оешырлык сыйныфы да юк. Хуҗалары ашаганда аргта баш иеп,

сөлге тотып торучылар гына бу эшне оештыра алмыйлар.»

Референдум, дигәннән, Татарстанда яшәүче урысларның аңа мөнәсәбәте нинди? 1992 елдагы референдумда «әйе» дип җавап биргән 62,3 процент тавышның иң кимендә 20-25 проценты—урыслар һәм татар булмаган башка милләтләр иде. Димәк, бер татарны гына түгел, урыслар һәм башка халыкларны да Мәскәү табыныннан коелган икмәк валчыкларын җыеп җан асрау гаҗиз иткән. Үзе иккән-үстергән икмәкнең Мәскәүгә китүенә һич тә риза түгел ул. Киләчәктә Россиядән байтак кына урыс төбәкләренең аерылып чыгу ихтималы, сәбәбе менә каян башлана! Ил белән, бүгенгедәй, бюрократлар хакимлек итсә, алга таба Россия, шигрин күнедәй, Московия чамасында гына калачак.

Урта сыйныф, дигәннән, аны киң колачлы итеп оештыру мөмкинлеге дә бар иде. Татарстандагы «Базар шартларына йомшак керү» сәясәте баштарак үзен аклаган иде. Минемчә, монда иң кулай юл—милли байлыкны хосусыйлаштыру, ягъни һәр кешегә үзенә тиешле өлешне бүлеп биреп, аннан милекче ясау. Бу хакта мин әле 1996 елда ук Минтимер Шәймиевкә дә әйткән идем. Әмма байлык белән идарә итүче түрәләрнең ул байлыкны халык белән һич тә бүлешәселәре килми. Үз эшен булдырып, базар мөнәсәбәтләренә күчүчеләргә арзанлы кредитлар бирү юлы белән дә ярдәм итәргә мөмкин ләбаса. Эшләргә теләгән кешене төрле салымнардан азат итү, аны бөлгенлеккә төшүдән саклау, яклау, югыйсә, дәүләтнең изге бурычы саналырга тиеш. Ныгытып аягына баскан урта сыйныф исә бүген үзенең Ватаны—Татарстанга ышанычлы терәк-таяныч булган булыр иде. XIX гасырда туган бик тә билгеле бер гыйбарә исегездәме: «Пролетарийларның Ватаны юк».

Без Россиянең кыл уртасында яшибез. Тарихтан билгеле: Россия гомер-гомергә бер диктатурадан икенчесенә, тагын да әшәкерәгенә күчә торган ил. Бөтен яктан килгән камил демократия безгә насыйп та булмас. Әмма либерал-демократлар моңа ике мәртәбә омтылып карадылар. Беренчесе, 1917 елгы февраль инкыйлабын да кертеп, узган гасырның башларында булды. Икенче омтылыш исә СССР таркалыр алдыннан башланып, бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Ике очракта да бер бәла—урта сыйныф юклыгы сәбәпле, чын демократия җиңә алмады. Бу сыйныф бүген дә юк. Аның кайчан туасын тегаен кистереп әйтеп тә булмый, чөнки хәзерге сәясәт элеккеге сәясәттән бернәрсәсе белән дә диярлек аерылмый, димәк, халыкка үз милкен барлыкка китерү өчен мөмкинлекләр бүген дә юк. Аның каравы, диктатура өчен социаль нигез пәйда булды. Дәүләт коллар сыйныфын бар итте һәм менә инде өч гасыр дәвамында бу дәүләт үзенең аерым бер милләтенә каршы—татарларга каршы геноцид сәясәте алып бара. Бу сәясәт анысы, урысларга да, башка милләтләргә дә кагыла. Бетмәс-төкәнмәс сугышлар, репрессия мәхшәрләре, хәерчелек, эчүчелек, наркомания—моңа төп дәлил.

Вәләкин бүгенге халыкара вәзгыять XX гасыр башларындагыдан барыбер дә азмы-күпме аерыла. Элек дөнья империализмы чәчәк аткан чор булса, хәзер исә дөньяда хәлиткеч рольне Европа, Төньяк Америка һәм Көнчыгышның алга киткән илләре тәкъдим иткән халыкара демократия башкара. Бу максаттан Европа Советы эшли һәм Россия аңа әгъза булып керергә мәҗбүр ителде. Хәзер без Халыкара мәхкәмә таләпләре киңлегендә яшибез, ул исә тиеш тапкан теләсә кемне җәзага тарту хокукына ия. Бу хөкемнән хәтта үзенең атом-төш кораллары белән шапырынучы Россия дә читтә кала алмый. Шөкер, Россия дә соңгы вакытта бераз яхшы якка үзгәрде. Ул «Сөзгәк сыерга Ходай мөгез бирмәс»—дигән гыйбарә белән дә, ниһаять, килешә башлады. Югыйсә, бу «мөгез» инде күптән сынып төшкән һәм ул хәзер үзенең тыңлаусыз «бозау»ларын гына сөзәргә яраклы.

* * *

ТАТАРСТАН Республикасының ун еллык «суверенлыгы»ның нәтиҗәсе ничек булды соң? Сәясәт уенында бюрократлар гына уйнагач, ни буласы билгеле инде... Әлбәттә, баштарак Мәскәү түрәләре төбәк түрәләренә җирле милли байлыкны үзләштерү өчен мөмкинлек бирделәр, соңрак исә, «күп ашап симергән эт хуҗасын тешли»—дигәндәй, бу эшкә нокта куйдылар. Әйе, мөстәкыйльлекне бер хуҗа (!) бирде, ә икенчесе кире тартып ала... Безне

үзебезнекеләр талады. Анысы, бу беренче генә талау түгел инде, аңа ияләшергә дә вакыттыр, безнең байлык әле моның белән генә тәкәнми ләбаса. Әмма: «Үзебезнекеләр талады!» дип шатлану да ахмаклык булыр иде. Җитәкчеләр, түрәләр киләләр дә китәләр, ә халык кала. Бу халыкны коллыктан арындырырга омтылучы затларыбыз да бар. Минтимер Шәймиевне мин шундый җитәкчеләрнең берсе дип исәплим. Ул үз даирәсендәгеләрнең мәнфәгатьләрен дә онытмады һәм шул ук вакытта аз керемле гаиләләр, сугышта катнашучылар һәм инвалидлар турында кайгыртты, тузган торакны бетерү программасын уңышлы гына гамәлгә ашырып килә, гомумән, башка мөһим эшләрне дә күз уңыннан ычкындырмый. Россиянең байтак кына башка субъект җитәкчеләреннән аермалы буларак, ул Татарстанны бөлгенлеккә төшүдән саклап калды һәм хәтта берникадәр дәрәҗәдә аның яшәү рәвешен яхшыртты да.

## 2. Милләтне юкка чыгаруга, таркатуга юл кую— тәкъдирме, кабахәтлекме, әллә җүләрлекме?

АЛТЫН УРДА чорыннан мирас булып калган бөеклек мифыннан, урыс кебек үк, без, татарлар да, әле һаман арына алмыйбыз. Ул чор, дөрестән дә, бөек булган. Әмма без ул чорда яшәмибез ләбаса. Без үзебезне арттан «ләң» дә «ләң» өреп калучы маэмайларга исе дә китмичә үз юлы белән атлаучы филгә охшатабыз. Татарларның илдәге башбаштаклыкларга карата битарафлыгын, ваемсызлыгын мин, һәрхәлдә, башкача аңлата алмыйм. Бу «филлек»кә түрәләрнең сәяси куркаклыгы да кушылып китә...

Кайчандыр татарлар сан ягыннан урыслар белән тигез булганнар. Әмма бүгенгесе көндә без илдәге тулаем халыкның егермедән бер өлешен генә тәшкил итәбез. Әйе, безнең милләт махсус рәвештә киметелгән, төрлечә бүлгәләнгән. Аны хәзер дә бүлгәләргә маташалар. Халык санын алырга әзерлек барышында бу аеруча нык күзгә ташлана.

Милләт язмышын кайгыртучы кайбер зыялыларыбыз: «Татарның психологиясендә бердәмлек хисе юк»—диләр. Әйе шул, «бездә бердәмлек юк шу-у-ул...»—дип елардай булып, бер-беребезгә зарланырга яратабыз анысы. Әлеге дә баягы бердәмлек булмау аркасында милләтнең нигезе какшады да инде. Моңа өстәлгән социаль, территориаль, һәм соңрак (татарларны көчләп чукындыра башлагач) конфессиональ сәбәпләр исә милләтне таркатуда хәлиткеч роль уйнады. Казанны алганда Иван Грозный гаскәрләренә татарларның да кушылуы (дошманына ярдәм итү күренеше алга таба да еш күзәтелде) милләтне эчтән таркатты. Мин байтак кына фәнни һәм әхлакый хезмәтләремдә татарның таркалу-бетү сәбәпләрен үземчә аңлатырга, ачыкларга омтылдым. Бу хәл башка милләтләрдә дә күзәтелә. Фәкать яһүд белән әрмәнгә генә кагылмыйдыр ул бетү-бетерелү-бетерелү. Югыйсә, бу ике борынгы халыкның тарихи җирләрендә бөтен дөньяга кирәкле нефть тә, башка төрле кыйммәтле минераллар, байлыклар да табылмый. Әмма аларның гаҗәеп зур байлык-хезинәләре бар. Ул—төрле кыйтгаларга, илләргә таралып, шунда яшәүче милләттәшләре! Бу бердәм, көчле диаспора тарихи Ватаннарында яшәүче кардәшләренә һәрдаим ярдәм итеп тора. Ә безнең «бердәмлек» славян халыклары бердәмлеге белән бер чамадарак. Славяннар исә беркайчан да бердәм булмаганнар... Ә менә урыслар, читтән куркыныч янаганда, (мәсәлән, сугыш вакытында) үзара шундук берләшәләр. Алтын Урда булмаса, урысның иң кимендә унлап мөстәкыйль дәүләте оешыр иде. Әмма алар тыныч шартлардагы таркаулык психологиясен хакимиятне кискен үзәкләштерү (вертикальләштерү), диктатура урнаштыру юлы белән җиңәләр. Вәләкин татарның мондый мөмкинлеге юк. Бу Алтын Урда таркалганнан бирле шулай. Бәлки, без һәлакәткә—упкынга илтүче сыйфатларыбызны соңгы сызыкка, соңгы чиккә килеп җиткәч кенә, инде милләт бетте, дигәндә генә үзгәртә алабыздыр?

Әгәр дә без бүгенге шартларда милләт булып яшәргә телибез икән, безгә барлык милли төркемнәребезне дә (социаль, территориаль, конфессиональ...) бер йодрыкка берләштерү зарур. Аерым-аерым тырпаеп торган бармакларны бик тиз сындырып ташлаулары ихтимал. Әмма татарны берләштерү бүгенгедәй эшкә яраксыз милли оешмаларның кодрәтеннән килми шул. Моның өчен татарларның Федераль милли-мәдәни автономиясе (ТФММА) белән Бөтендөнья

татар конгрессына тамырдан үзгәрешләр кертү кирәк. Бу оешмалар иң беренче эшләре итеп мондый мәсьәләләрне чишә башларга тиешләр:

1. Татарларны милекче-базар субъектына әверелдерү;
2. Милли капитал туплау;
3. Туган телне саклау һәм үстерү.

Бар булмыш көч-җегәрне инде оешкан, берникадәр эш тә күрсәткән федераль һәм бөтендөнья күләмендәге милли оешмаларны ныгытуга юнәлтәсе чакта, Мәскәүдә тагын бер оешма барлыкка китерелде. Танылган хирург Ренат Акчурин җитәкчелегендәге «Ватаным» («Мое отечество»). Гражданлык җәмгыяте үсешенә ярдәм итү өчен партнерлык элемтәләре» гомумроссия оешмасы, дип атала ул. «Бу оешмага берсеннән-берсе дәрәҗәлерәк, авторитетлы татар кешеләре керде»—дип белдерә аны оештыручылар. Ярый, шулай да булсын ди. Әмма анда мин белгән бер генә милләтпәрвәр зат та юк. Хәер, «авторитетлар» өчен дә берәр оешма булырга тиештер бит инде?! Бу оешма татарларны Россия мәнфәгатьләреннән чыгып якларга, аларга ярдәм итәргә алына. Шуңа күрә, исеме дә—«Ватаным». Югыйсә, моңа охшаш хәрәкәт элек тә бар иде инде. Татарстан референдумы алдыннан (1992 елның февралендә иде ахрысы) Кремль Республика партиясе (В. Н. Лысенко) белән берлектә шундыйрак бер хәрәкәт оештырган иде. Арабыздан тавышы бик каты чыга торган, дәрәҗә яратучы бер кешене сайлап алып, аны «надан» татарлар өчен мәдәният учагын торгызырга тиешле ниндидер гомумроссия оешмасына җитәкче булырга кызыктырдылар. Алга таба аңа: «Әгәр дә Татарстан мөстәкыйль була калса, читтә яшәүче татарлар һәртөрле кимсетүләргә һәм кысуларга дучар булачак»—дигән үтергеч тезисны алга сөрергә тәкъдим иттеләр. Татар язуын латинга күчерүнең кирәксез гамәл икәнлеге, милләтне таркатуга китерәчәге хакындагы «Мөрәҗәгать»тә дә шуңа охшаш тезис сизелә ләбаса. Яңарак өшәкелек уйлап чыгара алмадылар микәнни?!

Урысның: «Үлгәннәр ояла белми»,—дигән бер әйтеме бар. Оят дигәннәре анысы теп-тәре маңкортта да юк инде ул. Чөнки, маңкорт татарның фәкать үз дәүләте белән генә көчле-кодрәтле булуын белми, белергә дә теләми. «Ватаным»ның хуҗалары биш гасыр дәвамында мәрткә китеп йоклаганнан соң әле уянып кына килә торган дәүләтчелегебезне ястык белән томалап үтерергә телиләр. Никадәрле генә битәрләсәк тә, «җитлекми туган» суверенитетыбыз ун ел эчендә барыбер дә күзгә күренерлек уңышларга ирешергә өлгерде.

Бүгенге көндә Россия хөкүмәте «Аз санлы милләтләрне саклау турында»гы Законны санга сукмыйча, милләтләрне кимсетү, киметү, телен бетерү, милләттән кайбер территориаль һәм конфессиональ төркемнәрне ясалма рәвештә аерып чыгару (аеруча, бу татарларга яный), аның хокукларын тартып алу кебек кабахәт эшләр белән шөгыльләнә. Шул ук вакытта үзебезнең (әмма алар—безнеке микән?!) «авторитет»ларыбыз, Мәскәү Кремлендәге хуҗаларына ияреп, ялагайланып: «Соңгы елларда татарларның милли үзенчәлекләрен ныгыту һәм яңарту өчен башкарылган эшләрнең нәтиҗәләре тарихи үткәнебездә, Россия һәм дөнья халыклары арасындагы мөмкинлегебездә чагыла. *Әмма дәүләтне суверенлаштыру идеологлары һәм адептлары* (курсив минеке—Ә. Б.) күңелне күтәрәсе урында, киресенчә, төшерәләр генә» *(Р. Акчурин. «Татарский вопрос» в России».—Шанс. Февраль. 2002 г. № 3 (19).)*—дип белдерәләр.

Инде килеп, без дә урысның бер әкиятендәге мәет күтәреп баручы җеназачыларга: «Гел шулай армыйча күтәреп йөрегез»,—дип әйткән ахмакка тиң булабыз микәнни? Һай, көлке дә, кызганыч та! Югыйсә, һәр почмакта «ватаным»чыларның да, аларның Кремльдәге хуҗаларының да «озын колаклары» тырпаеп тора бирә. Татарларның бу «авторитетлыдан авторитетлы төркеме» хуҗаларының авыз ачып сүз әйтүен ишетү белән үк, татар милләтенә каршы төрледән-төрле өндәмәләр (мөрәҗәгатьләр) кабул итәргә һәм дә янә башка шуның ише пычрак-түбән эшләре белән милләтебез дошманнары тегермәненә су коярга өзер торалар.

Бүгенге вәзгыятьтә безгә нишләргә соң, ничек яшәргә?—Бездән шөбрәк яши торган халыклардан үрнәк алырга, аларга карап эш-фикер йөртергә кирәк!

Инде менә ничә гасыр буе кайсыбер урыспәрвәрләр Россияне югары, бөек рухи дәүләт итеп күрсәтергә тырышалар. Әле яңарак кына дөнья күргән бер китапта фәнне дин белән бәйләп, болай дип тә раслыйлар: «Кешелек дөньясын өченче меңъеллыкка Россия генә алып керәчәк. Аның бу миссиясе

моннан йөз ел элек үк инде Макс Гендель тарафыннан төгәл әйтелгән, күрәзә кылынган иде инде» *(Тихоплав В. Ю., Тихоплав Т. С., Физика веры, СП б. 2001 ел. 132 бит).* Шуннан соң укыйк: «Кояш Сукояр йолдызлыгы билгесенә кергәч, урыс халкы һәм славяннар рухи үсеш алачаклар һәм бу хәзергедән бик югары үсеш булачак. Славян цивилизациясенең күтәрелеше тиз, әмма дә бик якты һәм шатлыклы булачак, чөнки ул гаять тирән кайгы-газаплардан соң туа... Славяннар ария дәвереннән соңгы яңа халыкка әверелячәкләр. Славяннар цивилизациясе кешелекнең алтынчы расасы өчен нигезне төшкил итәчәк. *(Макс Гендель. «Космогоническая концепция». СП б. 1994, 242 бит).* Менә сиңа вәйт! Килсәң—кил, килмәсәң—ела, кем әйтмешли... Соң, әлеге фаразның халык кичерергә тиешле гаять «тирән кайгы-газаплары», дөрестән дә, чынга туры килә анысы... Славян цивилизациясенең нигезен төшкил итәсе Россия исә яртылашка калды, Югославия таркалды, аның коммунист-фашист җитәкчесе Милошевич хәзер төрмәдә ята, Польша, Болгария, гомумән Европадагы барча славян дәүләтләре дә, Россиядән тизрәк йөз чөереп, ЕЭС һәм НАТО әгъзалары булу көнен зарыгып көтәләр. Инде сезгә нинди кайгы кирәк тагын? Кешелекнең урыс рухыннан башка юкка чыгачагы турында әкият сөйләп, бөтен дөньяны көлдермәгез инде, господа!

Шөкер, татар милләте үзенең физик һәм психологик сәламәтлеген, урыслар белән чагыштырганда, барыбер күбрәк саклап кала алды. Аның аракы эчүе дә азрак дәрәҗәдә. Әмма баткаклыкка, фаҗигагә өстери торган бу эчүчелек дип аталган афәт татар менталитетына бөтенләй дә туры килми иде ләбаса. Татарга эчәргә ярамый.

Бүгенге көндә эчүчелеккә бирелгән меңләгән авыллар бар. Пролетариатның хәле дә мактанырлык түгел: гел махмырдан интегә. Соң боларның һәммәсе дә урыс дәүләте һәм православие дине калдырган мирас ләбаса. XVII гасырның икенче яртысында Россиядә булып киткән чит ил язучыларының язмаларына таянып, тарихчы Ключевский Мәскәүдә Пасханы ничек бәйрәм итүләре хакында болай дип яза: «Пасха атнасында байлар да, ярлылар да, ирләр дә, хатын-кызлар да күңел ачуның соңгы дәрәҗәсенә җитәләр (ягъни мәсәлән, егылганчы эчәләр) һәм бу вакытта аек фикерле беркем дә калмый. Эш туктала, бөтен кибетләр ябыла, бары тик кабак һәм бәйрәм итү урыннары гына ачык кала... Руханилар төре һәм иконалар күтәреп баручы малайлар белән бергә бәйрәм киемнәрендә урам буйлап чабышып йөриләр, туганнарына, дусларына кереп, алар белән исергәнче эчәләр. Кайсы гына якка карасаң да, исерек ир һәм хатыннарны гына күрәсең... *(В. О. Ключевский, «Сказание иностранцев о Московском государстве». М. 1991. 8-9 бб.).* Әле минем хәтеремдә: узган гасырның егерменче елларында авызына тәмәке кабып урамга чыгарга җөрьәт иткән зимагурларны авыл аксакаллары карары буенча таяк белән суктыралар иде. Ул чагында әле миңгә бер генә очрый торган аракы эчүчене кешегә дә санамыйлар иде. Хәзер исә «старший брат»ның начар гадәтләрен үзеннән дә уздырып кабатламыйбызмы, җәмәгать?! Урыста шәхси милекчелеккә каршы мөнәсәбәт яшәп килә. Ул аның канына сеңгән. Урыс бар булмыш милкәтен дә сатып эчәргә сәләтле. Ташландык, җимерек, салам түбәле (XXI гасырда!) урыс авыллары әле хәзер дә бар...

Без, татарлар, киресенчә—милекчеләр милләте! Шәхси милекчелек, базар мөнәсәбәтләре тантана иткән заманда яшибез икән, моннан һич кенә дә курыкмаска кирәк. «Кем заманы?»—дигәндә: «Безнең заман!»—дип яшик.

Бу җәһәттән, татарлар Россияне бик күп икътисади-сәяси бәлаләрдән йолып, коткарып кала алырлар иде. Начар үрнәк иярә, ә яхшысы файдалы була. Безгә дә үрнәк күрсәтергә вакыт җитте, җәмәгать!

Югарыда әйтелгән фикерләрдән соң, ниһаять, кире кагылмаслык төпле бер нәтиҗәгә килергә була: милләтебезне, димәк, телебезне, динебезне, мәдәниятебезне, иң яхшы гореф-гадәтләребезне, сәләтебезне, акылыбызны сакларга-җуймаска кирәк, ИРЕК һәм МУЛЛЫК өчен алга барырга кирәк!

* * *

РОССИЯНЕҢ Дәүләт Думасы башлыгы Г. Селезнев үзләренең тәүбә итәрдәй гөнаһлары юклыгын белдергән иде. Бер гаепсез дистәләрчә миллион кешене җәзалап юк итү, дәүләтне бөлгенлеккә төшерү, милләтләрне җәберләү,

бер-берсе арасына чөй кагарга маташу, халыкны махсус әчертү—болар яхшы гамәлләрмени?!

Россиянең бар халкы да бөек урыс галиме Д. Лихачев (инде мәрхүм) тәкъдим иткәнчә тәүбә кылырга тиеш. Әмма бу тәкъдимне Т. Абуладзедан гайре (бу грузин кинорежиссеры өлеге сюжет буенча искиткеч тирән мәгънәле «Покаяние» нәфис фильмы төшерде) беркем дә ишетмәде һәм ишетергә дә теләмәде.

Бүген исә урыс халкына һәм православие дине чиркәвенә, батырлык туплап, Россиядәге башка халыкларга да үрнәк күрсәтеп, тәүбә итәргә, озын-озак еллар буена җыелып килгән гөнаһларыннан арынырга тырышырга кирәк. Тәүбә итмәү, тәүбә итәргә теләмәү баткак тормышта калуны һәм алга таба да яңа гөнаһлар кылырга әзер булуны аңлата.

Бүген безгә—татарларга, православие чиркәвенең иерархлары зур куркыныч тудыра. Беренчедән, алар дәүләт тарафыннан ачыктан-ачык якланган диннәрен монополияле дәүләт дине итеп күрсәтеп, башка гомумроссия конфессияләрен игътибардан читкә юнәлтергә маташалар. Икенчедән, алар католик—христианнар белән аралашырга, эш йөртергә теләмичә, үз чиркәве кылган гөнаһлар өчен бөтен дөнья алдында гафу үтенеп башка конфессияләргә үрнәк күрсәткән Иоанн Павел II гә кимсетеп карарга тырышалар. Урыс чиркәве бүген «Чит кешеләр курыксын өчен, башта үзеңнекеләрне кыйна»—дигән борынгы гыйбарә белән эш итә. Мөселман татарларын әзәрлекләүдә, кысуда да аның тәҗрибәсе гаять зур. Коточкыч зур! Урыс чиркәве элек-электән үз ягына татар морзаларын аудару, сатып алу белән дә шөгыльләнде. Бу эш хәзер дә алар өчен уңышлы бара...

«Ташларны ата торган заман булды. Хәзер ул ташларны җыяр чак та килеп җитте»—Кешелек цивилизациясенең төп юлы шундый.

## 3. Россия белән яңа мөнәсәбәтләр: хокук, үзара татулык һәм килешү!

КАЗАННЫ яулап алуга 450 ел тула (1552 елның 15 октябре—2002 елның 15 октябре). Бу датаны Татарстан һәм Федераль Үзәкнең уртак тырышлыгы белән «Татулык һәм килешү көне» итеп билгеләү урынлы гамәл булыр иде. Казанны алганда һәлак булган сугышчыларга торгызылган һәйкәлне төзәтү-яңарту белән бергә Казанны саклап башларын салган фидаи татар яугирләренә дә лаек һәйкәл булдырырга кирәк! Урыс әсирлегендә вафат булган Сөембикә-ханбикә һәм аның улы Үтәмеш Гәрәйнең сөякләрен Казан Кремленә алып кайтып, хөрмәтләп изге җиребез куенына тапшыру да бик тә гадел гамәл булыр иде. Бу тарихи вакыйганы искә алуны татар һәм урысның бер-берсен гафу итү акты белән тәмамлау да фарыз. Бит киләчәктә барлык көч-дәрманны бердәм, уртак Ватаныбызны төзүгә багышлыйсыбыз бар. Бу җәһәттән, иң мөһиме—Татарстанны Россиянең ассоциацияләнгән статусына ия әгъзасы итеп беркетү бик тә зарур. 1994 елдагы мәгълүм Шартнамәгә нигезләнгән бу хокукны үтәү-үтәтү безнең төп таләпләребезнең беренчесе! Татар милләте бу вассал бюрократия илендә бер ятим гыйбад булып яшәргә теләми! 1992 елгы референдум аның мөстәкыйль яшәргә теләвен ап-ачык күрсәтеп бирде. Халык теләгән санга сукмау—үзе җинаять. Әгәр дә Россия белән идарә итүче бюрократлар безнең таләпләребезне үтәргә теләмәсәләр, безгә инде Россия белән башкачарак мөнәсәбәттә булырга туры киләчәк. Үтәлмәгән таләпләр безне халыкара демократиянең хокук институтларына махсус Мөрәҗәгать белән чыгарга мәҗбүр итәчәк.

Шунысы бәхәссез: кыргый тоталитаризм дәвере үтте һәм инде ул кире кайтмаячак!

## Мәгъсүм Гәрәев

# СОЛТАНАТЛЫ ГЕНЕРАЛ

АНЫҢ ЯКТЫ йөзендә, акыллы күз карашында, хәтта кашларының уйнаклашып өскә таба тилпенүләрендә дә тирән фикерләр чагылып киткәндәй тоела. Йомшак, ягымлы тавышы, мәгънәле, уткен сүзләре кешеләргә гаҗәеп дәрәҗәдә нык тәэсир итә. Бөтен килеш-килбәте, гәүдәсенә ятып һәм бик тә килешеп торган җыйнак һәм зәвыклы өс-башы бу кешенең тормыштан үзенә бер тәм, үзенә бер ямь табып, гомер сөрүнең кадерен белеп яшәвен күрсәтә. Коңгырт кара күзләре сине кеше буларак санга алып, хәтта якын итеп елмая. Күзләре өстендә бөркәү булып асылынып торган калын кара кашлары сөйләшкәндә әледән-әле селкенеп куя, әлеге мизгелләрдә бу зыялы кеше аеруча шат һәм сөйкемле булып күренә. Аның белән үз гомеремдә беренче мәртәбә очрашып, гәп корып җибәргән кешегә дә яхшы аңлашыла: интеллект көчле, дөньяга караш киң.

Кем соң ул мондый асыл зат?

Генерал-полковник Рәсим Акчурин, йөрәккә операция ясаучы—атаклы кардиохирург Ринат Акчуринның абыйсы.

* * *

КИЧ БУЕ матур, якты, җиңел һавалы булып торган бу иркен бүлмә кинәт кенә моңсулана, күңелсезләнә башлады. Инде төн уртасы, аерылыр вакыт җиткән. Әмма безнең сөйләшеп сүзләр бетмәс шикелле. Тукай-Кырлайдагы «Шүрәле» кафесыннан чыгабыз. Юлларыбыз аерыла. Машиналарга утырганчы, сүзсез генә бер-беребезгә карашып торабыз. Ямансу булып китте. Төнге тынлыкны Рәсим бозды, ул арабызда иң өлкәне.

—Сау-сәламәт булыйк, туганнар! Очрашуыбыз кыска кебек тоелса да, безнең танышлык озын гомерле булсын!—дип мәгънәле итеп әйтеп куйды ул.

Хәрби эштә пөхтә булган шикелле, сүздә дә кыска, асылын гына сөйли бит генерал дигән уй йөгереп үтте күңелемнән. Барчабыз да, аның белән теләктәш икәнлегебезне раслап, башларыбызны идек һәм ике куллап саубуллаштык.

Рәсим Акчурин Ташкент өлкәсендәге Зәнгиатя авылында 1932 елның 3 гыйнварында туган. Аның әти-әнисе Пенза якларыннан, укытучылар. Әнисе Тәзкирә башлангыч классларда укыткан, әтисе Сөләйман—географиядән, тарихтан. Сөләйман абый мәктәп директоры була, Әндиҗан өлкәсенең мәгариф бүлеге мөдире дәрәҗәсенә күтәрелә.

—Әнкәй карчык гомере буена үзбәкләргә чисталык һәм пөхтәлек белән үрнәк булып торган хатыннардан иде,—ди Рәсим.—Әтием исә кешене егетләндерә торган нәрсәнең фән булуына тирәннән инанган гыйлемле кеше иде. Әти-әниебез мине дә, энем Ринатны да бала чагыбыздан ук гыйлем алуның искиткеч түземлелек сорый торган, авыр эш икәнлегенә төшендерделәр. Гыйлем алу—энә белән кое казу, ди бит татар. Без моңа тугрылыклы идек. Әти-әниебез сиксәннең теге ягына чыккач, 1991 елда вафат булдылар: әти—гыйнварда, әни—июльдә. Бу югалтуларны без бик авыр кичердек. Без бер нәрсәдән канәгать: әти-әниебез улларының һәм оныкларының кем икәннәрен үз күзләре белән күреп киттеләр.

Рәсим һәм Ринатның атаклы фабрикант Акчуриннар белән туганлык мөнәсәбәтләре юк. Алар фамилиядәшләр генә. Әмма нәсел аң-белемле, затлы. Әйтик, генералның әнисе ягыннан бабасы Кыям—авыл мулласы, әбисе Мөхәммәтҗан байлар нәселеннән. Әтисе ягыннан бабасы Сафи шулай ук үз

заманының укымышлы кешесе булган. Генерал зыялылыгының, интеллектының чишмә башы менә кайдан икән! Татар телен, татар тарихын, татар әдәбиятын, татар сәнгатен әйбәт белүнең серләре, тамырлары әти-әнисенә генә түгел, әби-бабаларына ук барып тоташкан. Гаиләдә тәрбия, сөйләшү татар телендә бара. Рәсим туган телен саф белүен, татарча иркен сөйләшүен бабасы Кыям хәзрәт хезмәте, дип фараз кыла.

Рәсим яшьлегендә автомобильләр конструкторы булу турында хыяллана. Теләгенә ирешү өчен ул Ленинград политехника институтына укырга керә. Андагы фәннәргә әйбәт кенә кереп тә китә. Икенче курста көйле-җайлы гына укып ятканда, тәртипле, буй-сынлы, сәламәт егетләрне ВЛКСМның Выборг район комитетына чакыра башлыйлар. Армиягә офицерлар җитми икән. Студент егетләрне комсомол юлламасы белән хәрби училищеларга туплыйлар. Заман модасы, сугыштан соңгы елларда офицерларның дәрәҗәсе зур иде. Рәсим дә кызыга ялтыравыклы погоннарга, күн итекләргә, йолдызлы фуражкага. Шулай итеп ул зенит-артиллерия училищесы курсанты булып ала. Монда тәртип нык, укытучылар катгый. Ошый бу Рәсимгә, полковник-генераллар аның хәрби хезмәткә талантын күрәләр. Акчурин, училищеда өч кенә ел укый, аны гел бишкә генә тәмамлый һәм лейтенант погоннары тагып, 1954 елда әти-әнисе янына Әндиҗанга кайта.

—Кара-кара, әнисе, безнең малай түгелме соң бу? Офицер, лейтенант,— дип каршы ала әтисе Сөләйман ага ирләрчә сабыр гына.—Өстеңә хәрби кием киеп алгансың икән инде, улым, яхшы хезмәт ит! Хәрби антыңа тугрылыклы бул. Акчуриннар нәселенә тап төшерәсе түгел, иптәш лейтенант!

Бу гаиләдә ата сүзе—закон. Рәсим, хәрбиләр гадәте буенча, килешле генә итеп үкчәләрен бәреп, кулын күтәреп честь бирә:

—Әти, син дигәнчә булыр!..

Сөләйман абый лейтенант улының килешле, пөхтә өс-башына сөенә, күркәм йөзеннән күзен алмыйча сокланып озак карап тора. Улының килешкилбәте шактый җыйнаклана төшкән. Әмма моның белән генә эш бетми бит. Кешенең матурлыгы эшенә карап арта. Башы исән булсын, үсәр, ныгыр, әтисе кебек дәрәҗәләр алыр. Яшь солдатларга, үзе шикелле училищедан чыккан офицерларга күпме акыл бирәсе, хәрби хезмәткә өйрәтәсе бар әле улының! Үзеңнән югарыларны узып китәргә тырыш, менә шул чакта булырсың син егет!

Педагог ата ялгышмаган. Улы яшьлегенең, күктә янган йолдыз кебек, якты булачагын егерме-утыз елга алдан күргән.

Урта Азиядәге хәрби частьләрдә унбер ел хезмәт иткәч, Рәсим кулына янә уку әсбаплары ала. Сөләйман абый уйлаганча, яшьләргә акыл-киңәш бирү өчен училище белеме генә саерак икән шул. Рәсим Акчурин—Маршал Жуков исемендәге һава һөҗүменнән саклану академиясе тыңлаучысы. Биш ел дәвамында хәрби сәнгатьнең халык өчен сер булып кала торган яшерен кылларын чиертә. Шушында укыганда подполковник Акчуринның хәрби хезмәттәге аерым сәләте һәм таланты ялтырап-ялтырап китә. Шуның бер чагылышы буларак, яңа гына укуын тәмамлаган офицерны полк командиры итеп билгелиләр. Бу—СССР Кораллы Көчләре тарихында күрелмәгән хәл, Совет Армиясендә сенсация. Академияләрне тәмамлаучыларның урыны командир урынбасарыннан ары киткәне юк иде әле. 1970 елда Акчуринга ышаналар, ул-теләге яхшы, изге аның, юлсыз юлда да адаша торган командир түгел ул. Йә, татар кешесе, татар офицеры! Кем син? Күрсәт, таныт үзеңне, талантыңны ач, хыялларың диңгезендә йөз!

Командир меңнәрчә хәрбиләрнең язмышларын хәл иткәндә катып беткән трафаретларга ябышып ятмый. Саный китсәң, хәрби эштә Акчурин ярдәмендә үзләренең туры юлларын тапкан офицер егетләр аз булдымыни?! Моны Оборона министрлыгында җаваплы эшләрдә утырган генераллар, маршаллар да күрә башлый. Өч ел дигәндә ул подполковниктан генерал-майор дәрәҗәсенә күтәрелә, корпус командующие итеп күчерелә. Монысы да елы тулып, чираттагы чин алу гына түгел, булдыклылык, талант эше.

Ә дөнья куласа: әйләнә дә бер баса, ди татар мәкале. Хәрби эшләр шулай көйле-җайлы гына барган бер вакытта, «хәтсез тәгәрмәч, зур чарык» Рәсимне таптап китәргә йөри икән бит әле. Акчуриннар гаиләсенә бәхетсезлек килә:

хатыны Сафия ханым капылт кына вафат була. Ярославль зиратында җирлиләр аны. Рәсим үзе дә, улы, хәрби училище курсанты Марат та, җиденче класста укучы кызы Римма да 1977 елда булган бу фаҗигане бик авыр кичерәләр. Гаилә учагы суына. Күңел түрендә, йөрәгендә изгелек, игелек чаткысы йөрткән кешегә Раббым мәрхәмәтсез түгел бит ул. Рәсимнең үзе төсле кешелекле бәндәләре бетмәгән аның. Тормышының авыр чоры турында сөйләгәндә, генералның тыны кысыла, бугазына төер тыгылган күк була. 1985 елда ул—генерал-лейтенант, Мәскәү Хәрби округының һава һөҗүменнән саклану зенит-ракета гаскәрләре командующие. Тагын ике елдан шундый постны ул СССР Оборона министрлыгы күләмендә били. Татар милләтеннән булган хәрби кеше өчен бу—үтә дә зур урын. 1990 елда аны янә бер баскычка югары күтәреп куялар. Рәсим Сөләйман улы Акчуринга генерал-полковник дәрәҗәсе бирелә.

1992 елда, 60 яшен тутыргач, ул отставкага чыга. Полководецлык таланты чикләнмәгән хәрбиләрнең генә армия тормышы менә шулай озын була.

Акчуриннар турында минем күп ишеткәнем бар: Рәсим дә, Ринат та халыкка билгеле шәхесләр. Ләкин якыннан аралашып күңел түрендә яткан сүзләремне әйтә алмый йөри идем. Ниһаять, теләгемә ирештем.

Без 2000 елның 9 июнендә очрашып, төрле шартларда сөйләшеп, фикер алышып йөрдек: Казанда гына түгел, Арчада, Тукай-Кырлайда—музейда, мәҗлестә, Мирҗәмдә—мемориаль ачканда, авыл Сабан туенда... Бар гамәлебез халык арасында иде. Әйе, үз халкын, үз милләтен хөрмәт иткән, олылый белгән кеше, бөек Тукай туган Арча яклары белән күрешми китә алмый.



*Арчаның Мирҗәм авылында Советлар Союзы Герое Нәкыйп Сафинга һәйкәл ачу тантанасында. Сулдан-уңга: Арча районы хакимияте башлыгы Илһам Сабиров, Дамир Сафин, генерал-полковник Рәсим Акчурин, Мәгъсум Гәрәев, Арча районының хакимияте башлыгы урынбасары Ринат Фазлыйәхмәтов. 2000 ел.*

Ул көннең вакыйгасы нинди иде әле! Арчада, Америка Кушма Штатларыннан, Финляндиядән, Төркиядән, Үзбәкстаннан эшлекле кунаклар бар. Татарстан, Россия күләмендә билгеле шәхесләр никадәр! Барысын да тантанага, кунакка Дамир һәм Данил Сафиннар чакырган. Зурлап җыелуның асылы шул: Мирҗәм—Советлар Союзы Герое Нәкыйп Сафин туган авыл. Ул—озак еллар шушы тирәдәге авылларны берләштергән «Северный» совхозы директоры булып эшләгән, халыкка әйтеп-санап бетерә алмаслык игелекләр кылган кеше. Нәкыйп Сафи улының балалар тәрбияләүдә дә гыйбрәт алырлык эшләре байтак. Уллары Дамир һәм Данилгә төпле һәм зур белем алу мөмкинлеге тудыру өчен, ул үзенә олы дан китергән туган якларыннан Юдинога күчә. Таралып беткән совхозны аякка бастыру эшенә алына. Монысы—аның уллары киләчәге хакына кылган батырлыгы. Сугышта каһарманлык күрсәткән кыю кеше Юдиноны торгызуда да тиңдәшсез фидакарь җан була. Аны Социалистик Хезмәт Герое исеменә тәкъдим итәләр. Әмма документлар ЦКда кире беткән түрә кулына эләгә. «Советлар Союзы Героена Ленин ордены да бик җиткән»,—дип язып куя тәкъдим кәгазе почмагына. Нәкыйп Сафинга бирелəсе исемне шушы сүзләр хәл итә дә куя.

Генерал-полковник Рәсим Акчурин, генерал-майор Алексей Бобровның Татарстанга, Арча якларына кайтып төшүе—Нәкыйп Сафинның сугышта һәм тынычта легендаларга кергән эшләрен зурлап бәяләү, татар халкы каһарманына чиксез ихтирам һәм хөрмәт билгесе иде ул. Дамир белән Данил да,

әтиләре кебек, иркен күңелле, эшсөяр, һәр нәрсәнең җаен, рәтен белүче, көлдән төймә тәяргә сәләтле, уңган егетләр. Баланың ата-ана алдындагы бурычын үтәүнең шаккатырлык үрнәген күрсәттеләр. Дамир Сафин Нью-Йорктта яши, үзенең фирмасы бар, кибет ачып җибәргән. Витринасына «Чаян» журналын һәм «Мәдәни җомга» газетасын алып китеп куйды. Күрсеннәр Америкада яшәүче милләттәшләребез! Мирҗәмдә әтиләре хөрмәтенә корган мемориаль үзе ни тора! Нәкыйп Сафинның бронза бюсты, аның уң ягында Мирҗәмдә туып-үскән Социалистик Хезмәт Геройлары Галимулла Әсхәдуллин һәм Дания Галимова барельефлары, сулда Бөек Ватан сугышы кырларында ятып калган авылдашларыннан 102 кешенең исем-фамилияләре алтын хәрефләр белән уелган. Мемориальга сәнгать әсәре дәрәҗәсендә салып куелган зиннәтле мәчет һәм парк та керә. Шушы корылмаларга Дамир Сафин 170 мең доллар тоткан.

... Әнә микрофон янына Рәсим Акчурин килә. Ягымлы, күңелгә якын матур сүзләр белән саф татарча сөйли башлый. Туганнары белән сөйләшкән кебек. Гомер буе русча укып, башка милләт кешеләре белән русча аңлашып та, туган телен онытмаган безнең зыялыбыз! Халык моңа чиксез шат.

—Каһарман Нәкыйп Сафинның уллары Дамир һәм Данилның бу эшләре—бөтен татар халкына үрнәк. Тантанада Татарстанның зур-зур җитәкчеләре дә катнашырга тиеш иде. Бүгенге гамәл—яшь буынны тәрбияләүдә иң үтемле, иң күркәм чара, Россия тарихына да керерлек вакыйга. Кызганыч, республикада моңа тиешле бәя биреп җиткермәгәннәр...

Генерал Татарстанга сугыш ветераннарына тапшыру өчен маршал Жуковның якты истәлеге хөрмәтенә чыгарылган медальләр алып кайткан. Мәскәү мэры Юрий Лужковның махсус-бүләкләре дә бар. Шуларның берсе—Мәскәүнең 850 еллыгы уңае белән чыгарылган истәлек медале. Ул аны Арча районы хакимияте башлыгы Илһам Сабировка тапшыра: район талантларының башкалада үтә торган чараларда актив катнашуының ядкаре бу. Юрий Михайлович Акчуринга тагын бер бүләк биреп җибәргән—башкала сәгате. Анысы сатуга чыгарылмаган икән. Ул мэрия карары нигезендә аерым шәхесләрнең хезмәтләрен искә алып тапшырыла. Бик затлы һәм матур сәгатьне Рәсим Сөләйман улы миңа бүләк итте.

Миңа Юрий Лужковның татар генералын хөрмәт итүе күптәннән мәгълүм. Мәскәүдә хәрби-патриотик һәм гражданлык тәрбиясе үзәге оештырыла. Аның директоры итеп Рәсим Акчуринны билгеләү идеясе Лужковның үзеннән чыга.

Бу шәхесләр Мәскәү хакимиятендә еш очрашалар. Берсендә Юрий Михайлович, Мәскәүдә ничә мең татар яшәвен белергә теләп, Акчуринга сүз ката.

—Рәсим Сөләйманович, Мәскәүдә күпме татар бар? Дөресен генә әйт әле,—ди хаким.

—Соңгы тапкыр халык санын алу мәгълүматларына караганда, 180 мең. Бу—рәсми сан,—ди Акчурин.

—Минем уйлавымча, ярты миллионнан артык,—дип каршы төшә Лужков.

—800 мең. Бик тә төгәл беләсегез килә икән, анысын да әйтәм. Мәскәүдә 1 миллион 200 мең чамасы татар яшәп ята,—дип төзәтә мэрны генерал.

—Нидән чыгып әйтәсез?

—Юрий Михайлович, Сезнең беренче урынбасарыгыз Эрнест Бәһировның паспортына татар дип язылган. Ике энесенә рус, дип язганнар. Мондыйларның исәбе-саны юк!..

Мәскәү хакиме уйга кала. Урынбасарларының берсенә татарлар проблемалары белән шөгыльләнү эшләрен тапшыра. Башкалада татар мәктәбен, татар классларын ачу, мәчет төзелешен җәелдерү кебек эшләрне оештыру башында торучыларның берсе—генерал Акчурин. Сүз уңаенда Рәсим Сөләйман улының минем авылдашым, Шаледә Зәйтүнә апам укыткан Равил хәзрәт Гайнетдин белән аралашып, хезмәттәшлек итеп яшәүләрен дә әйтеп китим әле. Ел саен Измайлов паркында Сабан туен үткәрүдә Рәсим Акчуринның хезмәте әйтеп бетергесез зур.

Сабан туе дигәннән, 2000 елда генералның Татарстанга кайтуы республикабыз авылларында милли бәйрәмебез көннәренә туры килде. Ат чабыш-

ларын үлеп ярата икән ул. Миржәмдә бөтерчек хәтле генә малайларның атка атланып йөрүләрен күреп шаккатты, аларның кыюлыгына сокланды.

—Алар чабышларда катнашмый торгандыр бит?—дип Рәсим абыйлары.

—Катнаша,—дибез.

—Алайса, карарга барыйк!

Ат өстендә башлары гына калкып торган малайлардан күзләрен алмыйча, дулкынлана-дулкынлана күзәтте ул тегеләрне. Малайлар да, алар атланган чабышкылар да генерал карап торганын сизә, күрәсең. Сынатасылары килми. Дамир абыйлары Сафинның шундый җитезләр өчен алып кайткан аерым бүләкләре бар икән. Чистайда эшләтеп алынган бик матур сәгатьләр. Истәлек бүләкләрен тапшыру өчен сүзне генералның үзенә бирделәр. Ат өстеннән төшмичә генә бүләк алучылар кем дисезме? Шурабаш авылыннан Раил, дүренче класны тәмамлаган, аның абыйсы Рамил, җиденчегә күчкән. Зоотехник Шамил Шакиров малайлары. Туган авылында, бар халык алдында генерал булып генерал-полковник кулыңны кысып сәгать тапшырсын әле! Гомергә онытылмаслык вакыйга бу. Менә нинди кече күңелле, малай җанлы аларның Рәсим абыйлары. Авыл Сабан туен беренче мәртәбә күрүе икән, тәэсирләре ташып түгелер хәленә җиткән. Дәһи шагыйребезнең Тукай-Кырлайдагы музее залларында һәр экспонат алдында башын иде кунагыбыз. Бөек балерина, СССРның халык артисты, Ленин бүләге лауреаты Майя Плисецкаяны Казан артындагы татар авылында очратырмын дип беркайчан да уйламаган булган ул. Биюченең үз куллары белән язган хаты куелган монда. Майя Михайловна Тукайның «Шүрәле» поэмасына, Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетына соклануын белдереп яза. Сөембикә булып бию белән горулана. Музейда Плисецкаяның Мәскәүдә, Зур театрда Сөембикә ролендә төшкән фоторәсеме дә бар. Шатлана мәгърур генерал үз милләтенең талантын тануларына.

Рәсим Акчурин Татарстан җирендә ике көн булган чагында бик матур һәм җаваплы вазифа да үтәп йөрде. Юрий Лужков генералга, Мәскәүдәге татар җәмгыяте җитәкчесенә, Татарстанда яшәүчеләргә Мәскәү халкының кайнар һәм эчкерсез сәламнәрен тапшырырга кушкан.

* * *

... 2000 ЕЛНЫҢ 29 августы—Татарстан Дәүләт Советының тарихи сессиясе булган көн. Ул Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителүгә 10 ел тулуга багышлана. Миңа калса, бу сессия егерменче йөздә татар тормышында иң мөһим вакыйгаларның соңгысы булды бугай. Утырышлар залына күз салам. Хөрмәтле кунаклар арасында кемнәр генә юк! Мөгаен, бөтен дөньяда танылганнары һәм иң талантлылары Тәзкирә апа белән Сөләйман абый Акчуриннар уллары дыр! Рәсим—зенит-ракета гаскәрләрендә катлаулы теоретик мәсьәләләрне тормышка ашырган кыю генерал-полковник, Мәскәү татарлары автономиясе президенты, аның энесе Ринат—президентлар үз йөрәкләрен ышанып тапшыра торган мәшһүр хирург. Акыл, гыйлем ягыннан тиңдәшсез затлар.

—Икенче хатыным Фәүзиямнән дә ундым. Гаилә җанлы кеше. Үз тормышы да минеке шикелле кителеп калган булган,—дип сөйләде ул көнне Рәсим миңа.—Безне рус милләтеннән булган дусларыбыз очраштырды, кавыштырды. Аның да элекке иреннән Илнур атлы улы бар иде. Мин аны уллыкка алдым. Аннары үзебезнең Тимурыбыз туды. Аллага шөкер, балаларыбыз тәүфыйклы. Безнең өйдә үги ана, үги ата юк. Бу—зур бәхет.

Мин балаларның язмышы белән кызыксынам. Бу минутларда ата мәгърур елмая. Аның мавыктыргыч итеп сөйләве кызыклы бер хикәягә тиң.

—Марат минем юл белән китте, хәрби кеше, хәзер—полковник, бригада командиры. Риммабыз—әниләре һөнәрен сайлады, табибә-терапевт. Илнурыбыз—замана баласы, эшкуарлык юлыннан бара. Тимурыбыз укый әле, Илнур артыннан китәр, ахрысы.

## Фоат Галимуллин

# ОЛЫ ЮЛНЫҢ ЮЛЧЫСЫ

АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Казаннан нәкъ йөз чакрым ераклыкта борынгы Болгар чорларыннан ук яшәп килүче Саба авылы бар. Ул XIV йөздә иҗат ителгән данлы «Идегәй» дастанында ук телгә алына:

Изге шәһре Болгарны,
Астаналы Суварны,
Капкасы биек Казанны,
Чулпандагы Җүкә Тау,
Урмандагы Сабаны...

Район үзәге булган шул авылда 1932 елның 13 октябре көнне район советы сәркатибе Гыйльмулла Әхмәдуллин гаиләсенең беренче баласы туа. Ана Азат дип исем кушалар.

Бераздан район газетасы мөхәррире итеп билгеләнгән Гыйльмулла Әхмәдуллинга гаиләсе белән бер төбәктән икенчесенә күченеп йөрергә туры килә. Чөнки ул елларда житәкчеләргә бер урында гына озаклап эшләргә ирек бирмиләр (бу—үзенә күрә бер сәясәт). Гыйльмулла абзый Сабадан соң Кызыл Армия, Кукмара районнары газеталарының мөхәррире була. Ул елларның репрессияләре шаукымы ана да кагыла: Кукмара районы гәзите редакторын корткычлыкта гаепләп кулга алалар. Төрмәдә уздырган 3 ай турында, андагы тәртипләр (дөресрәге—тәртипсезлекләр), Кави Нәҗми белән очрашулары турында ул соңыннан өч улына һәм кызына кат-кат сөйли. Төрмәдән дә үзенең тапкырлыгы һәм нык торуы аркасында гына котыла. Тикшерүчегә: «мина яга торган менә бу «гаепләрне» мин сезнең кушуыгыз буенча эшләдем, дип әйтәчәкмен», ди ул. Гаепсезлеге расланган Г. Әхмәдуллинны Тархан районы газетасы мөхәррире итеп жибәрәләр. Олы Тархан авылында Азат беренче сыйныфта укый. Әйбәт укый, шуның өчен аңа «ерык иренле куян» турындагы китап та бүләк итәләр әле...

Бөек Ватан сугышы башлана. Азатның әтисе беренче көннәрдә үк үзе теләп фронтка китә. Кавалериядә кулы яралангач пехотада хезмәт итә, «Батырлык өчен» һ. б. медальләр белән бүләкләнә. Старшина дәрәҗәсендә, икенче группа инвалид булып, 1945 елның кышында гына Сабага кайтып төшә ул. Аннары Саба район газетасы редакциясендә, башка төрле эшләрдә...

Ә бу вакытта Азат Саба урта мәктәбендә укый. Җәйләрен колхозда атлар

кɵтə, элеваторга кырдан ашлык ташый, тɵннəрен ашлык суктыруда, Саба МТС ында комбайнда... Укуы əйбəт бара. Һəртɵрле җəмəгать эшлəрендə актив катнаша. Əйтик, 1 май, Октябрь бəйрəмнəрендə трибунадан балалар исеменнəн «бɵек Сталинга», «җиңүлəрдəн җиңүлəргə алып баручы партиягə» рəхмəт сүзлəрен русча җиткерүне (саф татар авылында митинглар русча бара!) Азатка тапшыралар. Һəм ул русчаны вата-җимерə булса да «ышанычны аклый». Вакыты җиткəч пионерга, аннары комсомолга керə. Монда да актив була, шунын ɵчен аны 1948-49 елларда ВЛКСМ нын Саба райкомы пленумы əгъзасы итеп тə сайлыйлар...



Азат кечкенəдəн үк музыкага һəм сəхнəгə тартыла. Гармуннары булган тɵрле гаилəлəргə йɵреп гармунда уйнарга ɵйрəнə, курайлар ясап җенлəнə. Анын бу тыелгысыз омтылышын һəм мавыгуын күргəн Гыйльмулла абзый белəн Дилшатбану апа, соңгы акчаларын җыеп, немецлардан трофей буларак кайткан кечкенə аккордеон сатып алалар. Менə шуннан китə инде... Мəктəптəге, сонга таба район үзəгендəге бер генə үзешчəннəр концерты да, җырлы-биюле кичəлəр дə Азаттан башка узмый. Клубта кино башланыр алдыннан микрофон аша тамашачыларнын күнеле ɵчен кɵйлəр дə суза (сонынна мəгълүм була: монын ɵчен ана район мəдəният бүлеге акча да «биреп барган» икəн, тик ул Азат кулына керми, кемнəрнендер кесəсендə югала. Əбит бу бик тə мохтаҗлык чоры: ɵс-баш начар, мəктəптə уку да ул елларда түлəүле, монысы да дүрт балалы гаилə бюджетында бик нык сизелə).

Татар музыкасына Хɵснулла һəм Аллаһияр Вəлиуллиннарны биргəн Сабада əле сугышка кадəр үк тынлы оркестр оештырыла. Анын традициялəре шактый үк нык булган күрəсен, музыкаль инструментлар да сакланган. Һəм менə оркестр янадан оештырыла. Азат беренче кɵннəрдəн үк анда йɵри, тиз арада нота танырга ɵйрəнə. Сəлəтен күреп, ана беренче трубада уйнауны ышанып тапшыралар. Оркестр тɵрле тантаналы кичəлəрдə, Сабан туйларында, кичке күнел ачуларда чыгыш ясый, күрше авылларга барып уйный...

Əйе, яшь егетнен музыка белəн мавыгуы шактый үк кɵчле була. Ул балалайкада, гитарада, үзе ясаган курайда, сонрак пианинода да əйбəт кенə уйнарга ɵйрəнə. Əбит боларнын барысы да—мɵстəкыйль рəвештə, үзлегеннəн...

Мəктəп елларында Азатнын тагын да бер яраткан шɵгыле—китап уку була. Матур əдəбият белəн «җенлəнгəн» малай район китапханəсендəге, Саба урта мəктəбендəге, район газетасы редакциясендəге китапларны күп укый. Бигрəк тə редакциядəге китаплар ошый ана, чɵнки анда латин хəрефлəре белəн татар һəм башкорт телендə басылган китаплар сакланган була. (Əбашка китапханəлəрдə, татар язуы кириллицага алыштырылгач, андый китаплар җыеп алына, юк ителə.) Латин шрифтын һəм башкорт телен шулар аша ɵйрəнə малай, алар анын ɵчен серлерəк тə тоела...

Шулай ук рус телендəге китаплар да Азат ɵчен мавыктыргыч була. Ят тел, анлап булмый, ə укыйсы бик килə. Саба—саф татар авылы, анда ул вакытта бары ɵч кенə рус гаилəсе яши, алар да гел татарлашып беткəннəр: татарча аралашалар, җырлыйлар, хəтта сүгенүлəре дə татарча... Тагын—укучылары анламаганда татарчага күчеп анлата торган ике рус теле укытучысы... Шулардан бигрəк тə Анна Ерофеевна Даниловага рəхмəтле Азат. Чɵнки ул укучыларына рус телен ɵйрəтүгə вакытын һич кызганмый, аларны кичлəрен «кружокка» җыеп, былиналар һəм əкиятлəр укыта, русча анларга ɵйрəтə. Укытучыларынын һəм үзенен дə тырышлыгы бушка китми, Азат русча китапларны да анлап һəм күплəп укый башлый. Ана бигрəк тə Жюль Вернныӊ мажаралы романнары ошый...

Театр һəм драматургия белəн мавыгу да шул яшьлек елларында ук башлана. Сабага эшкə егерменче-утызынчы елларнын танылган артисткасы Рокыя Кушловская килə. Шуннан сон район үзəгендə спектакльлəр кую, концертлар оештыру тагын да җанлана тɵшə. Авылларга агитбригадалар еш чыга башлый. Боларда гармунчы буларак та, үзешчəн артист тɵсендə дə Азат актив катнаша. М. Фəйзинен «Ак калфак»,

М. Әмирнең «Хужа Насретдин колхозда» исемле пьесалары нигезендә куелган спектакльләрдә Р. Кушловская кебек сәхнә остасы белән янәшә торып уйнау аның театр сәнгатенә булган омтылышын тәрбияли һәм ныгыта.

Саба урта мәктәбендәге аерата хөрмәт ителгән укытучылардан берсе—завуч, математика укытучысы Бари Ишалин була. Ул укучыларында үз предметына карата мәхәббәтне шул дәрәҗәдә тәрбияли ки: 1950 елда аттестат алган яшьләрнең күпчелеге район мәктәпләренә математика укытырга китә. Бу—сугыштан соңгы авыр еллар, мәктәпләрдә укытучылар җитми. Шуңа күрә яхшы укыганнарны җидееллык мәктәпләргә билгеләләр. Азат та Сабадан 12 чакрым ераклыктагы Шекше авылы мәктәбенә килә. Монда ул бер ел буе 5 сыйныфларда математика, 6 сыйныфларда физика укыта, класс җитәкчесе була. Шулай да әдәбиятка һәм сәнгатькә мәхәббәт аны Казан университетының татар филологиясе бүлегенә алып килә. Һәм ул, кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшырып, 1951 елдан—студент...

Студент еллары—яшь кешенең житлегү-өлгерү чоры. Югары белем алу мәгънәсендә генә түгел, шәхес буларак та житлегү чоры ул. Ата-анадан аерылып, башка мохиткә, башка шартларга күнегү, мөстәкыйль яшәргә өйрәнү еллары. Сугыштан соңгы авыр еллар бу. 20 сум стипендия алып укучы кичәге авыл малайлары материаль хәлләрен беркадәр яхшырту, ә кайберләре хәтта җан асрау өчен дә укудан буш вакытларында, еш кына төннәрен ялланып башка эшләрдә эшлиләр: кемдер ишек алларын җыештыра, кемнәрдер баржалардан, поезд вагоннарыннан цемент, утын бушата... Ә студент Азатка башка һөнәрләре ярдәм итә. Ул беренче курстан ук университетның тынлы оркестрында катнашып китә, 5 ел буе беренче һәм икенче трубаларда уйный. Демонстрацияләр бу оркестрдан башка узмый. Музыкантларны төрле бәйрәмнәрдә күңел ачу кичәләренә чакыралар. Әлбәттә инде, алар бушка уйнамый. Һәм тагын акча эшләү өчен мәетне озатканда урам буйлап матәм көйләре уйнап баралар—ул чорларда мәетне өеннән алып чыгу белән зиратка кадәр музыка белән озату гадәте була.

Акча эшләүнең икенче юлы да ачыла: тынлы оркестр инструментлары бүлмәсендә иске генә бер баян да саклана икән. Капельмейстрның рөхсәте белән Азат шуны алгалап тора, еш кына фатирына да алып чыга (ул 5 ел буе университет ишек алдындагы подвалда, маржа апайларда фатирда тора). Анарчы аккордеонны уңышлы гына үзләштергән егет инде баянны да «иярли», Сәйдәш маршы, Огинскийның «Полонез»ы кебек шактый катлаулы әсәрләрне, һәртөрле бию көйләрен уйнарлык булып өлгерә. Аның бу һөнәре дә ярап куя: бәйрәмнәр вакытында чакыруларны кабул итеп төрле оешмаларга, күбрәк фабрика эшчеләре арасына бара... Билгеле инде, беренче чиратта үз мохите: студент концертларында, ял кичәләрендә, көз көннәрендә колхозларга бәрәңге алышырга баргач авыл концертларында ул—гармунчы урындыгында...

Азат үзешчән артистлыгын да һич тә онытмый. Бишенче курста укыганда ул университетта оешкан драмтүгәрәктә актив катнаша, төрле факультет студентларыннан торган түгәрәк чыгарылыш спектакле итеп әзербайҗан драматургы Гаджибековның «Аршин мал алан» әсәрен Казанның Укытучылар йортында куя, Азат анда төп рольдә Әскәр булып уйный.

Ә төп гамәл исә—уку. Монда да Азат алдынгылар рәтендә: 5 ел буе югары стипендия алып укый, дүртенче курста татар филологиясе бүлегендә ике генә студентка бирелә торган дәрәҗәле Габдулла Тукай стипендиясе ала. Аны студентларның җәмәгать эшләрендә, гомумән, студент тормышында актив катнашкан өчен билгеләләр. Ә Азат бу яктан бик актив: комсорг, комсомолның курс бюросы әгъзасы һ. б. Шуның белән бергә ул фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнергә дә вакыт таба. Бишенче курста аның Ф. Әмирхан иҗатына караган хезмәте студентлар эшләре арасында җинеп чыга һәм диплом белән бүләкләнә.

«Фатих Әмирхан тәнкыйтендә реализм мәсьәләләре» дип аталган бу хезмәттә классик әдип иҗатын өйрәнүгә карата зур булмаса да бер яңалык әйтелә. Эш шунда, бу әдипкә утызынчы елларда «буржуаз милләтче» дигән тамга сугыла. Моның өчен, иң беренче, аның атаклы «Фәтхулла хәзрәт» повесте сәбәпче була. Әнә, диләр вульгар социологизм тарафдарлары, Ф. Әмирхан нинди җәмгыять турында хыялланган: 50 елдан соң терелтелгән хәзрәт нинди тормыш күрә: миллилек һәм дин чәчәк аткан, буржуаз тәртипләр хөкем сөргән җәмгыять... Мондый авторны милләтче буржуа вәкиле димичә, ни дисең?! Ә студент Азат үз хезмәтендә болай

фикер йөртүләргә Ф. Әмирхан үзе үк җавап биргән булган ич, ди. Монын өчен ул язучынын галимнәр игътибарыннан читтә калып килгән мәкаләсендәге сүзләрне китерә: «Фәтхулла хәзрәт» рисаләләрендә мина—язучысына матур булган нәрсә фәкать мөбарәк хәзрәтебезнен хәзинәи фикрия вә рухиясеДер. Калганнары, фәкать, канва эшләүче татар кызына марлянын әһәмияте кадәр генә әһәмиятледерләр» *(«Йолдыз» газите, 1910 ел, 23 март).*

Димәк, Фәтхулла карт терелгәч күргән җәмгыятьнен нинди булуы язучыны артык кызыксындырмый; анын төп максаты—хәзрәтнен наданлыгын һәм бозыклыгын гына фаш итү. Ә киләчәктәге җәмгыять фоны—канвачы кызга марля кирәк булган кебек кенә, ярдәмче ролен генә үти. Студент Азатнын бу табышын ул вакыттагы әдәбият кафедрасы мөдире Хатип Госман «бик файдалы» дип бәяли, ә диплом җитәкчесе Ибраһим Нуруллин фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә.

А. Әхмәдуллин студент вакытында ук инде матбугатта чыгышлар ясый башлый. Өченче курста алар шәрекътәше, булачак язучы Хәниф Хәйруллин белән беренче тәнкыйть мәкаләләрен бастыралар *(«Совет әдәбияты», 1953, 9 сан).* Мәкаләдә рус язучысы Л. Воронкованын «Городище авылы» исемле повестенын татарчага тәрҗемәсе, анын дөреслеге, образлылыгы тикшерелә. Шактый ук тәнкыйди рухлы бу мәкаләне Мирсәй Әмир язучылар җыелышларынын берсендә унай яктан билгеләп үтә. Моннан сон инде А. Әхмәдуллин имзасы куелган тәнкыйть язмалары вакытлы матбугат битләрендә даими күренә башлый.

Күрәсен, баянчы һәм «компанейский» булуы өчендер Азатны университетнын яшь укытучылары һәм аспирантлары да үз итә. Шундыйлардан Рәфыйк Нәфыйгов, Мирфатих Зәкиев, Фәрит Хатипов, Хәлиф Курбатов, Мансур Хәсәнов, Нил Юзиев (болар соныннан фән докторлары, профессорлар, академиклар һәм мөхбир әгъзалар булып үстеләр) һәм башкалардан оешкан фикердәшләр төркеме аны үз эченә ала, үзләре белән тин күрә. Бу яшьләрнен күп вакыты китапханәләрдә үтә, ә кичке якларда, укып-язып арганнан сон, Ленин (хәзерге Кремль) урамын инләп сөйләшеп йөрүләр... Сөйләшүләр исә үз эченә күпне ала: яна укыганнар, дөнья, ил һәм милләт хәлләреннән башлап кызлар турында, нәүбәттәге бәйрәм кичәсен кайда һәм ничек үткәрергә, кемнәрне арага алырга кебек сүзләр... Бу—«Хрущев җепшеклеге» еллары, милли ан үсешенә бераз иркенлек туган вакыт. Инде бу төркем элек сүз алып баруы куркыныч булган темаларга да кагыла: татар мәктәпләренен ябылып бетә баруы, милли иркенлекнен булмавы, татар әдәбияты һәм сәнгатенә мәйданнын тарая баруы һ. б.

Ә 1956 елнын башларында бер хәтәр хәбәр тарала: Казан дәүләт университетында 1944 елдан бирле яшәп килгән татар филологиясе бүлеген ябачаклар, аны пединституттагысы белән кушачаклар икән! Табигый ки, яшьләрне мондый хәбәр борчуга сала һәм ярсыта. Шунда ук бу хәлгә түзеп тормаска, дәүләт җитәкчесе Н. С. Хрущевка хат язарга дигән фикер туа. Хатны бүгенге танылган әдип Нурихан Фәттах яза, анын нөсхәсен Р. Нәфыйгов, Н. Юзиев, Л. Зарипова, М. Хәсәнов, А. Әхмәдуллиннар җыелып тикшерәләр, катырак, «бик үк дипломатик булмаган» аерым формулировкаларны камилләштерү буенча фикерләшәләр. Бигрәк тә марксизм-ленинизм фәне буенча укытучы Р. Нәфыйгов урынлы тәкъдимнәр кертә. Н. Фәттах хатнын яна вариантын яза, анда саллы дәлилләр белән Татарстанда милли сәясәтнен дөрес алып барылмавы турында, КДУ да татар бүлеген ябу шунын бер күренеше булу турында әйтелә. Кинрәк җәмәгатьчелекне тарту, хатка күбрәк имзалар җыю өчен, Нурихан Фәттах белән Азат Әхмәдуллин «халык арасына» чыгып китәләр. Хатка берсүзсез кул куючылар да, икеләнеп-куркып кына имзасын салучылар да, баш тартучылар да була. Ләкин ни генә булмасын, имзалар җыела һәм хат Мәскәүгә китә...

КДУда татар бүлеге ябылмый кала. Әмма хатка имза салучыларнын барысын да партия өлкә комитетынын мәдәният бүлеге мөдире К. Фасеев бүлмәсенә җыеп «матур гына» сөйләшәләр, Татарстанда милли кысунын юклыгын яхшылап «төшендерәләр». Кайберәүләргә бу «хатанын» салкын җиле дә тия. Нурихан Фәттахны коммунист җитәкчеләр гомер буе читләтеп килә, Р. Нәфыйговны, шул елларда шәһәрдән авылга колхоз рәисләрен җибәрү хәрәкәтен сылтау итеп, Казаннан читкәрәк олактыру өчен кат-кат басым ясыйлар. Ләлә Зариповалы бернечә елдан сон комсомолнын өлкә комитеты секретаре итеп сайлату мәсьәләсе тугач та хатка кул кую вакыйгасы калкып чыга. А. Әхмәдуллин университет тәмамлагач Татарстан

китап нәшриятына мөхәррир булып эшкә урнаша, яхшы гына эшләп тә китә. Әмма 3 айдан соң эштән кыскартылу мәсьәләсе «туа». Кызыл дипломга ия егет аспирантурага гариза бирә. Әмма... әмма... Аның яраткан укытучысы, доцент Якуб Агишев аны күреп, сер итеп кенә әйтә: «Азат, аспирантура бүлегенә синең турыда «ә сез беләсезме, ул бит күмәк хатка кул куйган кеше, укырга алырга кирәкми», дип шылтыратканнар. Син, иң яхшысы, гаризаңны кире ал да, Казаннан бөтенләй үк кит, сиңа рәтле көн күрсәтмәсләр»,—ди. Ул шулай эшли дә. Җае да чыга. Тубыл педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасының ул вакыттагы мөдире Габделхәй Әхәтов аны эшкә чакыра һәм ул Себергә китеп бара. 1956 елның октябреннән ассистент булып эшли башлый.

Кичәге студентка үзе кебек яшьләрне укыту, әлбәттә инде, ансат булмый. Дәресләр күп: монда XX гасыр башы татар әдәбияты, татар әдәбияты методикасы, татар теле дәресләре дә, рус-татар бүлегендә укучы студентларга татар әдәбиятын русча укыту да бар... Ә төп авырлык—белем житеп бетмәү, татар әдәбияты һәм теле буенча китапларның һәм чыганакларның гаять азлыгы. Шулай да, Тубылга алданрак килеп, институтта укыта башлаган иптәшләре һәм дуслары доцент Фәрит Хатипов һәм өлкән укытучы Гомәр Саттаровларның, кафедра мөдире доцент Габделхәй Әхәтовның ярдәме күп тия: ике ел дәвамында Азат эшнең эченә шактый ук керә. Яшь укытучының эшкә житди каравын, укытудагы уңышларын күреп, зур җәмәгать эшләре башкаруын да хуплап институт житәкчелеге аны бер елдан өлкән укытучы итеп билгели.

А. Әхмәдуллин студентларны, Тубылның 15 нче мәктәбе укучыларын һәм шәһәр яшьләрен туплап драмтүгәрәк оештыра. Спектакль куярга исеме яңа гына халыкка кайтарылган К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» музыкаль мелодрамасын сайлыйлар. 30 кешелек хор, кечкенә генә оркестр, үзешчән артистлар ансамбленнән торган коллектив бик тырышып әзерләгән бу спектакль Тубылның әле декабристлар ук салып калдырган шәһәр театрында 1957 елның башында куела, шәһәр матбугатында уңай бәяләнә. Спектакльдә укытучылар да актив катнаша. Режиссер А. Әхмәдуллин үзе Булат ролендә, Ф. Хатипов авыл карты Байгура булып, Г. Саттаров Җиһанша ролендә уңышлы уйныйлар.

Ә икенче уку елында инде А. Әхмәдуллин шәһәр күләмендә жыр һәм бию ансамбле оештыра. Ансамбль дүрт тавышка жырлаучы зур хордан, биючеләр төркеменнән, баяннар һәм мандолиналардан оешкан оркестрдан тора. Жыр-көйләрнең ноталарын, биюгә өйрәтә торган Гай Таһиров китабын (бу китап әле Татарстан китап нәшриятында чыгып кына ята, аның корректурасын «себерлеләргә» нәшрият редакторы Гөлшат Зәйнашева табып бирә) ансамбльнең житәкчесе Казаннан алып кайта. Ул үзе үк—хорның дирижеры да, күмәк биюләрне һәм жырлы-биюле уеннарны куючы да. Бу ансамбльнең шәһәр театры бинасындагы чыгышы да, күрше авыллардагы концертлары да матбугат битләрендә бик тә уңай бәяләнә.

Тубылда Азат Әхмәдуллин тагын да бер файдалы эш эшли әле. Бу—«Ленин юлы» исемле татарча газетаны оештырып жибәрү. Дөрес, Себер тарихында бу беренче газета түгел, утызынчы елларның урталарына чаклы Омск кебек шәһәрләрдә, шул җөмләдән, Төмәндә дә татарча газеталар чыккан була.

Газета чыга башлауның үз тарихы бар. 1956 елда Тубыл педагогия институтында дистә ел буе яшәп килгән татар филологиясе бүлеген ябарга ниятлиләр. Моны белеп, ул бүлекнең житәкчесе, татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире доцент Габделхәй Әхәтов Мәскәүгә юл тота. Анда партия Үзәк Комитетының Себер буенча жаваплы секретаре Л. И. Брежневның кабул итүенә ирешә. Секретарь доцентның Себер татарлары исеменнән сөйләгән зар-интизарларын, үтенечләрен тыңлагач, илнең ул төбәгендә күпме татар яшәве турында мәгълүмат соратып ала. Саннар аны гажәпләндерә: Себердә берничә йөз мең, ә Төмән өлкәсенең үзендә генә дә 80 мең татар яши икән (ә Тубыл районы шул өлкәгә керә). Пединституттагы татар бүлеге мәсьәләсе уңай хәл ителә. Алай гына да түгел. Тубылда татар телендә газета чыгарырга рөхсәт ителә, алга таба ул өлкә газетасы булып үсеп китәргә тиеш була (дөрес, газета дистәләрчә ел яшәсә дә, монысы тормышка ашырылмый).

Һәм менә газетаны 1957 елның 1 сентябрендә ачарга, дигән фәрман килә. Редакторы итеп татарчасы бик тә чамалы булган жирле кешене билгелиләр. Утызынчы елларда хәреф жыючы булып эшләгән ике апайны табып алалар (берсен Төмәннән китерттәләр). Шул елны гына Тубыл пединститутын тәмамлаган кызны әдәби сотрудник

итеп тәгаенлиләр. Редакциягә урын да табыла. Ләкин... матбугат эшен белүче юк! Мондый газетаны ачарга дип кат-кат мөрәҗәгатьләр язган татар теле һәм әдәбияты кафедрасы әгъзалары, бу эшне үзләренең бурычы санаганга, А. Әхмәдуллинны вакытлыча газетаның җаваплы сәркатибе булырга күндерәләр. Моның өчен нигез дә бар: ул мондый эштә «тәҗрибәсе булган» бердәнбер кеше, чөнки 6 ай гына булса да китап нәшриятында эшләп алган, корректуралар белән эш йөрткән. Нишләсен, алына бу эшкә ассистент. Газетаның беренче санын ничек итеп чыгаруларын соныннан кызык итеп болай сөйли ул: «Ничек итсәк иттек, беренче санга материалларны тупладык (күбесе тәрҗемә иде булса кирәк). Инде типографиядә җыярга кирәк. Апайлар кириллицаны белмиләр, тирләдек-азапландык, җыябыз... Берзаман карыйбыз, кассаларда «ә» хәрефе юк. Нишләргә? Мина гаҗәп «акыллы» фикер килә: «ә» урынына «э» хәрефен куеп җыярга! Һәм шулай эшлибез дә. Төне буе азапландык, әмма иртәнгә газетаның тәүге санын өлгерттек. Билгеле инде, татар сүзләрен «э» белән язган сан. Газетаның икенче санын җыйганда гына мин үземнең аңгыралыгыма төшендем: «ә» шул ук «е» хәрефенен киресе бит инде ул. Хәрефләрне кассаларга рус басмачылары тараткан, ә алар өчен «ә» ни дә, «е» ни—барысын бер кассага тутырганнар...».

Ничек итсә итә, җаваплы сәркатип газета эшен юлга салып җибәрә. Газетта Тубыл шәһәр һәм район хәбәрләре күпләп урын ала башлый, ул үзе дә газетада мәкаләләр, очеркларын бастыра. Бигрәк тә институт укытучылары зур ярдәм күрсәтә: Г. Саттаров, Г. Әхәтов хәтта татар теленең Себер диалекты турында фәнни мәкаләләрен дә бастыралар. Аерата Ф. Хатипов активлык күрсәтә. Иптәшләре аны, газетаны яшәтү өчен, алга таба җаваплы сәркатип вазифасын башкарырга күндерәләр. Институтта ярты ставкага гына калып (хезмәт хакын да шактый ук югалтып), ул елдан артык шул эшне башкара, газетның яшәвен тәэмин итә. Аның бу милләтпәрвәрлеген, фидакарьлеген дуслары бүген дә сокланып искә алалар һәм бәялиләр. Азат исә төп игътибарын җыр һәм бию ансамблен оештыруга юнәлтә.

Эшендә һәм җәмәгать тормышында һәрьяклап унай бәяләнсә, хупланса да, А. Әхмәдуллин туган якларына кайтырга, белемен күтәрергә ашкына. Шул арада Казан кызы Фирая Ярмөхәммәтовага өйләнгән егет, Себер белән араны өзеп, 1958 елның җәендә Казанга кайтып төшә, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы, Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантурасына гариза бирә. Имтиханнарны уңышлы тапшырып, конкурсны үтеп, укырга да керә.

Фәнни җитәкчесе профессор Мөхәммәт Гайнуллин белән киңәшеп, Азат Әхмәдуллин исеме әле генә халыкка кайтарылган, анарчы «халык дошманы» исәпләнгән Фәтхи Бурнаш иҗатын кандидатлык диссертациясе темасы итеп ала. Үз чорында шагыйрь һәм драматург булып танылган Ф. Бурнашның әдәби әсәрләре, бәхеткә каршы, төрле җыентыкларда, газета һәм журналлар битләрендә, китапханәләрдә, архивларда сакланган. Диссертантка аларны җыйнау, өйрәнү өчен Казаннан тыш Мәскәү, Ленинград китапханәләрендә, архивларында булырга һәм эшләргә туры килә. Мәсәлән, ул Кызыл Армия Үзәк архивында, Ленинградтагы Луначарский исемендәге Дәүләт театр китапханәсендә, Үзәк тарих архивында Ф. Бурнашка кагылышлы күп материал һәм аның кайбер әсәрләрен таба. Шулай да төп материалны язучының энесе Вафа һәм аның хатыны, библиограф Мәсгудә Бурнашева бирә. Репрессиянең иң котырган чорларында да Фәтхи абыйларының дошман булуына һич тә ышанмыйча, алар аның архивын яшереп саклыйлар, алып калалар һәм диссертантка шул архив белән танышырга мөмкинлек бирәләр. Нәтиҗәдә бу олы язучының, татар совет әдәбиятының һәм журналистикасының нигезен салышкан күренекле шәхеснең, тулы биографиясен һәм иҗатының үзенчәлекләрен ачыклыктан диссертация туа. 1964 елда авторына фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә китергән диссертация уңышлы яклана. Соңыннан А. Әхмәдуллин Ф. Бурнаш турында ике китап чыгара, үз шәкерте Н. Ханзафаров белән бергә әдипнең әдәбият һәм сәнгать турындагы хезмәтләрен туплаган җыентык төзеп бастыра. Бүгенге көндә Татарстан Фәннәр академиясе карамагындагы бер коллектив аның җитәкчелегендә Фәтхи Бурнашның 5 томлык сайланма әсәрләрен бастырып чыгару өчен әзерли.

Аспирантураны тәмамлагач, А. Әхмәдуллинны Тел, әдәбият һәм тарих институтында кече фәнни хезмәткәр итеп калдыралар. Ләкин аңа озак эшләргә туры килми. Партиянең Татарстан өлкә комитеты аны республика Министрлар Советы каршындагы радио һәм телевидение Комитетына радионың әдәби-нәфис тапшырулар

буенча баш редакторы итеп эшкә билгели. Ул—яшь коммунист—гәрчә радиода эшләү тәҗрибәсе булмаса да—бу вазифадан баш тарта алмый. Баш редактор кул астында әдәби-драматик тапшырулар, музыкаль тапшырулар, балалар өчен, русча тапшырулар, тагын берничә редакция бар. Аларда композиторлар Исмай Шәмсетдинов, Фасил Әхмәтов, Наилә Зарипова, шагыйрь һәм үзешчән композитор Ләбиб Айтуганов, тәҗрибәле радио-журналистлар Эльза Гобәйдуллина, Нәсимә Әхмәтжанова, Мәһинур Җиһаншина һ. б. лар эшли. Баш редактор тапшырулар әзерләргә атаклы композитор Җәүдәт Фәйзи, бүгенге тәҗрибәле режиссер Әхтәм Зарипов, хәзер театр белгече буларак танылган Дания Гыймранова кебек белгечләрне һәм сәнгать кешеләрен тарта, әдәби һәм музыкаль тапшырулар хәзерләүдә үзе дә җиң сызганып эшли. Радиода хезмәт иткән ел ярым вакыт эчендә А. Әхмәдуллин 30 га якын зур-зур концерт программалары, Г. Камал, Г. Коләхмәтов, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Н. Исәнбәт, Х. Вахит, Р. Ишморат, Ш. Сарымсаков һ. б. иҗаты буенча бер әр сәгатьлек 15 тән артык тапшыру (кереш сүз һәм инсценировкалар) төзеп эфирга чыгара. Э. Касыймов повесте буенча куелган «Кояш көн дә чыга» исемле радиопостановканың, А. Расих әсәрләре буенча хәзерләнгән «Ык суы буенда», «Язгы авазлар», В. Губаревның повесты мотивлары буенча куелган «Тылсымлы яулык» исемле радио-спектакльләрнең сценарийларын да яза ул. Аларның кайберләре радио фондында әле дә саклана. Шулай ук ул вакыттагы баш редакторның турыдан-туры катнашында-житәкчелегендә эшләнгән, бүген дә радионың бизәге булган иртәнге чакыру сигналының (позывнойның) да менә инде дүрт дистә ел буе яңгыравын әйтергә кирәк. «Без бик күп мелодияләр, композиторларның әсәрләре арасыннан А. С. Ключарев көеннән бер өлешне табып, татар радиосының символына әверелдердек,—дип искә ала А. Әхмәдуллин.—Бу эштә миңа Рөстәм Яхин үз киңәшләре белән нык ярдәм итте».

1963 елның башларында сырхаулап киткән А. Әхмәдуллин Тел, әдәбият һәм тарих институты дирекциясенең чакыруын кабул итә, конкурс аша узып, Институтка кече фәнни хезмәткәр булып эшкә кайта. Инде әйтелгәнчә, 1964 елда кандидатлык диссертациясе яклый.

Ф. Бурнашның тәрҗемәи хәле һәм иҗаты турында монографик мәгълүмат бирүдән тыш, бу хезмәтендә А. Әхмәдуллин татар совет әдәбиятындагы бер бик тә мөһим күренешне ача. Аны «революцион аскетизм» дип атый. Бу күренеш әдәби геройны берьяклы итеп күзаллаудан, аны иҗтимагый мәнфәгатьләр өчен шәхси теләк-омтылышларын корбан кылган кеше буларак сурәтләүдән гыйбарәт. Автор хезмәтендә бу күренешнең туу закончалыкларын, аның татар (һәм гомумән совет) әдәбиятына алып килгән һәм унай, һәм тискәре йогынтысын нигезли. Аерым алганда, революцион аскетизмның әдәбияттагы иң көчле алым-ысуллардан булган психологизмга зыян салуын Ф. Бурнаш иҗатыннан да, татар совет әдәбиятыннан да мисаллар китереп, ышанычлы раслый. Бу турыда матбугатта берничә мәкалә бастыра. Алга таба татар галимнәре дә, башкорт әдәбиятчылары да бу күренешнең барлыгын таныйлар, диссертант тәкъдим иткән «революцион аскетизм» терминын да кабул итәләр.

1965 елны А. Әхмәдуллинны Институтның гыйльми сәркатибе урынына тәкъдим итәләр. СССР Фәннәр академиясенең Президиумында расланып кайткач, ул җиң сызганып эшкә керешә һәм озакламый директор Мидхәт Мөхәррәмовның, аның фәнни эшләр буенча урынбасары Илбарис Надировның ышанычлы ярдәмчесенә әверелә. Дирекция бу елларда Институтны һәм фәнни, һәм структур, һәм финанс-хуҗалык ягыннан үстерүдә шактый эшләр башкара. Институт, турыдан-туры СССР Фәннәр академиясе карамагына күчерелеп, шактый ук мөстәкыйльлек ала, аңа күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов исеме бирелә. Институттагы фәнни хезмәткәрләр саны бермә-бер арта, анда яңа бүлекләр (сәнгать, халык авыз иҗаты, фәлсәфә) барлыкка килә. Хезмәткәрләр өчен фатирлар бирү арта, архив һәм китапханәләр баетыла һ. б. Иң мөһиме, язылган хезмәтләрне бастыру мөмкинлекләре беркадәр киңәеп, шактый санда капиталь фәнни китаплар дөнья күрә, археологик, этнографик, фольклор, диалектологик экспедицияләр ешрак оештырыла башлый, аспирантура бүлеге ныгытыла. А. Әхмәдуллин 5 томлык (соныннан—6 томлык) «Татар әдәбияты тарихы», «Әдәбият баскычлары», «Татар совет театры» һ. б. кебек китапларны язуның инициаторы, ул басмаларның һәм татар әдәбияты классикларының күптомлыкларының редакторы (яки редакторлардан берсе) була. Мондый эшләр ул 1972 елда директорның фәнни эшләр буенча урынбасары итеп күчерелгәч тә дәвам

итә. Институтның дирекциясе составында эшләгән 15 елын А. Әхмәдуллин нәтиҗәле, эшлекле еллар дип һәрвакыт сагынып искә ала.

Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасын ныгыту, эшчәнлеген яхшырту максаты белән партия өлкә комитеты А. Әхмәдуллинны 1981 елны кафедра мөдире итеп тәкъдим итә. Яраткан һәм белгән эштән китү ансат булмый, билгеле, баш тартып та карый, әмма... «тыңламасаң, партбилетыңны өстәлгә салырсың» дигәч (ә моның нәрсә икәнен ул чорны белгән кешеләр яхшы аңлый!), ризалашырга мәҗбүр була. Бу яңа урында эшләгәндә А. Әхмәдуллин Алма-Атага барып филология фәннәре докторы дәрәҗәсенә диссертация яклый (1988 ел), шул ук елда аңар профессор исеме дә бирелә. Кафедра мөдире вазифаларын үтәү 19 ел дәвам итә. Шулай ук фәнни яктан да, оештыру җәһәтеннән дә файдалы, нәтиҗәле еллар була бу. Шул вакыт аралыгында кафедраның өч әгъзасы докторлык диссертациясе, икесе кандидатлык диссертацияләре яклый, аспирантура нәтиҗәле эшли. Кафедра күмәк хезмәтләр хәзерләп чыгара («Әдәбият теориясенә кереш», «Әдәбият белеме сүзлеге» һ. б.). Мөдир үзе дә җиң сызганып фән белән шөгыльләнә. Шунысын гына әйтү дә җитә: матбугатта басылган барлыгы 370 кә якын хезмәтенең 155 ен шул чорда яза; ул редакцияләгән 75 хезмәтнең 50 гә якыны да шул елларга карый.



*Казан дәүләт университеты укытучылары (сулдан уңга) Азат Әхмәдуллин, Мөхәммәт Мәһдиев һәм Вахит Хаков. 1983 ел.*

1999 елның июленнән А. Әхмәдуллин кафедрада профессор, ә 2000 елның гыйнварыннан, төп урыныннан аерылмый эшләү тәртибендә, ул Казан дәүләт педагогика университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире вазифаларын да башкара.

Тел, әдәбият һәм тарих институтында, Казан дәүләт университетында эшләгән елларында А. Әхмәдуллинга күп төрле җәмәгать эшләре белән дә шөгыльләнергә туры килә. Аларның кайберләрен ул хәзер хәтерләп тә бетерми: алар шактый санда һәм күптармаклы. Кандидатлык диссертациясе яклагач та аны Татарстан АССР ның Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләре Комитеты әгъзасы итеп билгелиләр, ул анда ун елга якын эшли. 1998-2000 елларда тагын бер мәртәбә эшләп ала. 1974 елда аны Язучылар союзына кабул итәләр. Шул ук елны Язучылар союзы идарәсенә һәм аның Президиумы әгъзасы итеп сайлыйлар. Монда ул ике дистә ел буе сайланып килә. Идарә аны СССР Әдәбият фондының Татарстан бүлеге рәисе итеп тәкъдим итә, ул шул вазифаны да егерме ел буе башкара. Язучылар берлеге әгъзасы буларак А. Әхмәдуллин әдәби процесста актив катнаша, әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышларда, Язучылар съездларында драматургия буенча докладлар һәм чыгышлар ясый. Язучылар идарәсе тәкъдиме белән драматургия һәм театр тәнкыйте өлкәсендәге актив эшчәнлеге өчен аңа 1982 елда «ТАССР ның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә. Монда аның 15 елга якын Татарстан АССРның Мәдәният министрлыгы янындагы яңа спектакльләр һәм концерт программаларын кабул итү комиссиясе әгъзасы булып торуы да истә тотыла.

А. Әхмәдуллин дистәләрчә ел республикадагы «Казан утлары», «Татарстан коммунисты»—«Коммунист Татарии» кебек журналларның, Татарстан китап нәшриятының редколлегия әгъзасы була. Бүген дә бу эшчәнлеген дәвам итә: ул—халыкара «Мирас» журналы, «Мәгариф» журналы редколлегияләре әгъзасы.

Галим Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы буларак та өстәмә җәмәгать эшләре алып бара. Ул ТФА ның мөхбир әгъзасы итеп 1994 елда сайланган иде. Соңгы елга кадәр Фәннәр академиясенең Гуманитар фәннәр бүлеге Бюросының җаваплы сәркатибе булды. Бюро карамагындагы әдәбият белеме Советында рәис урынбасары (рәисе академик М. Х. Хәсәнов). Боларга өстәп аның Татарстан Фәннәр

академиясенең экспертлар советы әгъзасы, академиянең Гуманитар фәннәр бүлеге каршындагы иҗтимагый фәннәргә караган уку әсбаплары һәм программалар буенча фәнни-методик эксперт советы әгъзасы булуын да әйтергә кирәк. Ул—5 томлык «Татар энциклопедиясе»нең Татарстан Президенты указы белән расланган Баш фәнни-редакцион коллегиясе әгъзасы да; бу мөһим басманың театр белеме бүлеге буенча җаваплы редактор.

А. Әхмәдуллинның фәнни алмаш хәзерләү буенча да, югары уку йортларының фәнни советларындагы эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Ул 1981 елдан бирле Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер—сәнгать) институты каршындагы баштарак кандидатлык диссертацияләре, соңрак докторлык диссертацияләре яклау советларының, ә 1991 елдан Казан дәүләт университеты каршындагы докторлык диссертациясе яклау советының да әгъзасы. 80-90 елларда ул университетның Зур гыйльми советы, Тел, әдәбият, сәнгать институты советы әгъзасы булды, хәзер исә Казан педагогика университетының Зур советы һәм татар филологиясе факультеты советы әгъзасы, Казан университетының татар филологиясе һәм тарихы факультеты советы әгъзасы.

А. Г. Әхмәдуллинның фәнни эзләнүләре берничә юнәлешне үз эченә ала. Иң беренчесе, ул—драматургия белгече. Фәтхи Бурнаш драматургиясен җентекләп өйрәнүдән башланган аның бу эшчәнлеге торган саен тармаклана, тирәнәя барды. Ул Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Коләхмәтов, М. Фәйзи, К. Тинчурин, Ф. Сәйфи-Казанлы, Н. Исәнбәт, К. Тинчурин, Һ. Такташ, М. Әмир, Р. Ишморат, Х. Вахит кебек драматургларның һәркайсы турында үзенең сүзен әйтте. Бу сүз бигрәк тә Г. Исхакый, Г. Коләхмәтов, Ф. Әмирхан, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, Ш. Усманов, Һ. Такташ, Н. Исәнбәт, Х. Вахит, Ю. Әминев иҗатлары турында, аларның аерым әсәрләре хакында үтемле булды. Галим бу язучыларның сәхнә әсәрләре үз чоры өчен һәм фикер җәһәтеннән, һәм сәнгатьчәлек ягыннан нинди яңалыклар алып килүен ышандырырлык итеп раслады. Мәсәлән, ул Г. Коләхмәтовның «Ике фикер» һәм «Яшь гомер», Ф. Әмирханның «Яшьләр» һәм «Тигезсезләр», Һ. Такташның «Җир уллары трагедиясе» һәм «Югалган матурлык» кебек әсәрләрен өр-яңача «укыды», аларга оригиналь анализ бирде. Аның мәгърифәтчелек чоры драматургиясе турындагы хезмәтләре дә әдәбият фәне өчен үзенә күрә бер ачыш булды. Мәсәлән, әдәби герой концепциясендә актив башлангычның нинди роль уйнавы турындагы А. Әхмәдуллин фикерләре бу чордагы милли драматургиянең үзенчәлекләреннән берсе төсендә яклау тапты. М. Әл-Казаныйның «Ихтыярлы кыз ихтыярсыз улмыш» исемле романтик драмасы, Ф. Халидинең кайбер әсәрләре аның хезмәтләре ярдәмендә фәнни әйләнешкә кереп киттеләр. Мәскәүнең «Наука» нәшриятында басылган хезмәтендә («Татарская драматургия», 1983) ул татар драматургиясенең тууыннан башлап әдәби төр буларак тәмам ныгып-үсеп җиткәнчегә (XX гасырның 30 елларына) кадәрге чорын бербөтен иҗади процесс буларак күз алдына бастырды, бу процесста аның үзенчәлекләрен күрсәтте, нинди идея-сәнгатьчә үрләр яулавын билгеләде, кайсы авторларның нинди урын биләүләрен әйтте. Габдерәүф Ниязбаевның «Беренче таң», Ф. Бурнашның «Язмыш», К. Тинчуринның «Ач гашыйк», шәкерте Н. Ханзафаров белән бергә Н. Исәнбәтнең «Портфель» кебек әсәрләрен фәнни әйләнешкә кертеп җибәрде. Татар драматургиясенең 30-60 еллар арасындагы тарихи үсеше галимнең төрле хезмәтләрендә, аерым алганда 6 томлык «Татар әдәбияты тарихы»ның аерым томнарында, мәктәп дәреслекләрендә, югары уку йортлары студентлары өчен чыгарылган программаларда һ. б. яктыртыла.

1960 еллардан башлап А. Әхмәдуллин татар әдәби процессында актив катнашып килә. Монда да аның җиң сызганып өйрәнгән, фәнни-тәнкыйди фикерләре белән үсеш процессына билгеле бер дәрәҗәдә тәэсир ясаган өлкәсе—милли драматургия. Шул еллардан башлап бүгенге көннәргә кадәр актив иҗат итүче драматургларның һәрберсе турында, күренекле сәхнә әсәрләре хакында аның хезмәтләрендә анализлар һәм фикерләр бар. Болардан Т. Миңнуллин, А. Гыйләҗев, Ш. Хөсәенов, Ю. Әминев, С. Шәкуров, И. Юзеев, Ә. Баян, Р. Хәмид, Ю. Сафиуллин, Ф. Садриев, Батулла, Р. Мингалим, З. Хәким, Д. Салихов, Аманулла һ. б. уннарча авторлар, аларның пьесалары хакында махсус мәкаләләр, рецензияләр язылган. 60-90 еллардагы даими уздырыла торган әдәби ел йомгакларында, язучыларның корылтайларында А. Әхмәдуллин сәхнә әдәбияты турында докладлар һәм чыгышлар ясый, бу чараларга хәзерлек чорында проблемалы мәкаләләр бастыра. Алар «Ничек сурәтләргә сине, замандаш?» дигән монографиядә, «Сәхнә әдәбияты һәм тормыш», «Горизонты

татарской драмы», «Дәреслеккә ирешү юлында» исемле тематик җыентыкларда басылган, аерым драматургларның пьесалар җыентыкларында кереш сүз яки мәкаләләр төсендә урын алган.



*Азат Әхмәдуллин Казанда Тукай музеен ачу тантанасында чыгыш ясый. 1986 ел.*

Драматургия белгече, әлбәттә инде, театр сәнгатен дә үз итәргә тиеш. Чөнки әдәбиятның үзенчәлекле, В. Г. Белинский заманында «әдәбиятның тажы» дип атаган бу төрен яхшы белү өчен театр сәнгатенең нечкәлекләрен дә күзалларга кирәк. Шуңа күрә А. Әхмәдуллинның татар театрына багышланган хезмәтләрдә актив катнашуына, еш кына республика театрларында бара торган процесслар хакында, яңа спектакльләр яки аерым театр эшлеклеләре турында матбугат битләрендә театр белгече төсендә чыгышлар ясавына һич тә гаҗәпләнергә туры килми. «Татар совет театры» исемле, милли театрыбыз тормышын гомумиләштергән очерклар китабында ул 20 еллардагы татар театрларында, аларның репертуарында, актерлар уенында күзәтелгән үзенчәлекләрне сәхнә тарихын яхшы белгән галим буларак яктыртып бирде. Аерым алганда, ул татарның кабатланмас трагик актеры Мохтар Мутинның бу чордагы уен үзенчәлекләрен ачып күрсәтте. Әгәр дә «Народные артисты Татарии» җыентыгын бастырып чыгаруда ул редакцион коллегия әгъзасы буларак чыгыш ясаса, «Габдулла Кариев» исемле мәкаләләр, истәлекләр, документлар җыентыгын чыгаруда махсус редактор буларак кына түгел, текстолог буларак та эш башкара. Мәсәлән, бөек режиссер һәм актерның «Артист» исемле комедиясен элекке басмалардагы хаталардан коткарып, аны логик бөтенлеккә китерү өчен күп көч куя, китапның төзүчесе, театр белгече Хәсән Гобәйдуллинга һәрьяклап ярдәм күрсәтә. Аның бүгенге театрларыбыз турындагы, ТДАТ ының кайбер сезоны йомгаклары хакында, Әлмәт, Минзәлә театрлары репертуарына күзәтү характерындагы мәкаләләре, Башкорт театрының 1977 елгы гастрольләре вакытындагы аерым спектакльләренә рецензияләре, К. Тинчурин, М. Әмир, Х. Вахит, Т. Миңнуллин, Н. Фәттах, Р. Батулла, З. Хәким, Аманулла, М. Маликова әсәрләре буенча төрле театрларда куелган спектакльләргә рецензияләре ныклы белгеч кулы белән язылган.

А. Әхмәдуллин даими рәвештә матур әдәбиятның гомуми мәсьәләләре белән дә шөгыльләнә, аерым язучылар иҗаты яисә күренекле әсәрләр турында үз фикерләрен әйтә, мәкаләләр яза. Аны бигрәк тә әдәбиятның методологик проблемалары кызыксындыра. Җәмгыятьне үзгәртеп кору процессы башлангач, ул методологиягә багышланган берничә мәкалә язып бастырды. Бигрәк тә аның «Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер нәзари-методологик принциплары» дигән хезмәте әһәмияткә ия. Монда ул әдәби әсәрләрне анализлауда төп принцип булып килгән «табигатькә охшату» (Аристотель), ягъни «мимесис» теориясенең хәзер бердәнбер принцип булып бетә алмавы мәсьәләсен күтәрде. Хәзерге шартларда җәмгыятебезнең алга үсешен бары тик материализм ноктасыннан гына торып аңлауаңлатуның тар булуын, дини фәлсәфәне тиешенчә үзләштереп, идеалистик карашларны да истә тоту кирәклеген күрсәтте. Галимнең бигрәк тә Урта гасырлар әдәбиятларын «охшату» принцибына гына нигезләп өйрәнүнең җитәрлек булмавы турындагы фикерләре игътибарга лаек.

Галим үзгәртеп корулар чоры башлангач язган «Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең актуаль мәсьәләләре», «Татар драматургиясе тарихын яңача өйрәнү» кебек мәкаләләрендә, дәреслекләрдәге җәмгыятебезнең аерым чорларында әдәбиятыбызның үзенчәлекләренә караган өлешләрдә сүз сәнгатен яңа идея-эстетик таләпләр югарылыгыннан торып бәяләү критерияләренә туктала. Һәм шул критерийларны ул Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, К. Тинчурин, Һ. Такташ, Т. Гыйззәт,

Т. Миннуллин, Р. Мөхәммәдиев, Батулла, Р. Хәмид кебек язучыларның аерым әсәрләрен анализлаганда куллана («Көз», «Шәрифулла агай», «Ак кыялар турында хыял», «Сират күпере», «Жиде бажа» һ. б.). Аның иң соңгы хезмәтләреннән берсе булган «Гареб—Шәрекъ контекстында татар әдәбияты тарихы» дип аталган күләмле язмасы—татар әдәбиятының урта гасырлардан алып бүгенгегә кадәр узган юлын бүгенге методологик таләпләр югарылыгыннан торып өйрәнү һәм бәяләүнең бер үрнәге.

А. Әхмәдуллин үзенең иҗат гомерендә күп көч һәм вакыт сарыф иткән тагын да бер өлкә—дәреслекләр һәм уку әсбаплары язу, төзү. Урта мәктәпләр өчен дәреслекләр һәм уку әсбаплары хәзерләү эшенә ул 70 нче елларның башыннан ук тартыла. 9 сыйныф өчен М. Хәсәнов һәм И. Нуруллин белән бергә язылган дәреслек 1970 елда басылып чыга, шуннан соң төрле үзгәрешләр һәм төзәтүләр белән 15 мәртәбә кабат басыла. Соңгы басмаларында ул А. Әхмәдуллин редакциясендә эшләнә. Ә күренекле татар галимнәре Х. Госман, Г. Халит, Г. Кашшаф, Х. Хәйри, А. Сайганов, Н. Юзиев белән бергәләп язылган 10 нчы сыйныф дәреслеге 1971 елдан башлап 12 мәртәбә дөнья күрә.

Сиксәненче еллар азагында Татарстан мәгариф министрлыгы Казан дәүләт университеты ректорына урта мәктәпләр өчен татар әдәбияты буенча яңартылган программалар һәм дәреслекләр төзүдә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Бу җаваплы эшкә А. Әхмәдуллинны билгелиләр.

Иң мөһиме, билгеле инде, өр-яңа программа төзү була. Чөнки, иң беренче, аның концепциясе яңа булырга тиеш. Ул совет идеологиясеннән арынган, үзгәртеп кору таләпләренә җавап бирерлек булсын. Анда совет чорында бик аз гына урын карала торган урта гасырлар татар әдәбиятына лаеклы мәйдан бирелергә тиеш. Ул әдәбиятны өйрәнүдә анарчы баш рольне уйнаган сыйнфыйлык, партиялелек принциплары хакимиятеннән котылган булырга тиеш. Анда мәктәптә укып өйрәнү өчен сәнгатьчәлек ягыннан иң камил әсәрләр тәкъдим ителгән булу лязим. Бу программа анарчы халык дошманы дип каралган, яки зарарлы дип саналган язучыларның әсәрләренә дә урын бирергә бирергә тиеш. Ягъни укучыларга Гаяз Исхакый, Фатих Кәрими, Риза Фәхретдинов кебек танылган әдипләр иҗатларын кайтарырга кирәк. Һәм мондый программа эшләнә дә. Аның 5-8 сыйныфларга аталганының нигезен профессорлар Ф. Хатипов һәм А. Әхмәдуллиннар төзи, 9-11 сыйныфларныкын А. Әхмәдуллин яза. Программаның А. Әхмәдуллин (җитәкче), профессорлар Фоат Галимуллин, Флера Ганиева, педагогика фәннәре кандидаты Фәнис Исламовлардан торган коллегия редакциялэгәне 1992 елда басылып чыга, төзәтелеп кабат 1996 һәм 2000 елларда басыла. Шул программа нигезендә А. Әхмәдуллин җитәкчелегендәге авторлар коллективы дәреслекләр язу эшенә керешә. Бу коллективка күренекле галимнәрдән, профессорлар М. Хәсәнов, Н. Юзиев, Т. Галиуллин, Х. Миннегулов, Ф. Галимуллин, Ф. Хатипов, Ф. Ганиева, А. Әхмәдуллин, фәннәр кандидатлары, доцентлар Ш. Садретдинов, М. Җәләлиева, Г. Әдһәмова, Ф. Исламов, Р. Харрасова, тәҗрибәле укытучылар Д. Сибгатуллина, И. Гыйләҗев кертелә. Шушы галимнәр язган һәм төзегән, 1995 елдан башлап басылган башлаган бу дәреслекләр, хрестоматияләр барлык сыйныфлар өчен дә чыгып бетеп, аларның кайберләре инде икешәр-өчәр мәртәбә дөнья күрде. Бу хезмәтләре өчен дәреслекләрнең фәнни редакторы профессор А. Әхмәдуллин 1999 елда Татарстан Мәгариф министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге премиясе белән бүләкләнде.

...Олы галимебез турында аның 60 еллыгында мин «Җиңе сызганулы» дип бер мәкалә язган идем. Аның җиңе бүген дә сызганулы, әдәбият фәнебезнең өлгергән мәсьәләләрен хәл итү, драматургиябез тарихын өйрәнү, дәреслекләр төзү, фәнебезгә алмаш хәзерләү өчен сызганулы. Казан дәүләт университеты профессоры, бер үк вакытта Казан дәүләт педагогика университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире буларак та сызганулы аның җиңе. Без—аның каләмдәшләре, шәкертләре, күп санлы укучылары—аның тормыш һәм иҗат юлы озын-озак булуын телибез.

*Казанның 1000 еллыгына*

Әзһәр Мөхәммәди

# КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ ҺӘМ АНЫҢ БОРЫНГЫ ИСЕМНӘРЕ

**Казан турында хезмәтләр.** Борынгы тарихи чыганакларга һәм шулай ук галимнәрнең тарихи хезмәтләренә караганда, Казан шәһәренең барлыкка килүенә, аның Идел-йорт тарихында гаять зур роль уйнаганлыгына әһәмият биреп киленә. Шәһәрнең тарихи проблемаларын тәфсилләп өйрәнү буенча Казан дәүләт университетының үзенә хас тирән традицияләре бар.

XIX гасыр башында, Казан император университетының яңа гына ачылган чорында Германиядән килгән егерме биш яшьлек профессор Х. М. Френ беренче буларак төрки-татар тәңкәләрен өйрәнү белән, икенче төрле итеп әйткәндә, нумизматика белән шөгыльләнә башлый. Ул бихисап сандагы хазар[1], болгар һәм бигрәк тә Кыпчак (Алтын Урда) һәм Казан дәүләте тәңкәләрен шулкадәр үҗәтләнеп өйрәнү, аларны тәртипкә салу эшенә керешә ки, хәзерге вакытта фәндә аны «көнчыгыш нумизматикасының атасы» дип атап йөртәләр.

1817 елда аның ватандашы, Казан университетының профессоры К. Фукс «Казан каласының кыскача тарихы» дигән китап язып бастырырга тырышып карый. Ләкин китапның кайбер бүлекләре генә дөнья күрә. Хикмәт шунда, этник чистарту, ягъни колониаль түгел, ә бетерү сәясәте («папуас моделе») алып барган патша хөкүмәте татар тарихын дөрес итеп язарга омтылуны хупламаган. XIX йөз азагында гына тулаем нәшер ителгән әлеге китапның соңгы сүзендә профессор В. С. Иконников аңа мондый бәяләмә бирә: «Краткая история города Казани» К. Фукса представляет превосходный систематизированный свод всех документов, источников (более ста ссылок) по истории Казани от начала ее до царствования Федора Ивановича».

1875 елда Казан университеты каршында «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» төзелгәч, аның «Хәбәрләрендә...» («Известия общества археологии, истории и этнографии») Казанның борынгы тарихына багышланган гаять күп сандагы материаллар нәшер ителә. Алар, нигездә, шәһәрнең барлыкка килүе, Казан һәм Казан вилаяте тарихы кебек өч зур проблеманы яктыртуга багышланганнар. Бу материаллар турында фикер йөртү өчен, аларның кайберләрен телгә алып китү дә җитә: «История Казанского края» *(1878, 4 чыгарылыш)*, «Анализ двух книг об истории Казани и Булгар» *(1895, 4 чыгарылыш)*, «Исторические песни татар о взятии Казани» *(1899, 4 чыгарылыш)*, «Археологическая поездка в район Иски-Казани» *(1901, 4 чыгарылыш)*, «Иностранцы о Казани» *(1903, 5 чыгарылыш)*, «Древности Казани в актах» *(1904, 1-3 чыгарылыш)*, «Древние виды Казанского кремля» *(1906, 2 чыгарылыш)*, «Описание города Казани 1675 г.» *(1906, 1 чыгарылыш)*, «Где была старая Казань?» (XXVIт.) һәм башкалар.

«Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»ндә дөнья

[1] Итилдә сугылган тәңкәләрдә бу атама касар рәвешендә язылган.

күргән кайбер хезмәтләр хәзерге көндә дә үзләренең гыйльми әһәмиятен югалтмаганнар.

**Казан барлыкка килү турындагы фаразлар**. Кремль тавында урнашкан һәм таш гасырдан бирле берничә мең ел дәвамында яшәп килгән торлакның (поселение) Казан шәһәренә әверелү вакыты турында берничә төрле фикер булып, аны X—XI, XII, XIII яки XIV йөз азакларында төзелмәдеме икән дип фаразлыйлар иде. Алар арасында хәзерге чор археологиясе һәм чыганакларны өйрәнү фәне үсешенә таянып, ышандырырлык итеп нигезләнгәне Казан шәһәре X һәм XI йөзләр чатында барлыкка килгән дип раслый (бу турыда алдарак тәфсилләбрәк әйтеп үтелер), XII, XIII яки XIV йөз тарафдарлары фаразларына килгәндә исә, Казан каласының барлыкка килү вакыты бәхәс кузгаткан урыс елъязмаларында очыраштыргалаза да, алар үзләренең каршылыклы булулары белән аерылып торалар.

Казанның билгеләп үтелмичә калган 800 еллык юбилее, ягъни 1177 ел (XII йөз) датасына да ачыклык кертеп китмичә булмый. Юбилей алдыннан Кремльдә профессор А. Х. Халиков тарафыннан киң колачлы археологик казулар башлап җибәрелде. 1976—1977 елларда шәһәрнең юбилеена әзерлек алып бару көннәрендә бу юлларның авторы—ул вакытта университетның яшь доценты җитәкчелегендә бер төркем студентлар да археологик казу эшләре алып барды. Археология өлкәсендә тәҗрибә шактый иде инде. Моңа кадәр Түбән Иделнең тамагында гүзәл Актүбә буенда урнашкан Алтын Урда башкаласы Сарай әл-Җәдид шәһәрендә Мәскәү университеты профессоры Г. А. Федоров-Давыдов җитәкчелегендә унбиш еллар чамасы, үземә калса, «абруйлы раскоп начальнигы» булып эшләгән идем һәм Кремльдә апрель-июль айларында казыну эшләре алып барганнан соң июль азагында—кавын-карбыз җитешкән чорда тагын студентлар белән Сарай шәһәрен казырга төшеп китә торган идек...

Кремльдә казулар вакытында монгол чорына кадәрге болгар керамикасы (чүлмәк кыйпылчыклары) табылды. Беренче карашка зур әһәмияткә ия булмаган кебек тоелса да, керамика кебек массакүләм материал археологиядә шәһәрнең борынгылыгын дәлилләүче ышанычлы материал булып санала. Казуларда, шулай ук, күп санлы борынгы төймәләр, ук очлары, болгар чоры бина калдыклары, Багдад хәлифе Насретдин (1180—1225) исеменнән Болгарда сугылган берничә көмеш тәңкә дә табылды. Ләкин Казанның 1177 елларда гөрләп яшәп ятканлыгын күрсәткән бу материаллар уңышка ирештермәде, чөнки әлеге ел шәһәрнең барлыкка килүен күрсәткән абсолют дата буларак аек акыл белән уйлап алынмаган булып чыкты (дөресен әйткәндә, 1177 ел датасын яшь галим Рафаил Степанов күтәреп чыккан иде, ләкин кайбер партия бослары һәм галимнәр әлеге датаны тикшереп тә карамыйча «эләктереп», аны беренче күтәреп чыккан галим исемен телгә дә алмыйча шау-гөр килә башладылар) һәм бу тәнкыйтькә дучар итәр өчен үзенә бер төрле сылтау булды. Мәсьәлә шунда ки, XVI йөзгә караган (ләкин соңрак XVII—XVIII йөзләрдә күчереп язылган) 179 нөсхәдә сакланган «Казан тарихы» дип аталган һәм, күпчелек тарихчыларның раславынча, тенденциоз рәвештә бертуктаусыз сүгенә-сүгенә татарга яла ягуга корылган бу елъязманың бары бер генә нөсхәсендә хәзерге заман редакторы тарафыннан славян хәрефе «е», (ул вакытта Рәсәйдә әле хәзерге вакытта без куллана торган гарәп санын хәреф белән күрсәткәннәр) хата буларак, сан итеп кабул ителгән һәм шул сәбәпле бөтенләй булмаган 1177 датасы язып куелган *(И. Г. Добронравов, В. А. Кучкин. Этимология и старые географические объекты. «Топономика на службе географии» китабында.— М.,—1979. С.—160).* Тагын башка өч елъязма нөсхәсендә хәрефләр белән язылган 1172 ел датасы очрый кебек, ләкин бу инде булып үткән датага карый.

«Казан тарихы» елъязмасы аноним авторының фикере капма-каршы булуы тагын шуннан күренә—ул үз китабында берничә урында аңлы рәвештә Казан шәһәренең бик күпкә соңрак, ягъни XIII гасыр урталарында имештер Саин (Батый хан) тарафыннан төзелгән булуын бик тәфсилләп: «И много лет преидоше, до 300 лет, первого начало Казани от Саина царя», дип яза ул. Янсә: «И от своего царя Саина прежде зачася Казань, и словяще юрт Саинов», дип күзгә төтен җибәрә.

Елъязмачының бу раслауларына карата тик шуны гына әйтергә мөмкин,

моннан элегрәк булган, ягъни борынгырак урыс елъязмаларында һәм сакланып калган татар чыганакларында моның кебек мәгълүматлар юк—«Казан тарихы»ның авторы үзе дә моны инкарь итми: «А о первом зачале царства Казанского, в какое время, како зачяся, не обретох в летописцах русских, но мало казанских видех». Шулай булгач, XVI гасыр елъязмасын язган автор безнең өчен башка борынгырак чыганаклардан нинди дә булса яңалык китереп житкергән дип уйларга бернинди нигез дә юк.

**Кремльдә казулар.** 1994 елда 800 еллык юбилейны яңадан торгызу нияте белән Фәннәр академиясе археологлары, зур күләмдә булмаса да, Кремльдә казулар башлап җибәрде. 1995 елдан башлап Мәдәният министрлыгы һәм бигрәк тә Казан шәһәр хакимиятенең матди ярдәме белән Кремльдә Казан дәүләт университетының археология экспедициясе дә үз эшен җәелдереп җибәрде. Шушы елның июнь-сентябрь айларында үткәрелгән казуларда әлеге юлларның авторы—археология һәм этнография кафедрасы мөдире җитәкчелегендә тарих факультетының барлык беренче курс студентлары белән берлектә, археология һәм этнография кафедрасы хезмәткәрләре дә катнашты.

Югарыда искә алынган 1976—1977 елларда Кремльдә алып барылган казулар вакытында ике көйманең дә койрыгын тотарга тырышып, мин казуны Сөембикә манарасының көньяк стенасыннан берничә метр чамасы гына ераклыкта оештырган идем. Анда бер дә көтмәгәндә Сөембикә манарасына килеп тоташкан өч метр калынлыктагы борынгы стена-ныгытма табылды һәм шулай итеп, Кремль эчендә Казан патшаларының «Патша дивары» (елъязмаларда «Царев двор») дип аталган эчке кремль һәм Сөембикә манарасының аның капкалы каланчасы гына булуын ачыклаган идем.

Шуңа күрә, күпъеллык тәҗрибәдән чыгып, 1995 елның җәендә оештырылган казуларда бик борынгы Казанның ныгытма хезмәтен үтәгән стенасы соңрак Казан ханлыгы чоры Сөембикә капкасыннан төньяк-көнчыгыштарак (Казансуның югары ягында) урнашкан текә яр өстеннән үтүе ихтимал дигән исәп белән чагыштырмача зур булмаган казу эшләре Благовещение соборының төньягындагы әлеге яр өстендә 8x10 метр үлчәмендә итеп башлап җибәрелде. Казылу урыны бик тә төгәл һәм уникаль килеп чыкты. Кремльдәге казулар алып бару тарихында беренче буларак, анда чуер таштан салынган һәм җир астында ике метрдан артык биеклектә сакланган (3,1 метр калынлыкта) X—XII гасырларга караган стена табылды.

**1000 еллык белән бәйләнгән ыгы-зыгы.** Кремльдә җәйге сезон казу эшләре тәгәлләнгәннән соң, 1995 елның 18 октябрендә декан (ул вакытта декан урынбасары) Рәмзи Вәлиев җитәкчелегендә методик семинар булып узды. Казан дәүләт университеты тарих факультетының профессурасы һәм башка хезмәткәрләре каршында бу юлларның авторы тарафыннан «Казан шәһәренең барлыкка килүе» дигән темага доклад укылды. Докладта Казанның килеп чыгышы турындагы төрле фаразларга һәм елъязма хатасына корылган һәм үткәрелми калган 800 еллык юбилее турында сөйләгәннән соң, беренче мәртәбә буларак, «Күпсанлы археологик табылдыклар, шул исәптән X—XI йөзләр белән бәйле хазар һәм болгар керамикасы, болгар таңкаләре, бик борынгы кулъязма чыганаклар, шулай ук урта гасыр карталары Казанның 1000 еллык шәһәр булуына төпле дәлил булып торалар» дигән нәтиҗә ясалды. Әлеге сүзләрне дәлилләү өчен докладтагы тезисларның берничәсен ничек укылган булса шул рәвешле, ягъни документ буларак урысча нөсхәдә тәкъдим итәбез.

## Возникновение города Казани

*(Тезисы доклада, прочитанного на методическом семинаре истфака КГУ 18 октября 1995 г.)*

1. Хронология возникновения древней Казан мало исследовано и далека от окончательного решения. Археологические ракопки, проведенные в Казанском Кремле, показывают, что город возник в очень глубокой древности. К сожалению в прошлом датировка возникновения Казани базировалась на дошедших до нас поздних письменных источниках. Поэтому в своем докладе я старался указать на несколько таких возможных дат для того, чтобы, посоветовавшись, выбрать наиболее убедительную, опирающуюся


как на археологические материалы, так и на письменные источники, дату возникновения города Казани.

**2.** Основная трудность опеределения абсолютной даты возникновения города по письменным источникам заключается в том, что современное его название «Казань» возникло сравнительно поздно (и, судя по некотором данным, связано с именем правившего в Казани Хасана). В период своего многовекового существования город пережил периоды подъема и упадка и не раз менял сове название. Убедительным аргументом этого является то, что на десятках тысячах монет казанского монетного двора первой половины XV века, следуя старой традиции, место чеканка официально обозначено как «Булгар», и это несмотря на то, что древний Булгар уже давно переживает свое административное значение. Лишь на очень древних письменных источниках и на редких монетах XIII и XV вв., а также на некоторых итальянских картах XIV в. встречается древнее название города как Керман, то есть «крепость», «укрепленное место».

**3.** Первые поселения на месте древней Казани возникли еще в железном веке, то есть приблизительно 3 тыс. лет назад. Дело в том, что подобные созданные природой удобные места для постройки укрепленных поселений никогда не пустовали. Высокой крутой мыс слева омывался могучей рекой (современный Булак–старица древней Волги), а справа протекала быстротечная Казансу (Казанка) с крутыми берегами.

В то же время нет смысла связывать возникновение Казани с поселениями каменного или железного века. По-видимому, они были крайне бессистемны и располагались на бескрайних просторах Средней Полосы. К тому и этническая принадлежность племен, населявших подобные поселения или городища до сих пор вызывает споры и трудно доказуема. Совершенно новым и уникальным явлением для Поволжья и Северного Кавказа было появление очень ранней даже для всей Восточной Европы довольно высокой государственной цивилизации, созданной хазарами, которую армянские источники VII в. («История Албан») называли Туркестаном. Именно в ее недрах появляются зачатки Казани как таковой.

**4.** Сначала рассмотрим более древний вариант возникновения города. Систематические находки хазарской керамики в древнейшей части Казани–в Кремле показывают, что город как небольшой, но укрепленный форпост, возник не позже X века. Именно здесь скрешивались интересы хазар (в составе которых находились булгары, сувары и другие тюркские племена) и норманнов, рыскавших по всей Восточной Европе и поисках легкой добычи. Ибн-Русте писал (IX–X вв), что хазары, опасаясь соседних племен «окапываются рвами», а царь хазар Иосиф в письме, написанном в 960-х годах и




*XIV гасырда Идел буе. Каталония атласының (1375) Зур картасыннан алынган бүлек.*

адресованном сановнику кордовского халифа Абдурахмана еврею Шафруту ибн-Хасдаю сообщал, что он охраняет Волгу от руссов (норманнов): «Я воюю с ними. Если бы я их оставил в покое на один час, они уничтожили бы всю страну мусульман до Багдада». Подобных Казани городищ в средневековье было достаточно много, но такого важного по значимости и укрепленного самой природой (как Казань) во всем Нижнем или Среднем Поволжье больше не было. Видимо, не случайно царь хазар Иосиф, описывая северные границы своих владений, упоминает страну Б-ц-ра (Мещера) и Х-г-риим (Керем, Керман—«крепость», т. е. Казань), куда могли дойти некоторые кочевые племена, платившие дань царю хазар. То, что Керим или Керман—это Казань видно из средневековых карт. На карте венецианцев Франциска и Доминика Пицигани 1367 г. под изображение города Казани написано: cormancucho, а на карте Каталонского атласа 1375 года Казань нарисована более крупным городом, чем Булгар и с уникальной надписью—буквальным переводом названия города на латинский—castrama, то есть «укрепленное место», «лагерь».

Сказанное подтверждается обнаруженной в Казанском Кремле хазарской и раннебулгарской керамикой второй половины X в., которая достаточно убедительно доказывает 1000-летний возраст Казани.

Позднее под 1236 г. в период монгольских походов персидский историк Рашидеддин упоминает Кернек, видимо, Керман, то есть Казань, разрушенный монголами, наряду с Булгаром и другими городами Поволжья. В золотоордынский период город Казань переживает расцвет, о чем свидетельствуют монеты, выпушенные в 80-х гг. XIII в. с обозначением места чеканки «Керман».

Следует также добавить, что 1000-летие Казани совпадает с другим юбилеем, которой состаится в 1997 году. Как известно, в 737 году в Хазарском государстве (то есть в Восточной Европе) официально была принята одна и мировых религий—ислам, что подтверждается, кроме письменных источников, моссовой чеканкой в VIII в. на берегах Волги дирхемов, основанных на арабской графике.

Биредә шунысы гаҗәп, әлеге методик семинар турындагы хәбәр Фәннәр Академиясе даирәләренә дә, шәһәр хакимиятенә дә тиз арада барып җитте һәм икенче елны ук Кремль казуларын финанслау эше бермә-бер артты...

Шулай итеп, Казанның 1000 еллык шәһәр булуын беренче мәртәбә фәнни нигездә раслап чыгуда приоритет, ягъни өстенлек КДУның тарих факультеты өлешенә туры килде. Югарыда әйтеп үтелгән елларда Казан Кремленең Казансу буена якынрак урнашкан борынгы өлешендә КДУ археологлары һәм студентлары, шулай ук шактый киң күләмдә Татарстан Фәннәр Академиясе хезмәткәрләре *(П. Старостин, Т. Хлебникова, Ф. Хуҗин, А. Ситдыйков, Н. Нәбиев һ. б.лар)* көче белән киң колачлы масштабта археологик казулар үткәрелде. Алар чыннан да Казан шәһәренең барлыкка килүе бик борынгы заманнарга караган булуын, һәм казуларда табылган күп санлы табылдыклар, X—XII йөзләрдә сугылган таңкәләр—акча йөреше барлыкка килүе, ягъни шул дәверләрдә үк шәһәр тибындагы яшәү урыны барлыкка килүе турында сөйлиләр.

Әлбәттә, югарыда сөйләнгән нәрсәләр бар да болай язылганча шома гына бармады. Күңелдә төзәлмәслек җәрәхәт калдырган төрле ыгы-зыгылар аз булмады. Түбән мәнфәгатьле явыз кешеләр һәр җирдә дә бар—Казан галимнәре арасында, кызганычка каршы, бигрәк тә. 1976—1977 еллардагы казулардан соң «Вечерняя Казань» газетасы битләрендә Сөембикә манарасының эчке Кремль капкасы булуы турында язып чыккач (ул вакытта әле аның стенасында «Сторожевая башня XVII в.» дигән язулы мәрмәр такта ыржаеп эленеп тора иде), газетаның гади укучыларыннан алып, төрле галимнәргә кадәр нинди генә исемнәр тагып бетермәделәр дә нәрсә генә дип сүкмәделәр. Ә югарыда әйтелгән 1995 елның 18 октябрендә укылган докладтан соң, Фәннәр академиясенең археология бүлеге мөдире кафедрага менеп, көтмәгәндә (ул вакытта әле төрле этлекләрдә чыныккан элекке партия боссляры бар иде) безләрне пычракка мана-мана сүкте. Икенче елны исә студентларның археологик практикасын уздырырга кирәк, Актүбә буйларына китеп булмый—акча юк, ә шул ук «акыллы башлар» ыгы-зыгы оештырып, утыз ел дәвамында ел саен язылып киленгән казулар отчетыннан сылтау өчен гаеп тапкан булып, Кремльгә кертмиләр...

Казанның мең еллыгына каршы төшкән әлеге кешеләр (алар 800 еллыкны яңадан күтәрергә маташалар иде, ул турыда китап та әзерләгән иделәр һәм әлеге датаның урыс елъязмаларында телгә алынуының хатага корылган булуын белми яки аңламый иделәр), хәзер инде әлеге приоритетны үзләренеке итеп күрсәтмәкче булып йөри башладылар. Хәтта ниндидер Мәскәү археологлары да белмәгән (Мәскәү юбилеен билгеләгәндә) яңа методика турында төтен җибәрә башладылар. Монда кайбер татар галимнәре арасында фәнни этика җитмәве турында гына сөйләргә мөмкин, ә методика турында түгел. Археологиядә дәлилләү методикасы бер генә: язма чыганаклар һәм казып табылган археологик яки нумизматик материалларның ышанычлы һәм җитәрлек булуы.

Казанның мең еллыгын рәсмиләштерүдә «яңа методика» булып, чынлыкта исә, киң җәмәгатьчелекнең, халыкара конференцияләрне дә исәпкә алганда, меңләгән кешенең катнашуы тора. Бу турыда, 1976—1977 еллардагы казуларда да катнашкан кеше буларак, шуны әйтә алам: биредә төп рольне Татарстан Республикасы Президенты һәм аның командасы, шул исәптән Казан мэры Камил Исхаков активлыгы уйнады. Ул хәтта еш кына казылмаларны да үзе килеп кызыксынып карап йөрде. Монда шулай ук аның тарафыннан Кремльдәге казуларны оештыру һәм финанслау да (бигрәк тә мең еллык рәсми төсмер алганчы!), еш килеп торган күпсанлы төрле ил кунакларын кунакханәләргә урнаштыру гына түгел, ә «күңелләрен күрү» һ. б. да аның вазифасына керә торгандыр. Мисал өчен, «минем исемемне йөрткән» Каһирә университетының (әл-Әзһәри!) өч профессоры гына да ике тапкыр конференциягә килде. Ләкин нәрсә генә булмасын, фәндә этика дигән нәрсә яши һәм шуңа күрә барыбер мең еллыкның чишмә башы 1995 елның 18 октябрендә университетның тарих факультетында археология кафедрасы мөдире тарафыннан профессура каршында укылган докладтан башлана, аны күтәреп чыгу өчен исә кыюлык кына түгел, ә археология, нумизматика һәм тарих өлкәсендә күпьеллык тәҗрибә дә, җитәрлек дәрәҗәдә белем дә кирәк дисәм, бу шапырыну булмас дип уйлыйм һәм мондый тәкъдимне ачыш буларак, аның авторлык хокукын саклау законда каралган.

**Борынгы Казан** урнашкан җирдә беренче яшәү урыннары—торлаклар таш һәм тимер гасырларында ук, ягъни моннан 2,5 мең ел чамасы элек барлыкка килгәннәр. Моны, мәсәлән, археологик казулар барышында яңа эрага кадәрге ананьино чорына караган балчык савытлар, 1997 елда XIV казылмадан табылган бакырдан эшләнгән түгәрәк чәчкап һәм 1998 ел казылмаларындагы бакыр өтерге һәм башка табылдыклар раслый ала.

Археологларга мәгълүм булганча, борынгы ныгытылган торлаклар кору өчен табигатьнең үзе тарафыннан текә Кремль тавы кебек уңайлы булган урыннар беркайчан да буш тормаган. Бу урында текә кыялы Кремль тавының сул ягыннан куәтле Идел елгасы (хәзерге Болак—Кабан күле—борынгы Иделнең үзәне), ә уң яктан биек ярларын тутырып тиз агышлы Казансу елгасы аккан. Геологларның эзләнүләренә караганда һәм археологик казулар күрсәткәнчә, төзелеш материалларына бу заманнарда бер дә кытлык булмаган. Урыны белән өскә чыгып торган таш катламы Кремль тавы астында зур бер яссылык (плато) тәшкил итә һәм таш калалары белән дан тоткан Кырым белән тарихи бәйләнешле болгарлар, төзелеш материалы буларак, таштан оста файдаланганнар. Шуңа күрә, еш очрый торган, Казан каласы (ныгытмалары) башта агачтан булган икән дигән фикер яки ялганга, яки наданлыкка корылган.

**Татар тарихының яңа концепциясе.** Казан шәһәренең барлыкка килүе турында сүз алып барудан элек, Урта һәм Түбән Идел буйларындагы тәрәккыять тарихына тукталу, икенче төрле әйтсәк, беренче феодал дәүләтләр барлыкка килү, шәһәрләрнең тууы һәм үсүе мөмкинчелеген ачыклап китү мөһим. Чөнки XIX йөздә татар тарихыннан хәбәрдарлыгы чамалы булган Рәсәй (һәм кайбер хәзерге татар) тарихчылары кебек, Идел йорт цивилизациясен татар-монгол чоры белән генә бәйләп китсәк, Казанның меңъеллыгына бернинди урын да калмый. Югарыда искә алынган Казанның 800 еллыгын тәнкыйтьләүгә корылган мәкаләдә шулай дип язылган да. Анда, шулай ук, Казан шәһәре, имеш, чуашча «Хусан» дип атала һәм шуңа күрә ул берничек тә татар шәһәре

була алмый, ә болгар-чуаш шәһәре булган дип өстәлгән.

1999 елның язында Тарих факультетының 60 еллыгына багышланган конференциянең пленар утырышында бу юлларның авторы тарафыннан, феодализм чоры тарихы, археология һәм нумизматика өлкәсендә шәхсән эшләнгән эшләр тәҗрибәсеннән чыгып, татар халкы тарихының концепциясе тәкъдим ителде. Бу концепция буенча Идел буе дәүләтчелеге тарихы бер-берсе артыннан закончалыклы рәвештә килгән биш чорга бүлеп карала. Аларның иң **беренчесе**—һуннар (искилләр—эфталитлар) чорына караганы—археологиядә имән-кискәлеләр культурасы дип атала һәм IV—VII йөзләр белән чикләнә; **икенче чор** VII—X йөзләрне, ягъни Көнчыгыш Европада беренче феодал дәүләт—Хазар империясе яшәгән чорны эченә ала; **өченчесе**—Хазар дәүләте вакланганнан соң аерылып чыккан Болгар дәүләте чоры (X-XIII йөзләр); **дүртенчесе**—Алтын Урда (XIII—XV йөзләр) чоры, һәм ниһаять, **бишенчесе**—Алтын Урда вакланганнан соң XV—XVI гасырларны үз эченә алган Казан (һәм башка татар дәүләтләре) ханлыгы чоры. Бу концепциянең үзенчәлеге шунда, һәр чор дәүләтенең башкаласы Идел буенда урнашкан, ягъни уртак материаль культуралы төрки-татар тарихы белән турыдан-туры бәйләнгән һәм татар халкының килеп чыгышын һуннар империя төзегән көнбатыштан да яки гомумтөрки тарихына бәйле көнчыгыштан—Алтайдан да эзләп йөрисе юк.

Кызганычка каршы, икътисади яктан зур үсешкә ирешкән үзәк территорияләре һәм башкалалары Идел-йортта урнашкан бу дәүләтләрнең культура мирасы татар тарихында өйрәнелмәгән диярлек. Ни дисәң дә, бу бит дәүләтчелек тарихын, матди һәм рухи культура мирасын буыннан-буынга тапшыру, кабул итеп алу дигән сүз. Мәгълүм булганча, соңга табарак «Идел төркие» дип аталган тел Хазар империясендә үк гомум дәүләт теле булып әверелә һәм бердәм культура яссылыгы барлыкка килә. Кремль борынында алып барылган казуларда әлеге чорларга караган табылдыклар теге яки бу формада үзенең чагылышын табалар.

Мисал өчен, 50 еллардан башлап Кремльгә кагылышлы эшләп киленгән стратиграфик шкала буенча, Казан ханлыгы чорына караган культура яткыны 3 нче катламга, Алтын Урда дәверенеке 4 нче, ә монголларга кадәрге культура катламы, ягъни имән-кискәле, хазар һәм болгар чорлары барысы да 5 нче катламга карыйлар. Алар, нигездә, үзенә күрә аерым, кызыклы, ә кайбер очракта шактый күп санлы табылдыклар белән аерылып торалар, әмма, Болгар чорын исәпләмәгәндә, аларны хәзергә аерым катламнар итеп каралык түгел—алар аз өйрәнелгән һәм начар сакланган.

Җиз йөзек кашына басылган свастика рәвешендәге (борынгы төрки телендә суастик!) буддизмның тылсымлы яшәеш һәм кояш тамгасы һәм XV казылмада табылган үзенчәлекле шамотлы (яндырылган кызыл балчык төеп салынган) керамика бер дә очраклы гына түгел, ни өчен дигәндә, Идел-Кама көнкүрешендә бу культура «имән-кискәле» дип атала һәм IV—VII гасырларга карый. Ул Агыйдел, Кама һәм Идел елгалары арасындагы киң мәйдандагы җирләрне биләгән була. Моңарчы бөтенләй мәгълүм булмаган бу культура Балык бистәсе районына караган Имән-Кискә авылының исемен алды һәм танылган археолог В. Ф. Генниг тарафыннан, беренчеләрдән булып, монда имән-кискә эпохасына караган тарихи табылдыклар һәйкәле ачылды. Көньяк-көнчыгыштан үтеп кергән һәм соңыннан болгарлар белән кушылган имән-кискәлеләрне Генниг хаклы рәвештә төрки кабиләләр дип атады. Имән-кискәлеләр язма мәдәнияткә ия халык була. Моңа IV—VIII гасырларга караган югары зәвык белән затлы металлдан эшләнгән савытлардагы язулар да дәлил була ала, ә алар фәкать Идел белән Урал буе төбәкләрендә генә табылганнар. Әлеге бик борынгы төрки телендәге һәм төрки руннарының нигезен тәшкил иткән, ягъни аның килеп чыгышы белән бәйләнгән туран алфавитында язылган язуларны укып, бу юлларның авторы төрле мәкаләләр рәвешендә дә һәм аерым китап итеп тә бастырып чыгарды.

Имән-кискәлеләр шулай ук, беренче буларак, һәм киң рәвештә сәүдә белән дә кәсеп иткән халык. IV—VII гасырлардагы имән-кискәлеләрдән торган күпсанлы халык яшәгән һәм Көнчыгыш Европада беренче булып металлдан акчалар (сомнар) коелган Идел буендагы гаять бай культура катламына һәм

бакыр кою остаханәләренә ия булган торлаклар—феодаль чор шәһәрләрен хәтерләтәләр. Кремль борынындагы имән-кискәле табылдыклары бер дә очраклы түгел һәм бу, күрәсең, имән-кискәле заманнарында ук анда яхшы ныгытмалы сәүдә форпосты урнашкан булуын дәлилли. Имән-кискәлеләр турында сүз чыккач, тагын бернәрсәгә тукталып үтмичә мөмкин түгел. Совет чорында кайбер провинциаль шовинист археологлар аларны славян булганнар һәм соңрак көнбатышка таба күченеп киткәннәр дип язып чыккан иделәр. Язып чыгу бер нәрсә, ә менә дәлилләү икенче нәрсә. Хикмәт шунда ки, имән-кискәлеләр беркая да күченеп китмәгәннәр, чөнки югарыда телгә алынган җиз акчалар—сомнар хазар-болгар чорында да коелганнар һәм Идел Урал буйларында X—XII йөзләргә кадәр акча берәмлеге булып йөргәннәр. Әгәр имән-кискәлеләр күченеп китсә мондый акчалар көнбатышта барлыкка килгән булыр иде һәм борынгы Киевтә хазар-болгар тәңкәләре йөрмәс, ә үз тәңкәләре сугылыр һәм йөрер иде, яки иң беренче Мәскәү тәңкәләре татар тәңкәләренә охшатып сугылмас һәм аларның бер ягында татар язуы урнаштырылмас, аларны исәпләү өчен денга (дәнгә), алтын, сум, пул (бакыр тәңкә) кебек татар терминнары кулланылмас иде. Болай үртәлеп язуымның сәбәбе бар. Заманында шул провинциаль шовинист археологларның имән-кискәлеләр славян булганнар дигән фикерен ишеткәч, атаклы археолог А. В. Арциховский: булмас, әгәр алар славян булса, Идел буендагы барлык башка кабиләләрне дә суеп бетергән булырлар иде, дигән. Хәзерге вакытта кайбер Мәскәү археологлары да шул имән-кискәлеләр славян булган дигән фикерне хуплый башлады. Алай гына да түгел, Татарстан нәшриятында ФА Тарих институтының күптомлыгы басылып ята һәм аның беренче томы әчтәлегенә караганда, без, хөрмәтле укучылар, Казан алынганчы әллә кайчан инде килмешәк булганбыз һәм кеше җирләрендә яшәгәнбез, ә барлык Казан халкын суеп бетергән Иван Грозный славян җирләрен азат итеп йөргән икән ләбаса... Шуларны уйлыйсың да башка һаман шул бер үк уй кат-кат килеп йөдәтә: моннан биш ел элек төзелгән Тарих институты, җитәкчелеге башка өлкә белгече булганлыктан, тарихка җиңел генә караган, чеп-чи ялганнан торган пычрактан юынып, чистарынып бетә алыр микән, беткән очракта да әлеге тенденциозлыкка корылган уйдырма татар халкы тарихына ябышып калмас микән?! Болай да бит Казаннан чыгып китү белән типкәләргә генә торалар. Әнә ич, Волгоградта студентлар белән автобуста Мамай курганына барганда, экскурсовод, бик белдекле булып, биредә элек канәчкеч татарлар яшәгән, урыслар килеп бу җирләрне азат иткән, дип сөйләгән иде...

**Хазар патшасы Йосыф хаты.** Казан Кремлендә болгар чорына караган керамик әйберләр сериясеннән шактый күп санда хазарныкылар да очрый һәм бу да бер дә очраклы гына күренеш түгел. Идел һәм Тын (Дон) буе, Төньяк Кавказ һәм Кырым өчен хазар кабиләләре тарафыннан шактый югары культуралы дәүләт төзелгән булуы Көнчыгыш Европа өчен зур яңалык һәм уникаль күренеш санала. Башкаласы Идел буенда урнашкан Хазар дәүләте 300 елдан артык (VII—X гасырлар) яшәгән. Иран һәм Византия белән бәрабәр дәвердә бу чәчәк аткан дәүләт урта гасырлар башы өчен әлеге империяләр белән тиң саналган. Иран шаһлары яки Византия императорлары куәтле Хазар империясе белән дустанә яшәр өчен үзара ярыша-ярыша кызларын хазар бегичләренә (принцларга), ә улларын хазар каганы кызына өйләндерергә тырышканнар. Византия императорының улына кияүгә чыккан бер хазар каганының кызы Цәцәк (Чәчәк) исемле булган.

Яшь һәм көчле дин белән коралланган гарәп хәлифәлеге пәйда булу һәм аның белән бәрелешү нәтиҗәсендә (каты гына сугышлар Кавказда нефть—гарәпчә нафт чыганакларын кулга төшерү өчен барган) хазарлар рәсми рәвештә 737 елны ислам динен кабул итәләр. Бу турыда Петербург нумизматы А. А. Быков болай дип язган иде: «Сторонники ислама в VIII и в начале IX в. являлись в Хазарии носителями одной из наиболее передовых культур, с которыми приходилось сталкиваться хазарам...» Исламның Идел буенда рәсми рәвештә 737 елда кабул ителүен татар тарихчылары күрмәмешкә салыша. Ләкин без капчыкта ятмый дигән кебек, Идел буенда исламның акрынлап һәм киң рәвештә таралган булуын хазар башкаласы Итилдә гарәп хәрефләре белән сугылган меңләгән дирһәмнәр дәлилли. Югарыда телгә алынган А. А.

Быков Итил шәһәрендә сугылган тәңкәләр турында болай дип яза: «Невозможно поэтому не учитывать огромной роли Хазарского каганата, через который пролегал путь, снабжавший в IX в. серебром **население и Восточной, и Центральной, и Северной Европы.**» *(ассызыклау минеке—Ә. М.)*

Әмма хазарлар империя тоткан халык буларак, башка диннәргә карата да зур түземлелек күрсәткәннәр. Мөселман мәчетләре белән янәшә шәһәрләрдә христиан һәм яһүд динендәгеләрнең дә чиркәүләре яки синагогалары корылган була һәм үзара килеп чыккан низаглар хазар заканы (хазар сүзе булган закон тамырында «сак» сүзе ята, караим телендә «сакан» рәвешендә сакланган) буенча тикшерелгән. IX гасыр тирәләрендә хазар патшасы станы, ягъни бер өлеш аксөяк катлам, мөселманнарның рухани башлыгы—хәлифтән бәйсез булу өчен, яһүд динен кабул итә, ләкин бу дин традицион тәңречелек өстенлек иткән җәйләүләрдәге күчмә тормышлы халыклар арасында да, күпчелеге мөселман өммәтендә булган шәһәрләрдә дә киң рәвештә таралыш тапмый. Хәзерге вакытта беркадәр Белоруссиядә һәм Польшада сакланган «цана», «цалма», «пыцак» дип сөйләшкән һәм яһүд динендәге караим татарларын шул дин алмаштырган хазар кабиләсе токымыннан дип саныйлар. Хикмәт шунда ки, хазарлар һәм болгарлар үзләрен «төрки» дип атаганнар, хәтта кайбер чыганакларда Хазар дәүләте «Төркестан» дип телгә алына. Шуңа күрә Хазар дәүләте вакланганнан соң «хазар», йә булмаса Болгар дәүләте җиңелеп Кыпчак дәүләте төзелгәннән соң «болгар» дигән исем йөрткән халыклар сакланмаган, чөнки андый халык булмаган да. Хазар яки болгар кебек әлеге атамалар төрле исемдәге төрки кабиләләрен берләштереп дәүләт төзи алырдай көчле һәм куәтле кабилә исемнәре генә булганнар һәм шулай булып калганнар, ягъни кабиләләр, ырулар бетү белән юкка чыкканнар да, чөнки аларның берсе дә барлык кабиләләр өчен гомуми һәм уртак булган төрки этнонимын алмаштыра алмаган.

X гасырның 60 елларында хазар патшасы Йосыфның борынгы яһүд телендә язылган бик кызыклы бер хаты сакланып калган. Испан (Кордова) хәлифе Габдрахманда хезмәт иткән яһүд Хасдай ибн-Шафрут хазар патшасына хат юллаган була. Әлеге хатта ул үҗәтлек белән «яһүдиләр» дәүләтендәге хәл-әхвәлләрнең торышы белән кызыксына. Хазар каганы Йосыфның югарыда телгә алынган хаты исә шул Хасдайга җавап буларак язылган. «Мин Итил елгасы буенда яшим,—дип язып китә үзенең хатында каган,—бу елга буенда—буртас, болгар, сувар, арисулар, цирмецләр (угро-финнар), славяннар кебек бик күп халыклар яши». Аның сүзләренә караганда, алар ачык җирләрдә генә түгел, ә каланчалар белән уратып алынган ныгытмалы шәһәрләрдә дә яшиләр. «Аларның барысы да миңа хезмәт итәләр һәм ясак түлиләр...»,—дип хатын дәвам итә ул.

Хазар патшасына ясак түләп торучы болгарлар һәм башка кабиләләр турындагы бу хәбәр безгә шул турыда сөйли, алар күчмә тормышлы халыклар гына түгел, ә «ныгытылган диварлар белән уратып алынган шәһәрләрдә дә» яшиләр икән.

Соңгысын археологик эзләнүләр дә раслый. Хазар каганаты вакытында Урта киңлектә йөзләгән, гомумән, беренче мәртәбә кирпечтән (кәрпәчтән), гүзәл итеп шомартылган ак таштан корылган шәһәрләр һәм авыллар пәйда була. Урман-далалы урыннарда шәһәрчекләр тирәсендә күпләп урнашкан авыллар гадәти бер күренеш санала. Шәһәрчекләр исә Казан кебек үк биек кыя башында урнашкан ныгытмадан—кирмәннән торган *(С. А. Плетнева. Хазары—М.,—1976—С. 73).* Алар, гадәттә, элегрәк скифлар (!) салган торак урыннарына яисә шәһәрчекләр булган җирләргә (ягъни алар үзләре «скиф» булган) аларның ныгытмаларын яңартып корылганнар. Бу археологик фактлар искиткеч кызыклы һәм имән-кискәлеләр, хазар яки болгар кебек кайбер төрки-татар кабиләләренең күчмә булулары турында берниндн дәлилсез диярлек күпертелгән мәсьәләнең бик каты сорау астында булуы турында сөйлиләр.

Йосыф каган үзенең хатында кайбер шәһәрләрнең исемнәрен дә атап уза. Әмма аларның урыннарын билгеләү яки бу шәһәрләрне хәзерге исемнәр белән янәшә куеп карау шактый кыен хәл; ни өчен дигәндә, аларның урнашкан урыннары мәсьәләсендә галимнәр арасында күп кенә каршылыклар яши, әмма ул шәһәрләр арасында таныш исемнәр дә бөтенләй юк түгел. Мисал

өчен, Кырымдагы Керц (Керчь), хазарның Кавказдагы тәүге башкаласы Сәмәндәр, Идел буендагы башкаласы Итил, Тын (Дон) буендагы Сары Кала (Саркел) һәм шулай ук Алубиха.

Керц шәһәрен әгәр Керчь белән охшаш дип карасак, ул вакытта, хәлбуки, борынгы Көнчыгыш Европа шәһәре бигүк билгеле булмаса да, Алубиханы да Алабугага тиңләп карауда җирлек бар. Текә Идел ярында урнашкан Казан бик мөһим сәүдә үзәге шәһәрләреннән саналган булса, текә яр башында урнашкан Алабуга да затлы тире белән сәүдә итү юлы үткән Кама төбәгендә шундый ук зур роль уйнаган. Кызыл балчыктан яндырып эшләнгән савыт-сабадан чыгып фикер йөрткәндә, Казандагы кебек тулы канлы яшәеш монда да борынгы төрки халыклардан саналган имән-кискәлеләр (IV—VII гасырлар) дәверендә, ягъни Хазар дәүләте чорында ук башланган була. Археологик казылмалардан күренгәнчә, Алабуга шәһәрчеге гаҗәеп архитектуралы мәчет-кирмәннән гыйбарәт. Ул калын итеп эшләнгән ныгытмалы алты каланчадан тора (аның берсе безнең көннәргәчә сакланып калган), ягъни мәчет бер манаралы гына түгел, ә алты манаралы итеп салынган. Әлеге үзенчәлекле архитектура мәчетнең салынган вакытын да чамаларга мөмкинлек бирә. Мондый ныгытмалы мәчет-кирмәннәр исә Гәрәбстанда VIII—IX йөзләрдә ислам динен тараткан дәверләрдә барлыкка киләләр.

Шик юк, Идел яры башында, ягъни эре сәүдә юлында урнашкан Казан каласы кирмән буларак та зуррак әһәмияткә ия булган билгеле. Биредә хазарларга һәм борынгы болгарларга (имән-кискәлеләргә) урманнарда яшәүче кабиләләр белән алыш-биреш итеп кенә түгел, кайвакыт Идел буйлап төшкән дошман көчләр белән дә бәрелешергә туры килгән.

Кремль борынының Сөембикә манарасы урнашкан төньяк-көнбатыш яртысындагы тирән ур белән бүленгән Казанның тагын да борынгырак дәвердәге өлешендә хазар, иртә дәвер болгар һәм имән-кискәлеләргә нисбәтле чүлмәк ватыклары һәм башка табылдыкларның очрап торуы шуны күрсәтә ки: ул кадәр зурдан ук булмаса да, ныгытылган форпост кыяфәтендәге бу шәһәрнең X гасыр ахырларыннан да соңармыйча барлыкка килүен күрсәтә. Мәсәлән, 1999 елда Айрат Ситдыйков тарафыннан оештырылган казу эшләрендә күпсанлы таш корылмалар, ныгытмалар, янйөреш—тротуарлар, бер-берсе белән кисешүче (төрле чорларга карагангa күрә) күперчекләр вә бихисап сандагы ук очлары да табылды һәм шунда ук Византиядә эшләнгән кызыл лаклы чүлмәк фрагментлары да килеп чыкты.

Хазарлар һәм, сәүдәдән бигрәк, җиңел табыш эзләп айкалган норманнарның (Йосыф каган славяннардан аеры буларак аларны урыслар дип атый) мәнфәгатьләре нәкъ менә шушы борынгы сәүдә юлы үткән Идел-Кама буенда кисешкәннәр һәм чагылыш тапканнар да инде.



*Казан күренеше. XV гасыр гравюрасы.*

Дошманлашып яшәүче кабиләләрдән саклану өчен IX—X гасырларда ук әле хазарлар тирән урлар, ягъни ныгытмалар, кирмәннәр төзегәннәр дип яза Ибн-Рөстә. Йосыф каган телгә алган әлеге хатында бу хакта үзенең Идел буйларын урыслардан (норманнардан) саклавы турында болай дип яза: «Мин алар белән сугышам. Әгәр мин аларны бер генә сәгатькә булса да тынычлыкта калдырам икән, алар Багдадка кадәр җәелгән барлык мөселман илләрен тар-мар китергән булырлар иде».

**Борынгы Казан ныгытмалары.** 1995 елның 18 октябрендә тарих факультетының методологик семинарында Казан шәһәренең 1000 еллыгын билгеләп

үтү турында кузгатылган мәсьәлә бер дә очраклы гына түгел иде. Билгеләп, үтелгәнчә, Благовещен соборыннан төньяк-көнчыгыш якта җайлашкан КДУның археологик экспедициясе борынгы Казанның X—XII гасырларда торгызылган ныгытмасына тап тулды. Шәһәрне саклау максатыннан торгызылган әлеге ныгытмаларда 1999 елда һәм аннан соңгы елларда үткәрелгән археологик казылмалар да (7 казылма!) табылган стенаның чыннан да монголларга кадәрге чорныкы булуын раслый. Хуҗалык өчен казылган берничә чокырлар яисә янәшә урнашкан Алтын Урда, хәтта Болгар дәверенә караган корылмаларның да әлегәчә бу таш ныгытма астына кергәне очрамады, ягъни ул бик борынгы. Димәк, археология фәне өчен тикшеренү объекты булып хезмәт иткән бу стенаның борынгы Казан ныгытма системасына караганлыгы инкарь ителмәслек аргументлар белән раслана. Археологик казулар барышында табылган күп санлы тәңкәләрнең әһәмияте шунда ки, алар шәһәрнең XI—XII гасырларда кешеләр тупланып яшәгән гади торлак кына түгеллеген, ә натураль алыш-биреш, металл акча әйләнеше хөкем сөргән шәһәр тибындагы яшәү урыны булуының төп шаһиты саналалар. Сүз уңаенда шунысын да әйтеп китәргә кирәктер, КДУ тарафыннан оештырылган археологик экспедициянең әһәмиятен ничек тә кечерәйтеп күрсәтергә тырышу максатыннан чыгып, кайбер археологлар борынгы Казан ныгытмасы системасына караган бу таш дивар 1970 елларда ук билгеле булган дип язалар. Әмма, 1976—1977 елларда археологик казуларда катнашучы буларак, мин шуны раслап әйтә алам: А. Х. Халиковның Кремльдәге археологик казуларда аспиранты Л. Шавохин тарафыннан, чыннан да, югарыда телгә алынган стена өстендә (кочегарка почмагында) казулар алып барылды. Шомартылган таштан салынган һәм Сөембикә манарасын хәтерләткән (ян-якта шундый ук икенче катка менә торган баскычлары бар) башняның бөтенләе белән сакланган беренче каты табылды. Ләкин, аны XVII йөзгә карый диган исәп белән, казу эшләре тәмамлаганчы ук (археологиядә мондый ярым-йорты казуга караш бик тискәре) бу урын күмелеп куелды. 1995—2000 елларда шул манараны табарга тырышып берничә урында казулар оештырып карасам да аны табып булмады, чөнки, беренчедән, казып бетерелмәгәнгә һәм отчет язылмаганга күрә казылманың төгәл урынын билгеләү авыр; икенчедән, бу тирәдә культура катламнары 10 метр чамасы калынлыкта булганлыктан эзләве дә җиңел түгел...

**Казанның Борынгы исемнәре.** Язма чыганакларга таянып, шәһәрнең барлыкка килү датасын билгеләүдәге четерекләкләр шуннан гыйбарәт ки, аның «Казан» дигән бүгенге исеме соңрак барлыкка килә. Галимнәр арасында кайберләре шәһәр исеме «каз» атлы хазар кабиләсе исеменә «ән» (җир) кушылудан килеп чыккан дисәләр, икенчеләре исә XIV гасырның 70 елларында Болгар җимертелеп, аның әмире Булаттимер (1361—1367) һәлак булганнан соң, үз башкаласын куркынычсызрак урынга яхшы ныгытмалы Казан кирмәненә (дөресрәге, казулардан күренгәнчә, иске ныгытмалар инде җимерелгән булган, чөнки урда ханнары шәһәрләр тирәсендә ныгытмалар төзүне тыйганнар. 1368—1370 елларда Казан кирмәне яңадан торгызылган) күчерүче әмир Хәсән (Къәсән, Казан кирмәне, ә соңрак куштанланып фарсыча Казан каласы дип йөртә башлаганнар) исеменнән килеп чыккан дигән карашны алга сөрәләр.

Язма чыганаклар, нумизматикага караган күпсанлы табылдыклар һәм урта гасыр карталары раславынча, үзенең меңнәрчә елларга сузылган яшәеш дәверендә шәһәр чәчәк ату белән бергә, тормыш бер генә минутка тукталып тормаса да, түбән тәгәрәү чорларын да үз башыннан кичерә һәм берничә тапкыр исемен дә үзгәртә.

Искә алынган тарихи чыганакларда шәһәр берничә исем белән атала, әмма бу вариантларның барысы да, мәгънәсенә карап, төркемләнәләр һәм алар, нигездә, «кирмән» яисә шәһәр исемен аңлаталар. Мәсәлән, Керем, Кернәк, Кермән (урысча «крепость»), Кастро, Кастрама-Казан (латинча «крепость» һәм «крепость Казан»). Болгар—борынгы шәһәрнең варисы һәм болгар биләмәләренең башкаласы буларак, Казан акча сараенда сугылган меңләгән тәңкәләрдәге аның рәсми исеме.

Керем кирмәне, ягъни өлкә мәркәзе турындагы X гасырның 60 елларында язылган Хазар каганының телгә алып үтелгән хатында шактый ук саллы яңгырый. Үз хатында ул Кырым шәһәрләрен санаганнан соң

Тамутарханнан (Таман ярымутравы шәһәре) һәм Саркелдан (Дон буендагы кирмән) соң төньякка таба Б-ц-ра (Мещера) дип аталган җир ягына табан борылуы, даладагы көченеп йөргән кабиләләрнең Керем чикләренәчә яшәгәннәре турында яза һәм «алар бар да миңа хезмәт итәләр һәм миңа ясак түлиләр» дип хәбәр итә.

Шәһәр исеменең икенче варианты, ягъни Кернәк, күренекле фарсы тарихчысы Рәшидетдиннең тарихи язмаларында телгә алына. Монгол гаскәрләренең Идел буе шәһәрләрен яулап алуларын тасвирлаганда, ул Болгар һәм Биләр белән бер рәттән, Кернәк шәһәрен дә санап үтә.

Шәһәрнең Керман исемендәге өченче варианты XIII йөзнең 80 елларына караган—Казанның күпсанлы көмештән сугылган тәңкәләрендә очрый. Мәсьәлә шунда ки, XI—XII йөзләрдән соң болгавыр бер чорда өлешчә үзенең халыкара әһәмиятен югалткан Казан, XIII гасырның 50 елларында сәүдә эшләренә һәм сәүдәгәрләргә булышлык күрсәткән Батый хан заманында, сәүдә әһелләре аны Саин, ягъни «гүзәл», «яхшы» хан дип атап йөрткән чорларда сизерлек дәрәҗәдә югары үсешкә ирешә. Әйткәнебезчә, бу Идел буйларында сәүдә итү, сәүдә юлларының җайлануы белән бәйле була. Әйтик, Биләр кебек су юлы сәүдәчелегеннән, зур елгалардан читтәрәк урнашкан шәһәрләр тора-бара үзләренең элеккеге әһәмиятләрен югалта баралар.

Әрхирейга бирелгән бакчалыкта (Казан хакимнәренең җәйге резиденциясендә) табылган сәнгатьчә нәзакатьлек белән эшләнгән кабер ташларының кайберләре менә шушы чорга туры килә һәм, мисал өчен, 1297 елгы датаны күрсәткәне (Казанда тәңкәләр сугылган еллар) моннан 700 еллар элек җирләнгән Ялдаш кызы Алтынбөртекнең исеме белән бәйле. Ә гүзәл итеп эшләнгән һәм шунда ук табылган Казанның беренче әмире Хәсәннең мәңгеташы совет чорларында музей ишек алдында аунап ята иде. Казанның меңъеллыгына багышлап, аны тантаналы рәвештә Колшәриф мәчетенә кертеп урнаштыру үлгәннәрне искә алу йөзеннән саваплы бер эш булыр иде.

Шәһәр исеменең дүртенче варианты «Кастрама», ул латинча «крепость», «ныгытмалы урын»ны аңлата, дидек. Бу исем күпсанлы урта гасыр карталарында очрый һәм чыннан да Казанның иң борынгы исеме «Кирмән» («Крепость») булуын дәлилли. Яшь галим Д. Хафизов Германия архивында моңарчы бездә билгеле булмаган әйтеп үтелгән карталарның вариантларына тап булды. XV йөзнең соңгы чирегенә караган карталарның берничәсендә «Кастрама-Казан» дигән, ягъни Кастраманың чынлап та Казан булуын дәлилли торган язулар сакланган. Карталарның саны хәзергә 50дән дә артып китә!

Рәсми рәвештә Казан «Болгар» дигән исемне шәһри Болгар җимерелгәч (1367 елда аны башта урда ханы, аннары берничә ел рәттән Новгород һәм Мәскәүдән өерләре белән төшкән хәерче юлбасар ушкуйниклар җимерә һәм талый) һәм борынгы болгар җирләренең мәркәзенә әверелгәч ала.

**Казан тәңкәләре.** XV йөзнең беренче яртысында Казан акча сараенда Алтын Урда ханнары исеменнән сугылган уннарча мең тәңкәләр дә, Казанның беренче мөстәкыйль солтаны Гаязетдин (1422—1445) тәңкәләрен, Олуг Мөхәммәт (1445) тәңкәләрен дә кертеп исәпләгәндә, акча сугу урыны Казан урынына Болгар (әмма кайберәүләрнең ялгыш уйлавынча, «Болгар әл-Җәдид» түгел!) дип күрсәтелгән булуы инкарь итә алмаслык аргумент булып тора. Кайбер төрдәге тәңкәләрдә «Болгар» дигән язу урынына лира яки җиргә төбәп тартылган (татулык билгесе) ук-җәяне хәтерләтүче Казанның тугра-тамгасы сугылган. Сәхипгәрәй ярлыкларыннан аермалы буларак, тәңкәләрдәге Казан тамгасы бик матур, зәвыклы итеп бизәлгән һәм ясалган («Казан утлары»ның 1999 ел, 1 саны тышлыгында аның медальон рәвешендәге рәсеме дә бирелгән).

Мәскәүдә әле 1983 елда ук басылган монографиясендә бу юлларның авторы Казанның моңарчы билгеле булмаган беренче солтаны—улы һәм туганы Әстерхан һәм Кырым тәхетләрендә утырган Гаязетдиннең Казанда сугылган бер-ике данә генә түгел, ә меңгә якын яңа табылган көмеш тәңкәләре турында язып чыккан иде. Ләкин ни гаҗәп, кайбер татар галимнәре бүген дә Казанның беренче ханы Олуг Мөхәммәт булган дип язалар...

Казан Кремлендә археологик казулар вакытында табылган кайбер башка тәңкәләр турында да бер-ике сүз әйтеп китәсе килә. Барлык мөселманнарның әмире саналган хәлиф Насиретдин исеменнән Болгар шәһәрендә сугылган

берничә тәңкә 1976—1977 еллардагы казулар вакытында ук табылган иде. Сугылган еллары күрсәтелмәсә дә, бу тәңкәләрнең хәлиф үзе идарәлек иткән (1180—1225) елларда Болгар сугылган булуы шик тудырмый. Университет тарафыннан оештырылган археологик казуларда табылган тәңкәләрнең саны шактый күп булды. Мәсәлән, Насиретдин исеменнән сугылган бакыр тәңкәләрнең кайберсенә Кыпчак дәүләте төзелгәч, Батый хан (1237—1256) идарә иткән дәвердә иске язу өстенә өстәп бөек монгол ханы Мүнкә (1251—1257) исеме сугылганнары да очрады. Шулай ук башка Алтын Урда чорына караган табылдык тәңкәләр арасында XIII йөзнең 50 елларында монгол империясенең башкаласы Каракорымда бөек хан тәхетен дәгъвалаган Арык-Бука исеменнән Болгарда сугылган вак көмеш тәңкә һәм XIV йөз ханнары Үзбәк яки Җанибәк исеменнән сугылган көмеш һәм бакыр тәңкәләр, шул ук гасырның 60 еллардагы Хызыр һәм башка ханнарның бакыр тәңкәләре дә бар.

Шулай ук Казанның үз акча сараенда сугылган дистәгә якын тәңкә табылды. Өстәвенә, Явыз Иван чорындагы урыс тәңкәләре дә җитәрлек һәм шунысы кызык—аларның кайберләре әле Казан алынганчы ук сугылганнар.

Әмма казулар вакытында яисә очраклы рәвештә җирдә табылган тәңкәләр һәм хәзинәләргә карата аларның датасын ачыклау буенча нумизматика фәненең үз кануннары бар. Шул кагыйдәләрне белмәү кайвакыт тәңкә табылу, бигрәк тә журналистлар арасында, кош тоткан кебек итеп кабул ителә. Мисал өчен, әйтик, XII йөзгә караган катламда табылган Насиретдин тәңкәсенә карата аның 1180, ягъни сугылган елыннан да алда җир асты катламына керә алмавын тәгәл итеп әйтергә мөмкин. Ә менә шул күрсәтелгән елдан соң кай вакытта аның җир астына керүен әйтү шактый читен. Ул кемнеңдер сандыгында фәлән ел сакланырга яки бер чибәрнең чәч чулпысы булып гомере буе чылтырап йөреп, аның кызына да хезмәт итәргә мөмкин... Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Әгәр намусы бик үк чиста булмаган бер археолог юри ташласа... Археологиядә андый очраклар да билгеле...

Тәңкәләр табылып торуның әһәмияте даталар билгеләүдә генә түгел, ә берничә мең еллар дәвамында яшәп килгән торлакның кайсы чорда шәһәргә әйләнүен ачыклауда да, чөнки урта гасырларда акча әйләнеше бары тик шәһәрләрдә генә булган, ә кәҗә биреп чана ясату, яки мал түләп кыз алу кебек хәлләр, ягъни натураль алыш-биреш авыл җиренә хас булган.

Шуңа күрә, археология фәне өчен санлырак булганнарыннан хазар, имән-кискәле һәм болгар чорына караган керамика—чүлмәк кыйпылчыклары, ягъни массакүләм рәвештә көнкүрештә киң кулланылыш әйберләре, металлдан эшләнгән ук башы (аларның да формасына карап даталарын ачыклау өчен төзелгән графиклары бар), пычак һ. б. төрле әйберләр, шулай ук борынгы корылмалар, шул исәптән шәһәр ныгытмалары һәм башка төрле шуңа охшаш табылдыклар кыйммәтлерәк саналалар. Ә инде, мисал өчен, Айрат Ситдыйков казылмасындагы кебек шундый табылдыклар һәм шул ук чорга караган биналар янында алар белән бер комплекс тәшкил итеп дирһәм дә табылса, әлбәттә, абсолют датаны да билгеләргә мөмкин! Дөрес, әлеге тәңкәне танылган нумизмат, хәзер инде мәрхүм Г. А. Федоров-Давыдов X йөз уртасында сугылган дип билгеләгән иде. Ләкин урыс халкы әйтмешли, май ботканы бозмый лабаса...

Югарыда бәян ителгәннәргә йомгак ясап, шундый нәтиҗәгә килергә мөмкин: мәкаләдә файдаланылган чыганаклар—беренче мәртәбә шәһәр исеме телгә алынган X йөз ахырындагы хазар каганының хаты һәм шәһәрнең чыннан да монголларга кадәрге шәһәр булуын раслаган Рәшидетдиннең язмасы, XI—XII гасырлардагы шәһәр ныгытмасы хәлендә сакланып калган дивар (стена) кебек зур күләмле археологик мәгълүматлар, тораклар, балчыктан ясалган массакүләм хуҗалык кирәк-яраклары һәм металлдан эшләнгән һәртөрле әйберләр, шул исәптән, тимер ук очлары, шәһәрнең урнашкан урыны һәм иске исемнәре күрсәтелгән 50дән артык урта гасыр картасы, шулай ук XI—XII йөзләргә караган (гарәп, чех, болгарда сугылган) күпсанлы тәңкәләр—боларның барысы да безгә борынгы заманнардан—таш гасырыннан ук яшәп килгән торлакның ниһаять, XI йөз башыннан башлап шәһәр дәрәҗәсенә күтәрелгән Казанның 2005 елны 1000 еллык юбилеен билгеләп үтәргә тулы мөмкинчелек бирә.





# 31—ЛОКМАН (ЛОКМАН) СҮРӘСЕ

**Локман сүрәсе 34 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әлиф. Ләм. Мим. **(2)** Менә бу аятьләр хикмәт тулы Коръәннең аятьләредер. **(3)** Игелек кылсыннар дип, тугры юлга бассыннар өчен, *(Алланың)* рәхмәт(е) буларак *(иңдерелде)*. **(4)** Алар *(мөэминнәр)* намаз укыйлар, зәкят бирәләр, Ахирәт көненә чын күңелдән инаналар. **(5)** Менә шундый адәмнәр Раббы күрсәткән тугры юлдан йөриләр һәм (җәзалардан) котылып, Сәгадәткә ирешерләр.

**6.** Бәндәләр арасында шундыйлары да бар: бернәрсә дә белмәгән башлары белән кешеләрне Аллаһ диненнән читкә алып китәргә маташып, ул динне мыскыл итәр өчен, уйдырма-буш сүзләр *(язылган китапларны сатып алып)* сөйләүче күпме адәмнәр бар. Менә шундыйларны, әлбәттә, рисвай кылучы җәзалар көтә.

**7.** Андыйларга аятьләребезне укый башласаң, ишетмәмешкә салышалар, әйтерсең лә, колакларында чукраклык бар һәм алар борын чөереп, тәкәббер рәвештә китеп баралар. Менә син шундыйларны хәтәр газап тотачагы турында сөйләп «куандыр».

**8.** Иманлыларга һәм игелек кылганнарга—җәннәт бакчалары. **(9)** Алар анда мәңге калачак. Бу—Аллаһның хакыйкый вәгъдәсе. Аллаһ—кодрәт һәм хикмәт иясе.

**10.** Ул *(Аллаһ)* сезгә күренеп торучы күкләрне терәксез *(торырлык)* итеп яралтты. Сез чайкалмасын өчен, Җирне каты-нык баганалар *(таулар)* белән терәтте. Һәрбер җанлыдан ничә төрле токымнар үрчетте. Без Күктән янгыр яудырдык, туфракта һәр женестән гүзәл үсемлекләр житештердек.

*(Шушы аятьтә галәмнәрнең сере ачыла. Терәксез күкләр, Җирне гарасатлы калтыранулардан тотып торучы таулар, галәмнең гравитацион тарту көчләре, үзәктән куу, үзәккә тартылу куәтләре, тауларның тамыры, чыннан да, Җирнең үзәгенә кадәр сузылганлыклары, шуның аркасында Җир өстендәге хәтәр хәрәкәтләнүләрне тыеп торулары Коръән иңгән заманнардан күп вакытлар узгач кына, чын фәнни ачышлар белән раслана килде.*

Материалы Пятой Конференции международной комиссии по научным знакам в Коране и Сунне. 1993 г.)

**11.** Менә, боларның бөтенесе дә Аллаһ яралткан чынбарлык. Аннан башкаларның *(потларның, сыннарның)* ни яралтканнарын Безгә күрсәтегез, зинһар. Хәер, ул игелексезләрнең тугры юлдан язганлыгы көн кебек ачык.

**12.** Хактыр ки, Без Локманга, Аллаһка шөкер ит, дип хикмәт *(ачык зиһен)* бирдек. Шөкер иткән кеше үзе өчен шөкер итәр. Шөкер итмәгән кеше—шөкер итмәсен: Аллаһ аның шөкеренә мохтаж түгел. Аллаһ һәртөрле мактауга лаек.

**13.** Бервакыт Локман углына үгет бирә икән:

—Углым, Син Аллаһтан башка *(уйдырма)* илаһка табынма. Күп илаһларга табынудан да зур гөнаһ юк!

**14.** Без кешегә: ата-анаңа игелекле бул, дип васыять иттек. Анасы аны нинди кыенлыклар белән карынында йөртә. Ике ел буе сөтеннән аермаенча

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

имезеп үстерә. Бәс, иң башта Мина, аннан соң ата-анага шөкер ит, дип васыять иттек. Кайтарылыш бары тик Мина гына булыр.

**15.** Әгәр дә *(атаң-анаң)* сина мәгълүм булмаган берәр нәрсәне Мина тин күреп, сине шуна *(инанырга)* ирексезләсә—аларга буйсынма. Ләкин дөньяда аларга игелекле бул. Мина итагать иткәннәр белән бер юлда бул. Ахырда кайтарылышыгыз бары тик Минем тарафка булыр. Шул вакытта *(Кыямәттә)* Мин сезгә *(дөньядагы)* кылмышларыгыз турында искәртермен.

**16.** —Әй, улым,—диде Локман.—*(Игелекме ул, яманлыкмы)* кылмышын хәрдәл *(горчич)* бөртеге хәтле генә булып, ул да тау кыясына яки күкләргә яки җир астына яшерелгән булса да, Аллаһ *(Кыямәттә)* аны синең каршыңа чыгарып куяр. Хактыр ки, Аллаһ иң нечкә-яшерен эшләрне дә күреп-белеп тора. Ул бар нәрсәдән дә хәбәрдар.

**17.** —Балам, намазыңны укы, *(башкаларны)* игелеккә өндә, яманлыклардан ваз кичәргә чакыр, башыңа килгәнгә *(бәлаләргә)* сабыр ит. Хактыр ки, болар Аллаһ фарыз кылган, рух ныклыгы таләп ителә торган нәрсәләрдер.

**18.** —Тәкәбберләнеп, кешеләрдән йөз чөермә. Дөньяда масаеп, борын чөереп йөрмә. Аллаһ кәпрәючеләрне, үзен генә сөючеләрне, мактанчыкларны сөймәс. **(19)**

—Җәмгыятьтә табигый бул *(адымың нык булсын)*, тавыш күтәреп сөйләшмә. Шуны онытма, дөньядагы иң ямьсез тавыш—ишәк тавышы.

**20.** Аллаһ күкләргә вә Җирдә булган һәр нәрсәне сез файдалансын өчен бирде, яшерен һәм өстә яткан нигъмәтләрне сезгә мал итте. Шуны сез аңламыйсызмыни? Шуңа да карамастан, белемсез кешеләр арасында дәлилсез һәм кулларында фикер якхтылыгы бирүче Китабы булмаган көенчә, Аллаһ хакында тартышучылар бар.

**21.** Аларга:

—Аллаһ иңдергәнгә *(Коръәнгә)* иман китерегез,—дип әйтсәң, алар:

—Юк, без бабаларыбыз тоткан диндә калачакбыз,—диячәк. Шайтан котыртыгы илә аталарының дине җәһәннәмнең хәтәр газабына илтсәдәме?

**22.** Игелек кылганнар арасында үзен тәмам Аллаһка багышлаган кешенең, хактыр ки, ышанычлы тәрәге булыр. Бөтен эшләрнең ахыры Аллаһка барып тоташа.

**23.** *(Рәсүлем)* инкарь иткәннең инкаре сине хафага салмасын. Алар барыбер Безнең тарафка кайта. Менә шул вакытта Без аларның *(дөньядагы)* кылмышлары турында искәртербез. Аллаһ *(инсаннарның)* күңелендә ниләр булганны бик яхшы белеп тора. **(24)** Без аларга *(фани дөньяда рәхәт чигәргә)* ирек куярбыз, ахырда үзләрен авыр газапларга дучар итәрбез. **(25)** Хактыр ки, алардан:

—Күкләрне һәм Җирне кем яратты?—дип сорасаң, алар мотлак:

—Аллаһ!—дип әйтәчәк. Әйт син:

—Шулай булгач, Аллаһны мактагыз, әлхәмдүлилләһ—диген. Ләкин бу аларның күбесенең башына килми. **(26)** Күкләрдәге, Җирдәге бөтен барлык—һәммәсе дә Аллаһныкыдыр. Шик юктыр ки, Аллаһ ул *(бернигә дә)* мохтаҗ түгел һәм мактауга лаек.

**27.** Җир йөзендәге бөтен агачлар да каләмгә әверелеп, *(дөньядагы барлык)* диңгез-океаннарның суы җиде тапкыр артып, язу карасына әйләнсә дә, Аллаһның сүзләрен язып бетереп булмас иде. Шик юк ки, Аллаһ—бөек вә хикмәт иясе.

**28.** *(И, адәмнәр)* сезне юктан бар итү һәм *(үтереп)* яңадан терелтү—Аның өчен бер кешене бар итеп, яңадан терелтү кебек ансат эш. Хактыр ки, Аллаһ һәр нәрсәне белеп, күреп тора.

**29.** Күрмисеңмени, Аллаһ төнне көнгә вә көнне төнгә кертеп аралаштыра. Кояшны, Айны үз тәртибенчә йөртә. Боларның һәрберсе *(Аллаһ тарафыннан)* билгеләнгән бер вакытка кадәр шул тәртиптә хәрәкәт итәчәк. Һәм Аллаһ кылмышларыгыздан мотлак хәбәрдар. **(30)** Чөнки: Аллаһ—Хакыйкатьнең Үзедер. Аннан башкага табынганнарыгызның барысы да, һичшиксез, ялгандыр. Иң олуг, иң бөек—Аллаһтыр.

**31.** Күрмисезме, әллә күрмәмешкә салышасызмы, Аллаһ Үзенең бар икәнен күрсәтер өчен, рәхмәте илә дингездәге көймәләрне йөздерә. Шик юк ки, *(кяферләр кыерсытуына, Аллаһ җибәргән авыр сынауларга түзеп)* сабыр итүчеләр һәм шөкер итүчеләр өчен бу эшләрдә гыйбрәтләр бар.

**32.** Тау кадәр дулкыннар алар өстенә ябырылганда, алар ихлас мөселман кебек, Аллаһка ялвара башлыйлар. Аллаһ аларны коткарып, коры җиргә чыгарып бастыргач, аларның бәгъзеләре *(Аллаһка)* ышаныр-ышанмас кала бирә. Ләкин безнең аятьләребезне бары тик шөкерсез хаиннәр генә инкарь итә.

**33.** Әй, кешеләр, Раббыгызга гыйсъян кылудан тыелыгыз. Атаның—баласына, баланың атасына ярдәм итә алмаячак Көннән куркыгыз. Шуны белеп торыгыз ки, Аллаһ әйткән сүз, һичшиксез, тормышка ашачак. Зинһар, сак булыгыз, дөнья тормышы ул бер алдавыч кына. Һәм хәтәр ялганчы шайтан: Аллаһ барыбер сезне гафу итәчәк, дип аздырмасын.

**34.** Кыямәт Сәгатенең кайчан сугачагын бары тик Аллаһ кына белә. Яңгырны Ул яудыра. Ана карынында ни барлыгын Аллаһ белә. Иртәгә ни кылачагын *(ни казаначагын, корган тәдбирләренең уңышлымы, уңышсызмы булачагын)* һичкем белми. Кеше үзенең кайда үләчәген белми. Шик юктыр ки, Аллаһ бөтенесен белеп тора. Ул барысыннан да хәбәрдар.

# 32—СӘҖДӘ (СӘҖДӘ) СҮРӘСЕ

**Сәҗдә сүрәсе 30 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әлиф. Ләм. Мим. **(2)** Һич тә шик юк, бу Коръән—галимнәрнең Раббысы тарафыннан иңдерелгән Китап. **(3)**

—Аны Пәйгамбәр үзе уйлап чыгарган,—диярләр. Юк шул, Ул үзләренә кисәтүче *(Пәйгамбәр)* җибәрелмәгән халыкны кисәтер өчен, шуннан соң алар тугры юлга күнәр дип, Раббыңнан иңдерелгән Китап.

**4.** Күкләрне, Җирне һәм алар арасындагыларны алты көндә юктан бар итүче бер Аллаһ; соңыннан Аның хакимияте Гарешкә урнашты. Аннан башка сезнең бер генә яклаучыгыз да, бер генә химаячегез да юк. Инде шуннан соң да уйлашып, тәүбәгә килмәссезме?

**5.** Аллаһ Күктән Җиргә хәтле булган һәр эшне тәртип белән алып бара. Бөтен бу эшләр сезнең хисап белән мең елга торган бер көндә Аның тарафына кайтарыла. **(6)** Менә, күренгәннәрне дә, күренмәгәннәрне дә белүче, чиксез кодрәт һәм мәрхәмәт иясе—Улдыр. **(7)** Үзе ясаган һәрнәрсәне кем шулай мөкәммәл кылды? Иң әүвәл Ул Адәмне балчыктан ясый башлады. **(8)** Һәм чирканыч су тамчысыннан аның токымын үрчетте.

**9.** Сонра аны *(Адәмне)* камилләштереп, *(кеше)* рәвешенә китерде, аңа үз рухыннан җан өрде. Һәм сезнең өчен колаклар, күзләр, йөрәк яралтты. Ни сәбәпле сез шулкадәр аз шөкер итәсез?

**10.** Инкарьчылар әйтте:

—Үлгәннән соң череп туфракка әверелгәч, чыннан да, без яңадан терeләчәкбезме? *(Без моңа ышанмыйбыз)*,—диделәр. Хактыр ки, алар *(Ахирәттә)* Раббылары белән кавышуны инкарь итте.

**11.** Әйт:

—Сезнең җанны алырга вазифаландырылган үлем фәрештәсе җаныгызны алачак. Ахырда Раббыгыз каршына китереләчәксез,—диген.

**12.** Ул гөнаһкярларның Раббы каршысында ничек итеп баш иеп:

—Раббыбыз, күрдек, ишеттек, инде хәзер безне фани дөньяга кире кайтар, без игелек кылачакбыз, инде хәзер чын күңелдән иман китердек,—дип ялварганнарын күрсәң иде. *(Аларның мескенлекләренә шаккатар идең.)*

**13.** Әгәр дә Без ихтыяр итсәк, әлбәттә, һәркемне тугры юлга күндергән булыр идек. Ләкин:

—Җәһәннәмне женнәр һәм *(гөнаһлы)* кешеләр белән шыгрым итеп тутырачакмын,—дип катгыян әйтелгән сүзем бар.

*(«Аллаһ Тәгалә инсаннарның, женнәрнең барысын да ирексезләп, үз ихтыяры илә җәннәткә яки җәһәннәмгә кертеп тутырса, колларының ирекен, шәхси теләген кысып, шәхеснең азатлыгын буган булыр иде. Һәм кешеләрдән, женнәрдән имтихан алу, аларны сынап карауның кирәге калмаган булыр иде. Мөкәлләфләр, ягъни ихтыяр көчен кулланыр дәрәҗәдә балигълыкка ирешкәннәр тугры юлны сайлап, оҗмахка керергәме, әллә азгынлык юлын сайлап, тәмугка барыргамы икәнне үзләре хәл итәргә тиеш».*

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.)

**14.** *(Кыямәттә аларга болай диячәкбез):*

—Бу Көндә кавышу турында онытканыгызга күрә, жәзасын да татып багыгыз. Дөресен генә әйткәндә, Без дә сезне *(җәһәннәмдә)* оныттык. Кылмышларыгызга күрә, мәңгелек жәзага дучарсыз.

**15.** Безнең кисәтү вәгазьләребезне ишетеп, масаймыйча, сәҗдәгә киткәннәр вә Раббыга мактау илә тәсбих әйткәннәр генә Безнең аятьләребезгә ышаналар.

**16.** Курку илә өмет арасында Раббыга *(намазда)* ялварганнар җылы-рәхәт ястыкларыннан аерылып, төнлә торып дога укый. Безнең тарафтан иңдерелгән ризыкларыннан *(зәкятка, хәер-садакага)* сарыф итәләр. **(17)** Кылган гамәлләренә күрә бүләк буларак, нинди шатлык, күпме әҗер алачакларын берәү дә белмәс.

**18.** Иманлы кеше имансыз кеше белән бер булырмы? Юк, алар һичбер вакытта да тигез булмас.

**19.** Иман китереп, игелек кылганнар өчен, кылган игелекләренә күрә, мәңге яшәр өчен Мәъва җәннәтләре хәзерләнгән.

**20.** Бозык кешеләрнең барачак урыны—утлы Тәмуг. Күпме генә алар аннан чыгарга теләсәләр дә, кабат *(утка)* атылырлар һәм аларга,

—Сез ялганга санаган шул утның газабын татып карагыз,—дип әйтерләр.

**21.** Без бу хәтәр жәзадан *(җәһәннәмнән)* алда *(фани дөньяда)* аларга жәзалар *(әсирлек, кытлык, хасталыклар, дөньяви авырлыклар)* бирербез. Бәлки, алар тәүбәгә килеп, иман китерерләр.

**22.** Үзенә Раббының аятьләре белән үгет-нәсихәт бирелеп тә, алардан йөз чөергән кешедән дә игелексезрәк кем бар икән? Һичшиксез, Без гөнаһкярларга жәза бирербез.

**23.** Хактыр ки, Без Мусага ул Китапны *(Тәүратны)* бирдек. Син, һичшиксез, аның белән кавышачаксың. Без аны Исраил нәселен *(яһүдләрне)* тугры юлга өндәүче итеп күндердек.

**24.** Алар арасыннан *(кыенлыкларга)* сабыр итеп түзгәннәрен, аятьләребезгә чын күңелдән инанганнарын әмеребезчә тугры юлга өндәүче *(рәһбәр)* итеп тәгаенләдек.

**25.** Бәхәсләрнең сылтавы-сәбәбе турында, хактыр ки, Раббың Кыямәт көнендә *(аларның кайсысы хаклы, кайсысы хаксыз икәнен)* хөкем итәчәк.

**26.** Без әүвәлдә аларның *(Мәккә кяферләренең)* ничә токымын һәлак иттек. Йортларының *(хәрабәләре)* арасында әле хәзер дә аларның токымы яшәп маташа. Бу *(гыйбрәтләр)* аларны тугры юлга чакырмасмы? Бу эшләрдә, әлбәттә, сабак алырлык гыйбрәтләр бар. Бу гыйбрәтләргә алар һаман колак салмасмы икәнни?

**27.** Коп-коры туфракка яңгыр яудырып, хайваннар өчен дә, үзләре өчен дә тамак туйдырырлык игеннәр үстергәнебезне күрмиләрмени алар? Һәм шулай *(мәңге)* аңламаслармы икәнни? **(28)** Алар:

—Әгәр дә сез *(Кыямәт, җәннәт, җәһәннәм турында)* дөресен сөйлисез икән, аның нәтиҗәсе (жәзасы, савабы) кайчан булачак соң?—диләр. **(29)** Әйт син:

—*(Йомгак ясалачак Көндә)* Кыямәттә генә китергән иманнары аларга файда бирмәячәк. Аларның жәзасы да кичектерелмәячәк. **(30)** Инде син алар белән араны өз һәм *(жәза килгән)* сабыр итеп көт. Алар да көтә бит.



# «Казан утлары»на 80 ел

**27 августта III Бөтендөнья татар конгрессы кысаларында "Казан утлары" журналы үзенең 80 еллыгын билгеләп үтте. "Казан" милли- мәдәни үзәгендә редакция хезмәткәрләре Татарстан һәм Башкортстаннан, Россия төбәкләреннән, Финляндия, Төркия, Америка Кушма Штатлары һәм татарлар күпләп яши торган башка илләрдән кунаклар кабул итте.**



Юбилей тантанасында катнашучылар Татарстанның халык артисты, җырчы **Илһам Шакиров** белән *(уртада).*



Залга журналның якын дусларыннан язучылар, сәнгать әһелләре, даими әбүнәче-укучылар җыелган иде.



Бәйрәм кичәсеннән бер күренеш.



Безне котлыйлар. ТР Премьер-министры урынбасары **З. Вәлиева** *(уңнан сулга)*, БТК башкарма комитеты рәисе **И. Таһиров**, Язучылар берлеге рәисе **Ф. Галимуллин** һәм Татарстанның мәдәният министры **И. Тарханов.**



Сәхнә түрендә "Казан утлары"ның бүгенге хезмәткәрләре.



"Идел-пресс" басмаханәсе генераль директоры **И. Әхмәтҗанов** *(уртада)* журналның баш мөхәррире **Р. Фәйзуллинга** бәйрәм "күчтәнәче" тапшыра.



Журналны котларга Азнакай районы вәкилләре килгән иде.



Г. Камал театры артистлары да журналны тәбрикләде.

Сәхнәдә танылган җырчылар, сәнгать осталары:



**Георгий Ибушев**



**Илдус Әхмәтҗанов**



**Резеда Галимова**

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ОЛУГ ЖЫЕНЫ

29 августта Казанда, С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында III Бөтендөнья татар Конгрессының пленар утырышы узды. Президиумда конгресс делегатлары—Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимов, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Индус Таһиров, Россия Федерациясенең милләтләр эшләре министры Владимир Зорин, Төркия республикасының Казандагы генераль консулы Исмәгыйль Сафа Юджеэр, Татарстан житәкчеләре, күренекле дәүләт, жәмәгать, фән эшлеклеләре.

Пленар утырышны Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин ачты һәм татарларның бөтендөнья корылтаена Германия, Швеция, АКШ, Төркия, Финляндия, БДБ һәм Балтыйк буе илләреннән, Россиянең 50 дән артык төбәгеннән 562 делегат, 200 дән артык кунак килүен хәбәр итте. Утырышта беренче булып Президент М. Шәймиев сүз алды. «III Бөтендөнья Татар Конгрессы яңа шартларда уза,—диде ул. Россиядә унитар дәүләт ясау омтылышы сизелүне, сәяси сүзлектән «федерализм» төшенчәсенең югалып баруын, халык санын алганда татарларны бүлгәләп кечерәйтү омтылышы сизелүне искәртеп.—Жыенның төп бурычы—татар халкының бердәмлеген ныгыту юлларын билгеләү. Чөнки Татарстан Конституциясенең яңа редакциясендә республиканың читтәге милләттәшләр язмышын үз жаваплылыгына алуга кагылышлы 14 нче маддә барлыкка килде. Онытмыйк: без—әдәби телле, гомуми мәдәниятле бербөтен халык. Юк-бардан ыгы-зыгы китереп чыгармыйк. Бергә, бер юнәлештә эшләүнең үтемле юлларын табыйк. Яшәешебездә төгәл һәм житди гамәлләр чоры житте. Безнең көчебез—бердәмлектә!»

Милли идеянең мәдәният, мәгърифәт, гореф-гадәт, дини яшәеш тупланмасыннан торуын ассызыклап, бишьеллык эшчәнлеккә йомгакны Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Индус Таһиров ясады. «Конгресс тарафыннан биш елда Россиядә 22 региональ милли-мәдәни мохтәрият, 200 дән артык жирле оешма булдырылды».—диде ул.

Соңгы вакытта татар-башкорт мәсьәләсе нык сәясиләштерелгәнлектән, татардан «башкорт ясау» күренешенә урын бирелгәнлектән, Башкортстан Президенты Мортаза Рәхимов чыгышы да зур кызыксыну белән тыңланды. «Татар белән башкорт—бер-берсен ярты сүздән аңлый торган халык. Башкортлар һәм татарлар бер-берсенә терәк булып яшәр өчен дөньяга килгәннәр. Без һәрвакыт бергә булдык, бергә булырбыз. Ике республика Россиядә үз хокукларын бергә якларга тиеш»,—диде М. Рәхимов.

Аннары, күпсанлы котлау телеграммалары укылгач, 28 августта узган фән-мәгариф, татар яшьләре, эшлекле хезмәттәшлеккә кагылышлы секцияләрнең эш нәтижәләре турында Казан галимнәре Мансур Хәсәнов, Жәүдәт Сөләйманов, Сарытау өлкәсеннән эшкуар Камил Аблязов хисап тотты. Ижат интеллигенциясе исеменнән язучы Зөлфәт Хәким чыгыш ясады.

Пленар утырышта 15 тән артык делегат сүз тотты. Алар халыкның исән калуы өчен бик актуаль проблемаларны күтәрделәр. Бөтенроссия халык санын алуга әзерлек мәсьәләсе тикшерүнең үзәгендә булды. Бу мәсьәләдә делегатлар бер фикердә—бердәм халыкны этник төркемнәргә бүләргә юл куймабыз,—диделәр. Латин графикасына күчүгә уйлап-үлчәп якын килү зарурлыгы, бөтен дөнья татарлары үзенең мәркәзе дип саный торган Казанның 1000 еллыгына лаеклы әзерләнү, 2001 елның 11 сентябреннән соң Ислам диненә мөнәсәбәтнең үзгәрүе сәбәпле борчылу—делегатлар чыгышларында үзәк урынны алып торды.

Конгресста катнашучыларның уртак фикере шул: төрле илләрдә-жирләрдә яшәүче милләттәшләребез халкыбыз үсеше өчен нәрсә кирәклекне бик яхшы күзаллыйлар. Инде хәзер аларны ишетү, кәгазьгә теркәү белән генә чикләнмичә, идеяләрне гамәлгә ашыра башларга вакыт.

Фикер алышу тәмамлангач, Конгресс делегатлары йомгаклау документларын кабул итте. III Бөтендөнья татар конгрессы корылтае резолюциясендә илдә барлыкка килгән унай үзгәрешләр белән беррәттән, соңгы вакытта Россия жәмгыятенең сәяси тормышында, дәүләт төзелешендә федерализм принципларыннан тайпылу тенденциясе күренә башлавы күрсәтеп узылды. Бу, барыннан да элек, федерация субъектларының вәкаләтләрен нигезсез чикләү һәм Россия халыкларының аерылгысыз хокук-

ларын инкарь итәргә маташуда күренә. Хакимият вертикален ныгыту кысаларында кертелгән күп кенә яңалыклар РФнең гамәлдәге Конституциясенә каршы килә. Күп кенә төбәкләрдә Россия Федерациясе халыкларының телләре, мәгарифе, мәдәнияте турындагы федераль законнар үтәлми.

Конгресс делегатлары Россия Президенты В. Путинга мөрәҗәгать кабул итте. Анда гомумроссия сәяси процессында бара торган тенденцияләр, Россиядә демократия һәм федерализм язмышы өчен борчылу бар (бу мөрәҗәгать икенче көнне—29 августта В. Путинның үз кулына тапшырылды).

Яңа сайланган башкарма комитетының оештыру утырышында БТК башкарма комитеты рәисе итеп «Казан» милли мәдәният үзәге директоры Ринат Закиров сайланды. Корылтай эше тәмамлангач, БТК башкарма комитеты рәисе Р. Закиров һәм татар федераль милли-мәдәни мохтәрияте рәисе итеп сайланган Римзил Вәлиев Россия һәм Татарстанның III Бөтендөнья татар конгрессы эшен яктырткан күпсанлы журналистлар өчен матбугат конференциясе уздырды.

## ТАТАР ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕГЕ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Казан Кремлендә 30 августта Россия Президенты В. Путин Татарстанның житәкче даирәләре һәм III Бөтендөнья татар конгрессы делегацияләре башлыклары белән очрашты. Россия житәкчесенең татар милләте проблемалары турында мондый махсус очрашуы, ихтимал, беренче тапкыр булгандыр. Ике сәгатькә сузылган бу очрашуда чыгыш ясаучылар тарафыннан бик күп актуаль мәсьәләләр күтәрелде: Россиядә милли сәясәт, халык саны алуның кайбер четерекле аспектлары, республикадан читтә яшәүче татарларның рухи-мәдәни хәлләре, дин башлыкларының җәмгыятьтәге роле һ. б. Татарстан Президенты М. Шәймиев ачып җибәргән бу очрашу формаль булмаган шартларда узды. Очрашуда катнашучылар үзләрен борчыган сораулар белән берьюлы өч Президентка—Россия, Татарстан, Башкортстан Президентларына мөрәҗәгать итә алды. Унга якын кеше трибунадан чыгыш ясады. Алар арасында Р. Закиров (Казан), Ә. Алмаев (Астрахань), Н. Хөсәенов (Бәләбәй) һ. б. бар иде. Россия Президенты һәр чыгышны игътибар белән тыңлап, күтәрелгән мәсьәләләргә үз фикерен белдереп барды. Гомумән, очрашу ихлас атмосферада, демократик рухта узды.

Очрашуда РФ хөкүмәте Рәисе урынбасары Валентина Матвиенко, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы вәкиле Сергей Кириенко, РФнең милләтләр эшләре министры Владимир Зорин, Татарстан Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Башкортстан Республикасы Президенты Мортаза Рәхимов катнашты.

## БӨТЕНТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ҮЗӘГЕНЕҢ ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ХАЛЫКЛАРЫНА МӨРӘҖӘГАТЕ

Узган гасырда, Октябрь түнтәрелешеннән соң татар һәм башкорт халыкларының үзбилгеләнү процессына большевиклар хөкүмәтенең көчле басым ясавы һәм бу халыкларның тарихи яшәү территорияләрен дөрес билгеләмәве тугандаш милләтләребез арасында этник, сәяси һәм мәдәни ассылыктагы каршылыклар тууга сәбәпче булды. Менә бер гасырга якын инде ул каршылыклар дәвам итеп килә, һәм бу хәл ике халыкның да табигый рәвештә үсешенә зыян китерә. Һәр ике халыкның да рухи мирасын, яшәү территорияләрен, санын билгеләүдә яшәп килгән каршылыклар татар һәм башкорт халыклары арасында тәмам аңлашмаучанлыкка да китерергә мөмкин. Моңа кадәр мәдәният, мәгърифәт өлкәсендә һәм халык дипломатиясе ассылыгында ике арада алып барылган килешү-сөйләшүләр тиешле нәтиҗә бирмәде.

Без ике тугандаш халык арасындагы каршылыкларга бары тик ике халыкның ихтыяры белән, сәяси ассылыктагы чара ярдәмендә, ягъни узган гасырның 20 нче елларында күтәрелгән Татарстан һәм Башкортстан республикаларының региональ конфедерациясен төзү идеясен тормышка ашыру юлы белән генә чик куя алачакбыз. Бары тик шул шартларда гына ике халык читтән көчләп тагылган милли сәясәткә баш бирмичә, нинди санда булуына, нинди территориядә яшәвенә карамастан, бер-берсе белән уртак тел табып, иркен рәвештә үсә, бер-берсен санлый һәм яклый алачак.

Хөрмәтле кардәшләребез, татар һәм башкорт халкы! Әгәр алга таба кардәшләр булып, дус-тату яшик дисәк, Татарстан-Башкортстан региональ конфедерациясен төзү турында ике республикада да референдум уздыруны максат итеп куйыйк. Татар һәм башкорт халыклары үз язмышларын үз ихтыярлары нигезендә сәяси чаралар белән хәл итсен!

## «КАЗАН УТЛАРЫ»—КРЕМЛЬДӘ

Президент Минтимер Шәймиев белән «Казан утлары» журналы баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Фоат Галимуллин, республиканың күренекле язучыларының 27 августта Казан Кремлендәге очрашуы III Бөтендөнья татар конгрессы кысаларында журналның 80 еллыгын бәйрәм итүгә багышланды.

«Казан утлары» журналының 80 еллыгы—язучылар бәйрәме генә түгел, ә укучылар бәйрәме дә,—диде Президент.—Татарлар яши торган төбәкләрдә журналның һәр санын көтеп алалар. Чөнки татар язучыларының иң яхшы әсәрләре башта

шушы журналда басыла. Шушындый катлаулы заманда да журнал үз укучыларын, шактый югары тиражын саклап кала алды. «Казан утлары»—халыкка кирәк журнал».

Журналның әшен тагын да яхшырту, аны халыкка тарату, яшь буынны тәрбияләүдәге ролен арттыру турында очрашуда катнашкан күренекле язучылар Туфан Миңнуллин, Нурихан Фәттах, Флүс Латыйфи эшлекле фикерләр әйттеләр.

Очрашуда Президент аппараты җитәкчесе Әгъзам Гобәйдуллин, Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миңнуллин катнашты.

### ЖУРНАЛЫБЫЗ ТАНТАНАСЫ

Татар матбугаты өчен быелгы елны «Казан утлары» журналы елы булды дияргә дә ярыйдыр. Журналның 80 еллык юбилей чаралары май аеннан башланып хәзергә кадәр дәвам итә. Матбугатта журналыбыз турында дистәләгән мәкаләләр дөнья күрде, радио һәм телевидениедән күпсанлы тапшырулар булды, укучылар белән очрашулар өзлексез дәвам итте.

Һәм ниһаять, 27 август көнне, III Бөтендөнья татар конгрессының беренче мәдәни чарасы буларак, «Казан» милли мәдәният үзәгендә «Казан утлары»ның 80 еллык юбилеена багышланган тантаналы кичә узды. Камал театры артистлары башкаруында журнал тарихына багышланган театраль тамашадан соң, кичәнең рәсми өлешен «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин ачып җибәрде. Аннан соң редакция коллективын ТР Премьер-министры урынбасары З. Вәлиева, мәдәният министры И. Тарханов, БТК рәисе И. Таһиров, Казан шәһәре администрациясе башлыгы урынбасары Ф. Әхмәдиев, Азнакай районы хакимияте башлыгы, шагыйрь Ә. Исхаков, «Идел-пресс» полиграфия комбинатының генераль директоры Ислам Әхмәтҗанов, Камал театры директоры Ш. Закиров һ. б. котлады. Кичәнең әдәби-музыкаль өлеше дә югары профессиональ дәрәҗәдә узды. Күренекле сәнгаткярләребез—И. Шакиров, Р. Тажетдинов, Г. Ибушев, Ә. Шакиров, Илдус Әхмәтҗанов, Р. Маликовларның кичәдә чыгыш ясаулары тамашачыларда зур тәэсир калдырды. Режиссер А. Хафиз әзерләгән бу кичәне күренекле язучы Р. Батулла алып барды.

### МИНИСТРЛЫКТА ЗУР ҖЫЕЛЫШ

Татарстан элемтәчеләренең 2002 елның беренче яртысындагы эш нәтиҗәләренә багышланган бу җыелышта төп докладны Элемтә министры Ринат Җәләлов ясады.

Министрлыкның бар кереме 2 миллиард 400 миллион сум тәшкил иткән. Дәүләт предприятиеләрендә үсеш 29 процент булса, хосусыйларында ул 80 процентка җитә. Дәүләткә карамаган әлеге оешмаларның кереме 995 миллион сум белән исәпләнсә, шуның 792 миллион сумы кәрәзле телефон элемтәсенеке икәнлеген дә әйтте министр.

Мәгълүм булганча, бернигә ел элек массакүләм мәгълүмат чаралары, нәшриятлар һәм полиграфик комбинатлар Элемтә министрлыгы карамагына күчерелгән иде. Табигый, министр докладында бу тармак эшчәнлеге турында да сүз булды. Бүгенге көндә республика басмалары чыгымнарның 23,9 процентын гына үзләре («Татарстан яшьләре»ннән башка) каплый. Премьер-министр Р. Миннеханов милли басмаларның кыен хәлдә булуын аңлавын һәм Татарстан хөкүмәте үзенең ярдәменнән өзмәячәген белдерде. Бу җыелышта журналистлар исеменнән «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин чыгыш ясады, милли басмаларның тиражларын арттыру мөһимлеген һәм язучылык хезмәтенең матди яктан түбән бәяләнүен ассызыклап әйтеп узды.

### МИНИСТР АҢЛАТМА БИРӘ

«Время MN» газетенең 10 июль санында Россия Федерациясе министры, Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча дәүләт комиссиясе әгъзасы Владимир Зорин белән тиздән үтәчәк халык санын алу турында әңгәмә басылып чыкты. Автор күздә тотканча, халык санын алу—Россия Федерациясенең чын мәгънәсендә этник йөзен ачыклауга ярдәм итәрлек бердәнбер чара.

Бу материалда Россия Дәүләт статистика комитетының «Российский статистический ежегодник» дигән белешмәсеннән мәгълүматлар китерелгән. Халык санын алу мәгълүматларына караганда, Россиядә иң күп санлы халыклар—урыс, татар, украин, чуваш, башкорт, белорус, мордва, чечен, немец, удмуртлар. 1929 елда илдә 3241000, 1979 елда—5006000, 1989 елда 5,5 миллионнан артыграк татар яшәгән.

### МӘДРӘСӘНЕҢ ОЛЫ БӘЙРӘМЕ

Сентябрь аенда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе үзенең 120 еллыгын билгеләп үтте.

Ана 1882 елда атаклы дин белгече Галимҗан хәзрәт Баруди нигез салган. Бәйрәм тантанасы кысаларында мәдрәсә Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты белән берлектә фәнни-гамәли конференция уздырды. Бүгенге көндә «Мөхәммәдия»дә 820 шәкерт белем ала. Шуларның 220 се—көндезге, калганнары кичке бүлектә һәм читтән торып укый. Мәдрәсәне тәмамлаучылар Россиянең төрле төбәкләрендәге мөселман мәхәлләләренә эшкә җибәрелә. «Мөхәммәдия»дә хатын-кызлар өчен махсус факультет та бар. Анда укучылар Татарстан-Америка төбәк институтында да гарәп лингвистикасы буенча белем ала.

### ИЛ ОНЫТМЫЙ БАТЫРЛАРНЫ

Татарстан җәмәгатьчелеге һәр елның 25 нче августында каһарман-шагыйрь Муса

Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен искә алу мәрасимен үткәрә. Быел да Җәлилнең нацистлар Алманиясенең Плетцензее төрмәсендә вәхшиләрчә үтерелүен, милләттәшләребезне хәтергә алу церемониясе булды. Анда күп кенә рәсми кешеләр һәм танылган язучыларыбыз, шул исәптән, Татарстан Президенты администрациясе башлыгы Әгъзам Гобәйдуллин, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миңнуллин, Мәдәният министры Илдус Тарханов, Фоат Галимуллин, Рафаэль Мостафин, Илдар Юзеев, Хатыйп Миңнегулов катнаштылар һәм чыгыш ясадылар. Мәрасимне язучы Шаһинур Мостафин алып барды. Искә алу җыенында, шулай ук, немец антифашисты, бундесверның элекке бригада генералы В. Фогель дә бар иде.

## КИНОЧЫЛАР УҢЫШЫ

Мәскәүдә узган «Москва златоглавая—2002» VI халыкара киновидеофильмнар фестивалендә Татарстан кинематографистларының эшләре югары бәя алды.

Россия, Эстония һәм Украинадан тәкъдим ителгән 80 фильм арасыннан 39 сайлап алынды. Татарстаннан Казан һәм Чаллы кинематографистлары төшергән 4 фильм тәкъдим ителде. Танылган автор һәм режиссер Вадим Дросинның рәссам Альфред Шәймәрданов турындагы «Рәссам портретына эскизлар» документаль фильмы лауреат исеменә лаек булса, Альбина Зиннәтова һәм Полина Владимирова төшергән «Мелодия» фильмы белән шәһәребезнең «Фангорн» гаилә видеостудиясе җитәкчесе Тамара Шалманның музыкаль клибы диплом белән бүләкләнде.

## ТАРИХИ ТАМЫРЛАР

Касыйм шәһәренә нигез салынуга 850 ел тулды. Юбилей тантанасында Татарстаннан зур делегация катнашты. Аның составында мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре, иҗтимагый оешма вәкилләре, язучылар бар иде.

Шәһәргә 1152 елда Ука (Ока) елгасының сул як ярында Юрий Долгорукий тарафыннан нигез салынган һәм ул Городец-Мещерский исемен йөрткән. 1452 елда Василий II аны Касыйм хан карамагына тапшыра. XV гасыр уртасыннан 1681 нче елгача шәһәр Касыйм ханлыгы үзәге була.

## ШАГЫЙРЬ БҮЛӘГЕ

Танылган татар шагыйре, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миңнуллин үзенең йорт китапханәсен Башкортстанның Илеш районы балалар китапханәсенә бүләк итте.

8 мең китап арасында—аларның 600 енә авторлар имза салган—рус, татар һәм башкорт әдәбияты классиклары әсәрләре, фәнни хезмәтләр, күп санда белешмәләр бар.

## БЕЗНЕКЕЛӘР ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

* * *

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының 23 кешелек труппасы Финляндиядә гастрольдә булды. Ул Хельсинки шәһәренең «Арена» театры сәхнәсендә күренекле режиссер Марсель Сәлимҗанов куйган «Идегәй», «Моңлы бер җыр», «Зәңгәр шәл», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Гөргөри кияүләре» спектакльләрен күрсәтте.

Бу сәфәрдә артистлар белән бергә ТР мәдәният министры Илдус Тарханов, театр директоры Шамил Закиров, драматург Туфан Миңнуллин һәм Марсель Сәлимҗановның хатыны Гөлнара ханым да булды.

* * *

Татар дәүләт «Әкият» курчак театры Германиядә 17-22 сентябрьдә Боттроп шәһәрендә узган VII халыкара «Тылсымлы әкият» дигән курчак театры фестивалендә катнашты. Труппа, шулай ук, Германиянең Дюссельдорф, Франкфурт шәһәрләре тамашачылары алдында да чыгышлар ясады.

* * *

Танылган җырчы Идрис Газиев Африка иле Туниста иҗади сәфәрдә булып кайтты. Анда ул ел саен уздырыла торган Әл-Җем халыкара музыка-җыр фестивалендә катнашты. Быел әлеге бәйрәм унҗиденче тапкыр үткәрелгән.

Бу мәртәбәле иҗат сәфәренә Идрис Газиев белән бергә Казанның «Ля Примавера» дәүләт камера оркестры да барды. Рөстәм Абязов җитәкчелегендәге бу оркестр Тунис тамашачылары өчен берничә концерт биргән.

Идрис Газиев Тунистагы концертларда өч телдә—татар, итальян, рус телләрендә җырлаган.

## СӘЙДӘШ АЛАНЫНДА

Өченче ел рәттән август аенда милләттәшләребез Идел буена урнашкан Кызыл Байрак авылына Салих Сәйдәшев истәлегенә багышланган сәнгать бәйрәменә җыела. Бу бәйрәмнең төп оештыручысы Камал театры. Быел да бәйрәмдә катнашучы сәнгать вәкилләренең күбесе Камал театры артистлары иде. Иделнең текә ярындагы сәхнәдән чыгыш ясаучылар—Мәдәният министры И. Тарханов, Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, Г. Камал театры директоры Ш. Закиров, Югары Ослан районы хакимияте вәкилләре... Аларны мәшһүр артистларыбыз А. Арсланов, З. Сәнгатуллина, С. Фәтхетдинов, А. Фәйзрахманов һ. б. алыштырды. Илсөя һәм Рамил Төхфәтуллиннар мәшһүр «Зәңгәр шәл»дәге Мәйсәрә һәм Булат рольләрен башкардылар. Идел буенда көне буе диярлек Сәйдәш моңнары, халык көйләре яңгырап торды.

## КЫРЫМ КАРДӘШЛӘРЕБЕЗ ЯНЫНДА

Күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим Кырымда иҗади сәяхәттә булып кайтты. Ул Кырымтатар халкы тормышында соңгы елларда булган үзгәрешләр, андагы сәяси, икътисади һәм мәдәни вәзгыять белән танышты. Туган ягына кайтып урнашкан татар кардәшләребезнең яна авылларында, бистәләрендә, игенчелек, яшелчә һәм җимешчелек белән шөгыльләнгән хуҗалыкларында булды.

А. Хәлим Исмәгыйль Гаспринский исемендәге Акмәчет (Симферополь) Үзәк кырымтатар китапханәсендә укучылар белән очрашты, күп санлы сорауларга җавап бирде, китапханәгә Идел буе татарлары тарихы, мәдәниятына караган һәм үз китапларыннан торган тупланманы тапшырды.

Айдар Хәлимне Бакчасарай шәһәрендә Кырымтатар Милли Мәҗлесе рәисе, Украина Югары Радасы депутаты Мостафа Җәмилев, Кырым республикасы Югары Советы Рәисе урынбасары Ильми Үмәров кабул итте.

## ОНЫТЫЛМАС ШАГЫЙРЬ

5 сентябрьдә Башкортстанның Дүртөйле районы үзәгендә күренекле шагыйребез Нәҗар Нәҗмигә бюст куелды. Әлеге игелекле гамәл Дүртөйле районы хакимияте башлыгы Равил Дәүләтов инициативасы белән башкарылды.

Бюстны ачу тантанасында Башкортстанның халык шагыйре М. Кәрим, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Р. Бикбаев, язучылар Н. Сафуанов, Н. Әсәнбаев һ. б. килгән иде. Бу церемониядә Татарстаннан вәкил булып галим һәм җәмәгать эшлеклесе Азат Зиатдинов катнашты һәм чыгыш ясады.

## ЦВЕТАЕВА ИСТӘЛЕГЕНӘ

Марина Цветаеваның тууына 110 ел тулу уңаеннан Алабугада шагыйрә истәлегенә багышланган мемориал комплексны ачу тантанасы булды. Бу церемониядә Татарстан Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева, ТР мәдәният министры Илдус Тарханов, Марина Цветаеваның оныгы Ольга Трухачева, тәнкыйтьче һәм язучылар Ирма Кудрова, Лев Мнухин, Лидия Лебединская катнашты. Бирелә, шулай ук, Бөекбритания, Америка, Япония, Италия, Санкт-Петербург, Хабаровск һәм Казан әдәбият белгечләре, Мәскәү рәссамнар берлеге әгъзалары да бар иде.

## ИСКӘ АЛУ

Әгәр исән булса, күренекле галим һәм шагыйрь, Фатих Кәрим исемендәге премия лауреаты Зәет Мәҗитов быел үзенең 75 яшьлек юбилеен билгеләп үтәр иде.

Шагыйрьне искә алу Яңа Бистәдәге Татар зиратында аның кабере янында үткәрелде. Әдипнең туган көненә туры китереп, биредә аның каберенә ак мәрмәрдән эшләнгән истәлек ташын кую-ачу тантанасы булды. Әлеге ташны Актаныш районы хакимияте белән бергә Татарстан Язучылар берлеге эшләткән.

## МӘГЪЛҮМАТКА БАЙ БАСМА

Татарстан китап нәшриятында «Татар мөселман календаре»нең чираттагы 10 нчы басмасы дөнья күрде.

Анда ислам галимнәренең хезмәтләре, Коръән тәфсирләре, «Заман», Чаллыда чыгучы «Ислам нуры» газеталары авторларының, күренекле имамнарыбызның исламча яшәү рәвеше турында гыйбрәтле язмалары белән танышырга мөмкин. Баш мөхтәсиб Җәлил хәзрәт Фазлыевның «Бала тәрбияләүчеләргә бүләк» хезмәтеннән өзекләр дә урын алган. Календарьны журналистлар Шәех Зәбиров һәм Фәния Хуҗиахмәт төзегән.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар әдәбияты өлкәсендәге казанышлары өчен Татарстан Язучылар берлеге әдәби консультанты **Әһлиуллина Фирдәүс Әсәдулла кызына** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

# ТАТАР РЫЦАРЬЛАР ПОЭЗИЯСЕ

Гарәп әдәбиятына фәлсәфә, фарсыныкына гыйшык-мәхәббәт темасы хас, ә төрки әдәбият—яугирләр әдәбияты, дип телгә кергән. Урта гасыр татар шигърияте моның ачык мисалы. XV-XVI гасырларда Казан, Җаек, Идел, Азау тирәләрендә яу чапкан, дошманнары белән юлбарысларча көч алышкан һәм орыш-сугышлар тынган арада төрле уен коралларында уйнап, җор сүз, шигъри өндәмәләр, хәрби җыр белән яудашлары, коралдаш аркадашларының күнелен күтәргән татар импровизаторларының иҗаты әйтеп бетерә алмаслык кыйммәтле мирас. Казакъларның, Кырым һәм Казан татарларының авыз иҗаты теркәлгән мәҗмугаларда безнең көннәргә кадәр килеп җиткән җыр-шигырьләр давыллы "кыр патшалары"ның (соңгы вакытта ачылган чыганаклар буенча «рыцарь» сүзе «кыр-чары» (патшасы) сүзеннән килеп чыккан дигән фаразлар бар) самими образларын, «ирекле рухын», ватанпәрвәрлеген, Идел-йортка сүнмәс мәхәббәтен, үзләре яшәгән чорның афәт-фаҗигаларын күз алдына китереп бастыра. Бер үк вакытта Казан мәмләкәтенең башкаласы Казанда гарәп-фарсы әдәбияты һәм аның шактый каешланган штамплары хөкем сөргән заманда татар җыраучы чичәннәренең саф төрки назымга корылган ирекле вәзеннәрендә дөнья кайный, дала җилләре өрә, җикән-камышлар чайкала, атлар кешни, Атилла, Күлтәгин, Чыңгызхан кебек саргаскәрләрнең хәр авазлары яңгырый:

«Тугай, тугай, тугай су,
Тугай кундым,—үкенмәм.
Тулгамалы ала балта кулга алып,
Туп башладым,—үкенмәм.
Тубырчыгы биек җәй салып
Дошман аттым,—үкенмәм.
Тугынлы сырт нар җигеп,
Күч төзедем,—үкенмәм.
Ту койрыгы бер тотам
Тулпар мендем,—үкенмәм.
Туган айдай нурланып,
Дулга кидем,—үкенмәм.
Зәрле урындык өстендә,
Ал чыбылдык эчендә,
Толымчыгын түгелтеп
Ару сөйдем,—үкенмәм.

*Дусмәмбәт Җырау*

Рун язулы әдәбият тәэсирен саклаган, хәрби гайрәтләнү, алышка чакыру—«оран» салу жанрларыннан үсеп чыккан бу юлларда—гаҗәеп тел чаралары, көчәеп-үсеп барган кабатлау-градацияләр, дулкын-дулкын табигать сурәтләре, дәртләнеп каһарманның йә кылганын, йә ниятләрен санап чыгудан туган тасвир тезмәсе... Болар барысы да яугирнең һәм күчнең йөрү хәрәкәтенә, «ат җурту» тизлегенә, янсә ат өстендә чайкалып барган җайдакның йөреш ритмына нигезләнгән. Шул ягы һәм патриотизмы белән ул Баты җирләрендә, башлыча гүзәл алиһә («прекрасная дамага») мәдхия формасында иҗат ителгән Франция трубадурлары, Германия миннезингерлары, вагант, менестрельләрнең җырау поэзиясеннән аерылып тора:

«Иделдән аккан сызачык,
Без күргәндә тибенгегә җитәр-җитмәс су иде,—

Теләгәйдәй чайкалтып,
Жаркыраган бәренне
Дингез итсә, тәнре итте,
Тибенгенең астыннан
Ала балта суырышып
Типсенешеп килгәндә,
Тиң атаның улы иден,
Дәрәҗәнне артык итсә, тәнре итте...»

*Чалгиз Жырау*

Трубадурлар шигъриятеннән аермалы буларак, монда ясалмалылык, сентиментальлек юк, киресенчә, дөньяны ачык күрү, тирә-як пейзажларын оста сурәтләү, Ватан турында уйлануларның тирәнлеге, лирик хисләр, «җагына җефәк бәйләгән» аруга (гүзәл кызга) тыйнак кына сөю галәмәтен белдерү, Идел-Йортка мәхәббәт сүзләре («Шу иткән минем Иделем, хәйран минем Иделем! Хәерле булсын сезләргә миннән калган Идел Җорт!), күпне күргән дала бөркетенең яраланып ыңгырашуы, хөкемдарларның гамәлләрен өнәп бетермәве («Җара бер катлы, жан татлы, жара аузына кан катты...») ярылып ята.

«Күлдә йөргән кыңгыр каз
Кыр кадерен ни белсен!...
Күчеп-кунып күрмәгән,—
Җир кадерен ни белсен!..
Акылына күнмәгән—
Җорт кадерен ни белсен!»

*Әсән Кайгы*

Нугай диалектында иҗат ителгән бу шигырьләр тынлы һәм бәрмә уен кораллары: думбра, тамбур, дәф, барабан, корнәй-сорнай, кубыз, дум-думбак һәм давылбазлар гөрелдәгәнне хәтерләткәндәй... Киләчәктә «рекрут җырлары», «авыл-урам көйләре» булып, мәйдан йөреп, урам әйләнеп җырланачак халык җырларының елга башы бу. Шул ук вакытты «рыцарьлар поэзиясе»—тарихи чыганак та: монда тарихи шәхесләр, Алтын Урда таркалгач туган мөстәкыйль татар дәүләтләренең башкалалары, елга, тау атамалары, сугыш стратегиясе һәм аның барышына караган терминнар, дәүләтнең икътисади һәм сәяси үсеш дәрәҗәсен күрсәткән корал һәм хәрби кием сәнгатен чагылдыручы лексик байлык... Ләкин, иң мөһиме, алар—киң колачлы «Идегәй», «Ак күбек», «Чура батыр» кебек дастаннарның вәзеннәрен синтезлаштырган эпос кыйпылчыклары... Шунысы кызык, бүгенге көннең кайбер галимнәре (мәсәлән, Кырым татары Мозаффаров) кодрәтле «Идегәй» эпосын нәкъ менә шундый шагыйрьләрнең берсе—Сөембикәнең ятим карендәше—морза улы Чалгиз Җырау иҗат иткән дип фаразлый. Бик мөмкин. Ләкин бу күләмле дастанның кайбер строфалары, алда әйтеп үтелгән чәчән әсәрләреннән бигрәк, XV гасыр шагыйре Казтуган Җырау, XVI йөздә яшәгән Дусмәмбәт Җырау әсәрләрендә тагы да ешрак очрый. Ничек кенә булмасын, аларның авторлары гасырдан-гасырга килгән бөек традицияне дәвам иткән төрки импровизаторлар, татар поэзиясенең иң тирән катламнарыннан килүче элгәрләребез. Фатих Кәрим, Муса Җәлилләрне өермәдәй үз стихиясенә алып кереп киткән бу шигъри шаукым поэзиябезгә бүген дә хас...

Розалина ШАҺИЕВА.


**Тышлыкның беренче битендә:** Урта гасырлардагы татар яугире-рыцареның Милли мәдәният музеенда куелган сыны.

*Фәнни реконструкция авторы:* М. Горелик.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы-публицист Мәхмүт Әхмәтҗан.

# ЯҢА КИТАПЛАР

**Газиз Гобәйдуллин**: Фәнни-биографик җыентык.—Казан: Рухият, 2002.—336 б. Тиражы—2000 данә.




Китап күренекле татар тарихчысы, әдип һәм педагог Газиз Салих улы Гобәйдуллинның тууына 115 ел тулу уңае белән нәшер ителгән. Җыентык-китапны Мәскәү һәм Казан галимнәре (С. Гобәйдуллин, Э. Кульпин, Р. Мәрдәнов, И. Һадиев) бергәләп төзегәннәр. Китапта Газиз Гобәйдуллинның рус һәм татар телләрендәге тарихи, әдәбият тарихына багышланган мәкаләләре һәм хикәяләре урын алган. Аерым бүлекләрдә галимгә багышланган фәнни мәкаләләр, истәлекләр, архив материаллары, хатлар, фоторәсемнәр, библиографик белешмә туплап бирелгән.

Китап тарихыбыз белән кызыксынган киң катлау укучыларга тәкъдим ителә. Басманың фәнни мөхәррире—академик Миркасыйм Госманов.

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. **Шигърият баскычлары**: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре.—Казан: Мәгариф, 2002. —231 б. Тиражы—1000 данә.




Китапта филология фәннәре докторы, профессор, галим һәм язучы Тәлгат Галиуллинның соңгы елларда язылган әдәби тәнкыйть мәкаләләре тупланган. Галим егерменче гасыр татар шигъриятен яңача өйрәнә, аның үзенчәлекләрен хәзерге милли-мәдәни үсеш югарылыгыннан килеп бәяли. Хәзерге поэзия өлкәсендә дә галим үзенең белгеч икәнен раслый; бүгенге күренекле шагыйрьләр иҗатына тирән анализ ясый. Китап ахырында халык язучысы Гариф Ахуновның «Эшләгән эшләре таулар кадәр» дип исемләнгән мәкаләсе бирелгән.

Китап өлкән сыйныф укучыларына, студентларга, укытучыларга, гомумән, әдәбият сөючеләргә атап язылган.

Индекс 73210



Мәхмүт Әхмәтҗан

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)